
# КАЗАН УТЛАРЫ

2
ФЕВРАЛЬ
1980

*МУСА ҖӘЛИЛ*





*«КЫЗЫЛ РОМАШКА».*

**М. РӘХИМОВ** рәсемнәре.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**2**

ФЕВРАЛЬ
1980


## Бу санда


М. ХӘСӘНОВ. Шөгеровлар. Романнан өзек . . 3
И. ЮЗЕЕВ. Мәхәббәт китабы . . . . . . . . . 27
Р. ВӘЛИЕВ. Яшисе килә! Повесть . . . . . . 43
М. ГАЛИЕВ. Төнге кыюлык. Хикәя . . . . . . . 92
Р. КӘРАМИ. Кәккүк тавышы. Хикәя . . . . . 101

ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

М. ӘМИРХАНОВ, Р. КИЛЬМАТОВ. Юл . . . . 108
У. БЕЛЯЛОВ. Ныгу . . . . . . . . . . . . . 116

Солдат көндәлек яза . . . . . . . . . . . 123

«ВАКЫТ ҺӘМ КЕШЕЛӘР» КОНКУРСЫНА

К. КӘРИМОВ. Кайту . . . . . . . . . . . . 130

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Шигъри сүзнең җегәре . . 137

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ш. ХАММАТОВ. Идел бөркете, ил бөркете . . 147
М. МАННУРОВА. Героик симфониягә тиң гомер 156
Ф. СОЛТАНОВ. Хөр фикерләү юлында . . . . 161

СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Ш. САДРЕТДИНОВ. Таң җырчысы . . . . . 164

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

С. МИХАЙЛОВА. Татар халкының мәгърифәтче улы . . . . . . . . . . . . . . . 171

КИТАП КҮЗӘТҮ

Г. БӘШИРОВ. Көлкенең хикмәте бардыр . . . 175
Ф. УРМАНЧЕЕВ. Үлемсезлек юлы . . . . . . 178



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

ХӘСӘН ХӘЙРИГӘ 70 ЯШЬ

**Ф. ӘГЪЗӘМОВ.** Ихлас күңелдән . . . . . . 181

ГАЗИЗ НӘБИУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

**Г. НӘБИУЛЛИН.** Көтәләр кебек. Шигырьләр . . 183

МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

Түребездә — рус мәсәлчеләре . . . . . . . 185

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шамил Бикчурин, Аяз Гыйләҗев, Марсель Зарипов, Зөлфәт, Шәйхи Маннур, Фәрвәз Миңнуллин, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Кояш Тимбикова** (җаваплы секретарь), **Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Т. Шакирҗанова*

Производствога бирелде 25/X-1979 ел. Басарга кул куелды 22/I-1980 ел. ПФ 09002. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 94800 экз. Заказ Ц-420. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1980 ел.

**Мәхмүт Хәсәнов**

# ШӨГЕРОВЛАР

РОМАННАН ӨЗЕКЛӘР



Өй салкын иде. Шулай да өске киемнәрен салып ишек катында чөйгә элеп куюны кирәк таптылар. Түргә уздылар. Бәләкәй генә тәрәзә каршында торган өстәл янына килеп какшап беткән урындыкларга утырыштылар. Өй чиста иде. Идәннәр кырып юылган. Өстәл такталары да гәрәбәдәй.

Ул арада әлеге алтынчәч кече якка керде дә, өйдә күзгә күренерлек бердәнбер җиһаз, самаварны алып, шаулатып су салды. Өлгер-житез икән, минут та үтмәгәндер, бер башы белән учак алдына тыгылган торбадан ялкын катыш төтен ургыла иде инде.

Чәй өлгергәләгәнче бераз гәп сатып алдылар. Йортның төп хуҗасы, сырхау ананың бердәнбер улы, узган сугышта хәбәрсез югалган. Тормышның рәте-чираты беткән. Өйне колхоз бирген саламны ягып җылыталар икән. Авыру бар дип кәненә ике-өч яксалар да җылы тормый — өй иске. Саламнары да алты-җиде бәйләм генә калган...

Ул арада чәй өлгерде. Айсылу иң элек фатирчыларына чәй ясады. Аннары сырхау янына килеп чаршауның алгы өлешен ачып җибәрде. Ятак янына урындык алып куйды. Тастымал җәйде. Чәй ясап китерде. Кайдандыр бер шакмак шикәр, ярты телем икмәк чыгарды. Аларны әнисе алдына куйды.

Боларның берсе дә Корбанның игътибарыннан читтә калмады. Әлеге фәкыйрьлекне күрү аның күңелен меңгә телгәләп үтте. Ул каерып ике-өч телем күмәч кисте, мул итеп салкын ит турады, алар янына биш-алты шакмак шикәр салды. Мастерының нишләргә җыенуын Алексей да абайлап алды. Ул да мул гына итеп колбаса кисте, ике пешкән йомырка алып, әлеге ризыклар янына өстәде. Шуларның барысын да авыру карчык алдындагы урындыкка илтеп куйды Корбан.

— Зинһар, олан, мәшәкатьләнә күрмә...— диде сырхау.— Кирәкмәс. Ашау үтми инде хәзер...

Чәй эчсәләр дә эчкә җылы кермәде. Өй салкын. «Хәзер шулай, ятыр вакыт житкәч нәрсә булыр?» — диде уйлап куйды Корбан. Шунда аңарда, буровойга барып берәр ягарлык утын алып кайтырга кирәк дигән уй туды. Бу турыда ул Алексейга да әйтте. Тегесе дә: «Дөрес пулыр», — дип аяк чолгауларына ябышкан иде инде, әмма Корбан аңа йөрмәскә, ял итә торырга кушты.

[1] Ахыры. Башы беренче санда.

Фатирчыларның сүзен сырхау да ишетеп яткан икән. Әгәр дә рас, Айсылу кызым, бар, син дә әйлән, диде ул. Күндәм бала, әнисенә каршы тел тибрәтеп бер сүз дә катмады, җыена башлады. Җиңнәре, итәкләре кыскарып беткән иске бишмәтен кигәндә генә уңайсызланудан куырылып килгәндәй булды ул.

Урамга чыккач Корбан көннең аязып та, ачылып та киткәнлеген күреп чын-чыннан гаҗәпләнде. Болай буласын белгән булса, эшне дәвам иттерер иде...

Тирә-якта апрель хакимлек итә. Тикмәгә генә апрель һәр көнне җиде төрлегә үзгәрә димәгәннәрдер. Әле бая гына алар эштән кайтканда, яңгыр катыш кар ява, тәннәрне чиркандырып, яман зәһәр җил исә иде. Хәзер, әнә, җил басылган, болытлар таралган.

Апрельны тагын яктылык ае, диләр. Бер карыйсың, кояш көлтәкөлтә нурларын сибә, тирә-якта күз ачкысыз яктылык, гөрләвекләр ага. Шулай табигать уяна, һәр адымда үзгәреш хасыйл булуын сизәсең, тормышның күп төрлелеген тоясың.

Янында күтәрелеп карарга кыймыйча аяк очларына гына карап Айсылу кебек гүзәл дә атласа, анда инде бетте, ел фасылларының теләсә кайсы, табигатьнең сокланып туймаслык бер мизгеленә әверелә дә куя.

Алар шулай янәшә атлап, буровой урнашкан урманга якынлашып киләләр. Зәңгәрләнеп торган урман, язгы кар суларында юынгандай, ничектер сафланып, сыек зәңгәр төскә кереп күренә.

Шул вакыт Корбан, урман буенда сәер бер күренешкә игътибар итте. Урманның буровой вышкасы калкып торган турысында ниндидер, күзгә күренми торган кул кара челтәр яулык болгаган сыман булды. Җентекләбрәк караса, тагын кабатланды. Корбан түзмәде, Айсылуга мөрәҗәгать итеп: «Нәрсә булыр бу?»— дип сорап куйды.

Кызның күзе үткеррәк булып чыкты: «Кошлар ич»,— диде ул бер генә мизгелгә хисләнеп китеп. Шунда ук яңадан баягы хәленә кайтты да төште. Сизелер-сизелмәс кенә, беленер-беленмәс кенә табигый моңсулыкны бу баланың йөзенә язмыш үзе салган күрәмсең.

Айсылу хаклы иде, чыннан да өер-өер, көтү-көтү булып җылы яклардан кошлар кайталар иде. Яз көч җыйган, мең төрле төсләр, хуш исләр мең төрле авазлар белән тулы ул апрель кичен гомердә дә онытасы юк Корбанның. Шунда аңлады ул: кешенең яшьлек дигән могҗизалы чоры тиз уза икән, шул ук вакытта кешенең гомере буена да дәвам итә икән...

Шул беренче мәхәббәте аның күңелен нечкәртеп кенә калмады, йөрәгенә мәңге төзәлмәслек яра салгандай итте. Корбан тирә-юньгә дә бөтенләй башка күз белән карый башлады. Язлар җитсә дә, кышка керсә дә, күз алдына Айсылу килер иде аның. Бигрәк тә шаулы язларны авыр кичерде Корбан. Бер заманны җылы яктан кошлар кайта башлый. Күктән моңнар агыла... Бер карасаң, зәңгәр һавадан торналар уза, икенче карагандa,киек казлар. Ә тавышлары! Хәер, кошлар очып үтүе генә түгел, ак болытларның каядыр йөзеп китүләрен күргәндә дә күңелен сагыш били торган булып калды Корбанның.

Алар, буровой яныннан алган такталарын кием-салымнарын пычратмасын өчен цементтан бушаган чиста кәгазь капчыкларга төреп алдылар да, кайтырга чыктылар. Тәмам боздан арынырга өлгергән елга буена җиткәч хәл алырга туктадылар. Айсылу чәнчеп утырган тезләре өстенә тагын да иелә төшеп, күзләрен бер ноктага төбәгән дә, хәрәкәтсез утыра. Язгы җилләр хакимлек иткән елга өстендә күзләрне камаштырырлык төсләргә кереп шәфәкъ яктысы уйный. Шул нурларга коенып, нәкъ әкияттәге хур кызы кебек Айсылу утыра...

Болай авызына су капкандай утырырга яхшысынмады Корбан. Бик үк килешмәсә дә, бик үк урынлы булмаса да, сүз башларга итте:

— Әниең бик авыр хәлдә икән, Айсылу...
— Әйе шул,— диде кыз. Йөзендә яшерелмәгән авыр хәсрәт галәмәтләре.— Үзе дә быелдан калмам инде ди.
Корбан тагын сорау бирде:
— Ул-бу була-нитә калса, нишләрсең соң?
— Ташкент ягында әнинең бертуган сеңлесе яши. Әни шунда барырсың, ни әйтсәң дә туган кеше, төртеп екмас ди.
Каян килгәндер кыюлык, шунда Корбан әйтә салды:
— Ә син, Айсылу, тот та Ак-Калага кил. Үзем каршы алырмын...
Кыз җәһәт кенә аның ягына борылып ышаныр-ышанмасрак карап куйды. «И-и, хыялый! Син дә бер исәр икәнсең!..» Юк, бу сүзләр әйтелмәде, бары тик Айсылуның борчу тулы күзләрендә генә чагылып үтте. Әмма Корбан барысын да аңлады. Шул әйтелмәгән сүзләрне аңлаганга күрә ул тагын да батырая төште:
— Чын, әгәр. Кил, Айсылу! Үкенмәссең. Дусың да, хезмәттәшең дә, яклаучың да булырмын...
Кыз аның бу кыю-әрсезлегенә үпкә-сапкы белдермәде. Чак кына сыный карап торгандай итте дә:
— И-и, Корбан абый! Кая инде ул безгә андый бәхет,— диде. Шунда ук авыр көрсенеп күзләрен читкә алды.
Кызның шулай йөзенә мөлаемлык, ягымлылык өстәп икеле-микеле җавап кайтаруы да Корбанның күңеленә өмет чаткысы салды, үлгәндә дә тормышка ашмас хыяллар дөньясына алып кереп китте.

Әмма шунда ук күңел түрендә икенче бер яңа гамь уянды, аваз салды: «Тилермә! Кыз бала күңелен юкка алгысытма! Оял!.. Син бит гаилә башлыгы, ике бала атасы», ди иде әлеге көч.

Әйе, Корбанга егет булып йөрүләр тәтемәде, бик яшьли башлыкүзле итте аны Рахман карт. Аның бу мәсьәләгә карата үз уй-фикере, үз фәлсәфәсе бар иде. Ничу эт куып йөрергә диде ул бу турыда бүтән сүз кузгатмаслык итеп. Хәер, мәсьәләне шулай кабыргасы белән куярлыгы да бар иде. Газиз балаларын югалту фаҗигасен күтәрә алмаган ана кеше мантый алмады, чиргә уралып, урын өстенә ятты. Өйдә тормышны алып барырдай кеше калмады. Аш-су хәзерләүче дә юк. Өлкән киленнең дә тәртәгә тибенгәнрәк чагы. Андый вакытта малайны өйләндереп яшь килен төшерүгә ни җитә! Шулай иттеләр дә. Күрше йортта гына торган бораулау мастеры Гыйләҗевның төпчек кызы Мәхүбә белән таныштырдылар да, ду китереп туй ясап кавыштырып та куйдылар...

...Икенче көнне дә Корбан Алексей белән Айсылуларга керде. Әмма буш кул белән кайтмадылар. Скважина өчен трап, «елка»лар алып килгән машинаның йөген бушаткач та, аны кайтарып җибәрергә ашыкмады Корбан. Буровой тирәсендә чуп-чар булып яткан бүрәнә башларын, такталарны тау кадәрле итеп төятте дә, Айсылуларның ишегалдына алып кайтып бушатты.
Кич белән Корбан белән Алексей дәдәйне май кебек җылы өй, ягымлы йөз каршылады. Алай гынамы соң әле, фатирчылар кичке ашка дип өстәл янына утырышулары булды, алларына ыспай гына бер ярты акбаш килеп кунаклады. Әмма Корбан: «Һич кирәкмәс, хәзер үк алып куегыз, бер кирәге чыгар әле»,— дигәч, шунда ук юк булды.
Икенче көнне операторларның эшләре бетте, кайтып китәргә җыена башладылар. Аларны алырга автобус килде. Иптәшләре скважина тирәләрен җыештырган арада Корбан җил кебек очып кына авылга барып килде. Иң элек бик беткән, күзләре эчкә баткан хаста ана белән саубуллашты. Рәхмәтләр әйтте, тизрәк савыгуын теләде. Инде ничегрәк итеп Айсылуны тышка чакырып чыгарырга дип кенә торганда әни кеше: «Бар, кызым, кунакны озатып куй»,— дип үзе әйтә салды.

Баскыч төбендә Корбан Айсылуны кабат Ак-Калага чакырды, нефтьче итеп эшкә урнаштырырга вәгъдәләр бирде. Аннары: «Мин сине кötәрмен!..» диде дә, җәһәт кенә автобусына сикереп менеп утырып, китеп тә барды. Ә йөрәге баскыч урынына куелган дүрт кырлы Чупай ташы өстендә басып торган кыз белән калды.

Шул ук елның көзендә, вахтадан кайтып төшкәч, каршысына килеп баскан Айсылуны күреп, тораташ кебек катып калган иде Корбан. Өенә кайтып өс-башын да алыштырып тормады, шунда ук кызны квартирага урнаштырырга дип алып китте. Озак баш ватмады Корбан. Гастроном каршында гына яшәүче Маша исемле бер таныш хатыны бар иде. Ире атаклы бораулаучы иде аның. Үлде. Бәлки шуңа күрәдер, нефтьчеләр дип җанын фида кылырга да әзер Маша түти Айсылуны да ике куллап күтәреп диярлек каршы алды, теләгән кадәр яшәсен, бүлмәм иркен, дип берсүзсез риза булды.

Ул кичне сөйләшеп сүзләре бетмәде Корбан белән Айсылуның. Сырхау ана моннан ай ярым элек дөнья куйган. Айсылу кырыгын уздырып килгән. Йорт-җир ишелер дәрәҗәгә җиткән. Каршы якта яшәгән Гыймран абзый утынга дип сатып алган үзен. Авыру ана газиз баласының Ак-Калага барырга теләвенә каршы килмәгән. Корбанны да телгә алган. Әнисе: «Бар, бәбкәм, михербанлы балага охшаган иде. Шәт, ярдәменнән калдырмас»,— дип әйтеп әйткән, имеш.

Ике көн үттеме икән, Айсылу өйрәнчек оператор булып эшкә урнашты. Документы-фәләне җитми дип тормадылар. Шөгеровның сүзе һәркайда үтте. Өченче көнне инде алар бергәләп эшкә барырга чыктылар. Вахта автобусында таныш булмаган Айсылуга сәерсенеп тә, менә кайда ул гүзәллек, бәгырь өзгеч матурлык дип, сокланып та, әх-х, чәчбие лә дип, оятсыз рәвештә күзләрен тасрайтып караучылар да бар иде. Корбан: «Сеңлем!»— дип бер селтәнүдә барысының да авызын томаламакчы иде дә, кая ул! Егет-җилкенчәкләргә теш агартырга җитә калды. Шул бер автобуста гына да Шөгеровлар нәселе белән туганлашырга теләүчеләр бер көтү булып чыкты.

Машина урман юлы белән чаба. Грунт юл тап-такыр, оекчан йөрерлек. Көннең матурлыгына сокланып туймаслык. (Бәлки Корбанга гына шулай булып тоелгандыр). Олы аланлыкта эшләп торган сиртмәле насос янында автобус туктады. Ике-өч кешегә ияреп Корбан белән Айсылу да төшеп калдылыр. Автобус юлын дәвам итеп китеп барды.

Аланның тирә-юнендә алтын-сары, кызгылт-сары яфраклары белән купшыланып утыручы агачлар. Утлы күмердәй куе кызыл яфраклары белән масайгандай, яшь усаклар утыра. Аларга җил булды ни дә, булмады ни, барыбер яфракларын лепердәтеп үзара серләшәләр.

Күп тә үтмәде, кар төште. Нефть чыгаручылар чаңгыларга бастылар. Ул вакытта инде Айсылу да мөстәкыйль оператор булып эшли башлаган иде. Корбан сүзендә торды: ул чыннан да Айсылуның иң якын ярдәмчесе, киңәшчесе, шул ук вакытта таләпчән җитәкчесе дә иде.

Корбан өчен дөньялар киңәеп тә, яктырып та киткәндәй булды. Көндәлек тормышның вак-төяк мәшәкатьләре онытылды. Моңарчы үзе өчен билгесез ләззәт, билгесез бер талпыну белән яшәде. Хисләре хәттин ашкан, уйлары якты, тойгылары саф, ниятләре изге иде Корбанның. Мин гашыйк дип, чамадан тыш шашынмады, кирәксә-кирәкмәсә дә күңел кошы янына чапмады, өзелеп сагынганда хисләрен йөгәнләргә, шартларга җитешкән йөрәген учында кысып булса да түзәргә кирәклекне яхшы белә иде ул.

Зирәк Айсылуны күрү, Корбан өчен рухи бер хаҗәткә әверелгән иде инде. Ике йөрәк бер нәрсәне ачык төшенделәр: юк, бу инде күңел

зилзиләсе яки гади бер мавыгу гына түгел. Аларны хәзер олы назлы мәхәббәт һәм рухи бердәмлек бәйли иде.

Хисләр Корбанның бөтен барлыгын яулап алды. Кыз төнге вахталарда торганда аның күзләреннән йокысы, күңеленнән тынычлыгы кача. Басу киңлекләренә чәчелгән скважиналар янында эш белән тоткарланган Айсылу өчен борчылып һәр сәгате, һәр минуты шик шөбһә эчендә, ут эчендә үтә торган иде.

Ахыр чиктә түземлеге шартлый иде Корбанның, нинди машина туры килсә шуңа утырып промыселларга чыгып китә торган иде. Ә анда Корбанны яшьлек садәлеге бөркелеп торган, хисләр тулы зәп-зәңгәр күзләрен зур итеп ачып, кояш кебек балкып Айсылу каршылый. Я-а, ходай, булды микәнни шулай нечкә хисләр ләззәтеннән исереп йөргән чаклар!..

Мәхүбәсе аны-моны әйтми иде. Хәер, нәрсә дисең? Нефтьчеләр хезмәтенең ифрат та авыр, тынгысыз, ике сүз белән әйтсәк, ходай каргаган эш икәнлеген ул белми идемени?

Әле дә булса хәтерендә Корбанның, күз ачкысыз буранлы көн иде. Котырынган һава кичен дә басылмады. Иң элек диспетчерга шалтыратып хәлне белеште. Ничек итсәләр иткәннәр, вахталар алышынган. Бәхетенә каршы, алар участогы ягына бер йөк машинасы бара икән. Корбан да китте. Ике метрдан берни күрерлек түгел. Шунлыктан машина да бик акрын үрмәләде. Төн урталары җиткәндә Корбан үзенә кирәк культбудка турысында төшеп калды. Аңа кадәр кимендә ике километр чамасы бар. Маяклар куелган сукмак буйлап җәяүләп керәсе. Буран котырыпмы котыра. Басу киңлекләренең офыгы-күге бетте. Күз алдын тоташ ак пәрдә томалады. Корбан капшанып диярлек, буран белән көрәшә-көрәшә алга таба китте. Атлаган саен бер ялгызы скважиналар янында калган Айсылуга таба якынайганнан-якыная баруы аңа көч-дәрт өсти иде кебек.

Менә культбудка. Ул буш һәм салкын иде. Бу күренештән аның йөрәге туңып киткәндәй булды. Башында буталчык уйлар, күңелендә шыксыз бушлык хасил булуын тойды. Корбан иң элек тимер мич эченә җайланган газга ут төртте. Аннары җәһәт кенә чаңгыларын алып урамга чыкты. Ишек төбендәге кар салырга өлгермәгән эзләргә карaганда, Айсылу нарат посадкалары артындагы скважиналарны тикшерергә киткән булырга тиеш.

Корбан тиз генә чаңгыларын киеп алды да, посадкага таба юнәлде. Ул арада җил көчәйде. Әмма кар бураны туктады. Бер мәлгә күк йөзе ачылып киткәндәй булды. Йолдызлар күренде. Аның каравы, аяктан егардай җәяүле буран башланды. Ул күбекләнә-күбекләнә ярсып аккан ташкынны хәтерләтеп аякларга сарыла, рәтләп атларга да ирек бирми иде. Бераз тырыша торгач, Корбан агачлар куелыгына килеп керде. Монда ышыграк булса да караңгы, ничектер шомлы, артык күе булып үскән яшь наратлар күңел өшеткеч авазлар чыгарып шаулыйлар. Хәер, бу тирәдә җәй көннәрендә дә шыксыз, дым исе. Хәтта рәтләп үлән дә үсми. Кояш яктысы бик зәгыйфь төшә, үтеп кергән нурлары да ботакларга эленгән куе пәрәвез җепләре сыман гына булып күренәләр.

Корбан, кемнеңдер якынлашып килүен абайлап, операторлар сукмагы уза торган аралыкта туктап калды. Ялгыз чаңгычы гына үтәрлек ул. Чыннан да, каршыдан бәргән җилдән сакланыр өчен сыңар кулы белән йөзен каплаган Айсылу якынлашып килүен күрде Корбан. Кыз арыган, бөтен гәүдәсе белән алга таба иелеп, адымнарын санагандай, әкрен-әкрен генә атлый иде. Ул кулларын җәеп торган Корбанга килеп бәрелгәч кенә, кинәт башын калкытты. «Ой-й! — дип кычкырып җибәрде ул. — Корбан абый!..» Һәм шунда ук бураннан ышыкла-

нырга теләгәндәй, Корбанның таза гәүдәсенә елышты. Шактый вакыт тордылар алар шулай.

— Ничек килеп чыгасы иттең, Корбан абый?..

— Сагындым, җаным!

Менә шунда Корбан беренче тапкыр кызны кочагына алды, беренче тапкыр салкын битләреннән, уттай кайнар иреннәреннән үпте. Каракучкылланып торган агачларның куе ботаклары аша күз кысышкан кебек булып җемелдәгән йолдызлар чыршыларны бизәү өчен эленгән яктырткычларга охшап күренәләр иде.

Культбудкага кайттылар. Анда җәннәт иде. Шунда Корбан йөрәген ачты, Айсылудан башка яши алмаячагын әйтте, кая булса да китик, диде. Әмма үзен яулап алган әлеге ләззәтле хисләрдән, ялкынлы тойгылардан мәхрүм итә алмаячагын, мәхәббәтенең артык зур, артык тирән булуын, аларга каршы торырлык көче дә, тәкате дә калмаганлыгын аңлатты.

— Юк, Корбан...— диде Айсылу.— Ул уйларыңны башыңнан чыгарып ташла. Семьяңны җимермисең, балаларыңны ятим итмисең. Кирәкмәс! Миңа ничек тә ярар. Дөньяда яшәшемдә синең барлыкны белеп, тоеп яшәү миңа бик җиткән... — Шулай диде дә, килеп Корбанның кочагына керде. Үрелеп үпте. Һәм ярым пышылдап ахыр сүзен әйтте: — Телисең икән... мин синеке...

Вакыт үтә торды. Айсылу пропискага кергәннән бирле, Маша түтинең ишеге бары тик Корбанга гына ачыла башлады. Ике гашыйк күпме генә сак булырга тырышмасыннар, барыбер телгә керделәр. Мәхәббәт һәм утны яшереп буламыни соң! Бераздан әлеге сүз отыры зурайды, гайбәткә әверелеп бөтен поселокны аркылыга-буйга иңләп йөри башлады. Эшең алга барганда, күпмедер дәрәҗәдә уңышларың булганда, халык арасында чак кына дәрәҗәң, танылган исемең, шуның өстенә әле Корбанныкы кебек ил өстендә билгеле фамилияң дә булса, бетте, гайбәт котылгысыз. «Төнәтик әле үзен»,— дип эте дә, бете дә ябырылачак сиңа. Иң яманы шунда, гайбәт ише яман чир белән гадәттә үз-үзләрен әллә кемгә куеп йөреп тә, кулларыннан рәтле эш килмәгән, җыен сәләтсез, вак җанлылар шөгыльләнә, үзләренә корал итеп алалар. Шулай итеп зәһәр агулы укларын үзләреннән күп тапкыр намуслырак, акыллырак кешеләргә юнәлтәләр. Корбан итеп сайланган кешенең әллә ни исе китмәвен, вакланмавын күрсәләр дә алар канәгать: төз атып тидергәч авырттырмасаң да ярый, янәсе...

Билгеле инде, әлеге гайбәт Рахман картны да читләтеп узмады. Дөньяда үзенең Мәйсәрәсеннән башка хатын-кыз барлыгын белмәгән кешенең бу мәсьәләгә карата үз карашы бар иде. Шуңа күрә талканы коры булды аның. Корбаң да әтисенең мондый хәлне муафыйк күрмәячәген алдан ук бик сизенде. «Н-дә-ә!.. Чүштеки башсыз иилэзи икәнсең, — диде әти кеше калын кашларын җимереп. — Мин сине мондый ук ахмаксың дип уйламаган идем. Хатын-кыз кавемен беләм мин... Аның кая илткәнен дә чамалыйм. Шуны бел: абруеңны, авторитетыңны бер генә югалт, аннары кайтарып алырмын димә. Бу турыда бүтән ишетмим, штобы», — дип ачуланды ул.

Аның каравы, күп вакытта эндәшми кала белүчән, сабыр, тыйнак, дәгъвасыз Мәхүбә сер бирергә теләмәде. Башка хатын-кызлар кебек бәрелеп-сугылмады, җәвит итәргә барам дип янамады. Үзенең балалар анасы икәнлегенә, хаклык барыбер аның ягында булуына тирәнтен ышанган кешегә генә хас каты сабырлык күрсәтте. Билгеле, күпме генә сиздермәскә теләмәсен, аның да йөзендә рәнҗү, җәберсенү кебек хис-тойгылар чагылып киткәләләр иде.

Көнләшү — коточкыч афәт. Бигрәк тә хатын-кыз көнләшүе... Аңардан ходай берүк үзе сакласын. Гаилә абруен саклауны үзенең төп мак-

саты итеп куйган Мәхүбә сизенмәгәнме, Корбанның дөньялардан ашкандай онытылып китү галәмәтләрен күрмәгән дисеңмени. Бар, яшереп кара бәгырьләреңне меңгә телеп эчеңне өтәләгән хисләрне!

Яңа ел алдыннан Айсылу кыз бала тапты. Больницадан чыгаралар дип кенә торганда мастер Шөгеров бригадасында булган коточкыч фаҗига турындагы хәбәр палаталарга дә бәреп керде. «Ничәмә ничә кеше харап булган!..» Бу яман сүз күпләрне өнсез итте, ә бер атна гына элек баладан котылган Айсылуны хуштан яздырып, аяктан екты. Сәбәбе шул ук көнне билгеле булды: бичара яшь ана Айсылу Җәләева да ирсез калган... Бу хәбәрне балалар табу бүлегенең өлкән медсестрасы алып кайтты. Культура сараеның вестибюленә куелган биш ябык җеназаның берсендә «Солтан Җәләев» дигән сүзләрне үз күзләре белән күргән. Мәетнең аяк очында портреты да тора ди.

Айсылу хушына килеп нәрсәдер аңлар хәлгә кергәндә, мәетләр күмелгән, Культура сараендагы Яңа ел чыршысы янына балаларны янадан кертә башлаганнар иде инде. Нәкъ шул көннәрдә яшь ана ике кешенең исән калуы, аларның берсе — Корбан булуы турында ишетте. Әмма теге «Солтан Җәләев»кә бәйле булган аңлашылмаучылыкны инкарь итеп тормады.

Һәр шатлыкның кайгы, рәхәтнең михнәт, авырлыкның җиңеллек, кавышуның аерылышу сагышы белән чиратлашып килүе кеше тормышы өчен табигый нәрсәдер, күрәмсең. Корбан да күңелләргә моң тутырып, сагыш өстәп, тузгый-тузгый саргайган яфраклар коелган чорны авыр кичерә торган булып калды. Нәкъ менә шул «Алтын көз» дип атала торган бер вакытта алар Айсылу белән гомергә аерылыштылар. Яшь ана, Корбанга авырлык китермим дип, Алсу исемле нәни кызын күтәрде дә, Урта Азиягә, әнисенең туганнан туган сеңлесе янына китеп тә барды.

Я-а, авыр кичерде лә соң Корбан бу аерылышуны! Акылына зәгыйфьлек килә дип уйлады. Бу аерылышуның чынлыгына күп еллар буе ышанмыйча яшәде. Назлы сагыш аһәңе аның мәңгелек юлдашына әверелде. Корбан һәркөнне диярлек үз-үзенә ник китте ул дигән сорау бирә торган иде. Шундый чакта Айсылуның җыен тузга язмаган, ямьсез төскә кертеп күпертелгән гайбәт сүзләрен ишетеп кайткандагы кыяфәте хәтергә төшеп, күз алдына килеп йөдәтә иде. Бәхет кошының агарынган йөзен, качкан чырайларын, яшьле күзләрен күрү үлем белән бер иде.

Гаҗәп хәл! Корбан, барыбер кайчан да булса бер очрашырбыз, күрешербез, дигән уй-максат белән яшәде. Кешене өмет яшәтә дигән сүз хактыр шул. Чыннан да, кеше үз тормышында гомере буе нәрсәдер көтә, өмет итә. Гүя ниндидер бер ак пароход килеп чыгар да, кеше шуңа утырып бик күп еллар буе хыялланып, зарыгып көткән максатына юл алыр сыман тоела. Әмма еллар үтә торалар... Баксаң, менә була,' менә күптәнге хыял-максатларым тормышка аша дип өметләнеп, зар-интизар булып ашкынып ак пароход көтеп уздырган яшьлек елларың гомереңнең иң бәхетле чоры булган икән ләбаса! Корбанга да яшьрәк чагында бәхет илаһи зур, кочакларга сыймаслык булып тоела иде. Әмма гомер үткән саен хыял чикләре күзгә күренеп кимиләр икән. Бер үк вакытта нәрсәбезне дә булса югалтабыз, тик моңа игътибар итеп кенә бетермибез икән. Шул ачы хакыйкатьне күңелебезнең кайсыдыр почмагы белән тоя башладык исә сизенмәгәнгә салынабыз.

Өмете алдамаган икән Корбанны, очрашты ул... Тик Айсылу белән түгел, ә кызы Алсу белән. Төп-төгәл моннан бер ел элек булды ул хәл. Фәлән-фәлән сәгатькә телефоннан сөйләшергә чакырыласыз дигән кәгазь алды Корбан. Сугылган штемпеленә караса — Ташкент өлкәсе. Эчендә нәрсәнеңдер өзелеп төшүен сизгәндәй булды ул. Берсеннән-берсе яманрак уйлар миен томаладылар. Ничәмә-ничә еллардан бирле

хәбәр-хәтерсез торганнан соң шундый кәгазь алу яхшы фал түгел. Һәрхәлдә, Корбан шулай дип уйлый иде. (Айсылуның аңар дип Маша апасы исеменә язган хатларын алмаганга да биш былтыр бит инде. Фатир хуҗасы үлгәннән соң ул элемтә дә өзелде.) Берәр бәла-каза булгандыр, бик авыр хәлдәдер, саубуллашырга тели торгандыр дип җыен тузга язмаган нәрсәләр турында уйлап бетерде Корбан. Телефонда Айсылуның көр, ифрат та ягымлы тавышын ишетү янә әллә нишләтеп җибәрде, тел тибрәтеп юньле-саплы сүз дә әйтә алмады. Аның каравы Ташкент ягы абоненты әйтер сүзен әйтеп бетерә алмаудан курыккандай, тезде дә тезде. Алсу кияүгә чыккан. Яңарак кына туйлары булган. Бүген-иртәгә туй сәяхәтенә чыгып китәчәкләр икән. Мәскәүгә үтешли бер генә көнгә Бөгелмәдә төшеп калачаклар. Әтисенең каберенә чәчәк куяр өчен атап кайтачаклар. Язылышырга барганчы ук бу турыда сүз куешкан, адарынган булганнар. Корбан исә аларны каршы алырга һәм Солтан Җәләевнең каберен күрсәтергә тиеш иде.

Пыяла һәм алюминнан гына төзелгән яңа телеграф бинасыннан чыкканда Корбанның таныйрлыгы калмаган иде. Иөрәк төбенә, бәгыренә киселеп кереп утырган яшьлек истәлекләре яңа көч белән калыктылар. Я-а, ходай! Үз балаңа! «Менә, әтиең шушында күмелде...» — дип, җиде ят кеше каберен күрсәт инде.

Корбан күңеленең кайсыдыр өлеше белән Айсылуның бу адымын аңлый да, аклый да иде кебек. Бар, буй җиткереп, акыл керткән газиз балаңа син әтисез тудың дип әйтеп кара әле!

Корбан телеграфтан кайтышлый «Девон» гостиницасына кереп, кызы белән киявенә номер сөйләшеп куйды. Люкс алды. Аннан соң өенә дә кереп тормастан, туп-туры зиратка китте. Туганнар каберлегендә зәңгәргә буялган озынча чардуган. Анда өч кабер. (Ике мәетне туып-үскән туфракларында ятсыннар дип, авылларына алып киткәннәр). Каберләр өстендә нефтьчеләр телендә «фонарь» дип йөртелә торган ярым вышкалар макеты утыртылган. Мәрмәр такталарда исем-фамилияләре, туган еллары. Алары төрле. Әмма дөнья куйган көннәре бер. Уң як кырыйда Солтан Җәләев ята. Аның кабере башкаларныкына караганда ташланганрак хәлдә. Башкортстанның кайсыдыр районыннан килгән егет иде ул. Бригадада «Җәләй» дип кенә йөртәләр иде үзен. Эченә бикләнебрәк яши торган кеше иде, мәрхүм. Хәтта, бригадир Корбан да аның нинди уй, нинди максат белән яшәвен белә алмады. Фаҗигале хәлдән соң Солтанның туган ягына телеграмма да биреп караганнар, ләкин күмешергә килүче булмаган.

Корбан зират капкасы төбендәге будка янына килде. Ялган йозак кына эленгән ишекне ачты. Көрәк алды. Аннары зиратның су буе өлешенә, үзәнлеккә төшеп, беркадәр кәс хәзерләде. Шуларны ташып Солтан каберен рәткә китерә башлады. «Их-х,— дип көрсенде ул эченнән генә,— сәбәп чыкмаса, хезмәттәшләребезнең каберенә килергә дә вакыт таба алмыйбыз. Безнең дә тигез җирне түмгәк итәселәребез бар бит әле...»

Корбан иң элек кабернең як-ягын көрәк белән кырып, чүп үләннәреннән арындырды. Туфрагын җыеп өйде. Тирә-ягын шакмаклап кискән кәс белән уратып чыкты. Кабер матураеп китте. Түрдәрәк торган иске каберлекләр яныннан бер бәйләм сирень чәчәкләре алып килеп кабер өстенә салды. Менә хәзер теләсә кемгә күрсәтерлек булды дип, Корбан башкарган эше өчен эченнән генә куанып куйды.

Корбан вәгъдәсендә торды, барысы да Айсылу дигәнчә булды. Алсуны Бөгелмәдә каршылады, урнаштырды. Аннары Рахман карт бакчасыннан иң яхшы чәчәкләрне җыеп зиратка менделәр. Яшерен-батырын түгел, үнсигез яшьлек Алсуны күргәч Корбан тетрәнүдән телсез калды, үзенең Айсылуын күргәндәй булды. Төс-бит чалымнары гы-

на түгел, буй-сыннарына хәтле әнисенеке иде. Аерма тик шунда, Алсу бик тә инде бай, хәтта кирәгеннән артык купшы киенгән иде. Бәлки Корбанга гына шулай булып тоелгандыр.

Зираттан кайтышлый Алсу белән кияве (үзбәк егете) Ачилны чәйгә алды Корбан. Шул ук көнне кичен, кунаклар, сәяхәтләрен дәвам итеп, китеп тә бардылар.

Кызы белән очрашу Корбанны бер яктан сөендерсә, икенче яктан көендерде дә. Сагыш аһәңе яңадан бөтен барлыгын яулап алды. Күңеленең бер почмагы белән кабердә яткан «Җәләй»гә кызыгып та куйды. Тагын бер яман ачыш ясагандай, ачы хакыйкатькә төшенгәндәй булды Корбан: гомер дигән нәрсә ифрат та кыска, нәкъ искән җил кебек тиз узучан икән. Гүзәл Айсылуын күрү белән гашыйк булган көннәре әле кичә генә кебек. Онытылу түгел, сүрелергә дә өлгермәгән бит әле ул мәхәббәт. Карасаң, ул инде илле яшьне күптән узган, элеккеге ташып торган көч-дәртен югалта башлаган бабай...

...Шундый уйларга бирелеп, йокысыз төн уздырган Корбан июнь ае таңының кызарып атуын сизми дә калган. Шулай итеп меӊ төрле мәшәкате, ыгы-зыгысы, шау-шуы белән, тагын бер яңа эш көне туып килә иде.

## 10

Безнең һәркайсыбыз үз-үзенең адвокаты: нинди генә адым ясаганда да, хәтта гафу ителмәслек хата эшләгәндә дә акланырга ашкынып торабыз.

Ногман да үзен начар җитәкчегә санамый. Башкалар да аны каты куллы, алда торган хыял-максатларны тайпылышсыз үтәүчән, инициативалы, катлаулы ситуацияләр чыкканда да үзлегеннән хәл итәрлек, дөрес карар кабул итәргә сәләтле кешегә саныйлар. Шулар өстенә әле тагын, профессиональ эрудиция дә җитәрлек диләр үзендә. Бер нәрсәгә ачык төшенде Ногман: хәзер яхшы җитәкче булу, ай-һай, авыр. Юк түгел андыйлар, бар. Андый чын җитәкченең репутациясе, нәкъ сыйфат билгесе кебек, үзеннән алда йөри.

Соңгы елларда «производство климаты», «Психологик аспект», «Производство педагогикасы» кебек төшенчәләр турында аеруча күп сөйлиләр, күп язалар. Әлеге телгә алынган һәр төшенчәнең асылы бер нәрсәгә: кешеләр белән эшли белүгә кайтып кала. Ә бу турыда мәкаләләр укып кына өйрәнеп булмый. Хәтта җан дустыңның, якын коллегаңның бай тәҗрибәсе дә файдасыз. Бер урында яраган ысул икенче җирлектә капма-каршы нәтиҗәләр бирүе мөмкин.

Менә Ногман, минутны бишкә бүләрдәй булып, иртәгә магистраль линиядәге задвижканы алыштыру графигы төзеп утыра. Артур Павлович хаклы: бүген йокы тәтемәячәк аңа.

Графиктан тыш кирәк булачак техника, җиһаз һәм приборларның исемлеген төзеп, кичтән үк заявка биреп куясы бар. Сораласы нәрсәләрнең исәбе-хисабы юк. Күп алар. Сварка агрегаты гына да кимендә өчдүрт данә кирәк булачак...

Үзе эшли, әмма күңеле тыныч түгел Ногманның. Соңгы көннәрдә Галимов белән конфликтка керүе дә җанын бик нык борчый. Бу турыда уйлаганда гына да аның күңеле катып киткәндәй, күкрәгендә нидер актарылуын тойгандай була. Бу низаг тора торгач ямьсез төс алды, көрәшызгыш кискенләште. Их-х, башта ук ризалык бирмәгән булса, ак сакаллы карт буласы икән!

Иң яманы шунда: барысы да Галимовны яклыйлар кебек. Яңалык, янәсе. Әтисе булып әтисе Ногманга каршы чыккач, бүтәнгә ни сан!

Ниһаять, хаклык җиңде, бар да ул дигәнчә булды. Һәрхәлдә, Ногман үзен хаклы дип саный иде. Гаҗәп тә түгел, ул бит производство, дәүләт

планнары дип яши торган кеше. Галимов исә дөреслек аның ягында дип уйлый.

Ногманның җан тынычлыгын алганы, эчен пошырганы һәм ниндидер бер киеренке халәттә тотканы өчен Галимов, әллә нинди эш кыргандай, диссертант булып, борын чөереп йөри иде. Бер уйлаганда, ачуың да килмәслек түгел бит. Син монда, берьюлы берничәшәр камыт киеп производствоны тарт, шул ук вакытта, ниндидер җилкуарлар җайлы гына барган эшнең көен җибәрсеннәр, ди. Оппонентларын гына күр әле син аның, кайлардан гына килеп җитмәгәннәр! Бар да бериш. Ногманның иң ачуын кабартканы, канына тоз салганы, тегеләрнең үз эшләренең фанатиклары булып кылanулары иде. Чынлыкта исә теләсә кемнең кулыннан килерлек эш белән шөгыльләнәләр. Андый диссертацияне Ногман Шөгеров яклый алмас идемени?! Әлбәттә, алыр иде. Әмма ул болар кебек диссертация яклауның җиңел юлын, уңай методикасын эзләмәс иде...

Шундый уйлар Ногманның фикер эзлеклелеген чуалта, төп мәсьәләдән читләштерә, эшләргә комачаулый.

Үзенең дә фәрештә түгеллеген Ногман әллә белмиме? Белә, әлбәттә. Зур хорда үз тавышын таба алмаган җырчы сыман хис иткән чаклары да булгалады аның. Район инженерлык-технология службасы начальнигы булып эшли башлагач та корырак, дуамалрак, усал-кырысрак, хәтта чак кына үзсүзлерәк булырга тырышып карады. Һәркемнең үз характеры, холкы-фигыле булырга тиеш бит. Әмма алай итүнең кире яклары үзен бик тиз сиздерде: бу хәл Ногманны тиз арада ялгызлыкка китерде. Дошман дип санаган кешеләре генә түгел, якын итеп йөргән кешеләре дә аңардан читләшәләр. Дөя атны үркәче булмаганы өчен күрәлмый дигәндәй, бер мәлгә Ногман үзенең дуссыз да, киңәшчесез дә, сердәшсез дә калганына төшенде.

Соңрак бөтенләй икенче чиккә ташланды Ногман. Егетнең дә егете, бөтенләй ыштансыз, егылып үз кеше булып кыланды. Бу юлы да күңелсезлекләр озак көттермәделәр. Бабасының читәнне тәбәнәк урында атлап чыгалар... соңрак сукмак салалар, дигән сүзләренең төп мәгънәсен шунда төшенгәндәй булды. Йомшак агачны корт баса дигәндәй, бөтенләй «үз итеп» ташладылар, тирә-юнен: «Мал-лай, җаным!..» дип аның өчен җаннарын фида кылырга әзер торучы Әптрүш Ялагай кебек соры кортлар басып алды. Соңыннан инде, субординация сакларга тырышып караса да, байтак вакыт эшен җайга сала алмыйча интекте. Шулай итеп ул үзен, еш кына очракларда, давылда очкан кош сыман хис итте. Бары тик соңрак кына бер хакыйкатькә төшенде: башта ук үз-үзеңне куя бел икән.

Ногман үзендә тагын бер җитди генә кимчелек барлыгын тоя. Бу турыда аңа студент вакытта ук дус дип йөргән бер курсташы әйткән иде. «Синдә, Ногман туган, романтика дип атала торган изге очкын җитенкерәми: романтикасыз кеше исә — нәкъ чи утын кебек, ялкынланып янмый, пыскып, төтенләп, тирә-юнендәге кешеләрнең күзләрен кисеп яши». Гаҗәп хәл, нәкъ шуңа охшашлы сүзләрне аңа ничәмә-ничә еллар үткәннән соң хатыны Гөлгөл әйтте...

Секретаренең динамик аша искәрмәстән генә мөрәҗәгать итүеннән Ногман чәчрәп китте.

— Ногман Корбанович, гафу итегез!.. «Маяк» колхозы председателе килгән. Бик мөһим йомышым бар ди. Бер генә минутка кабул итүегезне сорый.

— Керсен,— диде РИТС начальнигы.

Җәүһәрә Сабировна керә-керешли үк сайрый да башлады.

— Зинһар, дип сорыйм, Ногман апаем, эшеңне бүлдергән өчен кичерә күр. Йомышым зур иде, шуңа бәреп керүем...

Гадәттә, әйдәгез, әйдә, Җәүһәрә Сабировна! Рәхим итегез, менә мондарак, түргәрәк үтегез, дип бөтерелеп торган Ногманның танырлыгы юк. Сөмсере коелган, алай гына да түгел, йөзендә җитди усаллык сыман нәрсә ярылып ята. Бәлки шуңадыр, председатель йомышын ике авыз сүз белән әйтте дә бирде.

— Ногман апаем! — диде ул, теләсә кемнең башын түшәмгә тидерерлек хәбәр салуына бик нык ышанган кыяфәт белән.— Тәки ачыкланды бит теге нәмәстәкәй...

— Нәрсә ул?

— Соң, теге, авариянең сәбәбе инде. Тәки очына чыктык...

— Ничек?

— Бәй, ничек дип, әлеге дә баягы, безнең егетләребез «шаярган» булганнар. Барыбер эшләми, тик тора дип, тотканнар да скважинаның задвижкасын, заглушкаларын, башка шурум-бурумнарын сүткәннәр дә алганнар. Алганнар да, сугару системасына файдаланганнар. Гаепсез кешеләр гаепләнәләр дигәч әйттеләр тагын үзләре...

Бу хәбәрне ишеткәч Ногманның кашлары өскә сикереп куйды. Әмма йөзендәге җитдилек кала бирде.

— Аңа карап кына хәлләр әллә ни үзгәрмәячәк, Җәүһәрә Сабировна. Хәзер соң инде. Ул мәсьәлә рәсмиләштерелгән, дело «Татнефть» берләшмәсенә барып җиткән...

Юньле, итагатьле сөйләшү булмаячагын кабинетка керү белән сизенгән иде председатель. Шулай да ул үз фикерен әйтеп бетерүне кирәксенде.

— Бәй, менә тиле! Кешене юкка гаепләнүдән йолып калу һичкайчан да соң түгел ул, кем, Ногман апаем. Безнең әчелешле булмыйча, үзара тату яшәүгә ни җитә? Корбан абый кебек олы җанлы, киң холыклы, кешелекле кешегә бигрәк тә инде тел-теш тидерәсем килми. Аңардан күргән яхшылыклар өчен... бу ашка каршы таш белән ату булыр иде. Кодрәтемнән килсә, бабаең бюсты янына, аңа да һәйкәл куйдырыр идем.

Ногман, тирән уйлардан арынгандай, маңгаен сыпырып алды.

— Их-х, Җәүһәрә Сабировна! Бар нәрсә дә сез дигәнчә генә булса...

— Бәй, шулай димиенчә! Баш ярылып күз чыкмаган әле... Аннары кайсыбыз гына сөткә коенган да, судан пакъ соң безнең? Эшләгәндә алай гына булыр инде. Әнә, анда хәзер нефтьнең табы түгел, исе дә калмады. Хәзер кара туфрак ташый калдылар...

Председательне озаткач та тыныч кына эшли алмады Ногман. Көтмәгәндә, искәрмәгәндә кабинетка өермә кебек булып Рәхим Галимов атылып керде. Кашлары җимерелгән, кояшта янудан каракучкыллашкан йөзендәге чем-кара мыеклары зәһәр селкенәләр.

— Мөмкинме?.. — диде ул, күзләрен иләс-миләсләндереп.

— Секретарь мине занят димәдемени? — Ногманның бу сүзләре, мыскыл булып яңгырады.

— Әйтте... — дип җавап кайтарды Галимов.

— Соң? — Ногман ясалма тынычлык белән башын да күтәрмичә эшләвен дәвам итте. Рөхсәтсез-нисез бәреп кергән химикка үзенең мөнәсәбәтен белдерергә теләгәндәй, урын да тәкъдим итмәде. Галимов беравык сүз таба алмыйчарак торды шикелле. Аннары, ярым җикеренеп, әйтә салды:

— Морадыңа, максатыңа ирештең алайса? Шулаймы?!.

Ногман күтәрелеп карамыйча гына:

— Сүз нәрсә турында? — дип сорап куйган булды.

— Кыланып маташма! Сүзнең нәрсә турында икәнлеген бик яхшы беләсең. Агрегатларны туктаттым дисең инде алайса?..

— Торып тор, хәзер отчет-хисап бирермен, — диде Ногман, һаман да әле тынычлыгын саклап. — Син уйлаган морадым да, максатым да бер минем: нефть чыгару графигын өзмәү.

— Шулайдыр шул!..

— Әй-йе, шулай. Тик менә синең кебек үз мәнфәгате артыннан куучылар гына атлаган саен комачаулыйлар, производствога аяк чалалар. Куст-насос станциясен туктату бер хәл. Синең аркада, әнә, баш инженер Власенко гөрләп нефть биреп торган егерме ике скважинаны яптырды. Иртәгә таң белән яңадан илледән артыгы туктатылачак. Так что, синең гыйльми дәрәҗә артыннан кууларың, безнең менә монда, муен тамырына менеп атланалар...

— Шулай итеп, нишләсәм дә эшләдем, әмма сынауларны азагынача үткәртмим дисең инде алайса?.. — Галимов бу сүзләрен мәкерле елмаю белән әйтте.

— Бу мәсьәләдә юлдаш була алмавымны алдан ук кисәттем.

— Ләкин ул сезнең шәхси фикерегез генә иде. Мине коллектив яклады...

— Коллектив исеменнән сөйләргә сине хәзергә беркем дә вәкил итмәде. Мастер яклаган икән, әнә, үз хатасын вакытында аңлады... Агрегатларны туктатты.

Куст-насос станциясен Корбан ага туктатуы турында Галимов үзе дә ишеткән иде инде. Яшерен-батырын түгел, ул хәбәр аның тез астына шактый сиздерерлек итеп типте.

Ул арада РИТС начальнигы дәвам итте:

— Хәзерге вакытта әлеге коллектив синең аркада килеп чыккан бәладән котылу эше белән мәшгуль...

Котылу өчен җинаять эшләп тотылу кирәк.

— Җинаятьне кем ничек аңлый бит. Безнең өчен, мәсәлән, авария һәр вакыт ЧП. Ә инде тотылу ягына килсәк, син хаклы. Һәрхәлдә син тотылмаячаксың... Шомарган син! — Ногман сабыррак булырга кирәклекне дә яхшы белә иде. Ул хәтта соңгы сүзе өчен үкенеп, үз-үзен битәрләп тә куйды. Әмма соң иде инде.

Аның бит тегесе дә җайлы-җайсыз әйтүе белән исәпләшеп тормый. Кирәкмәгән ачы телле, төртмә сүзләре үзәкләреңә барып тияр. Әнә, нәрсә ди бит.

— Ха-а!.. Минем диссертация бугазыңа аркылы килдемени?!! Син дә якла... — дигән булды Галимов мыскыллы елмаеп. — Кемдер теләсә кем академик була ала дигән иң. Тик шунда ук, берәүләргә моның өчен егерме ел, икенчеләренә... ике йөз ел кирәк дип, искәрмә ясаган ди.

Вөҗданы үртәлгән Ногман, йөзеннән кан качып, агарынуын сизде.

— Беләбез!.. Барысын да беләбез. Юкка, күз буяп йөргән буласыз шунда. Диссертацияң күптән инде Мәскәүдә расланып ук ята торгандыр...

— Сез гадәттәгечә хаклы, иптәш начальник! — Галимов тәмам өметен өзгән кеше сыман кул селтәде. Аннары бөтенләй башка тавыш белән өстәп куйды: — Булмый икән... Сезнең белән эшләүнең кызыгы бетә башлады.

— Сизелеп тора, — диде Ногман. — Сезгә, чыннан да, ул тәҗрибәләрегезне башка урында сынап карарга кирәк булгандыр?..

Галимов иреннәрен кыйшайтып кына елмайды.

— Ю-юк!.. Бик җиңел генә котылырга телисез икән. Шалишь, брат! Көрәшәбез әле...

Ногман җаны ташыса да сер бирмәскә тырышты. — Ну-ну, көрәшеп кара алайса! — диде ул күзләрен хәтәр уйнатып. — Минем бабаемның бабасы, көчле белән көрәшмә, телчән белән сүзләшмә, дияргә ярата торган булган.

— Акыллы карт булган икән; урыны оҗмахта булгыры! Ләкин ул акыллы сүзләрнең сезгә бернинди дә катнашы юк. Үзегезне көчле дип хаталана күрмәгез. Ә менә тел дигәндә... Да-а! Анда сезнең белән тиңләшүе, әлбәттә, кыен.

Бу хурлау сүзләреннән соң шартлау дәрәҗәсенә җитеп гарьләнде Ногман, ачудан буыла башлаганын сизде.

— Конкретрак мөмкин булмасмы икән?.. — диде ул җан ачуын тыярга тырышып.

Тегесе күзен дә йоммады.

— Теләсәгез, конкретрак та мөмкин. Моннан өч-дүрт кенә көн элек сез, нәкъ менә шушы кабинетта, яңа техника, фәнни казанышлар, прогресс дип, инженер-техник работниклар алдында чыгыш ясадыгыз...

— Соң? Бәлки миңа аларның һәркайсын аерым-аерым чакыртып алып яки яннарына барып, гафу итегез, иптәшләр, мин хаксыз, ялгыш сөйләгәнмен, дип әйтеп чыгаргадыр? Ә?..

— Ю-юк!. Мәшәкатьләнмәгез. Принциплар турында шәрран ярырга гына җиңел. Ә менә аларны тормышка ашыру, ай-һай авыр ла! Аның өчен беренче чиратта кеше булырга кирәк...

Шундый сүзләрдән соң да үртәлмичә, гарьләнмичә чыдап кара, бар! Шул чак Ногман, урынсыз гаепләнүгә тарыган кеше сыман итенде, җене чыкты, түземлеге-сабырлыгы чәлпәрәмә килде.

— Во-о-он!.. Эзеңне се-бер-р!.. — дип ишеккә күрсәтеп җикеренде, беравык сүзләренә тыгылып, иркенләп сулыш ала алмыйча торды.

Нәкъ шул вакытта кабинет ишеге ачылып китте, аннан кереп килүче Рахман карт, мистер Шандор һәм сылу Җәмилә күренде. Ул арада Галимов керүчеләр белән исәнләшкәндәй итте дә, ялт кына чыгып та шылды.

Ш а н д о р. Һелоу, мистер Шөгеров!..

Н о г м а н (Һаман да әле ярсуын баса алмыйча). О, кей, сэр!..

Р а х м а н. Нәрсә булган әлеге егеткә? Кинәт юк булуын әйтәм...

Н о г м а н. Иөри шунда... Тәкәббер йолкыш! Гарьлегеңнән үләрсең...

Р а х м а н. Ә син кызма... Тынычлан! Кешеләр белән алай тәмсезләнмә... Егетлек түгел ул. Бигрәк тә җитәкче кешегә килешми. (Шандорга). Менә, мистер әфәнде, монысы инде Шөгеровларның дүртенче буыны. Әмма, соңгысы түгел... Алмагачтан — алма, чыршыдан — күркә дигәндәй, күр әле син аның утыруларын. Министрмыни! Чүштеки, маладис безнең нәсел дисәң дә нахак сүз булмас...

Ш а н д о р (Җәмилә тәрҗемәсен тыңлап бетергәннән соң). Хак, хак, мистер Шөгеров!.. Хак!..

Н о г м а н. Әйдәгез, кунаклар, түрдән рәхим итегез! Утырышыгыз. Чәй әзерләтимме?..

Р а х м а н. Юк, юк, олан, борчыла күрмә. Кунакка синең эш урыныңны гына күрсәтеп чыгыйм дидем. Менә, мистер әфәнде, күр!.. Безнең нәселдән урындагы, ягъни, укымышлы нәчәлник кеше чыкты. Шәп бит!

Ш а н д о р. Шәп, шәп, хөрмәтлем! Бик шәп!

Р а х м а н (Кабинетны караштырып). Әт-тә-тә!.. Эшне олыдан куйгансың син, олан! Түрә булдым дисең инде алайса?.. Сам хозяин, сам хужа, дискет. Килештерәсең... Н-дә-ә! Зурдан купкансың. Министр янына да җиңелрәк керә идем мин. Монда, әнә, көнҗәлә башлы секретарең, юлга аркылы төшеп маташа. Начылый кердек...

Н о г м а н. Син, бабай, аны кичерә күр инде. Яңа кеше әле ул, танып бетермәгәндер. Аннары, срочный эшем бар, дип үзем кисәтеп куйган идем...

Р а х м а н. Шулайдыр, шулайдыр... Әллә арт сабагын укытып үземне танытыйммы дигән идем дә, ярар инде...

Ш а н д о р (Сүзгә кушылып). Әй-йе, мистер Шөгеров, эшегез колачлы...

Р а х м а н. Тиледән туры сүз дигәндәй, әйтегезче зинһар, нәрсә диган сүз ул: мистер? Сорыйм дип күпме телем кычытып тора... Җитмәсә тагын ул сүзгә иняләшә дә башладым кебек...

Н о г м а н. И-и, бабай! Бигрәк инде... Үземнән генә сорасаң соң. «Мистер» әфәнде дигән сүз.

Р а х м а н. Тфю-ю!.. Ҡакрас миңа бата торган исем икән. Нәкъ сыерга ияр кидерткән кебек...

(Ишектә Нәҗибә белән Гөлгөл).

Н ә ж и б ә. У-у, монда кунаклар да бар икән!.. Мөмкинме, абый?..

Р а х м а н. Әйдүк, әйдүк, балалар! Ҡерегез, түрдән узыгыз!..

Ш а н д о р. Сәлам, сылуларның сылуларына!.. (Гаҗәпләнүен яшерә алмыйча, хатын-кызларны җентекләп караштыра). О-о, сылу мисс Нәҗибә! Сезме бу?..

Н ә ж и б ә. Мин бу, мистер миллионер!..

Ш а н д о р. Нинди маскарад бу?..

Н ә ж и б ә. Әллә ошамыйммы?

Ш а н д о р. Алай дип әйтүем түгел...

Н ә ж и б ә. О-о, мистер Шандор! Сезнең монда икәнлекне белмәдем шул. Эш киемнәремне салып кергән булыр идем.

Ш а н д о р. Зарар юк, мисс Нәҗибә. Болай да, сез килеп кергәч, бөтен кабинет яктырып киткәндәй булды...

Н о г м а н (Нәҗибә белән Гөлгөлгә). Сезгә нәрсә? Нишләп йөрисез әле монда?

Н ә ж и б ә. Менә абый... Гөлгөлне эшкә алып китеп барышым. Үзебезнең участокка. Башта өйрәнчек булып эшләр. Соңрак инде, оператор...

Н о г м а н. Юк белән башны катырып йөрмәгез әле. Тапканнар шаярыр вакыт.

Г ө л г ө л. Шаяру түгел, Ногман. Чыны шул. Эшкә китеп барышым...

Н о г м а н (Аны бүлеп). Юкны сөйләмә! Бар, өйгә кайт. Бүтән эч пошырып йөрмә монда. Ул да нефтьче, имеш!..

Ш а н д о р. Чыннан да, нефтькә буялып йөрү хатын-кыз эше түгел. Шундый сылу хатын-кызларыбызның иркәләп сыйпар өчен, сокланып үбәр өчен яратылган нәфис кулларын нефтькә буярга ярамый..

Н ә ж и б ә. Кулдагы нефтьне юып була аны, мистер Шандор. Йөрәкнең пакъ булуы кирәк.

Р а х м а н. Хак әйттең, кызым!

Н о г м а н. Ишетергә дә теләмим. Бар, Гөлгөл, хәзер үк өйгә кайт...

Г ө л г ө л. Юк, Ногман, мин эшкә барам. Бу мәсьәләне хәл ителгән дип сана.

Н о г м а н. Кем тарафыннан? Кем хәл иткән? Хәл итәрмен мин... Бар, хәзер үк өйгә кайт.

Г ө л г ө л. Юк! Эшкә барам...

Н ә ж и б ә. Эшкә урнашты инде ул.

Н о г м а н (Нәҗибәне бүлеп.) Кая?..

Н ә ж и б ә. Эти участогына.

Н о г м а н (Нәҗибәгә җикеренеп). Әй, син!.. Хәзер инде безнең семьяны җимерергә керештеңме? Шөгеровлар нәселенә тап төшерүең генә җитмәгән...

Г ө л г ө л. Ногман! Ни сөйлисең син... Оялыр идең бераз!..

Н о г м а н (Җикеренеп). Сиңа да житкәндер, ниһаять! Сүзем сүз, әсине нефтькә якын җибәрмәячәкмен. Әйткән иде диярсең менә...

Г ө л г ө л (Кинәт җитдиләнеп). Ҡабатлатма, Ногман!.. Икесенең берсе... дип сөйләшкән идек бит инде. Я тегеләй, я болай!..

Н о г м а н. Сүзем сүз, әмма сине эшкә алмыйм...

Р а х м а н (Арага кереп). Чү-чү, кем, Ногман олан! Чү!.. Чамаңны югалта башладың түгелме? Ничек инде ул эшкә алмыйсың ди? Алай дип, әнә, мистер Шандор, ягъни капиталист әйтсә әйтә алыр. Әмма син түгел. Ю-юк! Үземә калса мин киленнең бу адымын бик хуплыйм. Мо-

карчы әле нефтьтә эшләп беребезнең дә ким-хур булганы юк иде, моннан соң да, шәт, сынатмабыз. Я, марш! Эшегездә булыгыз!..

Нәҗибә. Киттек, бабай! Очтык!.. (Чыгып йөгерәләр).

Ногман. Бу нишләвең инде, бабай?

Рахман. Мин дә синнән нәкъ шул турыда сорамакчы идем. Карап-карап торам да, тора-торып шак катам! Фарыз-гамәл кылган кебек, тырышып-тырмашып кешеләрнең күңеленә җәрәхәт салып утыруын күр әле син моның.

Ногман. Бабай дим...

Рахман. Дәшмә! Вәт, яхшыдан яман туган нәрсә! Тирә-юнеңә генә күз сал син. Заманалар үзгәрде. Ялган өмет, буш вәгъдәләр белән алдашып, күз буяп яшәүләр бетте хәзер. Шулай ук өстәл төеп, бугаз кирә торган заманнар да артта калды. Кешеләр бүтән хәзер.

Ногман. Бабай дим. Чит кешеләр бар бит...

Рахман. Чит кешеләрмени алар?! Берсе — кунагыбыз, икенчесе — кызыбыз Җәмилә... (Ногман өстенә килеп). Йөрәгеңдә тамчы да шәфкать, изгелек йөртмисең икән, ничу монда утырырга!..

Ногман. Җитте инде, бабай...

Рахман. Молчать! Тәмам алып узынгансың икән. Әйтәм этиең зарланып тора иде... Хак икән!

Ногман. Син нәрсә, бабай, миңа үгет-нәсихәт укырга дип килдеңме әллә?

Рахман. Иманыңны укытырга дип килдем. Әбәзәтелно укытам да!

Ногман. Каршы әйтүем түгел, бабай. Минем тоткан урыным, ягъни хезмәтем, шулай чак кына рәсмилекне таләп итә...

Рахман. Рәсмилек дисеңме? Миңа синең рәсмилегең түгел, ә сүз тыңлавың, сүзгә төшенүең кирәк. Сине кешегә санап, үтенеч-йомыш, гозер-ярдәм өмет итеп керәләр. Ә син нишлисең?.. Җылы сүз әйтәсе, файдалы киңәш бирәсе урында...

Ногман. Бөтен кешегә дә ярап булмый...

Шандор. Бу очракта яшь Шөгеров хаклы. Ул бит шеф... Бөтен кешегә дә ярарга, бөтен кешегә дә ошарга ул бит доллар түгел.

Рахман. Сэр, бездә сез әйткән шефлар да, буйсынганнар да юк. Бары тик үз арабыздан сайлап куелган җитәкчеләр, киңәшчеләр, ярдәмчеләр генә бар... (Ногманга). Болай булгач рәхим-шәфкать көтмә миннән. Нәсел-нәсәптә булмаган нәрсә бит бу! Инде килеп әйтсәм әйтим, һич тә булмаса, башкалардан үрнәк алыр идең. Алга карап үрнәк ал, артка карап гыйбрәт ал ди. Моңа кадәр бу урында кем утырганны белә идеңме син?

Ногман. Белә идем...

Рахман. Әйе! Степан Иванович утыра иде. Үтә дә чыккан акыллы, сирәк очрый торган зирәк кеше иде мәрхүм. Йөрәк авыруы белән китеп барды... Кешеләргә өләшеп бетерде ул йөрәген. Кешеләр күңеленә күпме шифалы нур, якты чаткы салды ул. Ә моның өчен үзеңә ялкын булып янарга кирәк.

## 11

... Юкка гына: «Покы чүлмәкләре» дип көләләр янгын сүндерүчеләрдән. Имештер, эшкә алганда да йоклатып карыйлар, әгәренки тоташтан өч тәүлек буе уянмыйча йоклый аласың икән, рәхим ит, урының янгынчылар командасында! Чынында исә, әнә, иң беренче булып алар килеп җиттеләр.

Комач-кызыл төскә буялган машиналар олы юлдан килеп төштеләр дә, тузан болыты күтәреп дистанцион насос станциясенә якынлаша башладылар. Берничә минут үттеме икән, янгын машиналары капка артындагы агачлар күләгәсенә елышып туктап калдылар.

Машиналардан, солдатлар сыман сикерешеп, хәрби форма кигән янгынчылар төште. Шактый иде алар. Шунда ук ыгы-зыгы башланды. Беренче булып мәйданга бәреп кергәнен таныды Корбан ага — икенче район хәрбиләштерелгән янгын часте начальнигы Заһит Фәтхиев иде бу. Кылган кебек сыек гәүдәле. Үзе иләмсез озын. Бик еш ишетергә туры килгәнгәме, Корбан ага аның яшелле-күкле ачы тавышын өнәп бетерми. Пожар каланчасы кадәрле гәүдәдән шундый чәрелдек-зәгыйфь тавыш чыгуы гаҗәп тоела.

Операторларның канына һәрвакытта да диярлек тоз салып кына торалар алар. Җир астыннан калыккандай әллә каян гына килеп чыгалар да, тотыналар бәйләнергә. Янгын сүндерү инвентаренең буявы ник унган? Ник скважина тирәсен үлән баскан? Ә ник әле лампочка монда элenгән, ни өчен тегендә түгел? Техника куркынычсызлыгы кагыйдәләре буенча, ул скважинадан кимендә фәлән-фәлән метр ераклыкта янарга тиеш. Инде бу юлы бәйләнә алмаслар, дип уйлаган чакларда да, кимендә биш-алты җитешсезлек табып: фәлән-фәлән вакытка эшләнгән булсын дип кисәтү ясап китәләр.

Фәтхиевнең яшелле-күкле тавышы һаваны ярды.

— Хәерле иртә, Корбан ага! Исән-сау гына яшәп ятышмы?

— Хәзергә шөкер әле, Заһит! Бик иртәләгәнсез әле бүген.

— Иртәсе бер хәл иде әле аның, Корбан ага. Төнлә дә тынгылык бирмәделәр бүген.

— Ник алай?

— Гадәттән тыш эш башкарылачак ди бит...

Сизелеп тора, янгын сүндерүчеләрнең үзләренә бүген эпипә көенә биергә туры киләчәк икән.

«ЧП»лы коенын кайдалыгын белештеләр дә, эшкә дә керештеләр. Фәтхиевнең көзге әтәчнекенә охшашлы тавышы әледән-әле яңгырап торды. Иң элек йөгерә-чаба ут сүндергечләрен ташыдылар. Егетләр арасында моңарчы Корбан ага күрмәгәннәре дә бар. Берничә кеше гидрантлардагы су басымын тикшерергә дип йөгерде. Күз ачып йомганчы «җиң» дип атала торган шлангларын да сүтеп аттылар. Ул да булмады, янадан машиналары янына йөгерештеләр. Бу юлы инде алар җилкәләренә салып, бүрәнәләргә охшатып төрелгән соры төстәге калын киезләр ташый башладылар.

Тырыш кырмыскалар кебек мәж килеп йөгереп йөрүче янгынчыларның эшләре, Фәтхиев әйтмешли, чыннан да шактый ук четерекле булып чыкты. Алар, яңарак кына алып килгән киезләрен җәеп, янәшәдәге коеларның авызларын томаладылар. Юк, моның белән генә эш бетмәгән икән әле, әлеге капланган киезләр өстенә унбиш сантиметр чамасы калынлыкта балчык түшәлде. Бары тик шуннан соң гына коеларның авызлары томаланган булып санала икән.

Ул да булмады, унлап кеше яссы йөзле көрәкләр белән коралланып, кое тирәләрендәге үләннәрне кыра башладылар. Аннары ялт итеп, ындыр табагыннан да болайрак итеп себереп куйдылар. Тирә-юньдә чыпчык чукырлык кына да чүп әсәре калырга тиеш түгел, янәсе.

Кояш калыкты. Станция мәйданын тутырып гигант резервуарларның каракучкыл күләгәләре ятты. Нәкъ шул вакытта, тоташ колонна булып, якынлашып килүче куәтле краннар, төрле агрегатлар, автобуслар, күп төрле йөк машиналары күренде.

Корбан ага капкага таба юнәлде. Аны бер нәрсә борчый: вахта членнарын барлап алып килә алсалар гына ярар иде.

Юкка гына борчылган икән мастер. Әнә, аның егетләре өерләре белән шау-гөр килеп автобуслардан коела да башладылар.

— Исәнмесез, Корбан ага!

— Салют мастерга!..

Шау-гөр килеп исәнләшteләр, төртмәле сүзләр әйтеп көлешүләр башланды. Ничек кенә шаярышмасыннар, йөзләрендә киеренкелек. Әйе, аларны бүген чын мәгънәсендә сынау вахтасы көтә иде.

Мастер операторларын барлый. Әнә, юк кына нәрсәдән дә кызык табарга яратучы ачык авыз Саттар Кәрамов. График буенча ял көне туры килүенә карамастан, Геннадий Аракчеев та килгән. Ул да кызыклы кеше. Шаклар катырлык хәтер үзендә. Кирәксә, күзен дә йоммый, тирә-юньдәге йөзләгән скважинаның «биография»сен сөйли дә бирә. Кайчан һәм кем тарафыннан бораулаган? Нинди ремонтлар үткәрелгән? Тәүлегенә күпме «кара алтын» бирә? Чыгарыла торган нефтьнең сулылыгы ничә процентка җиткән?..

Әнә, Фәүзия Мәҗитова белән Нәҗибә дә килә. Нәҗибәнең кулында төенчек, Корбан агага «әбәт» алып килгән булса кирәк.

Хәтта группаның иң өлкән операторы, лаеклы ялга киту өчен документларын барлый башлаган Касыймхан агай Сафиуллин да килеп чыккан. Нефтьче— ветеран. Утыз елдан артык «кара алтын» чыгара. Күз өстендәге каш кебек ул Касыймхан карт, үзенең намуслы фидакарь хезмәте белән зур коллективның тирән ихтирамын яулаган кеше.

Алып батыр кебек салмак кына атлап килүче җан дусты Касыймханны күргәч, Корбан ага ирексездән туктап калды.

Алар кул биреп күрештеләр.

— Ничек килеп чыгасы иттең?

— Шундый-шундый эш көтелә дигәч йөрәк түзмәде...

— Бик яхшы иткәнсең. Бүген монда булачак хәлләр. Борын тартырга да вакыт калмаячак.

Ниһаять РИТС «вездеходы»да күренде. Ул да капка артында туктап калды. Аңардан Ногман, службаның өлкән инженеры Наил Сабиров, партоешма секретаре Иван Говеров һәм Корбан агага таныш булмаган бер ир-ат төште. Алар хикмәтле тамашаның иң мәзәк өлешен күрә алмыйча калудан курыккандай, кызу-кызу атлап станция мәйданына керделәр.

— Хәерле иртә, әти!

— Саумы, Ногман.

— Ул-бу юкмы?

— Хәзергә бар да әйбәт.

Корбан ага улының йөзенә күз салды. Күңеле сызып куйгандай булды. Ногманның йокы әсәре күрмәгәнлеге йөзенә чыккан. Кәяфәте йончыганга, арыганга ошаган, күз төпләренә күмер каралыгы иңгән. Хәтта чак кына ябыгып та киткән сыман.

Улының сүзе бетмәгән булган икән.

— Менә нәрсә, әти, задвижка коесы янында сиңа күз-колак булырга туры килер.

Мастер катгый боерыкка буйсынган кебек җавап кайтарды:

— Ярар. Шулай итәрмен.

Гаҗәп хәл. Әти кеше күңеле түрендә Ногманга карата чак кына соклану сыман нәрсә тууын тойды. Ничек кенә булмасын, дип уйлап куйды Корбан ага, кешегә һәрвакыт ышаныч күзе белән карарга кирәк.

Капка артында яңадан ике җиңел автомашина күренде. Аларның берсеннән «Ак-Каланефть» идарәсенең баш инженеры Артур Павлович Власенко чыкты һәм үзе белән кемнәрнедер ияртеп, станция мәйданына үтте.

Ул арада каяндыр өстәл, берничә урындык чыгардылар. Шунда, капка янындагы калкулыкта ук идарә итү пункты сыман нәрсә әмәлләп куйдылар. Иң элек кыска гына киңәшмә уздырып алдылар. Һәр бригадага, һәр группага конкрет заданиеләр бирелде.

Аннары инде башланды хикмәтләр. Иң элек операторлар, үзләренең ярдәмчеләрен ияртеп, автобусларга утырдылар да, скважиналарны

ябарга китеп бардылар. Скважиналар тукталу белән беренче, икенче һәм өченче группа җыю установкалары да томаланырга тиеш иде. Эш ифрат мәшәкатьле. Монда инде задвижкаларны борып, килә торган нефтьне туктатасы гына түгел. Иң элек зур диаметрлы торбаларның үзара тоташтырылган фланецларын сүтеп, прокладкалар урынына, бармактан калынрак металлдан эшләнгән кунатакта зурлык махсус заглушкалар куелырга тиеш. Бары тик шулай иткәндә генә нефтьнең үзе түгел, газы да чыкмаячак икән.

Станция территориясендә дә эш башланды. Берничә урында агрегатлар эшли. Моторлар гөрелди, ыгы-зыгы, шау-шу. Әнә, тау кадәрле кран үзенең биниһая озын угын күкләргә чөеп, елкылдап торган өр-яңа задвижканы станция мәйданына алып кереп килә. Ул узганда тирә-юнь тетрәп кала. Икенче бер кран, кара мунча зурлыгындагы иске задвижканы күтәреп алу өчен кое янында тора. Ногман да шул тирәдә. Әнә ул, кулы белән нәрсәдер күрсәтә, әле бер җиргә, әле икенче урынга барып, кешеләргә күрсәтмәләр бирә. Әмер-киңәшләре кыска, төгәл һәм ярты сүздән аңлашыла.

Корбан аганың соңгы елларда менә шушындый җанлылык хөкем сөргән вакытны очрата алганы юк иде. Күр инде, нинди хәйран тамаша! Күңелләрне урыныннан кузгатып дәртле хезмәт симфониясе яңгырый. Йөзләрчә кешеләрнең бердәм алынып башкарган хезмәтен карап тору өчен генә дә әллә ниләреңне бирерсең. Корбан ага югарырак урынга басты да, тирә-юньне күздән кичереп, хәйран булып бер тын карап торды. Кеше үз гомерендә менә шушындый бер мизгел кичерү өчен генә дә дөньяда яшәсен икән!

Зур эш башкарыла. Шулай булмыйни! Йөзләрчә скважиналарның нефтен кудыручы зур диаметрлы иске задвижка шартлый-нитә калса, никадәрле мәшәкатьләр тудырачак иде бит. Ә андый хәлнең килеп чыгу ихтималы көннәр үтү белән һаман арта, чөнки нефть күбрәк чыгарылган саен магистральдәге басым да күтәрелә бара.

Җир астындагы зур диаметрлы магистральдән нефть ташкыны тукталганчы берничә сәгать вакыт үтеп тә өлгерде. Ниһаять, төп эшкә керешер чак җитте.

Корбан ага кое янында. Аста — слесарьлар. Алар иске задвижканы чатын-чатка сүтеп аттылар. Ыргаклы кран задвижка детальләрен берәмләп өскә алып тора. Ниһаять, бу эш тәгәлләнде. Коеның як-ягында кеше сыярлык шәрә торба башлары гына тырпаеп калды. Операторлар өчен җаваплы минутлар якынлашты. Коеның төбен экскаватор ярдәмендә тагын да тирәнәйтергә кирәк, нефтьнең үзе түгел, исе дә калмаслык итеп чистартылырга тиеш. Чөнки тиздән коега сварщиклар төшәчәк.

Бераздан кое төбе чистартылды, анда — кып-кызыл яңа балчык. Димәк, төп эшкә дә керешергә мөмкин. Иң элек коега һаваны тикшерү өчен махсус приборлар төшерелде. Бар да нормада: газ юк дәрәҗәсендә. Әмма Корбан ага сварщикларның юлына аркылы төште, кабат тикшереп карыйк, янәсе. Моның өчен автогеннарның берсенә ут төрттеләр дә шлангасыннан асып үзен генә коега төшерделәр...

— Менә хәзер мөмкин! — диде Корбан ага, коега төшәргә рөхсәт биреп.

Кое төбендә эш тәгәлләнү белән алдан ук хәзерләп куелган яңа задвижка төшерелде. Калганы инде — осталар эше...

Кыл өйлә вакыты. Түзәр хәл юк, кыздыра. Авызлар кипте. Маңгайдан агып кергән тир күзләрне ашый. Парафинга баткан яки кара тöскә буялган торбаларга кагылырлык түгел, өтәләп ала.

Берьюлы берничә сварщик эшләгәнлектән, кое янына килмәле түгел, тәмуг оясы анда. Корбан ага егерме минут саен электросварщикларны алыштырып торды. Коедан күтәрелүчеләргә карарга кызганыч.

Чыгалар да, эле генә ләүкәдән чабынып төшкән сыман, хәлсезләнеп җиргә авалар. Судан чыгарып ташланган балыклар кебек еш-еш сулыш алалар. Манма су булган тужуркалары шунда ук агач кабыгы сыман катып китә...

Авыр, чыдар чама калмады дип, эштән баш тартучы юк. Егетләр хәзер мин төшәм, минем чират дип, көтеп кенә торалар.

Нәкъ менә шул мизгелдә очраштылар да инде Корбан ага белән рәссамның күзләре. Карт нефтьче, катып беткән брезент бияләй кигән сыңар кулы белән астан, коедан бәргән сварка нурларыннан ышыкланып, киң итеп елмайды.

— Саумы, Рәсүл!

— Исәнмесез, Корбан ага!..

— Нәрсә, сиңа да эш таптылармы әллә?

— Табылды, Корбан ага... — диде рәссам тел төбенә тирән мәгънә салып. — Ничек кенә табылды әле!..

Әй-йе, ниһаять тапты! Менә нәкъ шушы моменттагыча гәүдәләндерәчәк ул Корбан Шөгеровны. Иөзенә генә игътибар ит син аның: никадәр илһам, дәрт, егәр! Бакырдан коелгандай йөздә сварка нурлары бии... Никадәр гамма, буяу, төс байлыгы!.. Менә ичмасам табыш, дип уйлап куйды кабат Рәсүл һәм вакыт табып килеп чыгуына сөенеп бетә алмады.

Гомумән, аның бүген рухы көр, күңеле күтәренке иде. Сәбәбе дә юк түгел. Баягынак, монда килер алдыннан гына, бөтенләй көтмәгәндә-искәрмәгәндә аның өенә Рахман карт белән Шөгеровларның кунагы мистер Шандор килеп керделәр. Яннарында, гадәттәгечә, Җәмилә.

Бу көтелмәгән хәлдән Рәсүл чак кына каушап калгандай булды. Әмма бик тиз исенә килде, рәхим итегез, кадерле кунаклар, дип, урын тәкъдим итте.

Океан арты кунагы аның сүзләренә әллә ни игътибар итмичә, эле һаман да мольберт өстендә торган Рахман карт портреты янына килде. Ул арада портретның моделе — өлкән Шөгеров болай вакытлы-вакытсыз йөрүләренең сәбәбен ике авыз сүз белән аңлатып та бирде. Мистер Шандор карт янында чәйдә булганда булачак портретның эскизын күреп алган һәм: «Кем эше бу?» — дип кызыксына башлаган. Төп портретның да барлыгы турында белгәч, шунда ук: «рәссамның үзен күрсәт», — дип өй хуҗасының күзен дә ачырмаган.

— Менә, кем, Рәсүл улым, шулай итеп басып кергән хәл,— дип аклангандай итте Рахман карт.

Мистер Шандор башта Шөгеровның портретын читкәрәк китеп тә, кулына алып та җентекләп караштыра, аннары, күпме сорасаң да бирәм, тик сат кына, дип чын-чыннан бәйләнә үк башлый. Рәсүл, әлбәттә, риза булмый. Әрсез кунак күзен дә йоммый, алайса бүләк ит, дип дауларга керешә. Бүләккә каршы бүләк итеп, остаханә салып бирергә вәгъдә бирә. Рәсүлнең, юк, портрет сатылмый, диюенә дә карамастан, мистер Шандорның үз сүзе сүз. Үзенең дә картиналар коллекцияләре җыюын, менә дигән галереясы барлыгын, анда Эль Греко, Франсиско Гойя кебек атаклы мастерларның полотнолары булуын, хәтта Пабло Пикассоның да бер рәсеме барлыгын әйтә.

Рәсүлнең мистер Шандор тәкъдимнәренә колак та салмавын сынапкүзәтеп торган Рахман карт та, ниһаять, телгә килде. Кунак кадәрле кунакны буш кул белән җибәрү бик үк килешеп бетмәс диде ул. Аннары, тавышын чак кына үзгәртә төшеп: «Әгәр дә ризалыгың булса, кем, Рәсүл улым, теге, миңа бүләк иткән иинне, эскиз дисеңме әле, шуны булса да бирик инде»,— дип өстәде. Рәсүл эскиз сезнеке, теләсәгез нишләтегез, диде. Шуның белән сүзләре дә бетте. Кунаклар китеп бардылар.

Шуннан соң Рәсүл, ниндидер йомыш белән, нефть һәм газ чыгару идарәсенә сугылды. Шунда ул Корбан Шөгеров участогындагы әлеге хәлләр турында ишетте һәм беренче очраган машинага утырып юлга чыкты.

Әле дә килгәнмен дип кабат сөенеп куйды ул. Югыйсә, күңелен канәгатьләндererлек композиция, тиешле ракурс таба алмыйча күпме вакытын юкка исраф итте бит ул. Корбан агалардан чыкмыйча атты, атаклы нефтьченең бөтен архивын актарды. Ә архив чыннан да бик бай иде. Корбан Шөгеров турында газета-журналларда басылган мәкаләләр, очерклар, репортажлар аша Рәсүл бөтен Татарстан нефть промышленностеның үсеш тарихын үзләштергәндәй булды. Тагын бер нәрсәгә бик ачык төшенде ул: Корбан ага Шөгеровның хезмәт юлы республикада нефть промышленностеның үсеш этаплары, тарихы белән аерылгысыз икән. Әй-йе. Корбан ага күп еллардан бирле житәкче саналса да, читтән күзәтүче була алмаган. Һәр эшне үз кулы белән тотып, тәмен табып башкарырга яраткан.

Уйлый китсәң, гаҗәп-хәйран калырлык эшләр башкарылган, Корбан ага промыселга эшкә килгәндә генә әле, һәрбер скважина янында, вахталарга бүленеп, аерым операторлар тәүлекләр буе дежур торырга тиеш булганнар. Нефть көчле басым белән тыелгысыз фонтан булып үзе өскә ыргылган. Корбан аганың бер язмасында мондыйрак сүзләр бар: «Нефтьнең торбаларны зыңгылдатып, үзенә бер төрле моң булып, саңгырау авазлар чыгарып җир өстенә күтәрелүен колак салып тыңладыңмы — бетте, үзеңне гомерлек әсир дип сана, син — нефтьче!»

Боларның барысы да Рәсүл өчен ифрат та кызык иде. Күп кенә белешмәләрне, саннарны, куен дәфтәре битләренә язып-язып та куйгалады.

... Сәгать артыннан сәгать үтеп кенә торды. Төш вакытлары күптән узып китсә дә, тамак ялгарга туктаучы булмады. Корбан ага да өйдән китерелгән азык-төлек барлыгын бөтенләй хәтереннән чыгарган.

Көчле кешеләргә уңыш юлдаш була. Сварщиклар төшүгә ике сәгать чамасы үттеме икән, коедан соңгы «җөй»нең тоташтырылуы турында хәбәр алынды. Әмма, сварщикларның бригадиры үзе коега төшеп җентекләп тикшереп менгәннән соң, өч-дүрт кешегә яңадан ярты сәгать чамасы очкын уйнатырга туры килде.

Капка төбенә әледән-әле җиңел автомашиналар килеп тордылар. Эшнең барышы бик күпләрне кызыксындырган. Хәтта Әлмәттән, Ленин орденлы «Татнефть» берләшмәсеннән дә килгәннәр. Әмма эш белән мавыккан Корбан ага боларның берсен дә абайламый калды.

Халык, сөйләшеп куйган кебек, кое тирәсен чорнап алды. Тәмам талчыккан, хәлдән тайган, әмма башкарылган эштән куанычлары йөзләренә чыккан нефтьчеләр, слесарьлар, сварщиклар, ремонтчылар барысы да бер урында. Бераздан коедан башкарылган эшне кабул итеп алу комиссиясе әгъзалары да күтәрелде. Авызлары ерылган, андый чакта артык сүзнең кирәге юк.

Шуны гына көтеп торган кебек, операторлар яңадан үзләренең ярдәмчеләрен ияртеләр дә, автобусларга утырышып «сәфәр» чыктылар. Хәзер алар «кара алтын» ташкынына юл ачачаклар...

Операторлар киткәннән соң ярты сәгать вакыт үттеме икән, кинәт кенә кемдер: «Нефть!» — дип кычкырып җибәрде. Чыннан да, юан торба эченнән шаулап сыек ягулыкның ага башлавы ишетелде. Ул да булмады, яңа задвижканың манометрына «җан» керде, аның стрелкасы торба эчендәге басымның артканнан-арта баруын күрсәтеп, калтырана-калтырана өскә таба үрмәли башлады...

Идарәнең баш инженеры Власенко сәгатенә күз төшереп алды. Аннары, ярылып торган украин акценты белән:

— Булдырдыгыз, егетләр! Сынау вахтасында да сынатмадыгыз,— диде. — График срогыннан бер сәгатькә элек үтәлде.

Аннары ул РИТС начальнигы Шөгеров тарафыннан төзелгән графикның гаять дәрәҗәдә тыгыз булуын, беренче тапкыр танышып чыккач та күңелендә, ай-һай, бер генә вахтада башкарып чыга алырлармы, дигән шик сыман нәрсә туган булуын да яшермәде. Һәм шунда, барысы алдында ул, дөрес ясалган расчеты өчен чиксез зур рәхмәтләр әйтеп, Ногманның кулын кысты. Җиңелчә генә алкышлар яңгырады.

Аннары баш инженер өлкән Шөгеровны эзләп тапты да күзләре белән генә елмаеп:

— Корбан Рахманович, туктатылган унбишенче куст-насос станциясе белән нишләргә уйлыйсыз? — дип сорап куйды.

— Хәзер үк җибәрербез, Артур Павлович! Хәзер үк...— Корбан ага, үзәк диспетчер белән элемтәгә керү өчен, егетләрчә кызу-кызу атлап, культбудкага таба китеп барды.

## 12

Мистер Шандор кичә соң гына Казаннан кайтып төште. Бүген кичкә Мәскәүгә очачак. Гадәттәгечә, иртәнге якта шәһәр башкарма комитетының кара «Волга»сы Рахман карт капкасы төбендә иде инде. Бүген алар соңгы тапкыр Шандор тавына барып килергә дип сөйләшкәннәр иде.

Тау башына, кайчандыр бабасының буровое торган урынга, Шандор берүзе генә күтәрелде. Озак утырды ул анда. Таш сын кебек кымшанмыйча утырды.

Искитмәле матур иртә иде. Үзе чалт аяз. Аста боргаланып Шушма елгасы ага. Яр буйларын, болынлыкларны бизәгән әрәмәлекләр читтән караганда ничектер яссы, җете яшел булып күренәләр. Гаҗәп тә түгел, җәйнең иң куәтле чоры шул — яфракларга тут та төшәргә өлгермәгән чак.

Бер кунак кына түгел, Рахман карт та, күзләрен бик еракларга төбәп, уй-хисләргә бирелеп утыра. Әнә генә, аның өчен берни белән дә чагыштыргысыз якын, кадерле, газиз авыл җәйрәп ята — аның туган Шөгер авылы... Ата-бабалары дөнья көткән, дөнья куйган изге туфрак... Рахман карт та бик еш була бу төбәктә. Кайчан гына булмасын, нечкә хисләр, изге тойгылар яңа көч белән уяналар аның күңел түрендә. Әйе, туган җирләрдән алган тәэсоратның һичкайчан да төсе уңмый, хуш исе бетми, җылылыгы кимеми икән шул.

Кайткач та Шандор Рахман картны яныннан җибәрмәде. Көндезге ашны да бергә ашадылар. Яратты ул, үз итте күңеле яхшылык белән тулган, эчкерсез, җор табигатьле картны.

Карт та шәп! Теләсә кем аны күреп сокланып уза. Хәер, сокланмаслык та түгел иде шул. Рахман карт гәүдәсен егетләрчә төз тота. Адымнары тигез, нык. Килеш-килбәт әйбәт. Сакал-мыегы һәр вакыттагыча пөхтә итеп төзәтелгән, өс-баш чиста, зәвыклы.

Шандор, Рахман карт һәм Җәмилә «Девон» гостиницасы каршындагы бакчада утыралар. Тигез рәткә сузылган пирамидаль тупыл агачлары, күе сәрби куаклары аша урам ыгы-зыгысы, машина тавышлары ул кадәр үтә алмый. Һава саф. Чәчәк түтәлләренә, сары ком сибелгән сукмакларга яңарак кына су сиптереп узганнар.

Мистер Шандор да, Рахман карт та, әйтер сүзләре беткән кешеләр сыман, кинәт тынып калдылар. Кунакның йөзен эшлекле житдилек басты. Сизелеп тора, бу якларга килү аңа нык тәэсир иткән.

— Менә, хөрмәтле Шөгеров!.. Саубуллашу сәгатьләре дә җитте.
Рахман карт ике кулы белән берьюлы таягына таянган да, бер ноктага карап, тик кенә утыра.
— Нишләмәк кирәк, кем, Шандор! Тормыш дигәне шул очрашу белән аерылышулардан тора торгандыр инде ул. — Аннары көрсенгән кебек итеп тирән сулап өстәп куйды. — Санаулы көннәр генә түгел, гомернең үткәнен дә сизмичә каласың икән аны...
Янә тынлык урнашты. Әмма озакка түгел, мистер Шандор ашыкмыйча гына сөйләнеп алды. Казанда булганда кызыклы кешеләр белән очрашуы, күп кенә нәрсәләргә төшенүе турында да сүз куертты ул.
— Күзем ачылып киткән сыман булды, — диде ахырда.
Рахман карт бу юлы да сүзгә катышасы итте.
— Йөз тапкыр ишеткәнгә караганда бер тапкыр күрүең хәерлерәк, дип тикмәгә генә әйтмәгәннәрдер.
Шул вакыт йөгерә-чаба Нәҗибә килеп җитте. Кулында зур гына бер бәйләм чәчәк иде аның.
— Менә сез кайда икән?!. Эзли-эзли иза чиктем. Хәерле көн, мистер Шандор!..
Кунак Нәҗибәне күрү белән аягүрә торып басты.
— О-о, мисс Нәҗибә!..— Шандор хәйран булган кеше сыман телләрен шартлатып, кулларын шапылдатып куйган булды. — Я-я, ходай-тәгалә юмартланса да юмартланыр икән... Кызганмаган, кочагы белән биргән үзегезгә...
Җәмилә, чын күнелдән елмаеп, Шандорның сүзләрен тәрҗемә итте. Нәҗибәгә чытлыкланырга шул җитә калды.
— И-и, көлмәгез инде, мистер Шандор!..— дигән булды ул, йөзен букеты артына яшергәндәй итеп.
— Нишләп көлим ди, мисс Нәҗибә! Алла алдында ант итә алам... Хәер, монда ант та, сүз дә артык: чын гүзәллек мактауга да, исбат итүгә дә мохтаҗ түгел. — Нәҗибәгә таба бер-ике адым атлап дәвам итте.— Бабаем үзенең зиһен дәфтәрендә, татар хатын-кызлары турында, әхлак һәм рухи яктан ифрат та сәламәтләр, дип язып калдырган. Шунда ук, юашлык-басынкылык ияләре, дип өстәп тә куйган. Их-х, нишләп яшьрәк чагымда килеп чыкмадым икән?!.
Андый вакытта Нәҗибә дәшмичә каламы соң!.
— Сез, мистер Шандор, хәзер дә карт түгел әле.
— О-о, мисс Нәҗибә!.. Зинһар дип сорыйм, күңелемне урынынна кузгатмагыз. Я китмичә калырмын...
— Соң, китмәгез!..
— Мин кабат киләчәкмен, — диде кунак. — Көтәрсезме, мисс Нәҗибә?..
— Көтәрмен.
— Димәк, вәгъдә?..
— Вәгъдә!
— Алайса, киләсе елга тагын көтегез мине.
Бу юлы Рахман карт та сүзгә кушылды.
— Рәхим итегез, мистер Шандор.
Ул арада шаулашып-гөрләшеп озатучылар да килеп җитте. Корбан ага, Ногман, Мәхүбә түти һәм Гөлгөлдән тыш монда Сабира да бар иде. Ногманның кулында нәни Борһан.
Барысын бергә күргәч кунак шаккатты.
— У-у, барыгыз да Шөгеровлармы? Менә бит сез никадәрле!..
— Шулай итеп, саубуллашабыз дамыни инде?..— дип башлады Корбан ага. — Тагын берничә көнгә калып булмый идеме соң? Минем дә бераз мәшәкатьлерәк чак туры килде. Рәтләп кунак итеп тә булмады үзегезне...
Шандор көлде генә.

— Бездә кунакның артык зарыктырмыйча китүе хәерле диләр. — Аннары Корбанны җилкәсеннән кочкандай итеп әйтте. — Нишләмәк кирәк, яшьтәш. Кеше — очар кош. Бүген монда, ә иртәгә инде... Адәм баласын кайларга гына илтеп ташламый ул язмыш дигән нәрсә.

Сүзгә Мәхүбә түти дә килеп кушылды. Кунакка ияләшүен, бер дә инде саубуллашасы, аерылышасы килмәве турында сүз куертып алды ул.

— Мин дә ияләштем, — диде кунак. — Яраттым үзегезне. Хәзер инде менә китәсем дә килми. Сез кай җирегез беләндер минем әниемә охшагансыз.—Ул, Мәхүбә түтине җилкәләреннән кочып, дәвам итте.— Рәхмәтнең иң, иң зурысы сезгә... Сезнең сый-хөрмәтләрегезне гомергә дә онытасым юк.

— Сый дигәннән, кара әле, Җәмилә кызым... Аңлатып бир әле үзенә. Иң элек менә шушы төенчекне ачсын. Ул бик яратып ашый торган тутырылган тавык анда...

Шандор Җәмиләне ярты сүздән аңлады.

— О-о, рәхмәт сезгә, рәхмәт!..

Аннары мистер Шандор Рахман картны кочагына алды.

— Я-ә, мистер Шөгеров! Хуш, сау бул... Үземә килгәндә, мин сезнең өчен чын-чыннан сөенеп, хәтта, әйтер идем, горурланып китәм. Бабай язмаларында: татарлар горур халык, диелгән сүзләр бар. Хак икән. Яшерен-батырын түгел, үземне лачыннар төбәгенә эләккәндәй хис иттем. Бабаем язып калдырганнарның барысы да расланды. Хәтта артыгы белән акланды...

Шандор Ногман янына килде. Аны да кочаклады. Америка Кушма Штатларына кунакка чакырды.

Кунак, җәһәт кенә иелде дә, әтисе кулына тотынып басып торган Борһанны җилтерәтеп кулына алды.

— Я-ә, нәни Шөгеров! Дәү үс, бәхетле бул. Киләчәк сезнең кулда. Минем дә оныгым бар... Дөньялар имин булсын иде дә, сез дә бер очрашсагыз иде. Нәкъ менә безнең кебек, туганнарча очрашсагыз иде.

— Рәхмәт, мистер Шандор! Яхшы сүзең өчен рәхмәт. — Корбан ага үзе Шандорны кочагына алды. — Исән-имин генә кайтып җитегез. Безне онытмагыз.

— Үлгәндә дә онытмам, мистер Шөгеров.

Шөгеровлар җыйнаулашып кунакны гостиница каршында көтеп торган машинага кадәр озатып куйдылар. Нәҗибә дә букетын шунда бирде.

Соңгы сүзне Рахман карт әйтте:

— Хәерле юл сиңа, ерак ил вәкиле!..

*

* *

Менә ул эштән кайтып килә...

Нинди хикмәттер, ару-талчыгуларына кадәр рәхәт бит!

Ярата Корбан ага эш вакыты узып, көн сүнгәндә шәһәр урамнарыннан атларга. Аның үзгәрүен, күзгә күренеп матураюын карап үтәргә ярата. Әйе, үзгәрде, танып булмаслык хәзер Ак-Кала.

Әле кайчан гына, Шөгеровлар монда күченеп килгәндә генә, кеше күзенә күренергә оялгандай, урман буена посып утырган «бер этажлы» нәни генә поселок иде ул. Хәзер кара!..

Өчәр, дүртәр, хәтта бишәр катлы ап-ак таш йортлары, урта мәктәпләре, техникумнары, асфальт урамнары белән тирә-якны балкытучы яна Ак-Каланы күреп, сокланып туя алмассың. Журналистлар аны үзләренең язмаларында яшеллеккә күмелеп утырган курорт шәһәрләре белән

чагыштыралар. Бүгенге Ак-Кала турында, аның сокланырлык эшләр күрсәткән данлыклы кешеләре һәм бетмәс-төкәнмәс байлыгы турында бөтен ил белә. Ак-Кала дигәч тә «Нефть» дип өстисе килә. Бу гаҗәп тә түгел. Чөнки республикада социалистик индустриянең бик мөһим тармагы булган нефть промышленностен үстерүгә ак-калалылар үзләреннән лаеклы өлеш керттеләр.

Урамны тутырып атлый Корбан ага, хуҗаларча җиргә нык басып атлый. Менә шушындый чакларны аны берни белән дә чагыштыргысыз күңел көрлеге, сүз белән аңлатып булмаслык илһам, дәрт биләп ала. Андый минутларда ул чиксез бәхетле. Тормыш бар, узган гомер бар, җандай газиз хезмәттәшләре бар, илгә, халыкка игелек китерү, хезмәт итү бар. Борынгылар тикмәгә генә, ир куанычы — хезмәте, димәгәннәрдер. Боларның барысын да Корбан ага үз башыннан кичергән кеше.

Һәрвакыт шулай, ялга яки санаторийга китеп берәр атна гына эшеннән аерылып торса да, Корбан ага дус-ишләрен, үзенең промыселын, эш урынын юксына башлый.

Соңгы көннәрдә Корбан аганың күңеле урынында түгел. Аларның яшь белгеч Рәхим Галимов белән үткәргән сынаулары аеруча яхшы узды, көткәннән дә шәбрәк нәтиҗәләр бирде. Бу турыда кичәге өлкә газетасында да зур гына мәкалә бар иде. «Ак-Кала эксперименты» дип аталган ул язмада нефть бирүдән туктаган скважиналарның «терелеп» яңадан сыек ягулык бирә башлаулары турында хәбәр ителгән иде.

Корбан ага эштән кайтып килә. Алып батырныкыдай зур буйлы, төз гәүдәле. Ул хәзер илленең өстендә. Әмма эштән кайтканда, ничектер, өлкәнрәк булып күренә. Көзге ачы җилләр, кышкы чатнама салкыннар, җәйге челләләр аның йөзенә шактый тирән эзләр салган. Әмма җыерчыклар ярылып яткан бу йөз бик мөлаем. Күз карашлары туры, хәтта үткерләр. Сүзләре тапкыр.

Очраган бере зурлап, хөрмәт итеп исәнләшеп уза аның белән.

— Сәлам, Корбан туган!

— Салют, Корбан Рахманович!..

— Исәнмесез, Корбан абый!..

Аны монда олысы да, кечесе дә бик яхшы белә. Хикмәт бер урында озак яшәүдә генә түгел. Ул депутат буларак та бик күп төрле эшләр башкара, йомышлар, наказлар үти, бик күпләрнең кайгы-хәсрәтен уртаклаша, кирәк икән, ярдәм кулы суза.

Корбан ага эштән кайтып килә. Урамны тутырып горур «эшче» исемен йөртүче кеше атлый. Хезмәт кешесе!..

## Илдар Юзеев

# МӘХӘББӘТ КИТАБЫ

**Тормыш — мәңге, гомер дигән бәхет**
**тик бер генә тапкыр бирелә.**
**Беренчесе, икенчесе юктыр,—**
**мәхәббәт тә була бер генә.**
**Кемдер аны гомер буе эзли,**
**һәрбер яратуы «чын» була...**
**Еллар узгач чын сөюен эзләп,**
**кире китә, әмма... соң була.**
**«Яшь гомерләр кире кайтмый**
**сулар үргә акса да»**
**дигән моңсу җырны көйли-көйли,**
**яшьлек, сиңа бераү хат сала...**

### Яшьлеккә хат

Шушы булыр минем сиңа язган
беренче һәм соңгы хатым да...
Беркемем юк өйдә серләшергә:
дусларым да, балам, хатын да...
Өйдә — бушлык, күңелемдә — бушлык
кырык биш яшь тулган көнемдә...
Төшемдә дә бүген сине күрдем,
күрә алмам ләкин өнемдә.
Йөрәгемдә яна соңгы бер дәрт,
бар гомерем хата булса да,
яшьлегемә кайтыйм, кайтыйм әле
бары... бары хатта булса да.
Соң булса да хыялымда гына
кайтам сиңа, кайтам сафлыкка...
Гомер язы бозларына басып,
утлар яга-яга актык та,
без, ташулар һәм шашулар тынгач,
гомер ярларына кайттык та
ямансулап, уйчанланып калдык
тын һәм тирән уйга баттык та...
Гомерем минем — сафлык рентгенында,
авыр төеннәр бар бәгырьдә...
Эштә генә түгел, сөюдә дә
тиң булдыммы соң мин дәвергә?

---

Ахыры. Башы I санда.

ГЭСлар кордым, биек йортлар салдым...
Мин бер йортта тора алмадым...
Күп яшьтәшләр тапты тиң ярларын,
мин... гомеремне кора алмадым.
Төзү һөнәреннән китмәсәм дә,
мин күчендем, һаман күчендем.
Мәхәббәттә син күченмә икән,—
яши-яши шуны төшендем.
Менә шушы көчле куллар белән
күтәрештем күпме нигезләр...
Сокланып та карыйм, көнләшеп тә:
күпләр бәхетлеләр, тигезләр.
Бәхетең дә тулы, бөтен икән
мәхәббәттә булса нигезең.
Парың да юк хәзер, ярың да юк...
Кем гаепле? Бары син үзең.
Альбомыма карыйм: монысы мин:
бөдрә чәчләр җилдә тузгыган.
Кулда — баян, барча кызлар — гашыйк,
кич урамнан җырлап уз гына:

«Китәм инде, китәм инде,
китмим син белгән якка,
мин китәм ерак-еракка —
чәчем сибелгән якка».

Хәзер инде — сирәкләнгән чәчләр
җилгә түгел, җиргә сибелә...
Үпкән-кочкан, җилгә очканнардан
йөрәгемдә бары син генә...
Тыелгысыз дәртем, ашкын хисем
ташландырган ерак юлларга,
киттем чибәрләрнең күзләрендә
яшеренгән серне урларга.
Их, әгәр дә тормыш — кино булса,
туктатыр да идем тасманы,
калыр идем синдә, бары синдә,
юк, яр итмәс идем башканы.
Имеш, мәхәббәтнең диңгезендә
калыйк әле рәхәт яшәп лә,
матурлардан матурларны эзләп,
чәчәкләрдән күчтем чәчәккә.
Һәр чибәрнең баллы иреннәре
исерттеләр мине алланып,
ләззәт кочагында югалдым мин
мәхәббәт дип белеп, алданып...
Их, әгәр дә тормыш кино булса,
бары синнән башлар идем мин,
синнән соңгы барлык өлешләрен
кискәләр дә ташлар идем мин.
...Бармакларым баян телләрендә
биемиләр, авыр уйлардан
мин сискәнеп китәм... әйе... шулай...
Җыр җырланган, көйләр уйналган...
Хисләр тупасланган, җан суынган,
бернигә дә инде ис китми.
Сандугачның шашып сулкылдавын
колак тыңлый, йөрәк ишетми.

Мин яраткан, кире каккан кызлар
күз алдыма барсы тезелгән,
гомеремә йомгак шулмы әллә?
Нәселем корган, буын өзелгән.
Тик бердәнбер өмет: синең рәсемең...
Карыйм... карыйм... карап туялмыйм...
Сүнгән хисләр кинәт кабына миндә,—
кабат сине янда тоям мин.
Их, әгәр дә тормыш кино булса,
туктатыр да идем тасманы,
калыр идем синдә, бары синдә,
юк, яр итмәс идем башканы.
Сафлыгымның чагылышы булып,
калды бары изге ядкарең...
Шул булган ич чык тамчысы сыман
таңда җемелдәгән чакларым.
Үкенечле зур газаплар аша
сафлыгыма кайтам... хат булып,
беләм: яшьлегемнең бер балкышын
каршыларсың инде ят булып.
Кызгану да, өмет, наз да көтмим,
тик теләктәш кенә бул миңа,
аңла җанның саф бер талпынышын,
иң зур бәхет хәзер шул миңа.
Йорт төзибез: ЗАГС... сез, гашыйклар,
язылырга чират торырсыз...
Сез дә минем кебек булырсызмы?
Гомерегезне ничек корырсыз?..

**Хуш киләсез, бәхетлеләр!**
**ЗАГСта — гаризалар...**
**Гомергә бергә булырга,**
**өйләнергә ризалар.**
**Яшәгез лә, и дусларым,**
**сөешеп, яратышып,**
**хәсрәт болытлары килсә,**
**бергәләп таратышып.**
**Булыр мәхәббәт гөленең**
**салкыны, кыраулары,**
**сезнең алда — мәхәббәтнең**
**иң авыр сынаулары.**
**Тормыш ваклыклары аша**
**кыю үткәннәр генә**
**җиңеп чыгар — йөрәгендә**
**сөю йөрткәннәр генә.**
**Дин, көчләүләр — тарих сезгә,**
**төшми дә исегезгә.**
**Сез — ирекле мәхәббәттә,**
**сез — хуҗа хисегезгә.**
**Сөю-сөелү — икәүнең**
**сайлап алган иркендә,**
**әмма сөймәгәнне көчләп**
**сөйдерәлми беркем дә.**
**Сөю сүнсә, бәйли алмый**
**ЗАГС, суд та, закон да.**
**Гаризалар, гаризалар**
**аерылу хакында...**

## Судка килгән гаризалардан

### ИР

1

Нинди авторитет калсын бездә,
үз хатының «кит!» дип кычкыргач,
ул — атаны, ата — улны белми,
ир кулыннан власть ычкынгач.
Аралагыз мине тупаслыктан,
бәлки, яклар безне законнар?..
Кыз вакытта бар да гүзәл була,
каян килә явыз хатыннар?..

2

Әти һәм әни,
кызлар һәм уллар...
Киң иде фатир,
тар дип кем уйлар?
Килде миңа — яр
хәзер — фатир тар...
ызгыша торгач,
күңел тар калды,
тик бер пар калды,—
ул да таркалды.

3

Әллә соң мин үз тиңемне
табалмам?
Ул бөтенләй артта калды
заманнан.
Соңгы хәбәр тыңлап уйга калу
юк,
театрга, киноларгә бару юк.
Ул, мөгаен, ФТР[1]ны тоймыйдыр,
уйламыйдыр, көймидер һәм
сөймидер,—
и мине дә артка таба сөйридер.
Әллә соң мин үз тиңемне
табалмам,
артка калмый торганнарын
заманнан?

### ХАТЫН

1

Нинди нәфислекләр калсын бездә,
үз иреңнән назлар күрмәгәч,
кушылганнан бирле иркәләүләр,
чәчәкләр һәм язлар күрмәгәч.
Өйләнүгә кадәр кайнар алар,
ә өйләнгәч — боздай салкыннар,
ирләр игътибарын көтә-көтә,
явызлана икән хатыннар...

2

Замана — башка,—
ярдәм итмәс дин...
Нәкъ алар кебек,
мин дә иптәш, тиң.
Бик матур семья
төзмәкче идем,
тик мин аларда
«хезмәтче» идем...

3

Ирем өчен мин кечкенә, мин вак
ич,
эштән кайтам, өйдә көтә — мең
вак эш.
Ә ул, кайтып, диванына ташлана,
миңа — бары хезмәт төне
башлана.
Культуралы минем ирем! Шах та
мат!
Хатын эшли,— кирәк түгел
автомат.
Кырык эшем үзенә бәйләп
тоткандыр,
шул ваклыклар мәхәббәтне
йоткандыр...

---

1 ФТР — фәнни-техник революция.

4

Минем иң зур теләк:
бала, бала кирәк...
Картлык елларында
булыр алар — терәк.
Ул аңламый мине —
гомер узып бара,
киләчәккә кала,
кала тик бер бала...
Болай барса эшләр,
шәһәр халкы кимер,
үз рәхәтең соңрак
бәла булып килер...

4

Без — ун бала үстек,
авыл — авыл инде,
ә шәһәрдә бала
карау авыр инде...
Ишле гаиләләр
бер дә торалмыйлар,
безнең кебек көчле
тормыш коралмыйлар.
Тудыммы соң әллә
арттырырга санны?
Ташлап китте мине,
аңламады җанны...

**Ни булыр иде хатыннар
һәм ирләр дошманлашса,
сөю нәфрәткә әйләнсә,
ызгыш чикләрдән ашса!
Гаскәрләр туктата ала
яу булып илләр кубса...
Туктатыр көч булмас иде,—
хатыннар, ирләр кубса.
Ярый ла хатыннар-ирләр
табыша, туганлаша,
бер-берсен эзләп табалар
утлар һәм сулар аша.
Ярый әле ике җанның
тартылу көчләре бар,
дөньяны яшәртә торган
илаһи хисләре бар.
Ә кайда безнең заманның
Зөһрәсе, Таһирлары!
Әллә юкмы сөю хисен
зурларлык шагыйрьләре!
Әллә сөю саекканмы!
Юк... юк... ул үз көчендә...
Мәхәббәт — тормыш эчендә,
сүнми шуның өчен дә.
Яшьләр кавыша торалар,
чәчләр-чәчкә бәйләнә,
мәхәббәт иң гадәти бер
гүзәл хискә әйләнә.
Мәхәббәтнең яшьлек чоры
кабынса ялкыннардан,
ә хәзер... сөю хисләрдән
чигенеп акылланган.
Ярлар табу җиңел түгел,
якыннар табылса да,
дөрләмичә яна күпләр,
ялкыннар кабынса да.
Сагындырса да кайчакта
сөюдә фанатиклар,
уйны били реалистлар —
аз сүзле яңа типлар.**

**Тик алар да тыя алмый**
**ярсу хыялый хисне,**
**сөю күкләргә күтәрә**
**иң аек реалистны.**
**Сөю дигән хискә лаек**
**бик-бик сирәкләр генә,**
**иң көчлеләр, иң хислеләр,**
**кыю йөрәкләр генә.**
**Сөю өчен, әйе, бары...**
**Бары ярату кирәк,**
**һәр кешедә булмый торган**
**сөю таланты кирәк.**
**Очар өчен яраксызлар,**
**куркаклар, канатсызлар,**
**үзе өчен яшәүчеләр —**
**һәммәсе — талантсызлар.**
**Сынаулар һәм сыналулар**
**сезне көчле итсеннәр,**
**ярлары ерак киткәннәр —**
**айлар, еллар көтсеннәр...**

## Көтегез!

Давыл кубып, кояш сүнсә дә,
кайтыр юлын боз-кар күмсә дә,
туфан калкып, ташкын булсә дә,—
    өзелмәсен һич тә өметегез:
    көтегез...
    Әминә Мусаны көткәндәй,
    көтегез!
Бик хәвефле яуга китсә дә,
тәрәзәне ятлар чиртсә дә,
«Яшь гомерләр зая үтсә дә», —
    өзелмәсен һич тә өметегез:
    көтегез...
    Әминә Мусаны көткәндәй,
    көтегез!
Ялгызлыклар авыр булса да,
сабыр канатлары сынса да, —
иркәләгән җыры тынса да, —
    өзелмәсен һич тә өметегез:
    көтегез...
    Әминә Мусаны көткәндәй,
    көтегез!
Илдә шомлы сүзләр йөрсә дә,
«Онытты!» дип, дошман көлсә дә,
«онытты» дип, дуслар килсә дә, —
    өзелмәсен һич тә өметегез:
    көтегез...
    Әминә Мусаны көткәндәй,
    көтегез!
Күзләр тоныкланып аргач та,
«үлде» дигән хәбәр алгач та,
гомерлек тол булып калгач та, —
    өзелмәсен һич тә өметегез:
    көтегез...

Әминә Мусаны көткәндәй,
көтегез.
Туфракка һәм комга әйләнгәч тә,
Өметкә һәм Нурга әйләнгәч тә,
сөюегез Җырга әйләнгәч тә,—
өзелмәсен һич тә өметегез:
көтегез...
Башка ярлар булып көтегез,
Әминә Мусаны көткәндәй,
көтегез!

## Заһир белән Таһирә

Вокзал. Перрон.

Заһир. Сизәм: күзләреңдә — ямансулык...
Таһирә. Тагын еракларга китәсең.
Заһир. Мин ышанып китәм Таһирәмнең
сер бирмичә өзелеп көтәсен.
Таһирә. Сине көтә-көтә саргайдым ла...
Заһир. Кичер, Таһирәкәй, тилмерттем,
гомерем буйларына гел киттем дә...
Таһирә. Гомерем буйларына мин көттем.
Яшьлегемдә — көтмәгәндә килдең...
Заһир. Авыр булды безнең кавышу.
Таһирә. Һаман әле йөрәгемдә чыңлый
«Сөям!» дигән моңлы тавышың.
Заһир. «Сөям!» дидем... салкын карап уздың...
Таһирә. Әйе, хатирәләр кузгала...
Заһир. Егетләрне якын китермәдең...
Таһирә. Мин — унҗиде яшьлек кыз бала...
Заһир. Синең өчен — ташкыннарга төштем...
Таһирә. Сиздермәдем — эчем ут иде.
Заһир. Син укыган җиргә җәяү киттем, —
синнән башка — яшәү юк иде.
Таһирә. Сезнең авылыгыздан күчеп киттек.
Заһир. Табалмаслык җиргә — Донбасска.
Таһирә. Мин — кыз бала, тыштан сиздермәдем,
син ашкындың миннән калмаска.
Үзем киттем, үзем — курыктым мин:
табалмассың, дидем, юл ерак...
Заһир. Син яшәгән якта һәрбер нәрсә
ягымлырак иде, нурлырак.
Таһирә. Эзләп таптың...
Заһир. Җир астына төштем,
«Шахта» көйләренә җырладым.
Таһирә. Айлар үткән саен аңлый бардым
күңелемдә минем кем барын.
Заһир. Мин янганчы — ташкүмерләр янсын!
Өеп куйдым ком-таш тауларын.
«Сөям» дигән сүзне ишетмәдем...
Таһирә. Әсир иттең инде, яуладың.
Заһир. Синең белән очрашуны көткән
көн — ай, ай — ел булып тоелды...
Таһирә. Чәчәк ташкынында йөздек ул көн...
Заһир. Туй булды!
Татлы бер төш итеп искә алам
бәхет чынга ашкан аемны...

Таһирә. Арабызга явыз дошман керде —
сугыш аерды.
Заһир. Сине авылыбызга илтеп куеп,
мин фронтка киттем...
Таһирә. Югалдың...
Кара мөһер суккан кәгазь килде.
Заһир. Хәтәрендә йөрдем юлларның.
Таһирә. Ышанмадым, әйтсәләр дә килеп:
«Үзем каберен күрдем иреңнең».
Заһир. Синнән «сөям» сүзен ишетү өчен
кырык үлеп, кырык терелдем.
Таһирә. Гаҗәпләнәм, ничек исән калдың
кичеп күпме сугыш, утларны...
Заһир. Авыр минутларда Таһирәмнең
«Көтәм» дигән сүзе коткарды.
Таһирә. Вузга киттең...
Тагын аерылу...
«Китмә!» диеп әйтү кыен ла...
Заһир. «Ах, авыр...» дип ник бер сүз әйтмәдең,
ниләр кичермәдең дүрт елда?..
Таһирә. Инженерым кайтты диплом алып...
Заһир. ГЭС төзәргә салкын Себергә
җибәрделәр, синең тәрбиядә
калды — бала, эти, сеңел дә...
Ничек түздең?
Таһирә. Сабырсызлык, кайгы яшьләрен мин
сөю дулкынында агыздым.
Синең белән горурланам, Заһир,
Җирдә күпме утлар кабыздың!
Заһир. Аңлауларың өчен мең-мең рәхмәт!
Тагын эшкә — ерак чит илгә...
Җылы сулышларың тартыр мине
булсам да мин дөнья читендә.
Таһирә. Сокланам мин... Яшең — өлкәнәя,
сынмый рухың, бетми көчләрең...
Гел күченеп йөрдең, ә сөюдә
һәрчак тугры булдың, күчмәдең.
Заһир. «Яратмый» дип артка чигенмәдем,
ярый әле сиңа бәйләндем.
Синдәй гүзәл ярны табалмадым, —
ярты дөньяларны әйләндем.
Таһирә. Утлар синнән башка янар, бәлки,
вакыттыр бит тыныч ялга да?..
Заһир. Ач халыклар, утсыз-сусыз илләр,
бәхетсезләр бик күп дөньяда...
Төнге сахраларда яктырырсың
барлык уттан нурлы булып син...
Бу дөньяның салкын җанын бераз
безнең сөюебез җылытсын.
Таһирә. Сау бул, Заһир,
поезд кузгала...
Заһир. Таһирәкәй, минем өчен һаман
Син — унҗиде яшьлек кыз бала.
Гомерең буе әйтәм диеп йөргән
сүзеңне әйт... өлкән гашыйкка.
Таһирә. Зинһар, ашыкма...

Мин ул сүзне, «сөям!» дигән сүзне
алтын туебызда әйтермен.

Заһир. Ул кадерле сүзне ишетү өчен,
кайта алмасам да кайтырмын!..
Хуш!..

**Мәхәббәтнең була шундыйлары:**
**нәфрәт килеп кергә уртага.**
**Юллардагы моңлы очрашулар...**
**Егет сөйли Китә.**
**Җыр кала...**

## Нәфрәт һәм мәхәббәт төне

Эзләдем мин авыл тынлыгында,
шәһәр шауларында,
Эзләдем һәм таптым сине, Анна,
Ленин тауларында.
Рәхмәт, язмыш, безне очраштырдың,
икебез — ике яктан,
мин — гади бер татар авылыннан,
ә син — Дойчландтан.
Зәңгәр күзләреңне мөлдерәтеп,
туры кара, дустым...
Ак чырайлы, сары чәчле Анна,
ә мин — кара-кучкыл.
Син — бик сабыр, тыныч һәм аз сүзле,
ә мин — дары, төтен,
төсләр — анти, холык-фигыль — анти,
уйлар-хисләр — бөтен.
Миндә булмаганнар — синдә, Анна,
миндә — синдә юклар.
Бер-берсенә шулай тартылалар
бары антиподлар.
Аңлашуның юлы озын иде, —
без бит ятлар, читләр,
аералар безне ераклыклар,
милләт, яклар, чикләр...
Без аларның барсыннан да өстен,
югарыда идек,
яшьлекнең иң биек үрләрендә,
юлларында идек.
Без бит ата-ана балалары, —
ризалыклар алыйк,
бәхилләсен алар — аерым-аерым
сәлам хатлар салыйк.
Гариза да әзер. Хатлар көттек.
Килде — көткән минут.
Очраштык без Ленин тауларында.
Син — тын. Ә мин — ут.
Йөрәкләрдә утлы кургаш сыман,
без укыган хатлар:
«Бәхиллек юк, Тайфур, алар белән
без бит — җиде ятлар.
Оныттыңмы әллә сөйләгәнне:
дөньяда син юкта,
бабаң газап чигеп җанын биргән
анда — әсирлектә...

Беләсең ич, немец пулясыннан
газапланып ятам...
Сүзләремне аяк аска салсаң,
гафу итмәс атаң.
Бала үстердекме җанга төбәп
аткан дошман өчен,
тәннән көчем чыга барган саен,
арта җанда — үчем...
Әниеңне аның атасы зар
елаткандыр, бәлки,
ачу-нәфрәт белән күкрәгемә
ул аткандыр, бәлки...»
Сулышларны кыса конверттагы
без укыган юллар:
«Нишләттең син, Анна, карт көнемдә
калтырыйлар куллар...
Соңгы сулышкача кимемәслек
ачы хәсрәт җанда,
нәкъ унсигез яшьтә яшь әтиең
ятып калды анда...

Әтиеңнең соңгы сүзе кайтты, —
тыңла, синең өчен:
«Минем юлны балам дәвам итсен:
алынмады үчем...—
Ул үч килә ерак-еraклардан —
бабамнардан башлап...
Рухың белән, Анна, илеңдә кал,
китмә безне ташлап...
Атаң иseме белән сорыйм синнән:
китмә бездән, китмә.

Ястыктагы соңгы сүзем шулдыр:
ризалыклар көтмә!»
Бала һәрчак үз итәргә тиеш
ата-ана хакын,
минем күңелемә — әти-әни,
сиңа — әнкәң якын.
Кинәт кенә Ай тотылды сыман, —
йөзләр — кара болыт,
йөрәкләрне телә хатлардагы
сүзләр — яра булып.
Куенымнан чыкты кайнар Анна,
тирән сулый-сулый...
Ни ишетәм: «Тайфур, оныт мине!
Юк! Юк! Булмый! Булмый!»
Пышылдыйлар миңа чит-ят җилләр:
«Анна — анда, анда!..

Ата-баба васыяте шундый:
якын дус та, яр да
булалмыйсыз, сез — дошманнар — икәү —
мәңге ике ярда.»
Төне буе дошман буды мине —
атты бер-бер артлы,
сөю туган йөрәгемә төбәп,
нәфрәт — пуля атты.

Кемдер корал бирә: «Син ояттан
коткарырга тиеш...

Анна — мишень... атаң-бабаң өчен
үч алырга тиеш!»
Үлем коралын мин атып бәрәм:
оят миңа, оят!
Анна, Анна, мәхшәр — оятлардан
Уят мине, уят!
Кайда соң син, Анна, араларга
шикләр кергән чакта,
төштә түгел, өндә!.. Әллә син дә
нәфрәт җиңгән якта?!
Атмасалар, Анна, мин ул ярга
корал тотып бармам,
тартып алыйм сине шик — дошманлык
нәфрәт чәчкән ярдан.

...Йокламыйсың, син дә газапларда,
ниләр булды безгә?
Үксеп-үксеп елыйсың син, Анна,
башың куеп тезгә:

«Бар дөньяның кайгы-хәсрәтләре
нигә минем башта?..
Әни сүзеннән дә чыга алмыйм,
булмый — синнән башка!
Төне буе син үзеңә тарттың,
өшим, тирлим, янам,
син — үзеңә, бабам, атам, анам
тартты үзенә табан.

Сөю бәхетен дә күрәлмагач
нигә таптың, анам?..
Безнең язмышка да дошманлыклар
баш булырмы һаман?..»
Я, тынычлан, Анна, сөрт яшеңне,
ата таң да әнә...
Бир кулыңны, киттек — без очрашкан
Ленин тауларына.
Күтәрелик дөнья картлыгыннан,
чикләү, тарлыклардан,
без төзәргә тиеш киләчәкне
бәхет, шатлыклардан.
Киттек, Анна, синең туган җиргә:
әнкәң белән, димәк,
күзне-күзгә карап сөйләшергә,
аңлашырга кирәк.

Әткәм сезгә корал тотып кергән, —
бурыч шулай кушкан.
Ул чагында, әйе, киләчәкнең
кодалары — дошман.

Узганнарның хәсрәт-фаҗигасе
яши бар да миндә,
әрнүләр бар, үтмәс яралар бар, —
үч юк әмма миндә.

Әтиемнең каны аккан ил бит —
уяу булып киләм,
нәфрәт хисен мәхәббәткә урап,
кияү булып киләм.
Аңлар, бәлки, әңкәң... авыр туй бу...
Күтәрелер тостлар,

Моабиттан чыгып безне Тельман,
җәлилчеләр котлар.

Китәрбез без, әниеңне алып,
минем туган җиргә,
ата-ана улларыннан җавап
көтә торган җиргә.

Авыр туфрак булып, илегездә
ятып калыр — атаң...
Күтәр башың, ата ялгышында
юктыр синең хатаң.

Мәрхүм атаң безнең күңелләргә
бер таш булып яткан:
киләчәктә кода булыр ирләр
бер-беренә аткан.

Бик кыйммәткә төшкән бу дөньяга
атаң ялгышлары,
алар вөҗданында — миллионнарның
үлем, язмышлары.

Әткәй, әнкәй, мин тик аны сөям...
Менә килен сезгә...
Көтмәдегез болай кайтуларны,
беләм: кыен сезгә.
Йөрәгендә синең дәртең типкән
улың булып әйтәм!
Нәфрәт хисен җиңик, киләчәккә
пуля атмыйк, әткәм!
Дөреслеккә, әткәй, туры карыйк:
кемдер мәхрүм туйдан...
Бәлки, бәлки... аны син аткансың, —
җир астында — кодаң...
Әйләндермә, әткәй безнең туйны
кайгы һәм газапка,
күчермә син дуска нәфрәтеңне, —
дошманнарга сакла!
Мин ышанам, Анна, килешерләр...
алар безне аңлар,
туебызны котлап, авылыбызда
сызылып атар таңнар.

Керербез без ЗАГС булмасенә,
тирән уйга калып,
сугышларның миллион корбаннарын
шаһитлеккә алып.

Янауларга, явыз карашларга
горур карап үтик,
дошманлыкның, шик һәм нәфрәтләрнең
киртәләрен сүтик!

Эзләдем мин авыл тынлыгында,
шәһәр шауларында,
эзләдем һәм таптым сине, Анна,
Ленин тауларында.

Артка чикте гүя караңгы төн,
атты инде таң да...

...Күзләреңдә һаман икеләнү —
Ник дәшмисең, Анна?!..
Анна?..

**Ишетәсезме серле биеклектән**
**«сөям сине» дигән тавышны!..**
**Миллиард еллар буе хыялланган**
**Җир белән Күк гүя кавышты.**

## Бортжурналга язылган шигырь

**Кеше — Җирдән** ычкынырга тиеш, —
куймаганнар бәйләп,
мәхәббәтең белән ашкындырдың
хыялыма әйдәп.
Синнән алдым янып яшәүләрнең
тиңсез үрнәген мин,
гомерем буе күтәрелдем Җирдән,
күккә үрләдем мин.
Хыялымда — синең белән бергә
ерак Айга бардым,
якынайдым — сиңа, Җирдән һаман
ерагая бардым.
Һава юлларына чакырдылар
бар кораблар мине...
Мәхәббәтең — барыр юлларымда
пар канатлар иде.
Илаһи рух, омтылышлар алып
ярсу хисләреңнән,
ычкындым мин кинәт туган Җирнең
тарту көчләреннән.
Мондый көчне синең янып торган
күзләреңнән алдым,
«сөям сине, сөям сине» дигән
сүзләреңнән алдым.
«Йолдыз булып күккә менәрмен дә...»
син яраткан җырлар,
хәзер инде шашкын бу җырымны
дөнья, галәм тыңлар.
Җир тирәли зыр-зыр әйләнәм мин,
тизлек артып тора,
мәхәббәтең Йолдыз илләреннән
Җиргә тартып тора.
Бар галәмдә, дөньяда юк синдәй,
син — гүзәле Җирнең
мин — йолдызы булсам зәңгәр төннең,
син — үзәге Җирнең.
Кап-караңгы салкын галәм буйлап
эзләр уеп барам,
«сөям!» дигән йөрәк тибешеңне
тыңлап, тоеп барам.
Беркемнең дә гүя минем кебек
сөеп шашканы юк,
беркемнең дә гүя минем кебек
күккә ашканы юк.
Мәхәббәтнең мондый араларны
үткәне юк әле,
беркемнең дә мондый ераклыктан
көткәне юк әле.

Безнең кебек яна алмас хәтта
мең Мәҗнүн, мең Ләйлә,
сүндерәлмас мондый януларны
бозлы мәкер, хәйлә!
Илаһи һәм олы сөенечтән
башым күккә тигән,
беркем юктыр дөнья, галәмендә
миндәй көчле сөйгән!
Чык та, иркәм, төнен, сагына-сагына,
һаваларга кара,
мәхәббәтең Киек каз юлында
йолдыз булып яна.
Галәм күзлегеннән карагандә,
кечкенә бер нокта,
әмма галәм җансыз булыр иде
шул бер йолдыз юкта.
Миннән бәхетлерәк йолдыз юктыр
зәңгәр чиксезлектә:
туган илем көтә, җирем көтә,
сөйгән ярым көтә.
Һаман югарыга омтылдыра
Киек казлар юлы...
чиксезлектә йолдыз булып яна
сөю дигән җылы.
Сөю җырын ишетмәгән галәм,
ишет, җырлап узам,
гашыйкларның дөрләп януларын
мәңгелеккә сузам.
Бу галәмдә нокта икәнемне
онытырга уйлыйм,
барлык йолдызларны сөю белән
җылытырга уйлыйм.
Йөрәк тибешеңне тыңлап, ерак
хыялыма ашам,
синнән ераклашкан саен, бәгърем,
сиңа якынлашам!
Сөю — маяк Җирдән аерылып,
күктә йөргәннәргә,
йолдызлардан сәлам алып кайтам
көтә белгәннәргә.

**Югары аң хөкем сөргән Җирнең йөзен**
**вакытлыча караңгылык чорнап алган.**
**Йоклый адәм балалары изрәп-арып,**
**миллиард акыл һәм миллиард җан ялга талган.**
**Берәүләре Матурлыкны төзеп арган,**
**берәүләре төзегәнне өзеп арган.**
**Иксез-чиксез яхшылыкны күтәргән Җир,**
**иксез-чиксез явызлыкны үткәргән Җир**
**бервакытны яманлыктан сыгылыр сыман,**
**сыгылыр да күк йөзенә егылыр сыман.**
**Ычкынмый Җир... нидер аны тотып тора,**
**явызлыклар һәр яхшыны йотып тора...**
**ә яхшылык һаман, һаман шытып тора,—**
**аек Акыл һәм Җан Җирне тотып тора.**
**Тик шулай да тыныч түгел Җир йокысы:**
**өнендә ул яман-яхшы эшләр күрә,**

миллиард-миллиард балалары белән бергә
саташулы һәм куркыныч төшләр күрә:
Бер якта — ут лавалары, бер якта — боз,
Җир куркыныч һәм дәһшәтле төскә кергән,
күп гасырлар иҗат иткән бөеклекләр
җимерелгән, барсы асты-өскә килгән.
Әй, адәмнәр! Сезгә дәшәм: коткарыгыз!
Әллә инде кешелекнең юлы беткән!..

Тормыш дигән иң гали бер дөнья төзгән
Акыл беткән, Йөрәк дигән җылы беткән!!

Җир йөзендә бер Адәм юк, бер Хава юк,
тере җан юк ярдәм сорап кычкырырга,
салкын галәм бушлыгында юкка чыгар
менә хәзер, менә хәзер ычкынып да...
Коткарыгыз!..

Һәммә тараф хәрәкәтсез катып калган,
булмагандай чын һәм ялган, яхшы, яман,
әллә шулмы бу дөньядан ваз кичкәннәр —
пәйгамбәрләр вәгъдә иткән ахыр заман!..
Коткарыгыз!..

Җир уянды ыңгырашып мәңге тынмас
сугышлардан, тынычлык һәм сабыр юктан,
тетрәп куйды кешелекне юк итәрлек
көч-кодрәткә ия булган авырлыктан.
Борчылма, Җир, сине сөйгән уллар-кызлар
керфек какмый саклый сине, уяу алар,
әнә ана кулындагы сабыйлар да
таң гөледәй өмет белән уяналар.
Бу төн калсын өметсезләр төне булып,
төштә генә калсын бары, юк, өн булмас!..
Җансыз Акыл, акылсыз Җан беркайчан да
Мәхәббәтнең, Матурлыкның юлын бүлмәс!
Ахыр заман — өметсезләр уйдырмасы,
сәләтсезләр һәм көчсезләр хыялы ул,
мәхәббәттән һәм яшәүдән тәм тапмаган,
ямь тапмаган мескеннәрнең хыялы ул...

Юк һәм булмас! Бу заманның — ахыры юк!
Бүген туган Киләчәкнең — ахыры юк!
Яхшылыкның, изгелекнең — ахыры юк!
Җанда туган мәхәббәтнең — ахыры юк!

Сөю — чиксез — Галәм сыман — ахыры юк!
Ахыр заман — аңсызлыкка, җансызлыкка!
Ахыр заман — дошманлыкка, кансызлыкка!
Ахыр заман — көчсезлеккә, мескенлеккә!
Ахыр заман — бөлгенлеккә һәм коллыкка!
Миллион куллар кочакласа колач җитмәс
Җир җанашым, йөрәгемдә тоям сине...

Ишетәсеңме...

Япь-яшь адәм балалары
бер-берсенә пышылдыйлар: «Сөям сине...»
Сөю барда син мәңгегә суынмассың,
гашыйклар да мәхәббәттән исермәсләр,
кучәреңнән ычкынырлык көч булса да,
алар сине йөрәкләрдән төшермәсләр.
«Сөям сине»... Шул ике сүз йөрсен синдә...

**Явыз җаннар аның көчен төшенсеннәр,**
**бу ике сүз Тынычлык һәм Ирек өчен**
**барган яуга бердәм булып кушылсыннар!**
**Дипломатлар теле булсын: «Сөям сине!»**
**Дөньяларда патша, король — шушы булсын!**
**Ачу-нәфрәт һәм дошманлык киртәләрен**
**үтү өчен иң шәп пароль шушы булсын!**
**Сөям сине... Илләр шулай аңлашсыннар...**
**Акыл һәм хис әнә шулай мәңгеләшә..**
**Йөрәгендә Сөю йөрткән бөек Кеше,**
**яшәт Җирне, үзең шунда мәңге яшә!**
Туар чорлар моңы якыная,
артта калган саен җыр башы...
Кеше тизрәк җитәр максатына —
сөю булса даим юлдашы.
Заман тизлегеннән калышмыйча,
еллар тизрәк алга чапкандыр,
парны, электрны, атомнарны
гашыйк җаннар уйлап тапкандыр.
Кеше бәхете өчен канлы көрәш —
максатлары олы, ачыклар...
Мәхәббәттән бетмәс көч алганнар
Маркс, Ленин — даһи гашыйклар.
«Кем баласы?» диеп сорасагыз,
мин мәхәббәт, чорлар баласы,
шашып яратулар бездән соң да
оныкларга күчеп каласы.
Азат булыр сөю явызлыктан,
матди исәпләрдән, ваклыктан,
сөю — гомергә тиң озын булыр,
кайгы калыр... артыр шатлыклар.
Вакыт җитәр, без дә суынырбыз,
тарих күмәр безнең эзне дә,
киләчәкнең бөек гашыйклары,
онытмагыз анда безне дә...
Безнең матурлыклар сездә кала,
без дә үзебезчә яшәдек,
сөю китсә — яшьли картайдык без,
сөю килсә — картлар — яшәрдек.
Безнең хисләр сезгә сәер тоелыр,—
аңлашылмас безнең сагышлар...
Бәлки, киләчәкнең бер шагыйре
сөю җырын безгә багышлар?..
«Җир кешесен өзелеп сөям!» диеп
галәм түрләреннән кем дәшәр?..
Сөю хисен әгәр югалтмаса,
Җир суынмас мәңге,
Җир яшәр!

1978—79.

# Разил Вәлиев

# ЯШИСЕ КИЛӘ!

ПОВЕСТЬ

«Хезмәт вазифаларын башкарганда күрсәткән ныклык һәм батырлыгы өчен рядовой Миргазизов Рифкать Шәфкать улын «Батырлык өчен» медале белән бүләкләргә (үлгәннән соң)».

(СССР Верховный Советы Президиумы Указыннан)

*Татар халкының каһарман улы, 70 нче еллар комсомолы Рифкать Миргазизов батырлыгына багышлыйм.*

1



— Тукта... тукта, — дип ыңгырашты Рифкать. — Тукта... хәзер...

Ул аска таба оча да оча, ә парашют һаман ачылмый. Тирә-юньдә беркем юк — дөм караңгы. Рифкать бар көче белән парашют бәжрасын тарта. Бармаклары әрни, ут яна, ә парашют һаман ачылмый да ачылмый. Башы бер өзлексез шаулый, чатнап авырта — әйтерсең, самолет моторын башына терәп куйганнар да бөтен көченә үкертәләр. Ә ул оча, һаман оча. Колак төбендә әче җил сызгыра. Менә хәзер, менә хәзер җиргә атылып төшәр дә челпәрәмә килер...

— Тукта! — дип тагын ыңгырашты Рифкать.

Кайда соң аның иптәшләре? Кайда башка солдатлар? Бөтен җир дөм караңгы. Әй, ул күзләрен йомган икән бит. Хәзер күзләрен ача да, дөнья яп-якты була. Нәрсә бу? Күз кабакларын авыр әйбер белән бастырып куйган кебек. Ул һаман саен тизрәк оча. Әллә шулай тиз очканга күзне ачып булмыймы? Бер ни дә күренми... Җиргә ерак калды микән? Юк, юк, тизрәк күзне ачарга кирәк! Юкса... Әнә, керфекләр селкенде. Димәк, ачып була. Әнә, еракта, бик еракта алсу яктылык сирпелә. Кояш нурлары... Кояш чыгып килә. Ә җир күренми. Колак шаулый, колак төбендә җил сызгыра. Ә җир һаман юк. Әллә җир бө-

тенләй юкка чыктымы? Әллә ул төпсез упкынга очамы? Алай дисәң, әнә, кояш нурлары да күренә. Иптәшләре генә юк. Ә-ә? Аның парашюты ачылмаган бит! Димәк, алар артта калган... Хәзер менә соңгы көчен җыеп бокраны тарта да... Ур-ра, ачылды!.. Әнә, баш очында — ап-ак гөмбәз! Әкренәйде. Ул хәзер әкрен генә оча, җилдә чайкала-чайкала әкрен генә оча. Әнә, аяклары да җиргә тиде...

Рифкать авырлык белән генә күзләрен ачты. Күзләрен ачты да, куркыныч төшеннән айнып җитмәгән сабый кебек, тагын бер ыңгырашып куйды:

— Башым...

— Аңына килде...

«Аңына килде! Аңына килде!» — дип чыңлады аның колагы.

Баш очындагы ап-ак гөмбәз талгын җилдә җилфердәп торды-торды да ап-ак җәймә булып аның өстенә ташланды. «Чуалды, парашют чуалды, — дип уйлады Рифкать. — Тизрәк аннан котылырга да алга чабарга кирәк...» Ул куллары белән чәбәләнде, аяклары белән тыпырчынды. Ә нишләп: «Атакага!» — дип кычкырмыйлар? Нишләп бу десантниклар ап-ак парашютка төренгәннәр дә бер урында тик басып торалар. Йөзләре дә бик кырыс. Парашютны вакытында ача алмаганга аңа ачуланалармы?

— Ят, Рифкать, ят, сиңа торырга ярамый.

Рифкать, аптырап, күзләрен ныграк ачты. Күз алдындагы аксыл томан әкренләп сыегайды. Иң беренче булып каршыдагы тәрәзә һәм тәрәзә артындагы кояш пәйда булды. Аннары ул ап-ак түшәмне, ак стеналарны, ак халатлы кешеләрне төсмерли башлады.

— Нәрсә булды? — дип дәште ул, ләкин тавышы бик тә зәгыйфь булып, бары тик хәлсез пышылдау гына булып чыкты.

Рифкать ачу белән тамагын кырып куйды да бар көченә кычкырмакчы булып авызын ачты, ләкин шулчак өзеп-өзеп башы авырта башлады, һәм бөтен гәүдәсе буйлап күтәрелеп килгән әрнү һәм үпкә катыш җан авазы тамак төбендә буылып калды. Ул тешләрен кысып ыңгырашты, күзләрен чытырдатып йомды.

— Шприц! — диде кемдер.

Менә аны сак кына әйләндерделәр, менә аркасы черки тешләгән кебек аз гына авырту сизде, менә бөтен тәненә акрын-акрын җылы йөгерде, күз алдындагы куе кызыл пәрдә теләр-теләмәс кенә күтәрелде һәм бөтен тирә-як тагын ап-ак төскә керде.

— Бирешмә, егет! Солдат бирешмәскә тиеш!

Рифкать тавыш килгән якка борылмакчы булды, ләкин башы тыңламады, тарттырып бәйләгән кебек, үз урынында ята бирде.

— Кыймшанма, кыймшанма, сиңа кыймшанырга ярамый, — диде шул ук тавыш.

«Кем соң бу? Нинди таныш аваз соң бу? Нинди кешеләр җыелган монда? Кайда соң мин?

Ә-ә-ә! Ул парашютына чуалган да болар аңа булышырга, аны коткарырга килгәннәр!»

Рифкать сүрән генә елмаеп куйды. Күзләрендә кабынган елмаю бит алмаларында бераз алсуланып торды да, иреннәренә барып җитә алмыйча, сүнде. Ул тагын күзләрен ачты һәм каршысында басып торучы өлкән яшьтәге хәрби кешене күреп, бераз аптырап калды. Җилкәсенә ак халат япкан кеше, урындык алып, аның янәшәсенә утырды.

— Хәлләр ничек, солдат? Бик авыртмыймы?

Кинәт, һич тә көтмәгәндә, Рифкатьнең тамак төбенә җылы төер килеп тыгылды, башы, утлы кыршау кидергәндәй, яна башлады.

— Шприц! — диде әлеге тавыш.

Аны тагын чак кына кузгаттылар, озакламый җилкәсе буйлап тагын рәхәт җылылык таралды. Рифкать бераз вакыт керфек кагарга да кыймый ятты. Кемдер баш очында утлы кыршау тотып тора кебек тоелды аңа. Күзен ачыйм дисә, утлы кыршауны башка кидерә дә куя. Менә ул, әлеге газраилгә сиздермәскә тырышып, әкрен генә керфекләрен күтәрде, аннары, баш очында утлы кыршау күренмәгәч, күзләрен ачты.

Каршыда шул ук хәрби кеше утыра. Аның янында — кулына шприц тоткан ак халатлы апа. Ә арттарак — тагын ак халатлы кешеләр.

— Түз, егет, түз, герой! — дип елмайды хәрби кеше. Ләкин аның елмаюы бик моңсу да, сәер дә килеп чыкты.

— Генерал... — дип пышылдады Рифкать.

— Әйе, мин бу, рядовой Миргазизов, мин. Мин исән, иптәшләрең дә исән, барысы да исән! Рәхмәт сиңа.

Һәм шул чак барысы да, барысы да аермачык булып Рифкатьнең күз алдына килеп басты. Ирексездән, аның йөрәге кысылып куйды, ике күзеннән ике бөртек яшь тәгәрәп төште, бераздан башы шаулаудан туктады, гәүдәсе җиңеләйгәннән-җиңеләя барды, менә инде ул аны бөтенләй тоймый да башлады.

Рәхәт. Рәхәт һәм бераз куркыныч та. Парашютта төшкәндә шулай була иде. Ул әле хәзер дә оча түгелме соң?! Әйе, әйе, оча! Ләкин шунысы гаҗәп, җиргә түгел, ә өскә, зәңгәр күккә таба оча! Аста автоматтан аталар, «урра!» кычкырып йөгерәләр, танклар үкереп чаба. Ә ул гранатасын уч төбенә кыскан да һаман-һаман өскә күтәрелә, күтәрелгән саен күңелгә рәхәтрәк була бара, көләсе, җырлыйсы килә. Ләкин ул көлә дә, җырлый да алмый, чөнки кулында — граната. Менә аның бармаклары ут яна башлый, граната сырлары уч төбен кисеп керә. Ычкындырмаска, түзәргә, түзәргә! Әгәр бармакларын язса, граната шартлаячак та ул, атылган коштай, җиргә егылып төшәчәк. Аның белән бергә кояш та, ай да, йолдызлар да шартлаячак, сүнәчәк.

Рифкать иреннәрен кысып ыңгырашты. Ана тагын укол кададылар.

Күзне чагылдырып, палатада кояш уйный. Тып-тын.

Беркем бер сүз дәшми. Басканнар да тик торалар. «Бөтенесе басып тора, мин генә нишләп болай ятам соң әле. Мин тормаганга сөйләшмиләрдер», — дип уйлады Рифкать һәм, күтәрелергә исәп итеп, кыймшанып карады. Ләкин кыймшануга ук тирә-юнь караңгыланып китте, кешеләр томан эченә кереп югалды. Ул, елап җибәрүдән куркып, тешләрен кысты да түшәмгә текәлде.

Тагын тынлык. Бу тынлыкны бары тик колак төбендәге берөзлексез шаулау авазы гына бозып тора. Самолет гөрелтесенә охшаган шаулау авазы. Әллә һаман самолетта очаламы соң? Юк, юк, ул инде хәзер барысын да хәтерли, барысы да күз алдындагы кебек...

## 2

Аларны төн уртасында тревога белән уяттылар. Ул икенче каттагы караватыннан сикереп төште дә юл уңайлый киенә-киенә казарма ишегенә таба йөгерде. Дөбер-шатыр килеп баскычтан чабып төштеләр дә казарма каршына тезелделәр. Караңгы күктә чекерәеп йолдызлар яна. Ике көн, ике төн берөзлексез койган янгырдан соң, дөнья киңәеп, иркенәеп киткән кебек. Түбәңә басып, күңелне борчып торган болытлар таралгач, күк шундый биегәйгән, ниндидер бер тантаналы төскә кергән. Шундый биек күккә караганда хәтта башлар әйләнә. Беренче тапкыр театрга баргач шулай булган иде. Гомер буе мондый биек түшәм

күргәне юк иде аның. Кешеләр тамаша карый, ә ул һаман күзен түшәмнән алмый.

— Смирно!

Өлкән лейтенантның төн тынлыгын ярып яңгыраган авазыннан хәтта йолдызлар да, бер-берсенә бәрелешеп, чыңлап куйдылар кебек.

— Десантниклар, — диде өлкән лейтенант Киреев, тавышын акрынайта төшеп, көньяк-көнбатыш яктан дошман гаскәрләре һөҗүм итеп килә. Безнең бурыч — дошман тылына төшәргә һәм көтмәгәндә арттан көчле удар ясап, аны юк итәргә! Калганын юл уңайлый аңлатырмын. Ма-ши-на-га!

Яшькелт-соры төстәге машина ут капкандай алга ыргылды да тимер капка аша чыгып аэродром ягына таба юл алды. Әллә инде йокыдан уянып җитмәгәннәр, десантниклар, берсе бер сүз дәшми, тын гына машина көенә чайкалып баралар. Бары тик ара-тирә парашютны җайлабрак куялар да янтыкка төртеп торган автоматны кырыйга шудыралар. Рифкатьнең сул ягындагы чегәннеке төсле кара чәчле, каратут йөзле, бөркет борынлы әзербайҗан егете Вагыйз дә сүз башламый. Мондый чакта ул, гадәттә, мең төрле мәзәк сөйләп эчне катырып бетерә иде. Бер уйласаң, мәзәге дә искитәрлек түгел үзенең, ә көлмичә түзә алмыйсың. Ул рус сүзләрен шундый кызык итеп, балаларча ватып-сындырып сөйли. Аның мәзәген кабатлап сөйләп кара, кешеләр, көлү түгел, елмаеп та карамас. Бөтен кызыгы шул сөйләвендә бугай.

— Илдус...

Рифкать сул ягындагы егетнең терсәгенә кагылуга, тегесе дерт итеп китте, башын күтәрде.

— Нәрсә, якташ, әллә йокы туймадымы?

Илдус, соры күзләрен яртылаш кына ачып, аңа карады, дәшмәде. «Үзең дә беләсең бит», янәсе. Рифкать, әй, сиңа дәшкән мин юләр, дигәндәй, башын илтифатсыз гына кыйгайтып куйды да, артка таба йөгерүче агачлар шәүләсенә карап, уйга чумды.

Соңгы арада алар, көн дими, төн дими, хәрби өйрәнүгә әзерләнделәр. Тәннән соңгы тирне сыгып чыгарганчы йөгерделәр, иңбашлары өзелеп төшәр хәлгә җиткәнче граната ыргыттылар, билләре торатташка әйләнгәнче парашют сүттеләр, парашют җыйдылар. Кичләрен Ленин бүлмәсенә кереп хат язарга утыргач, тупасланган бармаклар ручкага ияләнә алмый тилмерә иде.

Бу арада нишләп хат килми икән аңа? Тәлгатьтән дә җавап юк. Инде язганына ике атна булды бит. Әллә, акыл өйрәтә дип үпкәләде микән? Ниләр язган иде соң әле ул аңа? Монда хат язарга вакыт бик аз кала. Шуңа күрә ул язасы сүзләрен юлда йөргәндә, я берәр җирдә ялга туктаганда уйлап куя, ә инде казармага кайткач, аларны бары кәгазьгә генә төшерәсе кала. Шулай иткәч, шома да, тиз дә булып чыга. Хатларны төрле итеп, кызык итеп, озын итеп язасы килә аның. Ләкин яза башлагач һаман шул бер чамадан артмый.

«Исәнме, Тәлгать! — дип авыз эченнән сөйләнде Рифкать. (Хатны һәрчак «исәнме»дән башлый ул). Исәнме!

Сиңа солдат сәламнәре юллаучы дустың Рифкать. Бераз үзем турында язып китәм. Хатыңны алдым, бик зур рәхмәт. Дөресен әйтик, сез анда, теге җырда җырланганча, мине бөтенләй онытып бетергәнсездер инде.

Минем хезмәт яхшы бара, кәеф әйбәт, спорт белән шөгыльләнәм. Көннәр бик эссе тора, бөркү, түзәрлек түгел. Монда инде чия өлгерде, бар халык шуңа ябырыла. Кичә «Унике урындык» фильмын карадык, шунда сезне искә төшердем. Тиздән минем хезмәт итә башлаганга сигез ай тула. Озакламый, шушы айда, хәрби өйрәнүләр булырга тиеш. Менә, үзем турында шулар гына. Хәзер көндезге сәгать бер. Әле генә мунчадан кайттык.

Тәлгать, безгә кереп Азатка әйт әле, миңа бер-ике кассета җибәрсен. Монда бик шәп дискалар бар, яздырыр идем. Азатка хат язган идем, сорарга онытканмын.

Шулай итеп, эшләп йөрим, дисең инде. Эшлә, эшлә. Ләкин начар эшлисе булсаң, кара аны! Кайткач мин техникумга керермен, ахрысы. Ярый, бүтән язар сүз бетте бугай.

Бөтенесенә, бөтенесенә дә сәлам әйт, минем исемнән кулларын кыс.

Рифкать.

Хат яз!

22/06. 76.

P. S. Биш көннән миңа унтугыз яшь тула».

Минә туган көн дә узып китте. Ике шешә лимонад алып, дуслар белән утырдылар да, тагын гадәти солдат тормышы башланды.

— Иртәгә өйгә хат язарга кирәк,— дип уйлады Рифкать.— Хәрби өйрәнүләрнең ничек үткәнен дә язармын. «Исәнмесез, әнкәй, әткәй, Азат, Әнфисә!» — дип башлармын хатны. Юк, алай гел бер төсле була. Бу хатын ул болай башлар: «Исәнме, әнкәй! Исәнме, әткәй! Исәнме, Азат! Исәнме, Әнфисә!

— Мин үзем исән-сау яшим...»

Менә кызык, исән булуын белә торып, кешегә исәнме диләр! Харис бабасыннан бер сораган иде инде ул. Бабасы мыек астыннан көлемсерәп кенә куйды. Аннары, чалгысына таянып, моңсу күзләрен еракка, бик еракка, Вятка болыннары аръягына төбәде.

— Һәр сүзнең хикмәте бар, улым, — диде ул. — Сүз ул күктән төшмәгән, кеше күңеленнән өзелеп төшкән.

— Исән кешегә «исәнме?» дип әйтүнең ни хикмәте бар соң? — дип кабатлап сорады Рифкать.

— Әй, улым, улым, күп нәрсәне белмисең шул әле син. Кайчакта шундый хәлләргә каласың: исәнме-юкмы икәнеңә шикләнә башлыйсың. Ә инде исән икәнеңне белгәч, сөенеп бетә алмыйсың. Сугышта күп очраттым мин андый хикмәтле хәлләрне. Менә бу күзне фашист пулясы шаярткач, якты дөнья йөзен бер күрергә тилмереп яткан чаклар күп булды. Сау-сәламәт кеше генә яшәү кадерен белми ул. Бармагыңа шырпы керсә дә, үрле-кырлы сикерә башлыйсың. Үләсе килми, якты дөньяларны калдырып, кара гүргә керәсе килми адәм баласының! Яшьләргә ни?! Дөнья кадерен беләмени яшьләр? Сезгә әле ике дөнья —бер моржа...

Шулай диде дә Харис бабай, бер сәбәпсезгә чыккан ачуын басарга тырышкандай, киерелеп-киерелеп чалгысын селтәргә тотынды.

Рифкать, үчләшкәндәй, һаман үзенекен итте:

— Шулай да тере кешегә: «Исәнме?» — дип әйтү дөрес түгел инде.— Хәерле көн! Здравствуйте!— диярге кирәк.

Харис бабай, капыл туктап, чалгысын печән пакусы өстенә ыргытты да куак күләгәсенә барып утырды. Шешә бөкесен ачып, чәй уртлап куйды, кара кәләпүше астыннан чыгып торган яулык чите белән маңгай тирен сөртте.

— Исәнме дә исәнме!? Нәрсә аңлыйсыз соң сез? Здравствуй, имеш. Кемгә — нәрсә, кәҗәгә — кәбестә, ди. Аларныкы үзләренчә дөрес, безнеке — үзебезчә. Урыс әйтә: «Яшә, дөнья рәхәтен күр!»— ди, ә без: «Исәнме, саумы, хәлләрең ничек?»— дибез.— Исән булсаң, тазалыгың булса, ходай җүн бирер. Әнә, сугышта күпме әзмәвердәй ирләр ятып калды. Алардан «Исәнме?» дип сораган кеше юк бит. Ә аңа кадәр күпме кырылган? Безнең халыкның башы сугыштан чыкканга күпме генә әле! Гомер буе — сугыш, гомер буе — кырылыш. Шул мәхшәрләрне күрсәң, үзеңнең исән икәнеңә сөенеп бетә алмас идең.

Харис бабай үпкәләгән кыяфәт белән Рифкатька карап торды да, син аңлый торган нәрсәмени бу дигәндәй, чаж-чож чалгысын янарга

тотынды. Аннары, баш бармагын чалгы йөзенә тигереп карагач, аякларын аерып басты һәм ачу белән селти-селти киң пакус алып кереп китте. Рифкать аның артыннан иярде. Бабасы бүтән дәшмәде, авыз эченнән берничә тапкыр: «Исәнме? Исәнме, имеш»,— дип кабатлады да, йөзтүбән капланучы үләннәргә карап, онытылды.

## 3

— Десантниклар!

Рифкать бер мәл уйларыннан арына алмый торды. Чалгы тавышы әкренләп тонykланды, печән пакусы күзгә күренеп ерагайды-ерагайды да бөтенләй күздән югалды. Колакка машина гөрелтесе кереп тулды, өлкән лейтенант Киреевның өзек-өзек сүзләре ишетелде:

— Десантниклар!— дип кабатлады ул.

Башка вакытта аның һәр сүз бик тә ачык булып, авызыннан гаҗәеп олы борчак тәгәрәп төшкән кебек ишетелә иде. Ә бүген каршы искән машина җиле сүзләрне әле бер, әле икенче якка очырта, шуңа күрә җөмләсе, машинада барганда язылган хат юллары кебек, тигезсез чыга, авазлары, сүзләре калтырый, аслы-өсле килә.

— Без бүген дошман тылына төшәчәкбез,— дип дәвам итте Киреев.— Һәр адымыгызны үлчәп атлагыз, һәр хәрәкәтегезне уйлап эшләгез! Ашыкмагыз, кабаланмагыз! Иң мөһиме — һәркем үзе өчен дә, янәшәдәге иптәше өчен дә җавап бирсен! Һавада вакытта ук бер-берегезне югалтмаска, бергә булырга тырышыгыз. Сез бүген Үзәк штабтан килгән комиссия каршында, ил каршында, Ватан каршында сыналасыз. Әйдәгез, десантникларның кем икәнен күрсәтик!

Өлкән лейтенант ничек башлаган булса, шулай капыл гына сөйләүдән туктады. Бер якка янтайтып кигән зәңгәр береткасын арткарак шудырды, уңайсызланып кына елмайды. Әле яңа мыек чыгып килгән бу егетләрне ни көтәсен яхшы белә ул. Шуңа күрә аларны җилкендерәсе, берәр җылы сүз әйтәсе килә. Ләкин андый сүз табылмый да табылмый.

Киреев, ни әйтергә белмичә, егетләргә карап-карап торды да:

— Җыр башларга!— дип кычкырды.

Шуны гына көткәндәй, Вагыйз әллә кайдан, эчтән чыккан тавышы белән җырлап та җибәрде. Аңа казакъ егете Тансык кушылды, аннары грузин Гурамның тамак төбеннән калтырап чыккан авазы ишетелде. Аларны Коля, Виктор, Илдус — бөтен взвод күтәреп алды. Ә Рифкать авызын кыймылдатып кына торды, җырламады. Мондый да бай тавышлы гаҗәеп хорны беркайчан да тыңлаганы юк иде аның. Дөрес, алар бик еш җырлыйлар, ләкин бүгенге җыр, караңгы төндә тын далада яңгыраган җыр моңа кадәр җырланган бар җырлардан да матуррак кебек иде, ул күңелне чеметеп-чеметеп ала, сулык-сулык китерә иде. Казакъ далалары киңлеге дә, рус бәйрәмнәренең шашкын дәрте дә, грузин тауларының кайтавазы да, татар моңнарының моңсулыгы да бар иде бу җырда.

Рифкать тагын бераз ләззәтләнеп, хыялланып тыңлады да, үзе дә сизмәстән, ирексездән җыр агымына ияреп китте:

> Без — канатлы десант солдатлары,
> Бөркет булмау безгә ярамый.

Җыр, машина гүләвен, җил сызгыруын басып, япан далага таралды, агач ботакларын сыйпап узды. Аны арттан килүче машинадагылар күтәреп алды. Бер мизгелгә десантниклар үзләренең хәрби өйрәнүгә баруларын да, алда меңмең сынаулар торуын да оныттылар. Бөтен җирдә, бөтен дөньяда бары тик җыр, шушы җыр гына калды, ул әле

генә боегып утырган егетләргә канат куйды, йөрәкләргә дәрт, кыюлык өстәде, аларны бөркет итеп күккә күтәрде.

Машина тормозлары ачы итеп шыгырдады. Солдатлар дәррәү җиргә сикереп төштеләр. Җыр, басу өстендәге тургай кебек, һавада тирбәлеп калды. Төшкән уңайга тезелделәр дә, команда яңгырауга, самолетка таба йөгерделәр. Самолетның иләмсез зур крокодил авызына охшаган «капкасы» күз ачып йомганчы десантникларны «йотып» җибәрде. Аннары авыз акрын гына ябыла башлады. Рифкать, күрәсеңме дигәндәй, Илдуска төртте. Илдус гадәтенчә башын кагып куйды. Нәрсә әйтсәң дә, шулай башын гына кага ул, беркайчан да сиңа каршы килми. Кайчакта бу Рифкатьнең ачуын да китерә, ләкин ул моңа күнегеп бара. Менә хәзер: «Әйе шул, бигрәк зур»,— дисә, теле өзелеп төшмәс иде бит.

Монысы — Рифкатьнең инде сигезенче сикерүе. Ә шулай да иялә-шеп бетә алмый әле. Бу самолетны десантниклар яратып, үз итеп «оча торган сарай» дип йөртәләр. Чыннан да, бигрәк зур шул. Рифкатьләрнең ике катлы казармалары хәтле булыр... Беренче тапкыр сикергәндә шактый шүрләгән иде. Әле хәзер дә, шул искә төшсә, оялып куя. Ул сикерә торган люк пропеллер белән янәшә иде. Сикерүгә үк пропеллерга килеп эләгер кебек тоелды аңа. Командир: «Киттек!»— дип җилкәсенә кулын куйгач, бер ара икеләнеп калган иде. Аннан күзләрен чытырдатып йомды да сикерде. Сикерүгә үк тыгыз җил агымы аны артка таба чөеп җибәрде. Бүген ничек булыр икән? Күңел түрендә посып яткан курку хисе бүген тагын баш калкытырмы? Төнлә беренче тапкыр сикерүләре бит.

«Крокодил авызы» ябылып беткәч, самолет акрын гына гүли, калтырый башлады. Гүләү көчәйгән саен Рифкатьнең башы да шауларга, авыртырга тотынды. «Нәрсә бу, моңа кадәр болай булганы юк иде бит, әллә авырыйммы?»— дип уйлады ул. Ә башы аның саен ныграк авырта, Рифкать, авырту басылмасмы дип, маңгаен самолет тәрәзәсенең салкын пыяласына терәде. Тәрәзә артында, кул сузымы гына ераклыктагы офыкта, кызыл мишеньга охшаган кояш күтәрелеп килә. Таң ата.

Тәрәзә аша төшкән кызыл кояш нурларыннан солдатларның йөзләре бронза төсенә кергән. Рифкать, тәрәзә артындагы матурлыкны күрсәтергә дип, Илдуска дәшмәкче булган иде, түшәмдә кабынган сары утны күреп, уеннан кире кайтты.

— Әзерләнергә!

Бронза һәйкәлләргә охшап утырган десантниклар калкынып куйдылар, парашютларын, автоматларын рәтләгәч, дәррәү торып бастылар. Шулчак түшәмдә яшел ут кабынды. Тавышсыз-тынсыз гына люклар ачылды.

— Киттек!— дип кычкырды командир.

Бүген рәт башында Вагыйз тора. Бүген ул беренче булып сикерәчәк. Беренче булып сикерү бигрәк куркынычтыр,— дип уйлады Рифкать.— Иксез-чиксез күк дәрьясына берүзең, ялгызың гына чумасың бит. Берүзең генә су коенган кебек. Самолетта бөркү. Их, су коенасы иде хәзер. Чума-чума, су чәчрәтә-чәчрәтә су коенасы иде. Кама буендагы тын күлләрдә су коенудан да рәхәт нәрсә бар микән дөньяда?! Әтисе карьерда эшләгәндә көн саен барып йөри иде Рифкать. Ул алып килгән ризыкны бергәләп ашыйлар да, хуш исле печәнгә чалкан ятып бераз хәл җыялар.

— Үскәч кем булырсың икән син?— дип сорап куя әтисе.

Икесе бергә калдылармы, гел шулай дип сорый ул. Ә Рифкать ни дип тә җавап бирергә белми.

— Ә бабай нигә Түбән Камага килми?— дип әтисенең соравына

сорау белән җавап бирә ул.— Анда ялгызына читендер бит, бездә яшәр иде.

— Әллә ничә әйтеп карадым инде. Киләме соң?! Үзең күрдең бит, кунакка килгәч тә, бер кич кунуга: «Илмәт, Илмәт»,— дип сөйләнә башлады. Авылы да ерак түгел, Кама аръягында гына да бит. Кайтып китеп йөрер иде. Юк шул, аерып булмый кешене үз нигезеннән.

— Менә сез аерылгансыз бит әле. Авылны ташлап, Кизельга да киткәнсез, менә монда да килгәнсез.

— Әй, улым, үз ихтыярың белән йөрүмени ул. Нужа куып йөртте бит, нужа. Сугыштан соң, бәхет эзләп, ярты авыл шахта ягына кузгалды. Әниең белән без дә шуларга иярдек. Әниең белән дип, әле ул чакта өйләнешмәгән идек, егет белән кыз идек. Шунда тормыш корып җибәрдек. Ике авылдаш бергә булгач, азрак күңел дә тынычланып китте, ике сагышны бер итеп яшәдек инде шунда. Аннары сез дөньяга килдегез. Ә менә син: «Нигә авылны ташлап киттегез?»— дисең. Яратмаганнан, дип уйлыйсыңмы әллә. Ярату гына түгел, чуар тавыкларына, урам этләренә кадәр сагына идем, төнлә төшләремә кереп тилмертә иде. Кан береккән, җан береккән инде безнең ул авылга. Ата-баба гуфрагы бит. Кама буенда шәһәр салуларын ишеткәч, дәррәү күтәрелеп кайтып төштек. Ни өчен кайттык дисең? Шәһәр кайда да шәһәр инде ул: таш белән тимер дә төтен. Үзебезнең якка, туган якка якынрак булыйк, дидек. Ә менә авылга ук кайтып җитеп булмады. Бер аерылып киткәч, кире кайтулары һай кыен ул! Авыл безне үз итмәс, кешеләре иш итмәс кебек тоелды.

Рифкать чалкан яткан да күктә талпынып-талпынып сайраучы тургайны күзәтә.

— Әллә тыңламыйсың да инде?

— Тыңлыйм, тыңлыйм.

— Нәрсә тыңлыйсың, тургайнымы?

— Әткәй, ә мин үскәч авылга кайтам. Харис бабай белән бергә яшим. Печән чабам, утын китерәм, гармунда уйнарга өйрәнәм.

— Һе-һе,— дип көлемсери әтисе.— Карарбыз, азрак күзең ачыла башласын әле.

Аннары ул фуражкасын батырып кия дә олы-олы атлап экскаваторына таба китә. Чылбыр тәгәрмәчкә менеп баскач, артына борылып, Рифкатька кычкыра:

— Әйдә, утырасыңмы? Йөрергә өйрәтәм.

— Юк!— дип кычкыра Рифкать.— Юк! Мин балык тотам. Уха пешерәм.

Кармак таягын текә ярга кадап куйгач, ул аскарак төшеп чишенә дә суга чума. Ләкин артык эчкә керми, яр буенда гына йөзә. Әтисе белән я Әнфисә белән коенганда бу күлне аркылыга-буйга иңләп йөри ул, ә үзең генә булганда никтер куркыта. Юк, батудан курыкмый ул, кирәк булса, Рифкать Каманы да аркылы йөзеп чыга ала. Су түгел, ялгызлык куркыта бугай аны. Мәктәптә дә, урамда да берүзе йөрергә яратмый ул, өйдә дә ялгызы каласы килми. Янында кеше булмаса, бик тә моңсулана, хәтта башы авыртырга тотына. Әле менә хәзер дә чигәләре кыса. Яр буенда экскаватор үкерә, аның тавышы да мине бораулап-бораулап керә.

— Киттек!

Рифкать, сискәнеп, башын күтәрә һәм каршында янып торган яшел утны, бераз алга иелеп баскан десантникларны күреп, елмая. Соңгы арада шулай бик еш хыялга чума башлады әле ул. Әллә сагындыра инде. Менә бу өйрәнүләр үткәч, озакламый көз дә җитәр. Ә аннары — отпускага!

Самолет моторларының тонык, авыр гүләве колакларны чыңлата.

Әйтерсең, кемдер иләмсез зур агач тукмак белән башка суга да суга, суга да суга.

Каршыда — ачык люк. Командирның: «Киттек!»— дигән ишетү белән ул алга ыргыла. Тизрәк сикерергә, тизрәк котылырга кирәк бу мәхшәрдән. Самолеттан сикерүгә, мотор тавышлары тынуга салкын җил кочагына чумар да баш авыртуы басылыр кебек тоела аңа. Ләкин бер адым атлауга, битне кайнар дулкын сыйпап ала, аркасы, бөтен тәне буйлап ток йөгергәндәй була. Әйтерсең, ул очмый, ә бер урында һавада асылынып тора. Аннары әкрен-әкрен баш авыртуы да кими. Бөтен тән буйлап рәхәт җылылык йөгерә. Еракта, бик еракта кемнәрнеңдер сөйләшкәне ишетелә.



4

— Хәле ничек?— ди калын тавышлы ир кеше.

— Саташа. Вакыт-вакыт онытылып китә. Кычкыра. Укол кадагач тагын аңына килә. Бик күп кан югалткан. Кан бирергә кирәк.— Тавышы ягымлы хатын-кыз, гаепле кеше сыман, бик тә борчылып сөйли.

— Өлкән лейтенант, Сидоров, ротага хәбәр итегез: «Рядовой Миргазизовка кан кирәк»— диегез. Округ госпиталеннән хирург килеп җитмәдеме?

— Берничә минуттан самолетлары аэродромда булачак. Каршыларга машина җибәрдек.

— Яхшы. Барыгыз.

Таныш тавышлар ишетелгәч, Рифкать күзләрен ача. Палатада шул ук кешеләр. Генерал гына киткән. Аның урындыгында полк командиры утыра. Сул кулына шприц тоткан халатлы апа уң кулы белән аның битен сыйпый. Кулы шундый җылы, йомшак. «Битне сыйпаган җылы җил шушы икән»,— дип уйлый Рифкать.

— Уяндыкмы? Хәлләр ничек?— дип, акрын гына, сак кына сүз башлады полковник.

— Иптәш полковник, авыруны борчырга ярамый, ул бераз ныгырга, хәл җыярга тиеш.

Рифкать күз карашын врачка таба күчерде. Түгәрәк йөзле, зәңгәр күзле, коңгырт чәчле. Маңгаенда сырлары да бар. Нәкъ әнисе инде. Мөлаем һәм моңсу күзләрендә әнисенеке төсле бераз киная дә бар төсле. Әйтерсең, Рифкать бер-бер ярамаган эш эшләгән дә, ул аны: «И-и, шулай итәләрме соң, нәрсә уйладың син бала?»— дип, яратып кына ачулана сыман.

— Бик авыртмыймы, улым? Яхшы, яхшы. Тик кенә ят. Кыймшанма, улым, кыймшанма. Хәзер миңа кан бирербез. Хирург та килеп җитәр.

Аның сүзләре шундый ягымлы, шундый йомшак, җылы иде ки, врач апа сөйләшкән саен баш авыртуы кими бара, баш эчендә янган ялкын сүрелә төшә, кулларга, аякларга, күкрәккә җылы йөгерә. Аннары ул җылы бергә җыела да тамак төбенә килеп тыгыла. «Еламаска, еламаска! Еларга ярамый!»— дип эчтән генә кабатлый Рифкать. Шуңа гаҗәпләнә ул: кыйнаганнары да, ачуланганнары да бар аны, ә берчакта да еламый иде. Ә менә җылы сүз ишеткәч, «улым» дип битеннән сыйпагач, ирексездән, күңеле тулды да куйды.

Ул озак кына, бер нәрсә дә уйламаска тырышып, түшәмгә карап ятты.

Шул чак, сулык-сулык килеп, уң кулы сызларга тотынды, сызлау тора-бара бөтен гәүдәсенә күчте. Ул тешләрен кысты, йөзе җыерылып килде. Аңа тагын укол кададылар, бераздан авырту басыла төште һәм ул, хәлдән таеп, бер хәрәкәтсез ята бирде. Әйтерсең, аны бик каты

кыйнаганнар да ул, әнисе сизмәсен дип тын гына ята. Ыңгырашмый да, зарланмый да. Ә әнисе, сизсә дә, сизмәгәнгә салыша: «Нәрсә, әллә арыдыңмы? Ят, ял ит, авырып китә күрмә тагын», — дип юата.

Аның эчендә ачу кайный. Шул малайларга кыйнатып торган өчен җаны әрни... Илдуска арттан сукмаган булсалар, үзләренә дә эләгәсе иде...

5

Әнфисә, Галия, Илдус, ул — танцыдан кайтып килгәндә каршыга биш малай чыгып басты. Аларның берсен, сары чәчле, олы башлы, озын гәүдәле егетне инде берничә тапкыр күргәне бар Рифкатьнең. Күрше мәктәптән, баскетбол командасында да уйнап йөри. Танцы мәйданчыгыннан читтәрәк бер эскәмиядә Рифкать гитара уйнап утырганда өерләре белән әллә ничә бөтерелгәннәр иде. Малайлар, кызлар Рифкать утырган эскәмияне сырып алганнар да шау-гөр киләләр. Әле көлешәләр, әле җыр башлап җибәрәләр. Ә тегеләр ни танцыга бармыйлар, ни бу төркемгә килеп кушылмыйлар.

— Әй, тартырга бармы?— дип сорады озын буйлы егет эскәмиядәгеләрдән.

— Тартмыйбыз бит, әнә, безнең өчен химкомбинат торбасы тарта.— Тәлгать, илтифатсыз гына, шәһәр читендә кара төтен болыты ургып торган иләмсез биек торбаларга таба ымлады.

Әнфисә белән Галия пырхылдап куйдылар.

Озын буйлы егет кабаланмый гына кесәсенә тыгылды. Егетләр-кызлар, нидер көтеп, тын калдылар, гитара да, җыр авазлары да өзелде, бары тик танцы мәйданчыгында колакларны чыңлатып музыка авазы гына ишетелә иде. Егет, башын чайкап, тузган чәчләрен артка чөйде дә уч төбеннән бер бакыр акча алып Тәлгатькә сузды:

— Никулинга өч тәңкә түләп кергән идем. Мә, үз бәяңне ал, юморист! Кәмит күрсәтсәң, биш тиен дә бирермен.— Шулай диде дә, инде үзенә каршы сүз әйтә алмаслыгына ныклап ышангандай, авызын ерып җибәрде. Аннары, кисәк кенә борылып, Галияне култыклады:— Әйдә, чибәркәй, бер селкенеп килик әле!

Галия башта югалып калды, ләкин тиз генә аңына килеп, кулын тартып алырга теләде:

— Җибәр! Авырттырасың!

Ләкин егет аңа колак та салмады, Галияне өстерәп диярлек музыка гөрелтесенә таба баруында булды.

— Җибәр дим! Нәрсәгә каныктың, оятсыз!

— Минме оятсыз? Ха-ха-ха!— Егет көчәнеп кенә көлде. — Минме оятсыз? Оятымның кайда икәнен күрсәтер идем инде мин сиңа.— Ул тешләрен шыгырдатты да чертләтеп төкерде.— Бала-чага бар. Әйдә, читкәрәк...

«Сары баш»ның әйтә башлаган җөмләсе ярты юлда өзелеп калды, Галия, кулы бушаганны сизеп, бер читкә йөгерде.

Рифкать егетнең сул кулын артка каерып китергән, ә тегесе авыртудан кыймшанырга да кыймыйча, алга бөгелгән килеш тик басып тора иде. Менә ул ачы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Егетләр! Нәрсә карап торасыз? Егетләр, бирегез шуларга!

Ләкин «егетләр» урыннарыннан кыймшанмадылар, танцы мәйданчыгы янында йөрүче дружинникларга карап, бер урында тик басып тордылар.

— Җибәр! Сиңа тигән кеше юк бит.

— Әгәр тагын кызларга кагыласы булсаң, тәмәкенең кайда үскәнен күрсәтермен мин сиңа.— Ачудан Рифкатьнең тавышы калтырап чыга иде.

Рифкать, синең белән нигә кул пычратам дигәндәй, җирәнгән кыяфәт белән егетне этеп җибәрде.

— Бар, әниең янына кайт. Сөйләшергә өйрәнмичә монда күренәсе булма.

«Сары баш» алга таба сөрлекте, ләкин егылмады, барган уңайга гәүдәсен турайта-турайта куаклар арасына кереп югалды. Моңа кадәр, кузгалырга да куркып, бер урында шым торган дүрт егет аның артыннан иярде. Бераз баргач алар, туктап, куак төбендә казына башладылар.

— Ни эзлисез анда? Әллә җир тишегенә кереп качмак буласызмы?— Ниһаять, Илдус та телгә килде.

— Синең кебек бер бәләкәй малаебызны шушында калдырган идек. Еламасын дип. Шуны таба алмыйбыз.— Озын буйлы егетнең тавышы тагын көчәйгән, аңа элекке усаллыгы кире кайткан иде.

— Кара аны, артык шалтырама, баганаң башына фонарь элеп куймасыннар.— Илдус бер-ике адым алга атлап куйды.

— Ташла, Илдус, тәмәке төпчеге эзлиләрдер,— дип, Рифкать аның итәгеннән тартты. Аннары гитарасын, солдатлар автомат аскан сыман, җилкәсенә шудырып куйды да уң кулын дустының иңбашына салды һәм әкрен генә атлап китте. Үзе гамьсез генә сызгыра, үзе тегеләргә таба бара. Аның артыннан башкалар да иярде. Агач төбендә казынучы «Сары баш»ның кулында нидер бар иде бугай, шуңа күрә исе китми, сукмак уртасында басып тик тора. Аның артында «тән сакчылары» караеп күренә. Ләкин үз өстенә тоташ стена булып килүче малайларны күргәч, ул югалып калды, бераз таптанып торды да, кыеклыйкыеклый атлап, әкрен генә китеп барды.

— Аракы исе аңкый үзеннән,— диде Галия.

— Кесәсенә ниндидер тимер салды, тагын берәрсенә бәйләнә инде болар, — дип өзгәләнде Илдус. — Өченче көн генә бер егетнең башын ярганнар иде.

Ләкин болар сөйләшеп торган арада колга егет тә, аның иптәшләре дә юкка чыккан иде инде. Тегеләйгә чабып карадылар, болайга йөгерделәр — җир астына кереп киттеләрмени, эзләре дә юк.

— Фу, бандитлар,— дип алар югалган якка йодрык күрсәтте Әнфисә.

— Борын салындырмагыз, әйдәгез, көлегез әле,— диде Рифкать. Аннары, нәрсәдер исенә төшкәндәй, кинәт кенә кычкырып җибәрде: — Рөстәм, Галия, Сережа, Илдус, Тәлгать, әйдәгез, Саша янына!

— Ни сөйлисең, Рифкать, безне бу вакытта кем больницага кертсен?— диде Тәлгать.

— Ә без кермәбез, тәрәзә төбендә генә торырбыз. Гитара уйнарбыз, җырларбыз.

— Берүзенә генә күңелсездер аның,— дип Әнфисә Рифкатьне куәтләде.

— Хәле бик авыр аның, малайлар, безнең күршедә врач тора, шул әйтте, терелеп чыгуы да икеле, ди.

— Әйе, әйе,— дип Сережаны баш кагып тыңлады Илдус.— Умыртка сөяге сыну уен эш түгел.

— Киттек, егетләр, киттек!— диде Рифкать һәм, дәртләндереп, егетләрнең җилкәләренә суккалады да, гитарасын алып, озын көй башлады.

Кара да гына урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә...

Менә кызык, караңгы төн, дип җырлыйлар, ә җырлаган саен, киресенчә, төн яктыра барган кебек. Бигрәк серле, сихерле инде бу җыр дигән нәрсә. Җыр булмаса, дөнья бик тә күңелсез булыр иде.

Больница ишегалдына кергәч, җырлаудан туктадылар. Тәрәзәдә утлар балкый. Тәрәзә аша палаталарның ак түшәме, ак стеналары күренә.

— Кайсы тәрәзәдә икән соң ул,— дип пышылдады Илдус.

— Теге якта,— диде Рифкать.

— Каян беләсең?

— Мин монда көн саен килөм. Палатадагылар өйрәнеп беттеләр инде. Килгәнне көтеп торалар. Саша гына тәрәзә янына килә алмый. Ләкин барыбер ишетә бит ул. Сөйләшә дә.

— Рифкать, Сашаның тәрәзәдән сикерүе дөресме?— дип кыяр-кыймас кына сорады Тәлгать. (Ул бүтән мәктәптә укый, шуңа күрә бу турыда кешедән ишетеп кенә белә иде).

— Сикергән шул.

— Сикереп дөрес тә иткән,— дип чәчрәп сүзгә кушылды Әнфисә.— Егет кеше андый чакта ике уйлап торырга тиеш түгел.

— Кызлар бит аңа яхшылык эшләргә теләгәннәр. Азрак акылга утыртмакчы булганнар.— Илдус, кызларны яклавына үзе дә оялып, башын аска иде.

— Дәрестән соң алып калып самосуд оештырганчы, кызларга башта эшнең нидә икәнен, Сашаның нигә начар укый башлаганын ачыкларга кирәк иде. Ә алар тотканнар да тәрбия эшенә тотынганнар.— Рифкать ачудан гитара кылларына берьюлы биш бармагы белән сугып куйды. Гитара ыңгырашты да тынды, Рифкатьнең дә ачуы басылды.

— Фу, кызларның шул инде аларның,— дип саргылт кашларын җыерып куйды Әнфисә.— Алга-артка карап тормыйлар, турыга яралар. Ә Сашаның начар укый башлавының үз сәбәбе булган. Әйбәт кенә укып килгән егет тик торганда «ике»ле ала башламый бит инде. Димәк, я ул берәр начар компаниягә ияргән, я аның өендә бер-бер хәл булган. Өйләрендә гауга купкан аларның, әтисе белән әнисе аерылышуга кадәр барып җиткән. Билгеле инде, шундый чакта кемнең кәефе булсын да, кемнең дәрес әзерләп утырасы килсен. Малаебыз көннәр буе, кичләр буе урамда каңгырып йөри икән. Шул чакта кызларга аның күңелен юатырга, үзләре арасына гына алырга иде дә бит, ә алар тотканнар да самосуд оештырганнар.

— Ул әйткән бит, кисәткән бит,— дип Әнфисәне бүлдерде Рифкать.— Хәтта ялынган да бугай әле. Кызлар, чыгарыгыз, чыгармасагыз, тәрәзәдән сикерәм, дигән. «Хөрәсән судьялар» көлгән генә. Сикерә, имеш, каян килгән Котовский. Ә ул тоткан да ачык тәрәзәдән урамга сикергән...

— Тсс...— Әнфисә бармагын авызына куйды.— Ачык тәрәзә шуларныкы бугай, ишетмәсен.

Тәрәзә төбенә килеп җитүгә, Рифкать, сигнал биргәндәй, гитараның иң нечкә кылына чиертеп алды. Шунда ук тәрәзәдән берьюлы берничә баш күренде.

— Килде, безнең гитарист килде! — дип шаулашты алар.— О-о, бүген тулы бер ансамбль болар! Саша, дустың килде.

— Безнең парашютистның хәлләре ничек?— дип кычкырды Рифкать.— Үпкәләгән мәллә, тәрәзә янына да килми.

Палата эченнән Сашаның тоныкк кына тавышы ишетелде:

— Исем китте, сез килде дип, сикереп тордым, ди монда. Рәхәтләнеп ятам әле менә.

— Сикерүен сикергәнсең, ә парашют алырга онытkансың,—дип шаяртты Әнфисә.

— Соң син морфлотка китәм дигән идең бит, нишләп десантныйга язылырга булдың әле?— Рифкать шулай диде дә, ник әйткәненә үке-

неп, башын аска иде. «Кая инде хәзер аңа морфлот? Сынган умыртка сөяге белән, адәм рәтенә кереп, тигез җирдән атлап йөри алса да әйбәт булыр әле. Юкка әйттем, морфлот, дип авыз суларын корыта иде бит егет. Иң авырткан җиренә кагылдым», — дип уйлады Рифкать.

— Мин бит үземне, океан лайнерында йөзәм, дип уйладым. Корабка «дошман» басып кергәч, тоттым да суга сикердем. Ләкин мин йөзәсе диңгез өстен асфальтлап өлгергәннәр икән.

— Әй, Рифкатьме әле исемең? Ташлагыз әле юк сүз сөйләнүегезне. Сашагыз нык егет, бирешә торганнардан түгел, терелер, капитан гына түгел, контр-адмирал булыр әле.

— Контр булдым инде, адмирал буласы гына калды.

— Әй, җырлап күрсәт әле,— дип өзелгән сүзен ялгап китте тәрәзәдәге агай.— Мат якасына ул авыру-сырхауларның. Шул гитараңда бер җыру сузып җибәр! Дару түгел, җыру терелтә адәм баласын. И-их, гармунда уйнасаң икән син. Бу шалтыравыгың күңелне кытыклап кына уза бит ул. Ә гармун бар хәсрәт-кайгыңны актарып чыгара.— Агай: «И-их»,— дип озын итеп сузып куйды да буй-буй больница күлмәгенең якасын ачып җибәрде.— И-их, без яшь чакта... Әйдә, Рифкать энем, чиртеп җибәр әле шул нечкә муенлы нәрсәңне!

Рифкать, гитара кылларын барлап чыкты, аннары авызын тутырып елмайды, тыңлагыз дигәндәй, тәрәзәгә күтәрелеп карады. Тәрәзә төбенә сөялгән агайның ачык якасыннан бинт белән уралган күкрәге агарып күренә, уң кулы, гипслап, муенына асылып куелган: күкрәгенә ак биләүле сабый кысып тоткан, диярсең.

— Ә син үзең турында сөйлим дигән идең бит. Ничек больницага эләгүең турында. Сөйләмичә — уйнау юк.

Рифкать, чынлап әйтәм дигәндәй, гитараны аркасына ук этәреп куйды.

— Нәрсәсен сөйлисең аның?

— Сөйлә инде!

— Сөйлә, абый!

— Ялындырма инде!

Егетләр, кызлар, берсен-берсе бүлеп, агайны кыстый-үгетли башладылар.

— Муеныгызны сузып тормагыз, әнә теге каралты өстенә менегез. Аннан палата эче дә уч төбендәге шикелле күренергә тиеш. «Парашютист»ны да күрерсез.

— Әй, шуңа да башыбыз җитмәгән. Киттек, егетләр!

Әнфисә артыннан тәрәзә каршында гына җиткерелә башлаган каралтының караңгы баскычы буйлап менеп киттеләр.

— Берни күренми бит монда.

— Аякны сындыра яздым.

— Әнфисә, яулыгыңны чиш әле, сары чәчеңнән яктылык төшмәсме?

Шулай көлешә-көлешә өскә менеп җиттеләр дә, тәрәзә каршына аякларын асылындырып, тезелешеп утырдылар.

Чыннан да, палата эче моннан аермачык күренә икән. Әнә аларга карап, Саша елмайды, кузгалырга иткәндәй, аз гына, акрын гына талпынды да кебек.

— Сез монда алтау икән бит,— дип, гаҗәпләнүдән сызгырып куйды Рифкать.— Тора алмыйлармыни?

— Тора алган кешене бу палатага кертмиләр шул. Менә мине инде берничә көннән күчерәбез, диләр. Ремонтлап бетердек, слесарный мастерскойдан чыксаң да була, диләр. Дару исе иснәп тә туйдым, тизрәк кайтырга иде инде. Тракторым да көтәдер.

— Сөйлә инде...

— Нәрсәсен сөйлисең инде аның. Сөйлә дә сөйлә, диләр. Район газетасыннан да Рәхим атлы олы башлы корреспондент килеп, ярты

көн төпченеп утырды. Сорамаган нәрсә калдырмады, хиде бабама җитте, кабер ташларындагы язуларга кадәр сорашты. Гәзиттә язып чыгарган. «Герой» дигән булган. Һе-ем, агайне, кинода күргән бар, герой андый булмый ул. Трактор нәрсә ул? Тимер өеме. Тимер өчен яшәми бит кеше. Үзе өчен яши, гаиләсе, дус-ише өчен яши, кеше өчен яши. Тракторга ни ана, коткардың ни дә, коткармадың ни. Җаны юк бит аның, берни аңламый ул.

— Ә үзең, тракторым көтәдер, дисең.

Башка вакытта сүзгә катышмый, ни әйтсәң дә, «әйе», «әйе», дип баш кагып кына торган Илдуска бу юлы кыюлык каян килгән диген?

— Көтә, дип... ияләштем инде мин аңа, егетләр. Баштарак йоклый алмый идем, төшләремә керә иде.

— Ничек коткардың соң син аны?

— Былтыр җәй бик коры килде бит. Инешләр корып бетте, чишмә хәтле генә калды. Янгын-мазар чыкса, чиләк тутырып алырлык та су юк. Миңа бульдозер белән буа буарга куштылар. Көне буе эшләдем дә, тракторны буа каршында калдырып, өйгә кайттым. Ашап-эчеп йокларга гына яткан идем: «Ут чыккан, ут чыккан! Галимҗанның тракторы яна!»— дип, урам буйлап бер малай йөгереп узды. Аннан безнең капканы дөбердәтә башладылар. Чалбарны гына эләктердем дә чыгып чаптым. Килеп җитсәм, тракторымны арттан ялкын ураган. Җирдә яткан майлы бишмәтне алдым да утны кыйнарга тотындым. Ә ул сүнәргә уйламый, киресенчә, суккан саен күпереп-күпереп китә. Бишмәтне ыргыттым да пускачка барып тотындым. Пускач бавы уралып беткән. Димәк, бала-чага шаярган. Аны чишеп, рәтләп бетергәнче ут кабинага ук керде. Болай булса, ягулык багы кызып шартлаячак, аннары инде тракторың вәссәләм, диген. Бер тарттым пускачны, ике тарттым — кабынды бит, җаным, хуҗасын таныды. Калганын инде үзем дә юньләп хәтерләмим. Ут чорнаган кабинага атылып кердем дә арткы скоростька салдым. Тракторны көндез буган буага алып кереп киттем. Шуннан соң уянып китсәм, больницада ятам.

— Ә янып үлгән булсаң,— диде Тәлгать.

— Андый чакта алдын-артын уйлап торасыңмыни инде аның...

— Үзең, тракторның җаны бармыни, нәрсә аңлый ул, дисең, үзең шуның өчен утка керәсең. Аңлашылмый.— Рифкать, аптыраган кыяфәт белән, кулларын җәйде.

— Җаны юк, дип... Аның җаны булмаса, минеке бар бит. Җаны булган кеше ничәмә-ничә ел эшләгән тракторын күрәләтә утка саламыни? Аннары, егетләр, нигә шул бер сүзгә бәйләндегез әле. Җаны юк та җаны юк. Хатын-кыз шикелле.— Галимҗан агайның тавышы усал булып, үпкәле булып калтырап чыга башлады.— Менә шул җансыз трактор үстереп биргән икмәкне бөгәсез бит әле. Җансыз дип тормыйсыз.

«Кем тигән соң аңа?» «Нишләп яна башлаган?»— дип күпме генә сорашырга, аның телен ачарга теләсәләр дә, агай сүзгә кушылып китмәде. «Аптыратмагыз әле, белмим»,— диде дә больница коймасы артындагы иген басуына карап тора бирде. Шулчак Рифкать эчтән генә көлемсерәде дә гитарасын кулга алды.

Кара да гына урман, караңгы төн...
Яхшы трактор кирәк үтәргә...

Агай, бөтен палатаны яңгыратып көлеп җибәрде.

— Их, шельмалар, их башы беткереләре. Хәзерге яшьләр уен-көлке өчен генә яралгандыр алар. «Яхшы трактор кирәк»,— дисезме? Менә шул яхшы трактор янына сезнең кебек әзмәвер егетләр дә кирәк бит. Кая инде сезгә, фанер такта чиртеп, урамда трай тибеп йөрүдән

башканы белмисез. Белмим инде, белмим, кая бара бу дөньялар, үскәч кем булырсыз...

— Иртәгә өчен ишәк кайгырткан,— дип, илтифатсыз гына әйтте Сережа.

— Ишәк тә кайгырган, ди. Ә син, иртәгәнне уйламагач, ишәктән дә кайтыш буласың инде.

— Әй, син анда, картлач, чамалабрак сөйлә!— дип кызып китте Сережа.— Юкса, монда...

— Туктале, әтәчләнмә әле!— Рифкать Сережаның терсәгеннән тотты,— Ә син, агай, кайгырма, кешедән ким булмабыз.— Шулай диде дә, гитарада җитез генә бер көй уйный башлады.

Утларга да бер керербез әле,
Без менәрбез әле күкләргә,
Солдат булу безгә кыен түгел,
Риза булса кызлар көтәргә.

— Шулай бит, Саша,— дип кычкырды Рифкать һәм җырын ялгап китте.

Без кайтырбыз ныгып, ирләр булып,
Ике елы бик тиз үтәр дә.
Уттан чыгар солдат мәхәббәте...
Риза булса, кызлар көтәргә.

— Булдырасыз, егетләр, юкка тел тидердем бугай сезгә,— диде агай, җыр тәмамлануга.— Колакка кергән җыр түгел, яңадыр инде. Безнең бабай мәрхүм әйтә торган иде: «Солдатка бармаган кеше гомер буе малай булып кала, ир була алмый», — ди торган иде. Хак булган шул сүзләре, әнә, безнең авылныкылар, киткәндә, песи кебек юаш кына малайлар иде, арыслан булып кайттылар. Ә армиягә бармаганнарның күбесе кибет төбе саклап утыра. Тегеләрнең дә үтте ике ел гомере, боларның да. И-их!..

— Йөриләр шунда урам буйлап киләп сарып. Билләренә кадәр чәч үстергәннәр, җитмәсә. Кызмы, егетме икәннәрен дә белерлек түгел. Менә шулар арасыннан чыга инде бандитлар! Барыгыз, барыгыз, авыру кеше җанына тоз салып йөрмәгез! Болай да шау-шу җитәрлек монда...

Берсе-берсе икешәр потлы җәен балыгы хәтле кулларын тәрәзә тупсасына җәеп салган хатынның ачулы сүзләрен ишеткәч барысы да тын калдылар. Тирә-юнь кинәт кенә салкынаеп, шыксызланып киткәндәй булды. Бу үле тынлыкка хатын үзе дә аптырап калды бугай: авыз эченнән нидер мыгырданды да тәрәзәне шапылдатып ябып куйды. Тавыштан сискәнеп уянган тополь яфраклары берсен-берсе уздыра-уздыра кул чаба башладылар.

— Әй, егетләр, кызлар! Тагын җырлагыз әле!

— Әйдә, егет, өздер әле!

Менә кызык, больница тәрәзәләре барысы да диярлек ачык. Авырулар кул болгыйлар, җырла-җырла, дип кычкыралар.

— Әйдә, алайса, үзебезнең җырны җырлыйбызмы әллә?— диде Рифкать.

Озатып вокзаллар каршында
Маңгайдан үптеләр аналар.
Тузанлы юллардан үттеләр
Дөньяны күрмәгән балалар.

— Үзебез Саша янына килдек, үзебез аны бөтенләй онyттык,— диде җыр тәмамлангач Рөстәм.

— Әйе шул.

— Юк, юк, мин сезне тыңлап ятам бит. Сезнең белән сөйләшеп туйган инде, ә миңа җыр тыңлау рәхәт.

Рифкать сизеп тора: Саша бүген кирле-мырлырак сөйләшә. Үзе янына шушы кадәр кеше килүенә, дуслары килүенә эчтән генә сөенә иде ул. Ләкин үзенең шулай хәрәкәтсез, хәлсез ятуын аларга күрсәтәсе килми, бигрәк тә кызлар алдында уңайсыз аңа. Рифкать үзе генә килгәндә сәгатьләр буе сөйләшә иде бит. Ә бүген гел кирегә сөрә. Юк, аларга түгел, үзенә ачуы килгән аның.

— Ярый, алайса, без киттек,— диде Рифкать.

— Сау бул, Саша!

— Тизрәк терел.

— Сау бул, агай!

— Тракторыңа бездән сәлам әйт.

Егетләр, караңгы баскычтан капшана-капшана төшеп, больница капкасына таба атладылар. Алар артыннан: «Тагын килегез!»— дип кычкырып калдылар.

— Егет кеше гармун уйный белергә тиеш. Гармун белән килегез!

Арада тракторчы агайның тавышы аерылып тора иде.

Тәрәзәләр берәм-берәм ябылды, палаталарда утлар сүнде. Көләч йөзле кеше шикелле балкып торган больница кинәт төсен югалтты, караңгыланып калды. Әйтерсең, ул моңа кадәр уен-көлке, музыка-җыр белән күңел юатып, онытылып торган да менә хәзер аның эчендә бөтен әгъзалары сызлый башлаган. «Ә минем бер тапкыр да больницада ятканым юк,— дип уйлады Рифкать.— Саша ничек түзә икән? Аңа кузгалырга да ярамый бит. Хәзер үкенәдер дә бит. Аның урынында булсам, мин нишләр идем икән?»

Урамга чыккач, саубуллаштылар да, ике төркемгә бүленеп, ике якка китеп бардылар.

## 7

Рифкать әкрен генә гитарасын чиертә. Тик берсе дә җыр башламый. Әллә инде шаярып-көлеп туйганнар, әллә төнге шәһәр тынлыгын бозарга кыймыйлар — сүзсез генә атлыйлар да атлыйлар.

— Сашаның хәле шәптән түгел,— дип үзалдына әйтеп куйды Илдус.

Аңа җавап бирүче булмады. Бераз баргач, Әнфисә кинәт кенә гитара кылларына уч төбе белән басты.

— Тукта әле, Рифкать!— Больница янында гел басынкыланып калган иде, ә хәзер аның тавышында чаялык сизелеп куйды.— Безнең класста Саша турында һаман имеш-мимеш йөри бит. Берәүләр аны яклый, дөрес сикергән ди, кызларны гаепли, ә кайберәүләр исә — киресенчә...

Галия Әнфисәгә кушылды:

— Тәнәфес саен бөтен класс шуның турында чыш-пыш килә. Кемгә ышанырга, кемне якларга да белгән юк.

— Класста җыелыш җыеп, шуны хәл итәргә иде,— диде Әнфисә.

— Саша да инде... — дип куйды Илдус.

— Нәрсә Саша, Сашага нәрсә булган?— Рифкать сабыр гына Илдуска сүз ташлады.

— Нәрсә булган? Юләрлек эшләгән. Кызлар ачуланган саен тәрәзәдән сикерә башласалар, дөньяда исән кеше калмас иде.

— Аңламыйсың син, Илдус,— дип, Әнфисә Рифкатьне яклады.— Аңламыйсың. Эш монда кызлар ачулануда гына түгел, эш — принципта.

— Принципта, имеш. Принцип дип тәрәзәдән сикерәләрме инде, я?

— Синеңчә нишләргә тиеш иде соң ул?— диде Рифкать.

— Анысын белмим. Ярый, сикерде ди. Шуның белән нәрсә исбат итте инде? Үзенең юләрлегенме?

Рифкать, арттырып җибәрәсең дигәндәй, ачу белән Илдуска карады.

— Менә син, Илдус, аның урынында булсаң нишләр идең?

— Нигә миңа бәйләнәсез әле? Нишләр идем. Бер нәрсә дә эшләмәс идем. Партага утырыр идем дә кызлар акылга килгәнче кыймшанмас идем.

— Ә алар акылга килмәсә? Синнән көлсә, сәгать буе акыл өйрәтеп торса?

— Белмим лә!.. Мәгънәсезгә тәрәзәдән сикерергә, кем дип белдең соң мине? Баш ике түгел бит. Әнә, теге агай шикелле тракторың янып, шуны коткарырга дип утка керсәң — башка эш. Тракторы да исән, үзе дә исән, әле газетада да «герой» дип язып чыкканнар. Ә Саша янына синнән башка килеп караган кеше дә юк. Менә үзең кара инде: ул тәрәзәдән сикереп егетлек күрсәтмәк булган. Ә кызлар бер-ике көн мыштым гына йөрделәр дә тагын элекке хәлләренә кайттылар. Дөнья үзгәрдеме — юк, тамчы да үзгәрмәде. Ә ул инвалид булып калса?..

— Синең өчен үзгәрмәсә, минем өчен үзгәрде,— диде теш аралый гына Рифкать һәм гитарасын кулына алды.

— Нәрсә дисең?

Ләкин Рифкать онытылып җырлый иде инде:

Утларга да бер керербез әле,
Без менәрбез әле күкләргә.
Солдат булу безгә кыен түгел,
Риза булса кызлар көтәргә.

Аны Әнфисә белән Галия күтәреп алды. Илдус арткарак калды, җырга кушылмады.

Трамвай юлын аркылы чыгып, Рифкатьләр өенә таба борылгач, арттан аяк тавышлары ишетелде.

— Рифкать, йөгер! Кызлар, качыгыз!

Илдус үзе кычкыра, үзе бар көченә чаба иде. Аның артыннан олы-олы атлап озын буйлы, тузган сары чәчле егет куып килә. Арттан тагын дүртәү йөгерә. Озын егет Илдусны куып җитте дә кулын күтәреп кизәнде.

— Мә гитараны, Әнфисә!

Рифкать алар янына ыргылды, чабып килгән уңайга озын егетнең эченә китереп сукты, тегесе тротуарга барып төште, яткан килеш, ыңгырашып кычкырды:

— Изегез, егетләр! Гитарасын алыгыз! Бүтән урамга чыкмаслык итегез!— һәм ул, бер кулы белән эчен тоткан килеш, икенче кулы белән тротуарда яткан Илдусны дөмбәсләргә тотынды.

Рифкать аның кулын артка каерып китерде дә бар көченә этеп җибәрде, егет, сузылып, кырыйдагы агачлар арасына барып төште. Ләкин шул арада дүрт егет аны уратып алган иде инде. Ул Илдусны җирдән күтәрде дә, сул кулы белән аны кочаклап, уң кулын селки башлады. Егетләрнең берсе Әнфисә кулыннан гитараны тартып алды. Ул чәрелдәп кычкырды, аңа Галия кушылды. Шул чак Рифкатьнең йөзенә китереп суктылар. Аның күз аллары кинәт яктырып китте, һавада утлы күбәләкләр оча башлады. Ул чайкалып куйды, ләкин егылмады. Аңа тагын суктылар, тагын. Егылмаска! Егылмаска! — дип кабатлады ул эчтән. — Егылсаң, таптыйлар, изәләр. Менә кемдер фонарь белән күзләренә төбәгәндәй булды. Хәзер тагын сугалар, — дип уйлады ул. Ләкин күзләрен ачса, каршыда фараларын яктырткан милиция машинасы тора, ә теге егетләр куак арасыннан чаба иде.

— Бандитлар! — диде ул һәм авызына тулган ачы канны җиргә төкерде.

Менә хәзер Рифкать урында ята. Шул егетләргә бирешеп торганга эчендә ачу кайный. Әнисе аның хәлен сизсә дә, сизмәгәнгә салыша: «Арыгансыңдыр, улым, ял ит. Бигрәкләр озак йөрисез шул», — дип сөйләнә-сөйләнә алдына чәй китереп куя. Рифкать әнисенә елмайгандай итә дә тешләрен шытырдатып кыса. Кинәт түзеп булмаслык булып башы авыртырга тотына. Әйтерсең, кемдер баш миенә кадак кага, каккан саен кадагы эчкәрәк керә. «Тук, тук, тук-тук» килә чүкеч.

— Хәзер, хәзер, — ди әнисе. Әнисе, нишләптер, русча сөйләшә.

## 8

Менә баш миенә кергән кадак әкрен-әкрен эри, менә ул бөтенләй сизелми дә. Рифкать күзләрен ача. Каршыда елмаеп врач басып тора.

— Йоклыйсыңмы, әллә болай уйланып кына ятасыңмы? — диде врач.

Рифкать сүз әйтмәк булган иде, сүз чыкмады, иреннәре кузгалмады. Врач апа, хәлен аңлагандай, ияген кагып куйды.

— Хәзер, хәзер, — диде дә сулы мамык белән аның иреннәрен чылатты, маңгаена сулы чүпрәк куйды.

— Уйладым гына...

Рифкать сүзләренең шулай көчсез, ишетелер-ишетелмәс кенә чыгуына гаҗәпләнде.

— Артык уйламаска тырыш. Башыңа ял кирәк синең. Түшәмгә кара да тик кенә ят.

— Ә мин уйламыйча булдыра алмыйм. Уйламаска тырышам, булдыра алмыйм, уйлар үзләре килә.

— Ярый, ярый, — дип, врач апа аның иреннәрен тагын сулы мамык белән сыпырды. — Алайса, яхшы нәрсәләр турында гына уйларга тырыш.

— Мин шулай итәм дә. — Рифкать, врачның күңеле булсын дип, шактый вакыт түшәмгә карап ятты. Юк, болай күңелгә әллә нинди уйлар килә. «Округ госпиталеннән хирург чакырырлык булгач, димәк, хәлем шәптән түгел инде. Операция ясарга кирәк диләр».

Ул элек уколдан да курка иде, качып йөри иде. Ә менә хәзер — операция. Аннан исән-сау чыгармы? Баш бит. Уң кулы да исән түгел. Әтисенең дә кулында бармаклары юк. Шахтада өздергән. Ә Рифкатьнең бармак кына түгел бит. Гитарада сул кул белән уйнарга өйрәнергә туры килер. Рифкать тешләрен шыгырдатты, йөзен чытты.

— Авыртамы, улым, әллә тагын укол кадыйкмы? — диде врач.

— Кирәк түгел... Болай гына ул... — Аның сүзләре өзек-өзек чыга иде. — ... Өйгә хәбәр итмәдегезме?.. Кирәк түгел... Әнкәй белмәсен... Миңа хат килмәде микән?

— Синең янга бер солдат килгән иде. Кертмәдек, борчымасын дидек. Якташың бугай.

— Илдусмы?

— Әйе, шулай диде кебек. Көтте-көтте дә кертмәгәч китте.

— Кертәсегез калган. Хат алып килгәндер.

— Синең янга килүчеләрнең исәбе-хисабы юк бит. Барысына да рөхсәт бирсәң. Рифкать Миргазизовка кан кирәк дигәч тә бөтен полклары белән ябырылдылар. Арадан унберен сайлап алдык. Кан группалары туры килгәннәрен. Әй, сөенделәр, бәгырьләрем! Әнә, ишетәсеңме, ишек төбендә шулар шаулаша инде. Керергә даулыйлар.

— Нигә кертмисез соң?

— Ярамый.

— Бер минутка гына. — Рифкать, күзләрен мөлдерәтеп, врачка карады. — Бер генә минутка...

— Хәлең авыр бит... — диде доктор һәм каршындагы инәлүле күзләрне күргәч йомшады. — Ләкин озакка түгел. Үзең сөйләшмәскә тырыш. Тыңлап кына ят. Сөйләшкәндә башың селкенә, ярaң кузгала.

Солдатлар, тавыш чыгармыйча гына басарга тырышып, палата түренә уздылар. Зәңгәр береткаларын салып кулларына тотканнар.

— Сәлам, Рифкать!

— Тереләбезме?

— Синең янга якын да китермиләр хәзер.

— Биш минутка гына керттеләр.

— Илдус киттеме? — диде Рифкать.

— Әле генә китте. Капканы да чыкмагандыр. Чакырыйммы? — дип ашыга-ашыга тезеп китте таныш булмаган солдат һәм, җавап та көтмичә, шап-шоп атлап чыгып йөгерде. Врач, йөзен чытып, аның артыннан карап калды.

Солдатлар сүз башларга кыймый тора. Мондый вакытта ни әйтергә икәнен белми аптырый алар: юатсаң, Рифкать бала-чага түгел, кызганырга килгәннәр дип аңлар, үпкәләр, уен-көлке сөйләсәң дә урыны түгел.

— Бүген бөтен полкны җыйдылар. Генерал синең турыда сөйләде, — дип, ниһаять, сүз башлады кече сержант. Рифкать аны аз гына төсмерли, бер-ике тапкыр очрашканнары да бар. Володя исемле бугай, әйе, Володя, Владимир, Владимир Чигарев.

Рифкать солдатларга карап ята. Күбесе аңа таныш та түгел. Аның уйларын белгәндәй, Владимир исемнәрен атый башлады.

— Син егетләрне белмисеңдер дә әле. Ефрейтор Роман Шильтут, рядовойлар Виктор Бурка, Виктор Желятин, Николай Меблев, Владимир Богданов, Константин Абашкин, Владимир Ярмошевич, Михаил Бахтеев...

Сержант исемнәрен атауга, солдатлар бер адым алга атлыйлар. Әйтерсең, Рифкать — аларның командирлары, әйтерсең, ул строй алдына басып («һи-и... басып...» — дип уйлады эчтән.) солдатларын барлый. Ә алар уңайсызланып тагын тын калдылар.

— Стройда тормыйсыз бит, утырыгыз, — диде врач. Алар, гаеп эш эшләгән кебек, бөтенесе берьюлы кызарып чыктылар, бер урында таптанып тордылар да, каршыдагы караватка тезелешеп утырдылар. Утыргач, кинәт кенә барысының да теле ачылды, әле генә сөрәеп басып торган солдатлар бер мизгелдә җор сүзле егетләргә әйләнде.

— Рифкать булмаса, канымның кайсы группа икәнен белмичә үләсе икәнмен, — дип Виктормы, Володямы сүзне шундук уенга борды. Рифкатьнең уйлары чуалып, солдатларның исемнәре хәтерендә калмаган иде.

Сүзгә керпенеке төсле тырпайган җете кара чәчле егет (Роман бугай) кушылды:

— Миңа әйтәләр, ике йөз грамм алабыз диләр. Хет чиләге белән алыгыз, мин әйтәм. Юаш та юаш, дип теңкәгә тияләр иде, менә бер кансыз булып карыйм әле.

— Егетләр, каны бер группа булган кешеләрне бер маймылдан яралган диләр, дөрес микән? — Николай, бик мөһим сүз сөйләгәндәй, йөзенә җитди кыяфәт кертте.

— Димәк, без барыбыз да бертуган булып чыгабыз.

— Әй, моңа кадәр белми йөргәнбез.

— Ярый әле әйттең, рәхмәт инде.

— Әйтәм бит Коля үзенең бабасына охшаган, дип. Кара, кара, тач маймыл инде.

Солдатлар, палатаны күтәрерлек итеп көлеп җибәрделәр, көлүгә Рифкать кенә кушыла алмады. Егетләр уен-көлке белән аның авыру икәнен дә онытып җибәрделәр.

Врач:

— Тынычрак, тынычрак, кайда икәнегезне онытмагыз, — дип кисәткәч кенә, кинәт аңга килгәндәй, өнсез калдылар.

— Рифкать, — дип, шактый вакыт узгач кына Володя аңа эндәште. — Син чыгарган газета һаман казармада эленеп тора әле. Рәсемнәрне бигрәк шәп ясагансың.

— Ротада бүген синең турыда чыккан хәрби листокны командир кычкырып укыды.

— Часть музееннан прапорщик фотоңны сорап килгән иде. Полковник кушкан.

Рифкатькә алар барысы да бик еракта, томан аша күренгән кебек, ә тавышлары күрше бүлмәдән ишетелгән шикелле.

— Рифкать! Якташ!

Палатадагы томан тора-бара сыегайды һәм каршыда Илдус пәйда булды. Үзе мыш-мыш килә, маңгаена тир бөртекләре тезелгән. Әллә инде тир бөртекләреннән, әллә елаудан күзләре дә юешләнгән.

— Мин анда бөтенесе белән талашып беттем инде, — дип өзек-өзек сулыш ала-ала тезеп китте ул. Үзе иреннәрен җыя алмый елмая. Дустының нинди хәлдә ятуын да онытып, ниһаять, больницага Рифкать янына керә алуына сөенеп бетә алмый. Менә ул бераз тынычланды, сулышы да тигезләнде, караватт кырыендагы урындыкка утырды.

— Солдатлар! Вакытыгыз бетте, саубуллашыгыз, — диде шул чак врач.

Илдус гаҗәпләнү һәм инәлү катыш күз карашлары белән ак халатлы ханымга текәлде.

— Сезгә чыгарга вакыт, ә якташы калсын.

Егетләр теләр-теләмәс кенә торып бастылар, тавыш чыгарырга курыккандай, пышылдап кына саубуллашып, ишеккә таба чигенделәр. Барысы да чыгып беткәч ишек ачылды, аннан «маймыл» Коляның башы күренде.

— Без хәзер бертуган, Рифкать! Онытма! — дип кычкырды ул.

Илдус Рифкатьнең башын, кулларын, бөтен гәүдәсен капшап чыкты.

— Исән, бөтен җиреңдә исән!

Рифкать, менә, кара, дигәндәй, уң кулын кыймшатып куйды.

— Кул гына — чепуха. Анысы төзәлер. Хәзер әллә нинди протезлар ясыйлар, чын кулдан аерырлык түгел.

Рифкатькә аның сүзләрен тыңлау рәхәт иде. Туган шәһәре, дуслары исенә төште.

— Миңа хатлар килмәгәнме?

— Юк. Килер әле! Язалардыр.

Рифкать кинәт кенә моңсуланып калды, беркавымга хәтта янында Илдус барын да онытып, уйга чумды.

Бу арада нишләп бер хат та килми соң әле аңа? Әллә авырып киттеләрме? Әллә вакытлары юкмы? Аның өйгә язганына шактый булды бит инде. Нинләр язган иде соң әле ул? Гадәттәгечә, «Исәнмесез минем өчен кадерле булган әнкәй, әткәй, Әнфисә, Азат! — дип башлаган иде. — Солдат сәламе белән сезгә гвардия рядовое Рифкать Миргазизов яза.

Мин яхшы гына яшим. Яшим, дигәч тә, сез минем ничек яшәгәнне күз алдына да китерә алмыйсыздыр. Өйдәгечә иркәләнеп ятулар, нәрсә теләсәң, шуны ашаулар, кая теләсәң, шунда барулар турында хыяллана да алмыйсың хәзер. Һәр нәрсә режим буенча, һәр нәрсә приказ белән эшләнә монда. Ләкин сез анда исән-имин яшәсен өчен, илебез

тынычлыгы өчен хезмәт итүеңне уйлыйсың да, күңелең горурлык хисе белән тула. Җир җимертеп яшәр көннәр алда әле. Тормыш башлана гына безнең. Менә кадәр күп нәрсәне аңламаганмын икән. Иң беренче тапкыр самолеттан сикергәндә генә дөньяның нинди матур икәнен күрдем, яшәү мәгънәсен аңлый башладым бугай. Шул чак бөтен кешеләргә ишетерлек итеп: «ЯШИСЕ КИЛӘ!» — дип кычкырырдай булдым.

Ярый, мин артык нечкә күңелләләнеп киттем ахрысы. Шулай да бераз солдат тормышы турында да язып үтәм. Кичә безнең монда бәйрәм булды. 800 метр биеклектән тагын парашютта сикердек. Самолеттан сикерүгә күңел шатлык белән тулды, бәжраны тарткан идем, парашют ачылды да китте. Җиргә төшкәч, парашютны төрдек тә җыелу урынына киттек. Парашютлар бик шәп безнең, күрсәгез шаккатыр идегез.

Безнең ротада Татарстаннан — биш кеше. Димәк, сагынган чакта күңел юатырга якташлар бар. Бөтенесе әйбәт, тик менә вакыт кына җитми. Күптән түгел өч километрга кросс белән йөгердек. Полкта дүртенче урынны алдым. Беренче өч урынны алганнар отпускага өйгә кайтып киттеләр. Ә мин биш секундка калыштым. Ярар, барысы да алда әле.

Тәмәкене ташладым. Бөтен көчне спортка бирәм. Десант гаскәрләре иң яхшы, үрнәк гаскәр бит ул. Десантник булу бик җиңел түгел икән. Җиде кат тирләр чыга. Хат язарга да вакыт тими. Менә бу хатны өченче көн язам инде. Язарга дип кенә утырам, тагын чыгып чабарга туры килә. Тиздән бездә бик җитди хәрби өйрәнүләр була. Шуңа әзерләнәбез.

Хәзер әле мин «салага» гына, бер елдан «фазан» булам, ә аннары— «дембел». Шулай хыялланып ятам.

Ярый, сау булыгыз! Барысына, барысына миннән күп сәлам тапшырыгыз.

Рифкать».

Ул, хат азагында ясаган рәсемен күз алдына китереп, көлемсерәде. Үзен киң җилкәле, кабарып торган мускуллы итеп ясаган иде. Башта — кырын салынган берет, авыз — ерык. Көлкеле рәсемнәр ясарга ярата ул. Мәктәптә дә стена газетасын ул бизәде, частьта да гел ул ясый иде. Аның рәсемнәрен карагач шаркылдап көләләр иде. Хәзер көлкеле рәсемнәр ясый алмас инде.

Хәзер аның елмаясы да, көләсе дә килми. Узар микән бу? Аның да күңеле күтәрелер микән? Моңа кадәр гомере уен-көлке белән генә үткән икән... Гитара, магнитофон, дуслар, шаяру, көлешү. Бер урынга утырып, озаклап уйланган чаклары да сирәк иде. Һаман вакыт җитмәде. Гомер буе сау-сәламәт булыр, шулай уйнап-көлеп кенә яшәр кебек иде. Карасаң... Хәзер аның кемгә кирәге булыр икән? Галиягәме? Әлфиягәме? Кулсыз кеше белән нишләсен алар? Соңгы арада хатлары да юк. Больницадан чыккач бик озын итеп, бөтенесен-бөтенесен әйтеп хат язарга кирәк. Һе-е, — диде ул, үз уйларыннан үзе көлеп. — Кулсыз язарсың инде хат. Нинди хат ди әле ул? Кулсыз солдат була ди мени? Терелү белән кайтарып җибәрәләр инде аны: И-их!

— Нәрсә, нәрсә?

Илдус, Рифкатьнең хәрәкәтсез күз карашына, акрын гына кыймылдаган иреннәренә карап утыра, сүз дәшәргә дә кыймый. Ул бары тик: «И-их!» — дигән уфтану авазын гына ишетте.

— Их, монда гитара булсын иде, ә! — дип, тавышын күтәрә төшеп, күңеллерәк булырга тырышып башлап китте ул. — Хәтерлисеңме, Түбән Камада больница тәрәзәсе каршында уйнап торган идек.

Рифкать, «әйе», дигәнне аңлатып, керфек какты.

— Саша тәки гел кеше булды бит. Әйтергә онытып торам: өченчекөн өйдән хат алдым. Саша диңгез училищесына кергән. Астраханьнан бер борылып кайткан булган. Тагын барып Одессага кергән. Кап-кара моряк киеме киеп шәһәр урамын көнгә әллә ничә урый ди. Адмирал булганмыни!

— Саша егет ул. Адмирал да булыр.

— Ул умыртка сөяге сындырып та кеше булды. Синең нәрсә, кул да баш кына.

— Баш кына, — дип мыскыллы елмайды Рифкать. Бер хәрәкәтсез ятса да, ул тәнендә көч кайнап торганын сизә. Ярасы кузгалган саен бөтен мускуллары җәягә тарттыргандай була. Ә менә уң кулы белән башы берөзлексез сызлый да сызлый. Кул вакыт-вакыт онытылып та тора, ә менә баш авыртуы азга гына да туктамый, укол кадагач, суга тыккан утлы кисәү кебек сүрелеп ала да беркавымнан тагын ялкынланып яна башлый. Әйтерсең, нииндидер утлы өермә баш капкачы эченә кереп оялаган да дулый да дулый, утлы кисәүне берөзлексез яндырып тота. Рифкатькә ул мәңге шулай янар, бу авырту мәңге бетмәс кебек тоела. Авыртуны басарга тырышып, ул авыз эченнән генә көйли башлады:

Солдат булу безгә кыен түгел,
Риза булса кызлар көтәргә.

Илдус аны саташа дип белде ахрысы, врачка таба борылып карады. Ак халатлы ханым, игътибар итмә дигәндәй, кулын гына күтәрде, дәшмәде.

— Сиңа кан бирделәрме әле, Рифкать?

— Юк.

— Хәзер бирә башлыйбыз, — диде врач.

— Ә миннән кан алмадылар. Группаң туры килми диләр. Ничек инде, мин әйтәм, туры килмәсен, аның белән безнең бөтен нәрсә дә туры килә. Бергә укыдык, ничә ел дус булдык, бергә хезмәт итәбез. Димәк, кан да туры килергә тиеш.

Рифкать сүзгә кушылмады. Кинәт кенә аның бер нәрсәгә дә исе китмәс булды. Дуслар, якташлар, хатлар, юату сүзләре — барысы да ниндидер мәгънәсез нәрсә кебек тоела башлады. Врач ым какканны күргәч, Илдус тып-тын гына палатадан чыгып китте. Рифкать аны сизмәде. Ул уйлары белән моннан бик еракта, Кама аръягындагы иксез-чиксез болын уртасында йөри иде инде.

9

Мәктәптә укулар бетеп, каникул башлануга, һәр җәйне Илмәткә кайтам, дип атлыгып тора Рифкать. Кайткан көнне үк, болынга төшик, я урманга барыйк, дип бабасын тыкырдатырга тотына.

— Сабыр ит, улым, сабыр иткән — морадына җиткән. Юлдан соң бераз хәл җый. — Харис бабай шулай сөйләнә-сөйләнә кечкенә сандалга куеп чалгысын чүки башлый. — Авыл халкы эшсез кешене өнәми ул. Бераз печән дә чабып кайтырбыз.

Быел авыл бигрәк үз, якын тоелды Рифкатькә. Әллә инде тиздән армиягә китәсе булганга, туган як белән саубуллашыр чак җиткәнгә күңеле нечкәрә башладымы? Бабасы чалгылар көйләгән арада ул җәһәт кенә «Изгеләр чишмәсе»нә дә менеп төште, инеш буен да урады. Авылга кайттымы, әллә нинди үзе дә аңлый алмый торган хис били аны, иңнәренә канат чыккандай була, моңа кадәр күңелне борчып торган вак-төяк кайгылар да онытыла. Авылда аңа белгәне дә, белмәгәне дә сәлам бирә. «Шәфкатьнең кече малае кайткан!» дип, зурлар ерактан

ук сүз ката, шәһәр хәлләрен сораша, егетләре кичен капка төпләренә килеп утыра. Шәһәрдә өйләр бөтенесе бер-берсенә охшаш, ә монда һәр каралты, һәр йорт үзенчә. Аларның йорты Харис бабайның үзенә охшаган: какчарак йөзле, җиңел гәүдәле, ә-әнә, каршыдагы өй фуражкасын батырып кигән төксе йөзле кеше төсле, тәрәзәләре дә караңгы, ә менә монысында киң күңелле кешеләр яшидер: тәрәзәләре олы итеп уелган, капкалары да көне буе шар ачык тора.

Шулай һәр йортны кемгәдер, нәрсәгәдер охшатып бара торгач, авыл башына чыгып җиткәнен сизми дә калды. Басуга чыккач, дөнья яктырып киткәндәй булды. Бөтен җир сап-сары, бары басуның аргы ягындагы комбайн гына, кызыл чикерткәгә охшап, теркелдәп төшеп килә. Тулы башаклы игеннәр чәчләренә чал кунган аксакаллар кебек башларын акрын гына селки-селки нидер серләшәләр, кызыл чикерткәгә күтәрелеп карыйлар да, качарга теләгәндәй, тагын аска иеләләр.

— Игеннәр дә өлгерде... — дип куйды Харис бабай. Сөенә идеме, әллә уфтанамы — Рифкать аңлый алмады.

— И-их, яшь чагым булса, каерып бер пакус алыр идем дә кереп китәр идем басу буйлап!

— Комбайн белән диген. Чалгы белән иген чапмыйлар инде.

— Чабалар иде, улым, заманында чабалар иде.

— Ул заманнар узган инде, хәзер техника эшли бит. Әле газетадан укыдым, бер комбайн әллә ничә йөз атны, меңләп кешене алыштыра дигән.

Харис бабай һич көтмәгәндә кеткелдәп көлеп җибәрде. Рифкать, аптырап, аңа карады.

— Дөнья күрмәгән кеше язган аны, улым. Каптырмалы кабартма ул, белдеңме? Дөнья күргән кеше авызыннан мондый сүз чыкмас. Мең кешене алыштыра дисеңме? Алыштыра, чуртым! Кешене алыштыра торган нәрсә җир йөзендә яралмаган әле. Юка башлар сүзе ул. — Харис бабай чалгы сырты белән җиргә сугып куйды. Кисәк хәрәкәт белән колак аппаратын тартып алды да кесәсенә салып куйды. Ачуы чыкканда, кеше белән сөйләшәсе килмәгәндә шулай итә ул: аппаратын тартып ала да бөтен дөньяда бер ялгызы кала.

Аннары инде аңа сөйләдең ни дә сөйләмәдең ни. Ләкин бу юлы ачуы ныгук кузгалган ахрысы, тыела алмый, һаман кемнедер сүгә.

— Тамакларына аркылы килгере, уттай урак өстендә бакча артында сырт кыздырып яталар. Комбайннары тик тора, ә ул мәльгуннарның исләрендә дә юк. Килгән кешедән нинди иман булсын инде? Җир кадерен, икмәк кадерен беләмени алар? Авылда күзгә кырып салырлык та яшьләр калмады, барысы шәһәргә качып бетте. Ни дип шул сасы төтен исләргә кызыгалардыр. Бик исмисе килсә, исле мунчага кереп ятсын иде. Алар анда сигез сәгатен тутырып кайта да, иха-ха да миха-ха килеп, түшәмгә төкереп ята, ә монда эшләр кеше юк. Быел игенне җыеп бетерүләре дә икеле әле. Комбайннары тик тора, кул җитми. Әнә, шәһәрдән китергәннәр иде. Күргәнсеңдер, безнең ындыр артында кызыл сыер көтүе шикелле комбайннар тезелеп тора. Шәһәр кешесе таш җанлыдыр ул. Утырып кала бит игеннәр, утырып кала. Әле, бер каптырмалы кабартмасы, авыз ерып, көлеп торган була: «Кайгырма, бабай, ил зур безнең, хөкүмәт бай, монда иген булмаса, читтән китерерләр, мул җирдән», — дип акыл сата. Кеше ашын ашап өйрәнмәгән, безгә үзебезнеке җиткән. Гомер-гомергә шушы басу туйдырып килде, читләргә ялынмадык. — Харис бабай бераз тынычлана төште бугай, чалгысын иңенә салды да атлап китте. — Шушы җирне урак белән егып сала идек без, уч төбе хәтле кәкре урак белән. Ә хәзер комбайн белән кырпак төшкәнче маташалар. Ә син... мең кешене алыштыра дисең. Алыштырмый торсын әле. — Ул, артык кызып киттем дигәндәй, туктап тын алды да Рифкатька эндәште: — Нигә синң

сөйләп башыңны катырам соң әле? Синә нәрсә, син — шәһәр кешесе. Сезнең өчен ипи кибеттә үсә. И-их, минә синең шикелле егерме-утыз гына егет булсын иде хәзер монда. Бу басуларны ялтыратып кына куяр-лар иде. Әллә армиядән соң, чыннан да, авылга кайтасыңмы, улым?

— Күз күрер, — диде Рифкать.

— Нәрсә дисең, нәрсә?

— Кайтырмын, бабай, кайтырмын.

— Нәрсә дисең? — Харис бабай колак аппаратын салганын исен-нән чыгарган булса кирәк, Рифкатьнең сүзен ишетмичә, кабатлап сорады.

— Кайтам! — дип, ике кулын авызына бүрәнкәләп куеп бар көченә кычкырды Рифкать. — Кайтам!

Аның тавышын игеннәр дә ишеттеләр кебек, авыр башларын кагып куйдылар.

## 10

Рифкать, уйларыннан арынып, палатага күз ташлады. Врач чыгып киткән ахрысы, беркем юк. Башы да артык чәнчешми, еректан ишетел-гән комбайн тавышы кебек берөзлексез гүли генә. «Кая, кеше юкта торып карыйм әле». Торырга талпынып куйды, ләкин кузгала алмады. Көчәнүдән аякларын көзән җыергандай булды, тәнен калтырау алды, бар мускуллары киерелде, тик башы күтәрелмәде, хәрәкәтсез ята бирде. Башына кереп оялаган аждаһа тик кенә ят, кузгалма, дигәндәй, кыймшанып алды. Кинәт аңа бу авырту беркайчан да бетмәс, ул мәң-ге шулай хәрәкәтсез ятар кебек тоела башлады. «Тизрәк... тизрәк, — дип пышылдады Рифкать. — Нәрсә тизрәк? Нәрсә булса да, тизрәк кенә булсын... Юк, ул үләргә тиеш түгел!»

Ул беренче тапкыр үлемне күз алдына китерергә тырышып карады. Менә ул кызыл табут эчендә ята. Табут каршына солдатлар тезел-гән. Командир нидер сөйли дә сөйли. Ята торгач, Рифкатьнең җилкәсе чәнчи башлады. Ул, ике кулы белән табут кырына таянып, әкрен генә торды да, җиргә төшеп, стройдагы үзенең буш торган урынына таба атлады. Үзе атлый, үзенең аяклары берни дә сизми, әйтерсең, һавада очып бара. Солдатлар «урра!» кычкыра.

Менә аны, ак кәфенгә төреп, Илмәт картлары күтәреп бара. Алда Харис бабасының тавышы ишетелә: «И улым, улым, авылга кайтам, дигән идең, кайтуың шушы булган икән». Зират капкасы төбенә килеп җиткәч, басу ягыннан таныш гүләү ишетелә башлый. Бу тавыш көчәй-гәннән-көчәя бара, колакларны ертып керә, башка каба. Рифкать бар-ган көйгә урыныннан торып утыра да, кулын каш өстенә куеп, тавыш килгән якка иелә. Ә анда, иген басуын урталай ярып, комбайн килә. Үзе дөберди, шатырдый, тәгәрмәчләре, чылбырлары әйләнә, өстеннән тузан болыты күтәрелә, ә үзенең штурвалы артында беркем юк. Риф-кать җиргә сикереп төшә дә, ак кәфенен сүтә-сүтә, комбайнга таба йөгерә...

Менә ул үз өйләрендә олы бүлмә уртасына куйган караватта ята. Өстендә — солдат киеме, күкрәгендә — значоклар. Бөтенесе елыйлар, аның битеннән сыйпыйлар, соңгы тапкыр фотога төшерәләр. Рифкать-нең еламагыз дип әнисен, әтисен, туганнарын юатасы килә, ләкин авы-зыннан сүз чыкмый. Керфекләре аша саркып, тәрәзәдән төшкән якты-лык күренә. «Галия кайда?» — дип уйлый ул. Дәрестән кайткач, кеч-ләр буе шушы тәрәзәдән карап утыра иде. Каршыда — Галияләрнең тәрәзәләре. Теге кичне ниләр булганын өйләренә кайтып сөйләгән дә, менә хәзер Галияне бөтенләй диярлек урамга чыгармас булдылар. Элек Рифкать аңа гел игътибар да итми иде. «Сары баш» белән чә-

кәләшүе дә Галия өчен түгел, ә егеткә ачуы чыгудан, аның шулай тупас сөйләшүеннән, юкка бәйләнүеннән генә булды сыман.

Менә хәзер ул тәрәзә төбенә кунаклаган да, җәнлек сагалаган аучы төсле тын да алмыйча каршы балконны күзәтә. Балкон ишеге ачык. Димәк, ул бүген барыбер ишек янына киләчәк, ябар өчен генә булса да киләчәк. Ә инде килгәч, балконга чыкмый түзә алмаячак... Әнә, пәрдә артында шәүләсе чагылып китте. Әнә, зәңгәр күлмәге төсмерләнде. Әнә, әнә, балконга чыкты. Чыкты да Рифкатьнең дөньяда бар икәнен дә белмәгәндәй, бу якка күз ташлап та карамады, балкон аратасына таянды да тик тора бирде. Рифкать, тәрәзә төбеннән сикереп төшеп, бер бүлмәдән икенчесенә чабып йөрергә тотынды, аннары кинәт кенә туктады да стенадагы зур көзгене алды. Кызның чәчләре, йөзе, иңбашлары кояш нурына коенды. Ул бер мәл аптырап, берни дә аңламыйча, һушсыз басып торды, аннары як-ягына каранды һәм, Рифкатьне күргәч, авыз тутырып елмайды, үзе бармак янаган булды, нидер кычкырды. Ләкин аның яңгыравык тавышы вак кисәкләргә таралып юкка чыкты, Рифкать янына килеп җитә алмады. Рифкать кояш кыйпылчыгын кызның йөзеннән алып, стенага күчерде һәм көзгесен боргалый-боргалый хәрефләр «яза» башлады. «Я» Хәреф шундый зур булып, балкон стенасына көчкә сыйды. Кыз, аңлаганын белдереп, баш селкеде, урамны яңгыратып көлде. «Р». Галиягә бу уен бик ошады бугай, ул кулларын чәбәкли-чәбәкли сикерергә үк тотынды. «-А-Т-А-М». Рифкать калган хәрефләрне тиз-тиз генә язып бетерде дә, җавап эзләгәндәй, кояшны Галия йөзенә күчерде. Ә ул күзләрен кулы белән каплап бераз тын торды да капыл гына өйгә кереп китте, бераздан кире чыкты. Аның кулында да шундый ук зур көзге иде. Ләкин ул, күпме тырышса да, кояш җибәрә алмады, аларның йорты күләгәле якта иде. Галиянең шуңа бөтенләй кәефе китте, ахры, ул, салкын көзгесен кочаклап, тын калды. Рифкать кояш нурын аның көзгесенә төшерде, көзге кинәт яктырып, балкып китте, Галиянең дә йөзе ачылды. Менә ул, көзгесен күтәреп, Рифкатьнең кояшын кире үзенә җибәрде. Рифкатьнең күзләре, чагылып, яшьләнде, йөрәге депелдәп ярсый-ярсый тибәргә тотынды. Галия, асфальтка пыяла ташлагандай, чылтыр-чылтыр килә-килә урамны тутырып көлде дә көлде. Көлеп арыгач, кояш көлтәсе белән стенага сүзләр яза башлады. «Р-И-Ф-К-А-Т-Ь + Г-А-Л-И-Я-» Шулчак ишек ачылып ябылды. Әнисенең: «И улым!..» — дигән еламсыраулы тавышы ишетелгәндәй булды. Ул, яшерергә теләп, көзгесен тәрәзә пәрдәсе артына таба шудырды, һәм кинәт бөтен дөнья караңгыланып калгандай булды. Стенадагы кояшлы хәрефләр дә сүнде, Галиянең көзгесе дә, боз кисәгенә охшап, салкынаеп калды, бераздан Галия үзе дә юкка чыкты. Ул, аптырап, өзгәләнеп, үз-үзен белештермичә, кычкырып җибәрде: «Га-ли-я!». Ә... тавышы... тавышы...: «Әл-фи-я!» — дип яңгырады. Ул, әллә саташаммы дип, як-ягына каранды, хәлсезләнеп, башын тәрәзә пыяласына терәде...

— Хәзер, шприцлар гына әзер булсын да, сестра сиңа кан бирәчәк, — диде врач, Рифкатьнең маңгаена суланган салкын чүпрәк куя-куя. — Үнбер егет каны кергәч, баһадирның баһадиры буласың инде. Егетләре дә нинди бит әле. Әзмәвер мени!

## 11

Врач ишектән чыгуга, кинәт кенә Рифкатька рәхәт булып китте. Илдусны гына үпкәләтте бугай. Ни әйтсәң дә, якташ бит. Якын итеп килгән. Теге вакытта Саша турында дөрес әйтмәде әйтүен. Үзгәрер әле. Гел, «әйе», «әйе», дип кенә тормас. Тормыш өйрәтә ул. Донор егетләр хәзер шәһәрдә йөриder инде. Терелеп чыккач, алар белән бер

җыелып утырырга иде. Моңа кадәр кешеләрне аңлап бетермәгән икән ул, кешеләрнең кадерен белмәгән. Аннары, солдатта күп нәрсә приказ белән генә эшләнә бит. Җылы сүз бик тансык ул солдатка. Бергәләп увольнениегә чыгарлар. Бу тирәнең табигате безнең якныкы шикелле үк матур түгел дә. Шишкин урманнарын, Кама ярларын, Вятка болыннарын күрсәтергә иде аларга. Чыннан да, алар хәзер Рифкатька кан кардәшләр шикелле. Яз көне ул да донор булган иде бит. Кан биреп чыккач, шәһәр буйлап йөрделәр. Мондагы халык гел бүтән икән, сөйләшүләре дә үзләренчә. Колак салып тыңлагач, кайбер сүзләре аңлашыла да. «Әллә татарлар инде», — дип уйлады Рифкать. Хәтта бер кызга сүз дә катты. Тегесе горур булып чыкты: башын өскә чөерде, җавап кайтармады. Читтәрәк торган кара чәчле, тут йөзле апа белән абый да, курыккан сыман, кабалана-кабалана кызларын ашыктырдылар.

— Әй, агай, әллә безнең яктанмы сез? Таныш булыйк, мин — Татарстаннан. Телегез аңлашыла, шуңа әйтәм, — дип эндәште Рифкать.

Агай артка борылып карады да: «Җир йөзендә бар адәмнәр дә бер-берсенә туган. Шуны аңлаучы гына юк», — дип, китеп барды.

— Безнең халыкны, солдат халкын бик өнәп бетерми алар, — дип аңлатты прапорщик. Ул үзе Казан тирәсеннән, шуңадырмы, Рифкатьне үз итә иде. Буе ике метр булыр, куллары утын яра торган үтмәс балтага охшаган. Балта диярлеге дә бар шул, кулы белән бер сугуда кирпечне сындыра ул.

— Ә нигә өнәп бетермиләр?

— Солдат халкы бик шаян бит, бер дә тик тормый. Ә монда кызлар чибәр!

— Нинди халык соң алар?

— Кем икәннәрен дә белмәссең. Бик күп алар монда. Ну эшчән дә халык инде үзләре. Шушы ком даласында оҗмах ясап куйганнар бит. Оҗмахның берәр хур кызы белән танышасың килмиме соң, якташ?

— Белмим...

— Ниткән «белмим» ул тагын? Киләсе увольнениедә, күр дә тор, таныштырам берсе белән.

Алар, шәһәр урамын инләп, көлешә-көлешә күл буена төштеләр. Күл бик зур, Вятка киңлеге булыр. Чишенеп суга кергәч, Рифкать борылып карады. Яр башында экскаваторыннан башын тыгып әтисе карап торадыр шикелле иде аңа. «Әти, сиңа нишләп Шәфкать исеме кушканнар?» — дип сораган иде ул аннан бер тапкыр. «Кем белгән инде аны, улым? Аны-моны уйлап тормаганнардыр, тотканнардыр да кушканнардыр». «Юк-юк, алай булмый инде». «Нигә дип, шәфкатьле булсын дигәннәрдер. Миргазиз бабаң бик нечкә хисле, бала күңелле кеше иде. Шул кушкандыр. Нәкъ синең төсле иде инде: аксыл чәчле, озынча йөзле, зәңгәр күзле. Көлгәндә дә шаркылдап көлмәс, синең шикелле рәхәтләндереп елмаер гына иде. Ул елмайганда күңелләр эреп китә иде». «Әткәй, ә нигә аңа Миргазиз дип кушканнар?» «Кайлардан белеп бетерим соң инде, улым? Бик тә олы җанлы бәндә иде бит, әүлия иде инде, чын әүлия. Кеше сораса, соңгы ыштанын салып бирергә әзер иде. Гомер буе изгелек кенә кылып яшәде. Шул, гөнаһы булмаганга, күңеле чиста, кеше алдында йөзе якты булганга сиксән сигез яшенә җитте дә. Безнең нәсел озын гомерле ул. Әнә, Харис бабаң да җитмешнең өске ягына чыкты. Алла боерса, без дә бирешмәбез. Син, Миргазиз бабаңа охшасаң, йөзгә җитәрсең әле». «Аңа нигә дип Миргазиз кушканнар соң?» Бер сүзне кабатлап тору әтисенең күңеленә тиде бугай, малаен кырт кистерде: «Нигә булсын, мир газиз да җир газиз, аннан кала, ир газиз», — дип сөйләнә торган гадәте бар иде мәрхүмнең. И-И, сине күрсә, сөенер иде!»

— Рифкать, нәрсә каккан казык шикелле торасың? Чум, әйдә!

Ул, су чәчрәтә-чәчрәтә, йөгереп барды да колач җәеп йөзеп китте. Әгәр менә бу су Камага барып чыга, шунда хәтле йөзә аласыңмы дисәләр, ике дә уйламыйча «әйе» дияр иде. Увольнениегә чыккач гел шулай туган як турында уйлый ул. Әле самолетка утырып кайткандай була, әле поезд, әле машина белән кайта. Ә менә бүген йөзеп кайтырга да риза. Тизрәк отпуск җитсен иде инде.

Йөзеп арыгач, алар озак кына кайнар ком өстендә кызынып яттылар. Прапорщик (Рифкать аның исемен дә белми, бөтенесе дә «иптәш прапорщик» дип эндәшкәч, ул да шулай гына йөртә) һаман анекдот сөйли. Бер җөмләсен әйтә дә буыла-буыла көлә, тагын әйтә дә тагын көлә. Кеше тыңлыймы-юкмы, аңа барыбер. Ул аны кеше өчен сөйләми дә кебек. «Үзе сөйли, үзе көлә, үз күңелен үзе күрә», — дип уйлады Рифкать. Ул шулай юл буе шаркылдап кайтты. Әйтерсең, эчендә бәләкәй генә шүрәле баласы кереп утырган да кытыклапмы кытыклый тегене. Ул көлгән саен, Рифкатьнең кәефе төшә бара, әллә инде кан бирүдән, әллә эссе кояш астында ятудан, укшыта, башы әйләнә.

— Тукта! — дип кычкыра ул, ачуы чыгып, прапорщикка. — Җитте, маймыллланма, туйдырдың.

Моңа кадәр үзенә каршы әйткәнне ишетмәгән прапорщик аптырап кала. Бер мизгелдә ул шарык-шорык анекдот сөйләүче авыл малаеннан мәһабәт прапорщикка әйләнә.

— Нәрсә дисең, са-ла-га? Әллә башыңда кирпеч ярып күрсәтимме? — Ул кизәнә, янәсе Рифкатьне куркытмакчы була. Рифкать җәһәт кенә читкә тайпыла һәм, башы әйләнеп, чак егылмыйча кала. Солдатлар аны, бөҗра ясап, ул-бу хәл килеп чыкмасын дип, әйләндереп алалар. Прапорщик кәрәк кулын йомарлаган килеш басып тора-тора да, кинәт кенә борылып, китеп бара.

## 12

Рифкать күзен ачарга тырыша, ләкин күз кабаклары, җилем белән ябыштырган кебек, кузгалмый. Кояш нурлары, утлы инә шикелле башны тишеп керә. Менә ул утлы инәләр баш эчендә бергә тоташтылар да зырылдап әйләнергә тотындылар. Рифкать авызында бик тә ачы тәм сизде, аның күз аллары, күз аллары гына түгел, әйләнә-тирә, бөтен дөнья төпсез караңгылыкка чумды.

Шундый шомлы төш иде бу. Әле ул самолет пропеллерына ябышкан да, аның белән зыр килеп бөтерелә, аяклары, гәүдәсе өзелеп чыгарга җитеп тартыла, әле ул Илмәт урманына кереп адашкан да, кая барырга белми, бабасын чакыра, әле ул больница тәрәзәсе төбендә инде ничә сәгатьләр буе Саша өчен гитара уйнап тора; караса, уйныйуйный бармаклары чиләнеп беткән; әле ул ялкын чорнаган трактор кабинасына сикереп керә дә, бар көченә рычагны тарта, ә трактор кузгалмый. Менә ялкын аның киемнәренә каба, куллары, аяклары пешә, ялкын чәченә үрли, күз алмалары шартларга җитеп кызыша һәм ул, үз-үзен белештермичә, кычкырып җибәрә:

— Су!

Аның иреннәре буйлап су агып төшә, муены, җилкәсе юешләнә, керфекләре калтыранып куя. Өстән, югарыдан, тонык, салкын яктылык сирпелә, бөтен җиргә чәчелгән яктылык торган саен җыела, кечерәя бара һәм, ниһаять, бәләкәй генә ноктага әйләнә. Рифкать, баш очындагы лампочканы күреп, җиңел сулап куя.

— Уяндыңмы? — Врачның ягымлы тавышын ишеткәч, Рифкать, куркыныч төштән арынып, яңадан ак палатага кайта.

— Озак йокладың, егет, кан биргәндә дә уянмадың.

Нишләп болай аның әнисенә охшатып сөйли соң әле ул? Әллә әниләр бөтенесе дә бер-берсенә охшаган микән? Увольнениегә чыккач, ашханәгә кергәннәр иде. Анда да аш бүлүче апаны әнисенә охшатып, озак басып торды. Елмайганда бөтен кеше дә бер төсле. Ачуланганда, усал чакта гына төрле була алар. Бик күп уйлый бугай ул. Әллә башы шуңа авыртамы? Унтугыз яшьлек кешенең дә искә төшерер нәрсәсе булыр икән? Юк, чыннан да артык уйлый бугай, болай хыялыйланып китүең дә бар. Картлар гына үткәнне уйлый ул. Ә аңа киләчәге турында хыялланырга кирәк. Авылда «Миргазиз карт» дип юкка кушамат такмаганнар икән үзенә. Бөтенесен уйлый, ә менә әнисе, этисе, Азат, Әнфисә турында уйларга курка. Алар искә төшсә, никтер, күзенә яшь килә. Әнисе гел балавыз сыгарга гына тора иде бит. Армиягә озатканда да елады. «Исән-сау әйләнеп кайт, улым!» — дип кат-кат кабатлады. Сизгән диярсең. Озату мәҗлесендә дә баштарак күңелле утырды да азакка таба гел коелып төште.

— Сугышка китмим бит, нигә елыйсың? — дигән иде аңа Рифкать.

— Дөнья хәлен белеп булмый, улым.

— Бер мин генә түгел бит, бар да китә.

— Анысы шулай да. Минем өчен син бер генә шул.

— Ташлале, Миңниса, шул суган сыгуыңны. Малаең солдат булганга еларга түгел, сөенергә кирәк. Менә нинди егет үстереп бирдең бит. Хезмәт итсен әйдә, илне, җирне куандырсын! Безнең нәсел, аллага шөкер, моңа кадәр сынатмады, утка да, суга да керде, Рифкать тә йөзгә кызыллык китермәс. Шулаймы, әнисе, шулаймы, улым, — дип этисе өстәлнең әле бер башына, әле икенче башына йөри-йөри сөйләде. — Әйдә, улым, кунакларның күңеле ачылсын, үзебезчә бер көй сыздырып җибәр әле.

— Эрет әле йөрәк маен!

— Җыр да җырламагач, солдат озату буламыни!

Кунаклар гөр килеп шаулаша башлагач, әнисенең дә йөзенә нур кунды. Рифкать үз бүлмәсенә кереп гитараны алды да өстәл янына килеп басты.

— Нәрсә уйныйм соң?

— Һи-һи! Кит моннан,— диде аңа жизни тиеш кеше.— Бу шалтыравыкка кушыла алмыйм мин.

— Ташлале шул тимерчыбыклы әрҗәңне.

— Гармун кирәк, гармун.

— Гармунның көе су аккан шикелле бит аның. Ә бу нәрсә, шылтыр да шолтыр.

— Ярар инде, агайнеләр, — дип аларны тынычландырды этисе. — Кемгә нәрсә бит. Безнең колак шуңа күнеккәндер инде. Соң, улым, авылда өйрәнеп кайттым, дигән идең бит. Кунакларның күңелен күр әле бер.

Рифкать гитарасын стенага сөяп куйды да иң өстенә гармун каешын салды.

— Юньләп уйный белмим бит.

— Әйдә, әйдә, ялындырма!

Ул гармун төймәләренә карый-карый уйнап җибәрде. Шактый гына кызып җиткән кунаклар, берәм-берәм сөйләшүдән туктап, тын калдылар. Өстәл почмагына утырган агай гына нәрсәдер әйтергә талпына, ә хатыны аны тыярга тырышып, терсәге белән төртә. Менә ул, хатынының кулын этәреп куйды да торып басты.

— Ә минем малай бармый! — дип кычкырды ул. — Минем малай институтка керәм ди! — Мактануы идеме бу аның, әллә уфтануымы — беркем дә аңламады, аңа игътибар итүче дә булмады.

— Тукта инде, җүләр, — дип хатыны итәгеннән тартып урынына утыртты.

— Ә минем малай бармый, ә минем малай... — дип һаман сөйләнә бирде ул. Ләкин шулчак Рифкатьнең этисе җыр башлап җибәрде, һәм аның тавышы күмелеп калды. Җырны барысы да күтәреп алдылар.

Җиз кыңгырау тагып кына,
Атларда чабып кына.
Кайтыр идем яшьлегемә
Тик сине алып кына.

— Әйдә, кушыл, кода.
— Җиңги, җиңги, нигә авызыңа су капкандай утырасың?
— Ә-әй, күрше, малай көн дә китми бит армиягә, селкетик әле дөньясын!
Әтисе белән әнисе берсен-берсе уздырып кунакларны кыстый, болай да кызып җиткән мәҗлесне тагын да ямьлерәк, күңеллерәк итәргә тырыша иде. Җыр кунакларны җилкетеп җибәрде, кайберләре сикереп торып биергә үк тотынды. Рифкать бию көен белми, шуңа күрә гармунын өзек-өзек тарткалап кына торды. Ләкин җыр, бию, кычкырып сөйләшү авазлары астында гармун тавышы ишетелми дә иде. Ирләр чүгәли-чүгәли бии, ә хатын-кыз, өстәлнең бер башына җыелган да, берсен-берсе бүлә-бүлә нидер сөйләшә.
— Мәрфуганың малае армиядән кайткан, ул киемнәре, ул буй-сыны, коеп куйган гөрнәдир инде.
— И-и, кызый, әле генә елак бер малай иде бит. Әнисе итәгенә ябышып йөри иде.
— Сафуранықыннан да хат килгән. Макарон булып калам, дигән. Анысы нәрсәдер инде тагын? Солдатларны ашатып торучыдыр, я.
Ирләр дөбер-шатыр бии, ә өстәл читендәге агайның үз кайгысы-кайгы — каршысында торган шешәдән сала да эчә, сала да эчә. Эчкән саен йөзен чытып куя да һаман бер сүзне кабатлый: — Ә минем малай бармый. Минем малайны алмыйлар. Ул институтка керәм ди, зур начальник булам ди.
Үзен беркем дә тыңламаганга аның кәефе китә ахрысы, әле берсенә, әле икенчесенә төртә. Ә кунаклар, борылып, баш кына кагалар да тагын уен-көлкегә биреләләр. Тора-бара гармунның да кирәге бетте, һәркем үзе яраткан, үзе генә белгән җырны җырлады: «Порт-Артур»ы да, «Дранча»сы да, «Баламишкин»ы да калмады.
Кунаклар таралышканда төн уртасы җиткән иде инде.
— Улым, саубуллаш, — диде әнисе.
Рифкать һәрберсе белән аерым-аерым саубуллашып чыкты. Агайларның күңел йомшаган иде: аның җилкәсеннән сөйделәр, башыннан сыпырдылар, кочакладылар, ә ул, нишләргә белмичә, кызарынып, бер урында таптанып торды. Исерек абый алпан-тилпән атлап килеп Рифкатьнең кулын тотты да җибәрми генә.
— Әйдә инде, саубуллаш та киттек, — дип хатыны кырыенда тыкырдатып тора.
— Тс-с! — ди ул. Үзе нәрсәдер әйтергә тели, ләкин сүз таба алмый, Рифкатьнең кулын кыскан килеш тик тора. Хатыны башына бүреген кидергәч кенә ул, аңына килгәндәй, күтәрелеп карады да ишеккә таба атлады. Пальтосын кигәндә чайкалып китте дә стенага сөялде.
— И ходайларым, мәҗлестә дә кешечә утыра белмисең бит. Уҗымга чыккан сыер шикелле күбенгәнче эчмәсәң!
— Тс-с, хатын, — дип, еламсырады ул һәм бармак янады. — Тс-с! Ә минем малай бармый...
— Тукта инде, җүләр, тукта, ишеттек бит, бөтенесе дә ишетте. Бармаса, бөтен кешегә дә армиягә китеп бетәргә димәгән бит.
— Минме җүләр? Мин җүл-ләр түгел! Малаең җүләр синең. Боламык ул, мәми авыз. Синең эш, син шулай тәрбияләдең. Үчтеки-үчтеки

итеп үстерден. И-их, без яшь чакта! Армиягә киткәндә мине бөтен авыл озаткан иде. Бөтен авыл. Сабан туйда беренче килгән атны җиккәннәр иде. Шөлдерләр тагып, сөлгеләр элеп. Яшь чагым булса, тагын бер китәр идем! И-их!

Хатыны аңа артык сөйләшергә ирек бирмәде, таза куллары белән каерып алды да төрткәли-төрткәли ишектән алып чыгып китте. Подъездда аның исерек тавышы ишетелде:

Җиз кыңгырау тагып кына,
Атларда чабып кына...

Кунаклар киткәч өй кинәт тынып, бушап калды. Рифкать, үзенә урын таба алмыйча, ишекле-түрле йөрде, аннары, бүлмәсенә кереп, магнитофон кабызды. Кухнядан әнисенең тавышы ишетелде:

— Улым, үзеңнең җырларыңны яздырып калдыр әле. Сагынганда тыңларбыз.

— Сагынырсызмы соң?

— Әй, сөйләмә әле юк сүзне.

— Ярый, иртәгә көндез яздырырмын. Иртәгә дә көн бар бит әле. Өстәл җыярга булышыйммы?

— Кит аннан, ир кеше эше түгел ул.

— Моңа кадәр җыештырганда сүз әйтми идең бит әле.

— Моңа кадәр әле син малай идең, менә инде хәзер ир-ат булдың.

— Хәзер хатын-кызга, ир-атка аеру бетте инде ул.

— Алайса, нигә Әнфисәне армиягә алмыйлар соң? Аеру бетсә, аңа да солдат шинеле кидерерләр иде.

Рифкать җавап кайтармады.

## 13

Инде тәрәзәдән төн шәүләсе дә сизелә башлады, ә аның һаман күзенә йокы керми. Күрше бүлмәдә сәгать тавышы ишетелә. Келт-келт, келт-келт. Тагын бер көннән ул китәчәк. Келт-келт, келт-келт. Кара, моңа кадәр ул сәгатькә матур уенчык кына итеп, дәрескә барыр вакыт җиткәнне, тәнәфес беткәнне, әтисе эштән кайтырга чыкканны, кино башланганны күрсәтә торган серле бер уенчык итеп кенә карый иде. Баксаң, әйтеп тә, сөйләп тә аңлатып булмый торган вакыт атлы нәрсәне, гомер узганын, аның һәм башкаларның да гомере узганын искәртеп тора икән бит сәгать. Келт-келт... Әтисе белән әнисе дә йокламый бугай, стена аша аларның пышылдап кына сөйләшкәне ишетелә.

— Әллә Казанга хәтле озата барасыңмы соң, Шәфкать?

— Кит инде, булмаганны сөйләмә. Кеше көләр.

— Бик кыерсытмасалар гына ярар иде инде үзен. Бигрәк йомшак күңелле бит. Кешегә күтәрелеп бәрелә торганнардан түгел.

— Алай димә, әнисе. Юаштан юан чыга диләр. Бабасына охшаса...

— Анда караватлар ике катлы икән. Өстәгесенә эләгеп, егылып төшмәсә ярый инде.

Әтисе әкрен генә көлеп җибәрде.

— Син инде бөтенләй бетереп ташлыйсың малаеңны.

— Күңелем тыныч түгел. Төпчек малай булгангамы, бер дә читкә җибәрәсем килми. — Әтисенең тавышы ишетелмәде. — Ни кушсаң, шуны эшләргә генә тора иде.

— Иде дә иде... Мәрхүм кеше турында сөйләмисең бит, — дип кызып китте әтисе.

— Игезәк бала үстерү авыр диләр иде, болар икесе бер бала караган шикелле дә булмады. Әнфисәсе дә бик тәүфикълы. Тик менә,

Шәфкать, игезәкләрнең берсе озак яшәми диләр, хакмы икән шул сүз?

— Авызыңнан җил алсын! Каян башына килә мондый тузга язмаган уйлар? Әллә, мин күрмәгәндә, шайтан суының катырагын да авыз иткәнсең инде?

— Болай гына әйтәм инде, аптыраганнан.

— Йокла, әйдә, йокла, юк белән бетеренмә.

Әнисе авыр сулап куйды да тын калды. Ләкин аларның йоклый алмауларын, түшәмгә карап һәр икесе тиң үз алдына уйланып ятуын Рифкать стена аша да сизеп тора иде.

Иртән ул Әнфисә тавышына уянып китте:

— Подъем! Торырга вакыт, солдат. Казарманы җыештырасы бар. Әйдә, паласларны кагып керәбез!

Рифкать бераз гына иркәләнеп ятты да сикереп торып, магнитофоннан музыка җибәрде.

— Хәзер, җыя тор!

Өчәр-дүртәр баскычны берьюлы сикерә-сикерә урамга йөгереп чыктылар. Паласны, ике башыннан икесе тотып, кага башладылар. Рифкать кинәт кенә ныгытып тартып җибәрә дә Әнфисә паласны кулыннан ычкындыра.

— Мин киткәч, бу паласларны ничек кагарсың икән? — ди ул, ә үзе көлә.

— Бер башын баганага бәйләп куярмын.

— Ул баганаң да армиягә китәргә йөри бит.

— Әй лә, синең белән сөйләшеп тә булмый... Китсә, синекеләр кала бит. Киленнәрне чакырырмын.

— Нинди киленнәр ул тагын?

— Галия белән Әлфияне.

— Икесен дә берьюлымы?

— Әйе.

— Чакырсаң соң, исем китте...

— Исең китмәсә, бохар мәчесе шикелле көннәр буе тәрәзә төбендә утырмас идең... Сер итеп кенә әйт әле, кайсын яратасың аларның?

— Икесен дә... Кайсы миңа хат яза, кайсы мине солдаттан кайтканчы саргаеп көтә — шунысын... Солдат булу безгә кыен түгел, риза булса кызлар көтәргә...

## 14

Кич аларга дуслары, классташлары, иптәшләре җыелды. Әтисе белән әнисе, яшьләргә комачауламыйк дип, туганнарына китмәкче булганнар иде дә, никтер яхшысынмадылар, Рифкать бүлмәсенә кереп утырдылар. Яшьләрнең сүзләре дә бүтән, уен-көлкесе дә бүтән. Кичәге кунаклар шикелле тәмләп, озын-озак итеп сөйләшми болар: әйткәнне ярып әйтә, хет җир астына кереп кит, җырласа, әдәп саклап, авыз эченнән генә көйләп утырмый, түшәмнәр күтәрерлек итеп яңгырата. Рифкать тә бүген танырлык түгел, артык сүз сөйләмичә, ни әйтсәң дә, елмаеп тора торган малай мәҗлес үзәгенә әйләнде дә калды. Әле кызык сүз әйтеп, кызларны көлдерә, әле егетләрне дәртләндереп ала, әле гитарада үзе уйнап, үзе җырлый. Әтисе, йомыш белән чыккандай итеп, бүлмә аша узды. Күрә Рифкать, өстәлне тикшерә инде: бик тә шаулашалар, ул-бу юкмы, янәсе. Андый-мондый нәрсә күрмәгәч, суыткычтан алып, өстәлгә шампанский шешәсе утырта. Кызлар: «У-у-у!» — дип куя, егетләр бөтенесе бергә «урра!» кычкыра. Рифкать шешәсен төби дә: «Бирелəсеңме, атам!» — дип кычкыра. «Бирелəм,

бирелэм». Ул шешэне икенче, өченче кешегэ төби, алар да кулларын күтәрә.

— Хәзер сез — минем әсирләрем. Ни әйтсәм, шуны эшлисез, кая кушсам, шунда барасыз, — дип көлә Рифкать.

— Риза! Риза! — дип кычкыра барысы да.

— Автоматларны корырга! — Ул рюмкаларга күбекле шәраб коя.

— Коралларны әзерләргә! — Кызлар, егетләр, командага буйсынып, кулларына кашык, чәнечке алалар.

— Ата-ка-га!

— Ә тост? — дип сорый арадан кемдер.

— Дуслык өчен!

Рюмкалар чәкәшә, тәлинкә шалтырый, уен-көлке, шаян сүзләр сибелә.

— Җыр башларга! — дип, барысының тавышын басарга тырышып кычкыра Рифкать. Ләкин аны ишетмиләр. Ул, аптырап карап тора да кулына гитара ала.

— Теге яңа җыр ничек әле?

— Солдат турындагымы?

— Башладыкмы шуны.

Утларга да бер керербез әле,
Без менәрбез әле күкләргә.
Солдат булу безгә кыен түгел,
Риза булса кызлар көтәргә.

Кунакларны озатканда Рифкать Рөстәмне үз бүлмәсенә чакырып кертте.

— Мә, Рөстәм, — диде ул, бүреген аңа сузып. — Миңа барыбер кирәк түгел. Картлар әйтмешли, ашау байдан, үлем ходайдан анда.

— Кирәк түгел, кайткач киярсең.

— Кайткач, малай, тагын да затлырагын алырбыз. Мә, минем төс итеп киярсең.

Алар гитара уйнап, кочаклашып таңга кадәр Түбән Кама урамнарын әйләнделәр. Йокыларыннан уятмыйк, дип, Әнфисә белән чышынпышын сөйләшә-сөйләшә ишекне ачсалар, борыннарына коймак исе бәрелде, кухнядан таба чыжлавы ишетелде.

— Кайттыгызмы? — Әнисе онлы кулларын алъяпкычына сөртәсөртә аларга каршы чыкты.

— Пинжәгең кая? Әллә хулиганнар салдырдымы? — дип көлмәкчән генә басып торган Рифкатькә аптырап карап алды. — Әллә...

— Борчылма, беркем дә бәйләнмәде. Бирдем мин аны.

— Кемгә бирдең?

— Кемгә булса да барыбер түгелмени, — дип Рифкатьне якларга ашыкты Әнфисә.

— Бирдем дип. Әйбер кызганудан түгел... Китмәскә кайтмыйсың бит... Әйбер — кеше шикелле бит ул, кайтканыңны көтеп торыр иде. Көтәр әйберсе күбрәк булган саен тизрәк кайта ди, адәм баласы. И-и, улым... — дип сукранды-сукранды да кухнядан тәлинкәсе белән коймак алып чыгып өстәлгә куйды. — Ашагыз, ачыккансыздыр.

Рифкать бу бөркеп торган тәлинкәгә үрелде, ләкин, коймакка кагылуга, бармакларына ут капкандай булды, ул, үрсәләнеп, кычкырып җибәрде:

— Кайнар!

— Нәрсә дисең, улым?

... Күзләрен ачса, бернинди өй дә, энисе дә, коймак та юк, бары тик акшарланган буш стеналар да ап-ак түшәм генә.

— Нәрсә кайнар? Башыңмы?

Шундый рәхәт, татлы уйлардан бүленеп, газаплы, борчулы дөньяга кайтканы өчен Рифкатьнең җен ачулары чыкты, ләкин үзенең кайда икәнен аңлагач, шушы шыксыз палатага ямь биреп торган таныш йөзне күргәч, күңеле тынычланды. Ул дәшмәде, аның өзелеп-өзелеп җылы өйләренә, уйларында гына булса да, әнисе янына кайтасы, тубалдай зурайган, утлы шарга әйләнгән башы белән әнисенә сыенасы килә иде. Ләкин күпме тырышса да, әлеге уйлар төш кебек бик еракта калган, таралган, юкка чыккан иде инде. Врач апа палата түрендә үзенең инструментлары белән әвәрә килә: берсен ала, икенчесен куя, суга сала, мамык белән сөртә. Нәкъ әнисе кухняда кайнашкан кебек. Ләкин монда төчкелтем коймак исә урынына, борынын ярып, күңелне болгатып, дару исе килә.

Бер карасаң, бигрәк гади дә инде бу дөнья. Кеше туа, үсә, тегеләй итәм, болай итәм, дип хыяллана, дуслар таба, әллә кемнәр белән бозылышып бетә, тагын татулаша; шулай шау-гөр килеп яшәгәндә кинәт кенә үлә дә китә. Нигә мәңгелек түгел икән соң бу адәм баласы? Карга булып, бернинди максаты, олы хыяллары булмаган гапгади карга да берничә йөз ел яши диләр. Анысы, үлем бөтенләй булмаса, яшәүнең дә тәме бетәр иде. Кеше нәрсәдән булса да куркырга тиеш. Кайчан да булса үләсен, мәңге яшәмәсен белгәнгә күрә дә эшләнәсе эшләрен тизрәк эшләп, хыялланасы хыялларын хыялланып бетерергә ашыга ул. Ә мәңгелек булса, түшәмгә төкереп тик ятар иде. Ялкау кеше үлемгә ышанмыйдыр ул. Ләкин үлем мәрхәмәтсез... Ул, урам хулиганнары шикелле, һич көтмәгән җирдә сагалап тора да якаңа килеп ябыша. Бу дарулар белән генә кешене терелтеп булса... Медицина хәзер теләсә-нәрсә эшли ала диләр. Йөрәкне дә күчереп утырталар. Минем... баш бит. Башны күчереп утыртып булмый... Юк, юк, үлсәм, башта ук үлгән булыр идем инде. Кан да бирделәр. Миңа үләргә ярамый. Мин бит авылга кайтырга вәгъдә иттем, әткәйгә дә, дусларга да кайтам дидем. Кайтмасам, алдакчы булам. Әнә, Сашаның умыртка сөяге сынган иде, терелгән бит. Яз көне авариягә очраган солдатка кан биргәннәр иде. Ул да кеше булды. Азат абыйсы биш катлы йорт түбәсеннән егылып та исән калды. Ә ни өчен Рифкать кенә терелмәскә тиеш? Әле ул бер нәрсә эшләргә дә өлгермәде бит. Кайткач, аны слесарь итеп алмаслар инде, кулы юк. Әлфия белән ничек исәнләшер икән?! Исәнләшеп тормас, кочаклар да алыр. Тәлгатькә, техникумга керермен, дип язган иде, ярар, анысы качмас, көтеп торыр әле. Тотар да авылга китәр. Авыл халкының кул юкка гына исе китми аның. Әнә, бабасын инвалидка санаган кеше дә юк. Бүтәннәр белән бер рәттә йөри, җир җимертеп эшли. Аһ, ул тегеләй, аһ, ул болай дип араламыйлар. Аннары, бераз түл җыйгач, күз күрер әле. Читтән торып та укырга була. Ныгытып тотынса, кешедән ким укымас. Өйдә, кич җиттеме, гел шул уку турында була иде сүз. Әнисе көндәлеген карый да көрсенә, карый да көрсенә. Ә ул, юләр кеше шикелле елмая гына. Аңа бу уку мәңге бетмәс, бүген укымаса, иртәгә укыр кебек тоела. Чирек азагы җитәрәк эшнең мөшкеллеген сизенә башлый да көне-төне китап белән утыра. Гел шулай. Спорт буенча мәктәптә аңа тиңнәр юк, дуслары да күп — барысы да әйбәт, тик менә көннекен көнгә укып, дәресләрен карап бара алмый. Унынчыны бетергәндә дә ике-өч ай кала гына ныклап әзерләнә башлады. «Булмый инде синнән, булмый, шул гитара, магнитофон белән җенләнеп, чабыш аты шикелле басу буйлап йөгерүдән ары китә алмассың»,— дип әнисе көн дә колакка тукый башлагач, моңа да барып җитте

бугай, кинэт кенә басынкыланып калды, өстәл читенә китапларын өеп куйды.

— Зимнийны штурм белән алырга булдыңмы?— дип көлде аннан Әнфисә.

— Нигә, без кемнән ким?

— Әйдә, әйдә, маташып кара.

Рифкать дәреслекләренә аның саен үҗәтләнебрәк тотынды, төн йокылары качты, урамга да чыкмады, гәүдәсе ябыгып, суырылып калды.

Имтихан тапшырган көнне ул өйгә атылып кайтып керде. Кәрәкерешкә: «Әнфисә кайда?» — дип сорады һәм аны күрүгә: «Зимнийны алдык!» — дип кычкырды. «Ничәле, «өч»леме?». «Зимнийны алдык» дим бит. Котла. «Дүрт»ле!»

Ә имтиханнарны биреп бетергәч, күңелендә бушлык сизде ул. Нишләргә, кая барырга? Әнфисә ГПТУга керәм ди. Аның йөрәге каядыр атлыга, ярсый, ләкин кая икәне билгесез. Әнисе укырга керергә кыстый, укымаган кешегә сан юк хәзер, дип тә карый. Әтисе теге якка да, бу якка да кистереп сүз әйтми. Ә Рифкать көч ташып торган әзмәвердәй гәүдәсе белән тагын кысан парта арасына кереп утыруны күз алдына да китерә алмый, ул, көтүдән аерылып, үз иркенә чыккан тай кебек бертуктаусыз чаба да чаба, тәртә арасына керер алдыннан соңгы тапкыр уйнап калырга ашыга кебек. Аның инде күңел түрендә ныгытып куйган уе да бар, ләкин хәзергә бу турыда берсенә дә әйтми. Чөнки өйдә: «Малаебыз кем булыр икән, кайда урнашыр икән?»— дип, әти-әнисенең ләззәтле борчылу белән табын янында сөйләшкәнен тыңлау аңа әйтеп бетергесез рәхәтлек бирә иде. Август ахырына хәтле шулай яшьлек иләслегенә бирелеп йөрде дә көннәрдән бер көнне серен ачарга булды.

— Әнкәй, мин монтажлау идарәсенә язылып кайттым. Өйрәнчек слесарь итеп алалар.

— һе-е, — дип, аптырап, аңа карап торды әнисе.

Рифкать, бу «һе»нең хуплаумы, әллә өнәп бетермәүме икәнен төшенмәде, шуңа күрә, акланган шикелле тиз-тиз аңлатырга тотынды.

— Киләсе елга барыбер армиягә китәсе. Азрак эшкә өйрәнермен. Беренче эш хакыннан сиңа менә мондый зур бүләк алып кайтырмын.

— Анысы өчен рәхмәт. Слесарь дисеңме әле?..

— Әйе.

— Нигә, бик яхшы һөнәр,— дип сүзгә кушылды әтисе.— Малайның тимер-томырга кулы ятып тора.

— Шулай да бит...

— Кайгырма әле юкка, әнкәй, менә күрерсең, армиядән кайткач та укырга керермен. Ә хәзергә эшче класс булып карыйк. Менә син үзең гомер буе шахтада эшләгәнсең, хәзер — маляр. Исемеңне гел мактап телгә алалар.

— Безнең заманасы бүтән иде, укырга җай чыкмады, ә хәзер бөтен нәрсә җитеш бит.

— Генетика дигән фән белән таныш түгел бугай син, әнкәй. Менә шул фән әйтә, бер нәсел кешеләренең холык-гадәте, төс-кыяфәте — бөтен нәрсәсе буыннан-буынга күчеп йөри ди. Димәк, телисеңме-юкмы, син әллә кайчангы бер бабаңа охшаган булып чыгасың. Ә безнең нәсел, белгәнеңчә, эшчеләр нәселе, игенчеләр нәселе. Шулай итеп, мин әлеге нәселнең бер чылбыры, табигать законының табигый бер чагылышы булып чыгам.

— И-и, әллә нинди сүзләр белән баш болгатып утырасың инде. Алма агачыннан ерак төшми ди, охшасаң, охшарсың икән...

— Миргазиз картка,— дип йомгаклады әтисе.

Рифкать, уйларыннан арынып, тагын күзләрен ачты. Кич житә бугай, кояш нурлары сүрәнләнгән, палата да тоныкланып, бәләкәйләнеп калган сыман. Ята торгач, бик кызык уен уйлап тапты бит әле ул: тели икән, күзләрен генә йома да шунда ук әллә кайдагы кешеләр янына барып чыга, алар белән сөйләшә, күңел юата, тели икән, күз кабакларын гына күтәрә дә мең чакрым ераклыктагы палатага кайтып төшә. Тора-бара бу уен белән шундый мавыгып китте ки, ул хәтта янына кешеләр кереп чыгуын да сизмәде, укол кадаганда гына бераз айнып, нәрсәдер тойгандай булды да тизрәк күзләрен йомып, иксез-чиксез әкияткә охшаган татлы уйлар, истәлекләр, хатирәләр дөньясына ашыкты. Ни гаҗәп бу, элек алай булмый иде, ә хәзер күз алдында бар нәрсә шулкадәр ачык, кул сузымы житәрлек якын булып күренә. Әнә — аларның казармасы. Уртада ара калдырып, ике стена буена тип-тигез тезелгән икешәр катлы караватлар. Һәр ике карават арасында — тумбочка. Тумбочка өстендә — китаплар. Әнә, иң өстә Рифкатьнең кызыл тышлы блокноты ята. Анда — дусларының адреслары, шигырьләр, җырлар язылган. Йокларга ятар алдыннан көн саен диярлек шуны бер актарып чыга ул. Армиягә килгәч тә, әле «ямь-яшел чакта» ук башлаган иде аны. Беренче битенә яшел кара белән солдатның нинди булырга тиешлеге язылган. Политинформациягә әзерләнгәндә бер китаптан тапты ул бу сүзләрне. «Солдат теләсә нинди хәлдә калганда да үз алдына куелган бурычны үтәп чыгарга, моның өчен берни белән дә исәпләшмәскә, кирәк чакта тормышын да куркыныч астына куярга, Ватан намусы өчен, иптәшләре өчен гомерен дә кызганмаска тиеш. Бөек Ватан сугышы елларында мондый канатлы сүз телгә керде: «Үләргә мөмкин, ләкин Ватан приказын үтәмәү мөмкин түгел». Совет солдаты шулай булырга тиеш». Блокнот битенең астына ул десантниклар эмблемасы ясап куйган иде.

Казарма тып-тын. Ишек төбендәге дневальныйның гына вакыт-вакыт таптанып куйганы ишетелә. Казарма түрендә, агачны көйдереп бизәлгән стена буенда, телевизор, күзе ачык килеш аягүрә йокыга киткән солдат төсле, тын гына басып тора.

«Илдус килгәч, әйтергә кирәк, кызыл тышлы блокнотны алып килсен иде».— Анда ниләр язылганын сүзгә-сүз хәтерләсә дә, никтер блокнотын актарып карыйсы килде аның. «Мин, Советлар Союзы гражданины Миргазизов Рифкать...» Ант бирергә әзерләнгән чакта шул сүзләрне язгач, озак уйланып утырган иде. Бигрәк тантаналы яңгырый: Советлар Союзы гражданины. Мәктәптә аны тугызынчы класс укучысы, унынчы класс укучысы, дип йөрттеләр, ярыш вакытында спортсмен дип әйткәлиләр иде, ә авылда Миңниса малае, Шәфкать малае булды. Ә хәзер — Советлар Союзы гражданины. Ничектер күңелгә сыйдырып, мәгънәсен аңлап бетереп булмый бу олы сүзнең.

Ватан алдында тугрылыклы булырга ант биргәч, аларны часть музеена алып килгәннәр иде. Музей каршындагы аллеяда унике батырның, унике Советлар Союзы Героеның барельефлары уелган стена тора. Командир алар хезмәт иткән частьның хәрби традицияләре, часть узган данлы сугыш юлы турында сөйләде. «Бу традицияләр бүгенге көндә дә дәвам итә,— диде прапорщик һәм музей түренә узып, утны кабызды.— Менә монда — тыныч вакытта батырлык кылган десантниклар турында сөйләүче экспонатлар».

Стендтан нәкъ Рифкатьнеке төсле форма кигән, аның яшьләрендәге ике егет елмаеп карап тора. Сурәтләре астына эре хәрефләр белән болай дип язылган:

«Гвардия старшинасы Савченко Анатолий Иванович, 1953 елда туган, ВЛКСМ члены, беренче класслы специалист, Совет Армиясе отличнигы.

Гвардия өлкән сержанты Котло Виктор Владимирович, 1954 елда туган, ВЛКСМ члены, беренче класслы специалист, Совет Армиясе отличнигы.

Хәрби һәм политик эштәге зур уңышлары, югары хәрби осталыклары һәм авыр һава десанты техникасын «дошман» тылына төшергәндә күрсәткән батырлыклары өчен комсомолецлар А. Савченко һәм В. Котло Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнде».

Рифкать үз күзләренә үзе ышанмады. Күктә тургайлар сайрап торган тып-тыныч заманда ничек итеп шундый зур батырлык эшләде икән соң алар? Армиядә төрлесе булырга мөмкин: автоматтан да аталар, граната да ыргыталар, туплар да гөрселди, самолетлар да сызгырып оча, танклар да җир селкетеп йөри,— чын сугыш бара диярсең. Ләкин шул чак игътибар белән тирә-ягыңа карасаң, полигон читендә чайкалып утырган игеннәрне, зәп-зәңгәр тыныч күк йөзен күрәсең дә бу хәрби өйрәнүләрнең, ни әйтсәң дә, ул киноларда күргән, китапларда укыган, бабасы сөйләвеннән ишетеп белгән чын сугыш түгеллеген, ә, бәлки, бик зур һәм кирәкле, бик җитди уен гына икәнен аңлыйсың. Нәрсәсе беләндер ул бала чакта уйнаган сугыш-сугыш уенын да хәтерләтә кебек. Бәләкәй чакта, уйный торгач, чынлап сугышып киткән чаклары да еш була иде. Чөнки уенга бирелеп, кызып җиткәч, уйный торган иптәшең чын-чыннан дошман булып күренә башлый. Монда алайга ук барып җитми җитүен, ни әйтсәң дә, балачага түгел бит, солдатлар. Ә шулай да өйрәнүләр вакытында кайчак, үзең дә сизмәстән, онытылып китәсең, әгәр инде шундый чакта каршыңда чын дошман да торса, үз-үзеңне аямыйча, өстенә ташланасыңа бер шигең дә булмый.

Наполеон заманыннан калган мылтыкларны караганда да, төрле револьверлар, пистолет-наганнар, автоматлар, туплар, сугыш трофейлары белән танышканда да Рифкать һаман шул турыда уйлады. Музейдан чыгып казармага кайткач та, елмаеп карап торган ике егет сурәте күз алдыннан китмәде. «Димәк, солдат хезмәте — сугыш-сугыш уены гына түгел. Орденны юкка бирмәсләр иде. Сугыш вакытында да теләсә-кемгә бирмәгәннәр аны»,— диде ул эчтән генә үз-үзенә.

## 17

Нәрсәдер шапылдаган тавыш ишетелде. Ишек ачылып ябылган икән. Гөр килеп палатага берничә кеше килеп керде.

— Шушымыни инде безнең герой? Берәр җире тырналган мәллә? Хәзер без аны...— Түгәрәк йөзле, итләч борынлы, ак башлыклы врач, Рифкатьнең ыклап ятуына ышанмаган кебек, шаяра-көлә урындыкка килеп утырды. Баш бармаклары белән аскы күз кабакларын тартып карады: Бер дә врач димәссең, нәкъ шәһәр ашханәсендәге пешекче абый инде.— Шактый бәргәнсең икән шул. Сакларга кирәк иде, нәрсәне-нәрсәне, ә башны сакларга кирәк иде.

— Куркак кеше генә арты белән суга керә бит, иптәш доктор,— дип кыяр-кыймас кына сүз катты шундый ук ак халат, ак башлык кигән аксыл-сары йөзле егет.

— Батыр кеше башы белән утка керә дисеңме?

— Әйе.

— Анысы дөрес. Егет кеше утка да керсен, суга да төшсен — шуңа күрә «җегет» дип атаганнар аны. Ләкин исән чыксын!— Шулай дип кистереп кенә әйтте дә, тавышын йомшата төшеп, Рифкатькә эндәш-

те:— Ә син борчылма, күпкә түзгәнне азга гына түзәрсең. Эчендәге юк-бар уйларыңны чыгарып ташла. Кара аны, берсен дә калдырасы булма, башыңны ачкач, барыбер күрәм мин аны, миннән яшерә алмассың. Без аны — момент, ачып тимер-томырын алабыз да шалт итеп ябып куябыз. Сизми дә калырсың. Ярый, син әзерлән. Без киттек.

Рифкать идән шыгырдаганны гына ишетте, күзләрен күтәреп карыйсы килмәдеме, әллә хәле киттеме — тавыш-тынсыз, бер хәрәкәтсез ятуында булды.

«Исән чыксын!»— диде врач. Әйтүе генә җиңел. Андый чакта ничек чыгасыңны уйлап торып буламыни? «Ачабыз да ябабыз»,— ди. Алай җиңел генә булыр микән? Алар шаяргач-көлгәч тә, Рифкать үз хәлен үзе генә белә. Авыртуны басам дип көчәнә торгач, тешләре сызлый башлады инде. Күңел дә болгана. Әллә дару исеннән инде? Тәрәзәне ачсыннар иде, ичмасам. Врач апа да чыгып киткән. Ул да арыгандыр инде. Тәүлек буе яныннан китми утыра бит бичара. Артык сөйләшми дә, борчырмын, дип уйлый, ахрысы, моңсу күзләре белән аңа карый да шулай сәгатьләр буе тик утыра. Тәрәзә артында сәрби куаклары арасыннан алсу күк йөзе күренә. Кояш инде йортлар артына кереп югалган. Димәк, монда төгәл бер тәүлек ята. Авыру кешеләргә гомер бик озын тоеладыр ул. Әллә кирәсенчә микән? Шулайдыр. Аларга әле яши дә башламаган кебектер, бөтен гомерләре— киләчәк матур-матур гомерләре алдадыр, ә монысы яман бер төш, саташу, табигать ялгышы кебек кенә тоеладыр. Ә минем хәл башкачарак бит. География дәресендә узган субүлгеч кебек кенә. Субүлгечнең бер ягында — кояшлы тау итәгеннән челтерәп агып төшүче саф сулы чишмә төсле унтугыз ел гомер, ә икенче ягында — икенче тау итәге. Ләкин ул ягында нәрсә булыр, нинди сулар агар анда? Әллә караңгы упкын булырмы? Хәзер ул кояшлы тау итәгенә таба йөз белән басып кыяташ өстендә тора. Ә артка, дөресрәге, алга, киләчәгенә, киләчәк гомере ягына борылып карарга курка. Борылып карауга, төпсез упкынны күреп, башы әйләнер дә шунда очар төсле. Ничек кенә булса да шушы таш кыядан ычкынмаска кирәк, тырнаклар белән ябышып булса да торырга, ләкин егылмаска, түзәргә, бирешмәскә кирәк!

Ничек булды соң әле бу? Өйрәнүләр дә үткән, барысы да исәнсау, ә мин монда ятам. Врач дөрес әйтте, болай юк-бар нәрсә уйлап, үземне газапламаска кирәк. Онытырга, барысын да онытырга!

Я, булмаса, врач әйтмешли, яхшырак нәрсәләр хакында уйларга кирәк...

Самолеттан сикерүгә баш очында шартлап ак гөмбәз ачылудан да рәхәт нәрсә юктыр бу дөньяда!

## 18

Самолеттан сикерүгә, ул җил тыгызлыгыннан, җил ачылыгыннан саклану өчен, ирексездән күзләрен йомды. Нәрсәгәдер таянырга теләп, тырыша-тырыша аякларын аска суздьі, куллары белән тотынып җир эзләде. Берни дә таба алмагач, нәрсә булса, шул булыр дигәндәй, бөтенләй битараф калды. Ләкин бу битарафлык озакка бармады, күңелгә бер-бер артлы шомлы уйлар килә башлады. Гүя ул шаулап агучы тау елгасына егылып төшкән дә ярга чыга алмыйча ага да ага.

Рифкать, колач җәеп йөзәргә теләгәндәй, кулларын бутап алды да, гәүдәсе, ныклыгын югалтып, бөтерелә башлавын сизгәч, күзләрен ачты. Аста бик зур тәлинкәгә охшаган түгәрәк күренде. Кинәт, аңа ул үзе аска таба төшми, ә күлләр-елгалар, басу-кырлар, авыл-калалар тезелгән шушы гаҗәп зур тәлинкә, Җир атлы тәлинкә күзгә күренеп якыная, өскә таба очып килә кебек тоелды.

Менә кызыл көчеккә охшаган кояш астан гына үрелеп алсу теле белән тәлинкәнең бер читен ялый башлады. Көчек-кояш башын күтәргән саен, аның кызыллыгы сыегая. Ул әкренләп үзенең алтын-сары төсенә керә бара — әйтерсең, кемдер аны ялгыш кызыл буяулы чиләккә төшергән дә хәзер, кеше-кара күргәнче дип, ашыга-ашыга сөртә иде.

Җылы кояш нурлары тыгыз һава белән өретелгән, шартларга җитеп киерелгән гөмбәз аша узып, салкын шәмәхә төскә керде. Күк йөзе тулы — шәмәхә гөмбәзләр. Күзне кысыбрак карасаң, ниндидер җан ияләре болыт мендәрләргә эленеп торган кебек күренә. Рифкатьнең шулчак җырлыйсы килеп китте.

> Фәрештәдәй күктән төшә дә ул,
> Җен шикелле керә сугышка...

Бүген аларга, чыннан да, җен кебек чабарга туры киләчәк. Рифкать сул кулы белән автоматын капшады. Җир, тәлинкә формасын югалтып, гадәти җиргә әйләнеп калды. Аста — куе яшел төстәге дала. Анда-санда, төрле зурлыктагы күзге ватыкларына охшап, күлдәвекләр ялтырый. Ике көн тоташ яуган яңгырдан соң җир әле кипшерә дә башламаган. Кояш нурлары, яңа гына йокысыннан торып, юынырга җыенган малай кебек, иренеп кенә, теләр-теләмәс кенә күлләвекләрдә коена. Рифкать башын күтәреп кенә карады: зәңгәр күк йөзен исәпсез-сансыз гөмбәзләр чуарлаган, хәтта кояш та болыт арасыннан башын тыгып караган сыман күренеп-күренеп кенә китә. Бу гөмбәзләр барысы да төшеп җиткәч, җирдә басар урын да калмас шикелле. Көнбатыш яктан салкынча җил исеп куйды. Әйтерсең, бу хозурлыктан аерылып җиргә аяк баскач, аларны ни көтәсен искәртә иде ул. Әллә инде өстә генә шулай тын булган, төшкән саен җил көчәйгәннән-көчәя бара, парашют гөмбәзенә кереп сызгыра, аны үзенә ияртеп алып китмәк була. Төшеп җитәргә берничә йөз метр калгач, ул бөтенләй чыгырдан чыкты, офык читеннән шактый күтәрелеп өлгергән кояш та, бу минем эш түгел дигәндәй, уңайсызланып кына елмая. Ә җил һаман саен котыра, парашютны йолкып-йолкып ала, өреп сүндерергә теләгәндәй, кояшка ташлана, ә кояш, җил искән саен гаҗәеп зур утлы күмердәй кызара да яңадан күксел элпә белән капланып, тоныкланып кала. Җир өстенә шомлы караңгылык иңә, колак төбендә улаган җилдән күңелләр чымырдый. Әле генә шундый тыныч, шундый матур дөнья, кемдер авырткан сөяленә баскандай, өзгәләнә, ачуын кемнән алырга да белмичә, ачы җиле белән юлында очраган һәр кешенең битенә китереп бәрә, дала буйлап чәчелеп яткан күлдәвек көзгеләрен шадралатып уза, үләннәрнең башын җиргә бәрә-бәрә кыйный. Әйтерсең, аста, иге-чиге күренмәгән дала эчендә чыннан да мәхшәр купкан, әйтерсең, анда хәрби өйрәнүләр түгел, ә чын сугыш бара. Командир: «Өйрәнүләр сугыш шартларына якын китереп үткәреләчәк», — дигән иде. Анысы шулайдыр, ләкин бу давыл да командир приказы белән килмәгәндер бит.

Менә кояш бөтенләй күздән югалды. Парашют гөмбәзе хәтле генә болыт астыннан кояш озакламый яңадан килеп чыкты, ләкин аны болытның икенчесе — зуррагы каплады. Офык ягыннан, көннең тәмам бозылганлыгына шик калдырмыйча, өем-өем болытлар агыла иде. Бер караганда алар «дошман» десантникларына охшап күренә, әйтерсең, уңай вакытны гына көтеп торганнар да менә хәзер хәйлә белән артка төшмәк булалар.

Рифкать үз уйларыннан үзе көлеп куйды һәм, җиргә якынлашуын күреп, автоматын кулга алды. «Та-та-та. Та-та-та». Кемдер алданрак өлгерде, ул тәтегә басканчы ук автомат тавышлары яңгырады, күктә бер-бер артлы «урра!» кычкырган авазлар ишетелде. Җирдә атканда алай булмый иде: автомат иңбашына китереп бәргән саен, гәүдә артка таба этәрелеп, шуышып китә. Менә аяклар җиргә тиде, Рифкать, тез

буыннарын йомшатып чүгәләде, бер аягы чокырга туры килеп, гәүдәсе чайкалып китте, ләкин егылмады, күн итек астыннан чәчрәп чыккан су өскә сибелде. Ул, сул кулына автомат тоткан килеш, уң кулы белән битендәге мәтеле суны сыпырып төшерде дә, җир өстендә тыпырчынып яткан парашют гөмбәзен үзенә таба тартты. Гөмбәз эченә кереп тулган җил, бирешергә теләмичә, парашютны алга өстери, тәгәрәтеп йөртә, ак ефәкне пычрак суга манып-манып ала. Рифкать тиз генә бауларын ычкындыруга, парашют, үпкәләгәндәй, бөтерелә-бөтерелә җиргә төшә калды, ә ул җилгә йөз куеп алга йөгерде. Берничә минуттан батальон җыелу урынында сафка тезелгән иде инде.

— Булдырдыгыз, егетләр! Һавада вакытта ук ут ачып, сез «дошман»ның алгы позициядә торган шартлы көчләрен чигенергә мәҗбүр иттегез. Ләкин «дошман» мәкерле, бик көчле. «Дошман» көньяк-көнбатыш яктан һөҗүм итеп килә, ул бик нык коралланган. Без хәйлә белән аның тылына үтеп керергә һәм житәкчелек итү пунктын кулга төшерергә тиеш. Башка батальоннар, маневр ясап, «дошман»га һич көтмәгән җирдән китереп бәрәчәкләр, ә без, бөтен ударны үзебезнең өскә алып, турыдан һөҗүм итәбез! Десантниклар, алга!

Солдатлар береткаларын бастырып киделәр дә, алга таба иелә төшеп, йөгереп киттеләр. Җил бар көче белән гәүдәне артка этә, автомат көпшәсенә кереп ачы тавыш белән сызгыра, күзләрдән яшь чыгара. Аяк асты тайгак, үзле балчык ябышып, күн итекләр күтәрә алмас хәлгә килде, житмәсә, бер булгач, булсын дигәндәй, йөзгә бәреп яңгыр сибәли башлады.

Иртәнге хозурлыктан соң кинәт купкан бу мәхшәр шундый да урынсыз һәм гаҗәеп тоела, әйтерсең, табигать инде бүген күкне аяз итим, дөньяны ямьләндерим, урман-болытларны, басу-кырларны сөендерим дип, изге ният белән офык капкасыннан кояшны тәгәрәтеп җибәргән дә, күз алдында төтен бөркеп, тирә-юньне дер китереп очучы самолетларны, исәпсез-хисапсыз болыт ертыгына охшаган парашют гөмбәзләрен күргән, һәм, мин сезгә яхшылык теләгән идем, ә сез аңламадыгыз, мәгез инде, алайса, күрмәгәнегезне күрегез дигәндәй, котырынырга, бөтен патшалыгын пыран-заран китерергә тотынган.

Солдатлар чылбыр булып як-якка сибелеп йөгерәләр. Командир, арткарак калган солдатларны дәртләндереп кычкыра, шаян сүз әйтеп ала да кинәт кенә усал һәм таләпчән тавыш белән сөрән сала: «Чылбыр! Чылбырны өзмәгез!»

Рифкать чылбырның уртасында, юл буйлап бара. Танклар, машиналар йөреп, юл инде саз боткасына әйләнгән, урыны белән хәтта күн итекнең куныччы да күренми. Командир аның хәлен аңлый бугай, бер сүз дә эндәшми, бары тик ара-тирә янәшә үк килеп, бергә йөгереп бара да, аны үз урынына калдыргандай, тагын чылбыр читенә китә. Өйрәнүләргә әзерләнгәндә үк берничә солдатны җыеп: «Сез полкта физик яктан да, мораль яктан да — кыскасы, бөтен яктан да иң әзерлекле солдатлар. Шуңа күрә өйрәнүләр вакытында бүтәннәрне үз артыгыздан ияртергә, иң кыен җиргә башлап керергә тырышыгыз. Десантниклар өчен иң кирәк нәрсә: физик көч, теләсә-нинди шартларда да югалып калмау, тиз ориентлаша белү һәм рухи яктан нык булу. Мин сезгә ышанам!» — дигән иде командир. «Сезгә ышанам», — дип әчтән генә кабатлады Рифкать. — Миңа ни өчен миңа сүз катмый икән ул».

Инде маневрга киткән батальоннар да күптән күренмәс булды, аяклар кайнар суга тыккан шикелле кызышты, бөтен тәннән пар күтәрелә башлады. Ә «дошман» юк та юк. Ниһаять, командирның кырыс тавышы яңгырады: «Туктарга! Унбиш минутлык ял».

Ләкин тирә-юньдә ышыкланырга, җилдән качып сыенырга, баш төртергә ник бер агач, ник бер куак булсын! Әллә нинди җанвар

авазлары чыгарып үкерүче җил дә, шәрә яланны ярсый-ярсый чәбәкләүче рәхимсез яңгыр гына.

— Кил монда, палатка корабыз! — дип кычкырды аңа Володя Ищенко. Володя — музыкант егет, торбада уйный. Гитарада уйнаганга, җыр яраткангадыр инде, Рифкатьне гел якын итә ул, бәхәс чыкса да, гел аны яклый, һәрчак булышырга гына тора. Әллә торбада уйный-уйный мускуллары тартылган, әллә тумыштан ук шулай булган — ике як яңагы, авызына йомырка капкан шикелле, кабарып тора.

Рифкать, поты-поты саз пычрагы ияргән аякларын өстерәп, палатка белән кайнашучы Володя янына килде.

— Нинди палатка кору ди ул? Унбиш минуттан кузгалабыз бит. Корып та булмый аны, бу җилдә.

Володя каршы сүз әйтмәде, палатканы җиргә җәйде дә кайтарып өстенә япты.

— Бөркәнеп кенә утырабыз, кил!

Ләкин җил аларга иркенләп утырырга ирек бирмәде: әле палатканы баш өстеннән каерып ыргытты, әле, бөтерелеп килеп, яңгыр тамчысы белән йөзгә сыпырды. Йөгереп манма тир булганнар иде, хәзер менә тән буйлап салкын тәпиле бөҗәкләр чабыша башлады, аннары, тешләр тешкә тиеп, калтыратырга ук тотынды. Ярый әле шулчак күтәрелергә команда булды, юкса, Рифкатьнең аяклары да оеп, кузгала алмас хәлгә җитеп килә иде.

Сикереп тордылар да тагын «атакага» ташландылар. Рифкать үз урынына, соры тасма булып сузылган баткак юлга чыкты. Дерелдәп торган салкын үзле балчык аякларны суырып-суырып ала. Кырыйдан йөгерүчеләргә бераз җиңелрәк, анда әле җир алай ук актарылмаган, болгатылмаган — суы сулай, җире җирләй аеры тора, шуңа аякка да алай ук иярми. Ләкин җиле барыбер шул ук җил инде...

Рифкать, аяк тавышлары ишетеп, борылып карады. Егерме метрлар чамасы гына артта юлның ике як чите буйлап генерал белән полк командиры килә. Алардан аз гына алдарак — өлкән лейтенант Киреев.

Рифкатьнең ару-талулары кинәт юкка чыккандай булды, ул барган уңайга аягындагы ләмне кагып төшерә-төшерә иптәшләрен куып җитәргә ашыкты.

Генерал киләсе дип сөйләгәннәр иде инде аларга. Ләкин менә шулай, һич көтмәгәндә янәшәдә күрермен дип уена да кертмәгән иде Рифкать. Җил-давылга, яңгырга карап тормаган, полигонга чыккан. Хәер, нәрсәгә шаккатырга, заманында генерал да солдат булган бит, сугышта мондыйларны гына күрергә туры килмәгәндер аңа.

Әллә инде йөгерә торгач җылынды, әллә арттан командирлар килүен сизеп торганга шулай булды — Рифкатьнең җилкәсе буйлап җылы май агып төшкән сыман тоелды. Алда «дошман» күренгәндә ул инде җил-яңгырны да сизмәс дәрәҗәгә җиткән, аның бөтен тәне утлы йомгак төсле кызышкан иде. Шулчак һавада ракета кабынды, алдан киткән батальоннар «дошман»ның тылына төшкәннәр иде, ә Рифкатьләр батальоны «маңгайдан» китереп бәрде.

Ләкин, «идарә итү пункты» алынгач та, «дошман» бирешергә теләмәде, үзенең резервын кертеп, соңгы көче белән һөҗүмгә күчте. Монысы инде — иң соңгы, иң хәлиткеч бәрелеш иде.

## 19

— Гранаталарны әзерләргә! — Командирның җан ачысы белән ертылып кычкырган авазы, яңгыр пәрдәсен үтеп, солдатларга ишетелде.

Рифкать, саз чапылдатып йөгергән уңайга, гранатасын алды. Каршы искән җил керфекне күтәреп карарга да ирек бирми, тир белән кушылган яңгыр суы, маңгайдан агып төшеп, ачыттыра-ачыттыра күзгә керә. Бөтен тән: баш та, аяклар да, куллар да, гәүдә дә ут яна, хәзер менә атылып барган шәпкә танк астына ташланса, аның кызуыннан танк яна башлар сыман. Бары тик кулдагы граната гына, салкын бака кебек уч төбен кытыклап тора. Бу кытыршы салкын тимерне тизрәк «дошман» өстенә ыргытасы, тизрәк аннан котыласы, бу игечиге булмас төсле тоела башлаган мәхшәрле көнгә чик куясы килә. Мәрхәмәтсез җил дә, бөтен тәнгә генә түгел, хәтта үзәкләргә үтеп яуган яңгыр да шушы күз алдына аның китереп булмый торган шартлы дошман эшедер, ул дошманны җиңүгә җил дә басылыр, яңгыр да туктар һәм, болытларны куа-куа, түгәрәк йөзле, ерык авызлы көләч кояш та килеп чыгар төсле.

Рифкать граната бөҗрасын тартты да, уң кулы белән кизәнеп, артка каерылды. Бөтен көчкә киерелүдән мускуллар зыңлагандай булды. Хәзер... хәзер... граната «дошман» өстенә очачак. Ул, аякларын саздан суырып чыгара-чыгара, алга атлады. Каршыда бәләкәй генә тауның калкып чыкты. Хәзер... менә шул калкулыкны гына үтә дә... Кинәт аның сул аягы һавада асылынып калды. Нәрсә булды, әллә башы әйләнәме, әллә аягы оеды да берни сизмиме? Ул, җир катысын тоярга теләгәндәй, гәүдәсенең бар авырлыгын сул аягына күчерде һәм, тигезлек саклый алмыйча, янтаеп китте. «Чокыр! Аяк чокырга туры килгән!» Яшен тизлеге белән ялтырап куйган уйдан баш мие бер мизгелгә яктырып киткәндәй булды, күздән утлы инәләр чыгып очты. Ниһаять, сул аяк җирне эзләп тапты, ләкин тотынып кала алмады, таеп китте, һәм Рифкать таучык итәгенә барып төште. Уң кулының терсәге чыкылдап ниндидер каты әйбергә бәрелде, бармаклары ирексездән язылып китте... һәм граната җиргә тәгәрәде. Рифкать, ни булганын үзе дә аңламыйча, граната өстенә ташланды, эләктереп алды да аны учына кысты. Шулчак баш миен өтеп, көйдереп утлы өермә узды. Ул, сытып юкка чыгарырга теләгәндәй, гранатаны һаман саен ныграк кысты. «Дүрт секунд!..»— дип пышылдады ул. Рифкать граната тотып тезләнгән җиреннән сикереп торды: тәндәге бөтен ару-талулар, сыпырып алгандай, юкка чыккан иде. «Тизрәк!» Тизрәк!»— дип типте йөрәге. «Тизрәк! Тизрәк!»— дип исте җил. «Тизрәк! Тизрәк!»— дип колагында кайтаваз яңгырады, колагы чыңлады. Кинәт, алда, калкулык артында, җир астыннан калкып чыккан кебек солдатлар пәйда булды. Әле генә мишень белән ике арада буш ялан иде бит... Әллә миңа гына шулай күренәме, дип ул күзләрен бер йомып, бер ачып карады. Әйе, алда, аннан ерак та түгел, солдатлар, десантниклар йөгерә иде. «Туктагыз!»— дип кычкырырга һәм, бар көченә йөгереп барып, гранатаны алар алдына томырыргамы? Юк! Юк! Дөньяларын онытып алга омтылучы десантниклар аның тавышын ишетмәсләр, ишетсәләр дә, аңламаслар.

Дүрт секунд...

Дүрт секундтан граната шартлаячак! Кая куярга, кая яшерергә, кая томырырга аны? Әгәр тигез, коры җир булса, йөгереп килеп кизәнер иде дә, әллә кая еракка очырыр иде. Юк, йөгереп булмый, йөгерү түгел, батман-батман үзле балчык өстерәгән итекләрне урыннан кузгатулары да кыен. Нишләргә? Алга ыргытырга ярамый, алда— солдатлар, алда — аның иптәшләре. «И-их, — дип, тешләрен шыгырдатты Рифкать.— И-их!» Граната ыргыту буенча частьта беренче урынны алгач, командир аны бөтен солдатлар каршында мактаган иде. «Миргазизовка гранатомет та кирәк түгел, ул болай да гранатометтан ераграк ата», — дип шаярткан иде. Хәзер күрсә...

Рифкать, граната тоткан кулын баш очына күтәргән килеш, уң якка борылып карады. Анда да, берни булмагандай, «урра!» кычкыра-кычкыра солдатлар бара. Күз алмалары атылып чыгар дәрәҗәгә җитеп киерелде, йөрәк ярсып-ярсып типте. Нишләргә?

Дүрт секунд!

Рифкать аптырау һәм сорау катыш күзләрен сул якка төбәде. Чылбыр булып сузылган десантниклар алдагы «дошман»нан башка бер нәрсә дә күрми чаба да чаба. Йөрәк тибеше аермачык булып чигәгә бәрә, бармак очларын чәнчеп-чәнчеп ала.

Дүрт секунд! «Секунд! Секунд!» дип тибә йөрәк.

Рифкать, башын борып, артка карады һәм кул сузымы гына җирдә, үзеннән егерме метр чамасы гына ераклыкта, олы-олы атлап килүче генералны, аңа нәрсәдер аңлатып, колагына иелгән полковникны, майор белән өлкән лейтенантны күрде. Атылып чыгарга җитешеп типкән йөрәк тагын бер тапкыр: «Секунд»,— дип куйды да тын калды, әйтерсең, бөтенләй эреп юкка чыкты. Әллә кайдан астан, күңел түреннән ачыттырып, бөтен тәнне куырып ниндидер дулкын күтәрелә. Менә ул күкрәк турын яндырып узды, менә ул бугазга килеп тыгылды. Рифкать бер мизгелгә генә күзләрен чытырдатып йомды. Ул нидер уйларга, нәрсәдер исенә төшерергә тырышып көчәнде. Ләкин бер әйбер дә хәтеренә килмәде; бар дөнья, бөтен истәлекләр, барча дуслар һәм якын кешеләр урыннарыннан купканнар да бергә җыелып өстән, күктән, тын гына, сүзсез генә карап торалар төсле.

Рифкать соңгы мәртәбә як-ягына күз йөртеп чыкты. Аның тирәсендәге боҗра кысылганнан-кысыла гына бара иде. Алда һәм ике якта — десантниклар, артта — командирлар. Ул, граната ыргытырга урын эзләгәндәй, аптыраудан күккә күтәрелеп карады. Анда кайнап, ярсып, әллә нинди коточкыч кыяфәтләргә кереп болытлар актарыла. Кинәт кенә аның күккә күтәрелеп китәсе, шул болытлар арасына кереп адашасы, югаласы килде. Шулчак тамак төбендә буылып торган утлы дулкын әкрен генә юл ярып баш миенә тула башлады һәм тиздән аның башы утлы тубалга охшап калды. Рифкать инде берни күрми дә, берни сизми дә иде. Бары тик кайдадыр, күңел түрендә генә әйтеп аңлатып булмый торган үпкәләү һәм аптырау, ачу һәм үҗәтлек катыш бер хис туып кила. Ул, бөтен тирә-юньне, иксез-чиксез даланы, бар дөньяны яңгыратып нидер кычкырырга теләде, ләкин кирәкле сүз табылмады, тамак төбеннән ыңгырашуга охшаган «аһ» авазы гына чыкты. Онытылып торган йөрәк тагын уянды, тагын атылып-атылып тибәргә тотынды, салкын граната, кызганнан-кыза барып, уч төбен, бармакларны көйдерде. Рифкать җан ачуы белән кулын суырып китерде дә күкрәгенә кысты һәм, кемнәндер гафу үтенгәндәй, җиргә тезләнде. «Хәзер! Хәзер!»— дип пышылдады ул. Йөрәге бөтен гәүдәсен селкетеп тибә, бөтен дөньяда шул йөрәк тибешеннән башка бер нәрсә дә юктыр кебек. Яңгыр суы бит буйлап ага. Әллә күз яшьләре инде? Юк, ул елый алмый, аның күңеле каткан, бары тик баш миенең бер почмагында гына сөенечкә дә, горурлыкка да охшаш бер юләр уй кисәге генә шарчык төсле тәгәрәп йөри. Ниндидер куркыныч нәрсә буласын сизенгән, шуны туктатып калырга, булдырмаска тырышып та көченнән килмәгәнен аңлаган табигать елый, болытлар елый, өстәгеләр елый.

Кинәт, караңгы күкне чәрдәкләп, яшен яшьнәгәндәй булды, җир гөрселдәде, аяк астындагы дала бер якка таба шуышып китте дә томан арасына кереп, юкка чыкты. Рифкать бер мәл, һичнәрсә аңламыйча, һавада асылынып торды, аннары салмак кына каядыр аска, төпсез упкынга төшә башлады. Төшкән саен дөнья караңгылана барды, күз алдында бөтерелеп торган утлы шар сүнде, колаклардагы гөрселдәү шавы тоныкланды...

## 20

— Дусларың килгән.

Рифкать врачның упкын төбеннән килгән тавышын ишетә, ләкин җавап бирергә кирәкме-юкмы икәнен аңламый, күзләрен күтәреп карамый, аңа хәзер тирә-юньдәге бар нәрсә буталган, үзенең элекке әһәмиятен, мәгънәсен югалткан кебек тоела, әйтерсең, ул монда кадәр аңына килә алмыйча, үлем исереклеге белән саташып яткан да менә кинәт кенә үзенең ни эшләгәненә, нинди хәлдә калганына төшенгән иде.

— Дусларың килгән, Рифкать...

Ә мин монда әллә ниләр искә төшереп, хыялланып ятам, дип уйлады Рифкать. Бөтенесе беткән, бөтенесе артта, граната шартлавы артында калган иде. Хәзер... бары тик саубуллашып кына була... Хыяллар... Кирәк түгел. Дуслар да... саубуллашырга килгәндер. Округ госпиталеннән хирург чакыртмаслар иде. Димәк...

Рифкать, һәр нәрсәнең шулай кинәт кенә яңа төсмер алуына гаҗәпләнеп, мыскыллы елмаерга уйлады, ләкин елмаю барып чыкмады, бит мускуллары, иреннәре аны тыңламады.

Ишек ачылып-ябылды. Солдатлар, кемнедер йокыдан уятудан курыккан сыман, аяк очларына гына басып, Рифкать янына якынлашалар. Аларга үч иткәндәй, аяк атлаган саен, тешләрне камаштырып, идән шыгырдый. Менә алар карават янына тезелешеп бастылар да, ни әйтергә белми тик торалар. Сүзне, ниһаять, Вагыйз башлады. Ул көчәнүдән кызарынып, бүртенеп чыкты, дугаланып торган кара кашлары уртадан сынды, күзләре кечерәеп, сүрәнләнеп калды.

— Нихәл, Рифкать!

Әйтте дә, мәгънәсез сүз ычкындыргандай, бер урында таптанырга тотынды, бармаклары белән гимнастерка төймәләрен барлап чыкты. Рифкать, иреннәрен кыймылдатты, ләкин сүз чыкмады, аннары, минем хәлне үзең дә күреп торасың дигәндәй, моңсу итеп карады да тагын үз эченә бикләнде. Аның хәле юк иде. Вакыт үткән саен, ул мускулларында кайнаган көчнең кими баруын, ком сәгате төсле каядыр агуын сизә. Менә ул агар-агар да бер заманны бөтенләй бетәр, бөтенләй юкка чыгар төсле. Баш миенең бер почмагына кереп оялаган шомлы уй бераз гына онытылып тора да тагын тырмаша башлый, өскә чыга, аннары бөтен күңелне актарып ташлый. Юк, үлем куркытмый аны. Ни өчен алай эшләгәненә дә үкенми, шулай иткән икән, димәк, дөрес эшләгән, димәк, аның башка юлы булмаган. Тумаган кеше генә үлми диләр бит... Билгеле, әле яшәргә дә яшәргә иде. Армиядән кайтып әти-әнисен сөендерәсе, дуслар белән бергә урам тутырып йөрисе, эшкә урнашасы, укырга керәсе, ныгытып гашыйк буласы, гаилә корасы, ниндидер зур эшләр майтарасы иде. Ә ул әле яши дә башламаган иде, әле ул яшәргә әзерләнгән генә иде бит. Туды, үсте, дөресрәге, үстерделәр: киендерделәр, ашаттылар, эчерттеләр, мәктәпкә озатып җибәрделәр, теләге булса үтәделәр. Пионерга керде, комсомол булды, спорт белән җенләнде, музыка-җыр белән шашып йөрде... Ләкин болар барысы да ниндидер зур эшкә әзерлек кебек кенә иде. Армиягә килгәч, аларны ай буе карантинда тоттылар, солдат мәктәбен үткәрделәр, аннары тагын айлар буена парашютны мең сүттереп, мең җыйдырдылар. Бары тик шуннан соң гына самолеттан сикерделәр. Кеше дә шулай ярты гомерен әзерлек хәстәрләре белән үткәрә, бары тик үзендә көч, ныклык, ышаныч сизгәч кенә күккә күтәрелә. Мин кеше гомерен үземчә аңлатам — десантникларча, ә бабай бүтәнчә сөйли иде. Кеше гомере — тау кебек ди иде ул. Кеше тау итәгендә туа да ярты гомере буе өскә күтәрелә, менеп җиткәч, хозурланып як-ягына карана — бөтен дөнья уч төбендәге кебек, бар нәрсә кечерәеп, бәләкәйләнеп кал-

ган, ә ул — зур, ул хәзер теләсә нәрсә эшли алыр, аның кулыннан бар нәрсә дә килер төсле. Ләкин... туктап кала алмый. Вакыт — рәхимсез, вакыт аның аякларын сәгать маятнигы иткән дә алга-артка, артка-алга йөртә, ул ирексездән хәрәкәт итәргә мәҗбүр, ул ирексездән атлап бара. Кеше башта кая барганын да аңламый тора, аннары, кинәт кенә аңлап ала да аякларын терәп түбән төшмәскә тартыша, ә маятник туктамый, алга-артка, артка-алга йөри дә йөри. Тау төшкән саен кешенең күңеле дә төшә, аңа шул ук агачлар да, шул ук үләннәр дә, шул ук чәчкәләр дә бүтән төсле булып, теге яктагылардан кайтышрак булып күренә, дөнья да караңгылана барган сыман тоела. Аның күз аллары томалана, ул алдындагы әйберләргә игътибар итми, һаман-һаман теге як тау итәген, андагы кояшлы аланнарны, чыклы үләннәрне, сайрар кошларны — тауга менү ләззәтен искә төшерә, бары шуның белән генә яши...

## 21

Кинәт Рифкать сискәнеп китте... Ул да бүген көне буе балачагын, үткән көннәрен уйлап ятты бит. Ул да тау төшә микәнни? Юк, ул әле тауга менеп тә җитмәгәндер... Менеп җитә алмыйча егылып төшкәндер. Аның күз алдына аерымачык булып тау килеп басты. Менә алар, альпинистлар кебек бер бауга тезелешеп, кыяга үрмәлиләр. Бау очында: Вагыйз, Тансык, Илдус, Володя, Юра, астарак: генерал, полк командиры, өлкән лейтенант, ә уртада — Рифкать. Менә аягы таеп китте дә ул упкын өстендә асылынып калды, иптәшләре дә, командирлар да, нишләргә белмичә аптырашып карап тора. Берничә секундтан алар барысы да упкын төбенә очачак. «Юк! — дип кычкыра Рифкать,— Юк!» Һәм кесәсеннән пычак алып үзен бәйләгән бауны кисеп җибәрә, зур бау тартылудан зыңлап куя һәм Рифкать аска, упкын төбенә оча.

— Аһ!

Ул, тотынып калырга теләгәндәй, сул кулын һавада бутады һәм, кулы ниндидер җылы әйбер тапкач, күзләрен ачып җибәрде. Илдус аның өстенә иелгән дә кулын кыскан килеш ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдый иде:

— Рифкать, тынычлан, Рифкать, без монда.

Томан эченнән әкрен генә Вагыйз килеп чыкты, аннары Тансык күренде, аннары — Юра...

— Әйе... — диде Рифкать.

Ул — әле яртылаш кына монда, яртылаш әле ул үзенең уйлары дөньясында иде. Шуңа күрә бу «әйе»нең нәрсәгә әйтелгәнен дә аңлап бетермәде: менә килеп тә җиттек, таудан түбән тәгәри башладык, дияргә теләдеме ул, әллә, янында дусларын күреп, әйе, мин сезне күрәм, әйе, мин исән, мин сезнең белән бергә яшәячәкмен әле, дип расларга уйладымы? Аның уйлары хәзер соң чиккә җитеп буталган, әйтерсең, баш сөяге эченә умарта күче оялаган иде. Күчнең гөжләве көчәйгәннән көчәя бара, кортлар, ирекка чыга алмаган ачудан, яндырып-яндырып тешлиләр, чыгарга юл эзлиләр сыман.

Врач килеп укол кадагач, умарта күченең гөжләве басыла төште, һәм Рифкать үзе янында кешеләр бар икәнен исенә төшерде.

— Ә син артык үзгәрмәгәнсең. — Тансык болай да зур авызын җәеп җибәрде, күзләре урынында кара сызык кына калды.

Рифкатьнең инде иртәдән бирле үз-үзен күрәсе килә иде. Йөзен генә ачык калдырып, башын бәйләгәннәр — анысын сизә, ә менә күзләре, борыннары, кашлары, авызы, бите нинди икән. Берничә тапкыр врачтан көзге сорарга да җыенды, ләкин никтер җөрьәт итмәде. Менә... хәзер җае чыкты.

— Көзге... — дип пышылдады ул. — Үземне күрәсем килә.

Илдус кабаланып, гимнастеркасының түш кесәсенә тыгылды, тик шулчак, Вагыйзьның күз карашын күреп, акрын гына кесәсен яңадан төймәләде, кулын кая куярга белми аптырап торды да береткасын әвәли башлады. Рифкать аның бу хәрәкәтен күрде, һәм мөлдерәп тулган чиләк өстенә бер тамчы тамганнан соң ташып түгелгән су төсле, күңелендәге ачыну хисе бөтен күзәнәкләренә таралды. Илдус та, Вагыйз да — барысы да ул белмәгән ниндидер яшерен һәм коточкыч бер серне беләләрдер, бары тик аннан гына яшерәләрдер, аңа гына әйтмиләрдер төсле тоелды аңа.

— Без чиратлап синең янда утырырга теләгән идек. Врач рөхсәт итми, — диде моңа кадәр бер читтә сүзсез генә торган Юра. Ул, гомумән, күп сөйләшергә яратмый, авыз эченнән генә һәрчак нидер көйләп йөри, кеше сүзенә кушылып китми, бары тик иң кирәкле урында, инде сүз әйтмәскә мөмкин булмаган җирдә генә бер-ике сүз ыргыта да тагын көйли башлый. — Операциягә кадәр ярамый, диделәр.

— Тыш-та... җы-лы-мы? — дип, әйтергә җиңел булсын өчен, һәр сүзне иҗекләргә бүлә-бүлә сорады Рифкать. Егетләр, сүзнең палатадан тышка чыгуына куанып, бер мизгелдә балкып киттеләр, аларның йөзләренә нур кунды.

— Җылы!

— Шундый шәп!

— Әй, һавасы да һавасы, сулап туярлык түгел.

— Аяк асты да корыды.

— Бөтен җирдә — җиләк тә җимеш, шартлаганчы ашадык.

Егетләр, берсен-берсе бүлдереп көнне мактый, алар сөйләгән саен Рифкать тә үзен суырып торган куркыныч уйлар баткагыннан чыга бара, ул да алар белән бергә сөенә, аның да җаны талпына башлый. Вагыйз бөтенләй кызып китте, ул, пышылдавын онытты, шау-гөр килергә тотынды, аннары кинәт кулын җәеп җибәрде.

— Ә-әй, егетләр, оныттык түгелме соң? Рифкатькә кучтәнәч алып килдек бит без. Кая әле, Илдус.

Илдус урындыктагы төргәкне сүтеп җибәрде.

— Бу шапталларны ашасаң, терелмәс җиреңнән терелерсең, — дип тезеп китте Вагыйз. — И-һи, безнең якта инде ул шапталлар — телеңне йотарлык. Менә, өйгә генә кайтыйм...

— Кайтырсың да безне онытырсың әле, — дип, юри генә үпкәләгәнгә салынып, Тансык аның сүзен бүлде.

— Минме онытам, минме!

Шулчак Юра да сүзгә кушылырга булды:

— Әйдәгез, егетләр, хәзер үк килешеп куябыз, — диде ул. — Армиядән кайтып, бер ел узгач, отпускаларны бергә туры китереп алабыз һәм кайда да булса очрашабыз. Мәсәлән, беренче елны бөтенегез дә миңа кунакка киләсез, Ярославльгә. Мин сезгә шәһәрне күрсәтермен, безнең шәһәр бик борынгы ул, һәр йорты музей кебек, хәзерге шырпы каплары түгел. Ә бездәге кызларны күрсәң, кызларны...

— Кызлар кайда да бар ул, — дип исе китмичәрәк кенә сүзне эләктереп алып китте Илдус. «Шырпы кабы» дигәнгә бераз күркәсе кабарды бугай аның. — Безнең Түбән Каманы — яшьләр шәһәре дип йөртәләр. Менә безгә килеп карагыз әле! Урамнары болын шикелле — үзе киң, үзе ямь-яшел, кырыенда гына — Кама, Кама буенда исәпсез-сансыз күлләр, нарат урманнары, химкомбинат белән ике арада — оҗмах бакчалары төсле алма бакчалары...

— Һи! Рәхәтләнеп атта чабарлык даласы да булмагач, нинди җир ди ул? — Тансык, атта чапкан сыман итеп, ике кулын җәйде.— Чабасың-чабасың, ә даланың очы да, кырые да күренми. Аннары, озын итеп сузып җырлап җибәрәсең. — Ул онытылып, җырлый да башла-

ган иде, ләкин, барысының да уңайсызланып, аңа карап торуын күреп, кисәк туктап калды.

— Жыр-ла... жыр-ла... — диде аңа, өзеп-өзеп, Рифкать.

— Юк... гафу итегез, мин... онытылып киткәнмен. Сагындырган... шуңадыр.

— Жырла, Тансык, әкрен генә жырла, беркем дә ишетмәс. — Ялындырма инде!

Ләкин Тансыкның күңеле утырган иде инде.

— Алайса, әйдә, үзебезнең жырны жырлыйбыз! — дип, Илдус Рифкатьнең баш очына ук килеп басты. Рифкать, «әйдә» дигәнне аңлатып, күз кабакларын селкетте.

> Утларга да бер керербез әле,
> Без менәрбез әле күкләргә.
> Солдат булу безгә кыен түгел,
> Риза булса кызлар көтәргә.

Илдус, Рифкатьнең жырга кушылмавын, дөресрәге, кушыла алмавын күреп, ничек башласа, шулай капыл туктады да: «И-и-их!» — дип, сузып куйды.

— И-их, кайткач...

Барысы да, әллә инде туган якларына кайткач нәрсә эшләселәрен уйлапмы, әллә жыр моңыннан тәэсирләнепме, тын калдылар. Кичке кояш нурлары идән буйлап шуышып килделәр-килделәр дә кыяр-кыймас кына Рифкать янына, караватка үрмәләделәр. Алсу яктылыктан күзләр чагылды, палата сихри төскә керде, егетләрнең йөзенә ут капкандай булды. Алар күзләренә кояш нуры төшмәсен дип, кулларын каш өстенә кыйгачлап куйдылар. Вакыт үткән саен тынлык көчәя барды, Рифкатьнең якты, ләкин салкын кояш нурларына да исе китмәс булды. Ул егетләрнең болай сүзсез торуына борчыла, моңа үзен гаепле саный, әгәр дә шулай ятмаса, сүзләрнең дә, уен-көлкенең дә башкача буласын, башка төсмер аласын сизенә һәм, иң кыены, алар аннан нәрсәнедер яшерә, әнисе үлгән баланы, «кунакка гына китте, тиздән кайтыр әниең», — дип юаталар төсле тоела. Бу хис торган саен көчәя барды, ә инде куллары белән кояштан күзләрен каплагач, моның анык шулай икәненә ышанды, әйтерсең, алар, дөресен әйтмәгәннәренә, алдаганнарына оялып күзләрен яшерәләр иде.

— Минем тәкъдимне оныттыгыз бугай. Кайткач, миңа кунакка киләсез! Чакыру шушы булыр. — Юра сүздән туктады, каш өстендәге кулын төшерде.

— Кайткач, кайткач... — дип кабатлады Вагыйз. — Самолетта очкан саен, тәрәзәгә карыйм, туган як күренмәсме, дим. Зуррак су күзгә чагылса, Каспий диңгезе, дип уйлап, йөрәк дөп-дөп тибә башлый... Миңа килгәндә самолет белән килегез. Әзербайжан илен башта һавадан, өстән карарга кирәк. Югыйсә, синең дала шикелле, — ул Тансыкка таба борылды,— такыр басу түгел ул. Таулары ни тора, таулары! Йөзем, карбыз, кавын, анар...

— Нәрсә ул анар? — дип сорады Илдус.

— Анармы? Сезнеңчә ничек соң әле?.. Эче тулы кызыл төш инде, кыссаң, әчкелтем ширбәт сиптерә, тешләрне камаштыра, әй, тәмле дә үзе! Сездә ничек диләр соң әле аны? Һи, истән чыккан. — Вагыйз, кашларын жыерып куйды, аннары, кинәт кенә кычкырып жибәрде: — Гранат! Гранат, диләр! Гранат ашатам мин сезгә!

Шул чак егетләр барысы да сискәнеп киттеләр, аптырау катыш сораулы караш белән Рифкатькә төбәлделәр. Аның йөзенә газаплы елмаю чыккан иде. Вагыйз дә авызы ачык килеш туктап калды.

— Рәх-мәт... — дип пышылдады Рифкать. — ... Мин... а-ша-дым... ин-де...

Бу сүзләрне ул шаяртып әйтергә, шуның белән егетләрнең әңгәмәсенә кушылып китәргә уйлаган иде, ләкин аның сүзләре аһылдауга охшап чыкты, аларда усал киная дә, үзенең хәлен искәртергә теләү дә бар иде сыман. Юра Вагыйзнең ялгышын төзәтергә уйлады ахрысы, сүзне бөтенләй бүтән якка борып җибәрде.

Моңарчы алар, арслан читлеген урап йөргән балалар кебек, иң төп нәрсә, Рифкатьне бөтен солдатлардан аерып, берничә секунд эчендә әллә кая өскә, югарыга күтәреп куйган вакыйга турында сөйләшүдән курәләтә качарга тырышалар, гүя, шулай итеп бу турыда бөтенләй онытырга уйлыйлар иде. Ләкин Юраның бүтән түземе калмаган иде.

— Граната шартлар алдыннан мин синең янәшәңдә үк идем. Барысын да күреп тордым, — диде ул үзенең гадәти, җырлап чыга торган сузынкы тавышы белән.

Салкын суда бер чирканчык алган шикелле, егетләрнең дә курку-лары бетте. Вагыйз карават башына таянды.

— Ә мин күрмәдем, мин алда идем, — диде ул.

— Мин артта калганмын. — Монысын Илдус әйтте.

— Граната шартлавын ишеткәч, борылып карасам...

— Мин граната шартлавына да игътибар итмәдем, быргы авазы яңгырагач кына туктадым.

— Быргыны ничек кулга алуымны да, ничек «отбой» уйнавымны да юньләп хәтерләмим.

— Юраның «отбой» уйнавы булды, бөтен солдатлар туктап калды. Бөтенебез дә синең янга йөгердек. Син инде... аңсыз ята идең. Командир белән врач башыңны бәйләи. Аннары сине алып киттеләр. Ә без тагын «атакага» күтәрелдек.

Әле генә граната вакыйгасын искә төшерергә дә куркып торган егетләр, урмандагы күккә ашкан зифа агачны екканда кызганып та, өйгә алып кайткач, аңа инде табигать бизәге дип түгел, ә утын итеп караган, хәзер инде аның җылысыннан ләззәт тапкан агай кебек, хәрби өйрәнүләр вакытында ниләр булганын, кичә-бүген частьта Рифкатьнең исеме телдән төшмәвен бер дә тартынмыйча, хәтта иркенләп үк диярлек сөйләргә тотындылар. Шулай итеп алар, үзләре дә сизмәстән, палатага җан керттеләр, матур ялганга охшаган юату сүзләре, томан сыман таралып, тирә-юньне яктырып киткәндәй булды.

## 22

Тәрәзә артындагы сәрби куаклары караңгылык кочагына кереп чумгач, Рифкать үзенең ак палатасын кара төн диңгезе буйлап йөзүче корабльгә охшатты. Диңгездә давыл купкан. Ул, корабын дулкыннарга каршы куеп, зилзилә белән көрәшкән, рубкасыннан чыкмаган. Һәм, ниһаять, диңгез тынычлангач, каютасына кереп егылган. «Каюта...» дип, көлемсерәде Рифкать. Бераз тын торгач: «Саша»,— дип, көрсенеп куйды. Ул, беренче тапкыр күргәндәй, палатага күз йөртеп чыкты. Өстә — кайгыдан арына алмаган кеше маңгае төсле җыерчыкланган саргылт түшәм. Каршы як стенада — дүрт кнопка белән беркетелгән олы гына плакат. Анда ике кеше сурәте ясалган. Берсе авызына пычрак алма капкан, үзе дә бик шапшак. Яшькә яшь булса да, бөкресе чыккан, гәүдәгә бетәшкән. Ә икенчесе кран астында җиләкҗимеш юып тора. Анысы — Алып батыр сыман таза, йөзләре алсуланып тора. Плакат астына шигырь белән болай дип язылган:

Яшим дисәң йөз яшьне,
Юып аша җимешне!

Рифкать плакатка озак карап тора алмады, качарга теләгәндәй, күз карашы белән стена буйлап йөгереп китте. Ләкин палатада күз нуры төшәр урын, күз карашы туктап ял итәрлек җир юк иде. Аптырагач, ул, чыгар урын эзләгәндәй, тәрәзәгә таба текәлде һәм анда караңгы төннең чекерәеп торган олы күзләре белән очрашкач, йөзен читкә борды.

Йомшак чүәкләре белән акрын гына атлап врач апа палатага керде. Аның ак халатыннан Рифкатьнең күзләре чагылып киткән төсле булды. Әйтерсең, күктәге якты ай аның ялгыз ятуын күргән дә тәгәрәп төшеп палатага килеп кергән.

Врач, төн тынлыгын бүлдерүдән курыккандай, сүзсез генә Рифкатьнең сул кулын сызгандырды, мамык белән ышкыды да шприцка дару суыртты. Бары тик шунда гына, телгә килеп, сүз катты:

— Дусларың киттеме?

Рифкать керфекләрен какты.

— Әниеңә... бергәләп хат язасыгыз калган...

— Хат язасы калган... Калган... Калган—дип кабатлады ул эчтән.— Калган нәрсәләр күп әле ул. Әтисе белән, әнисе белән һич югы бер тапкыр иркенләп сөйләшеп утырасы, күңелендәге бар уйларын ачып саласы калган... Әнфисәгә вәгъдә иткән күлмәген бүләк итәсе, Әлфияне... Галияне кочакка алып бер суырып үбәсе калган... Бабасына печән чабып өясе, авыл малайлары белән туйганчы уйныйсы, танышлар белән ныграк танышасы, дуслар белән ныграк дуслашасы калган... Түбән Кама урамнарын, Зәй, Кама болыннарын, нарат урманнарын, түгәрәк күлләрен күзләре талганчы карыйсы, аларга җылы сүз әйтәсе калган... Калган... Калган...

Рифкатьнең ирен читләреннән әрнүле елмаю дулкыннары йөгереп узды.

— Хәзер сиңа операция ясаячаклар.

Рифкатьнең чырае үзгәрмәде. Врач, шприцын өскә караткан килеш, бер мәл уйланып торды да, кинәт кенә хәрәкәтләнеп, инәне кулга кадады. Ничектер, гадәттәгедән авырттырыбрак, хәтта бераз дорфарак та итеп ясады ул бу юлы уколны. «Арыгандыр, мине каравыллап, хәлдән калгандыр», — дип уйлады Рифкать. Шушы авыруы белән күпме кешегә борчу китерде. Әле күпме кешегә китерәчәк... Шунда, граната шартлауга ук өзелгән булса...

Ул торган саен гәүдәсенең җиңеләя барганын сизде, башында утлы сөңгеләр әкренләп сүрәнләнде, аннары бөтенләй юкка чыкты: кулларын күтәрергә теләде, ләкин мускуллары аны тыңламады, нәрсәдер кычкырмакчы итте, әмма тавышы чыкмады. Рифкать, соңгы көчен җыеп тешләрен кысты, ачу белән кулларын йомарлады, һәм шулчак уң кулы беләзектән түбән көйдереп алгандай булды. «Аһ! Граната!» — дигән ыңгырашу авазы күкрәктән өзелеп чыкты да һавада асылынып калды. Ләкин ул аваз таралып бетмәде, киресенчә, һаман үсә, зурая барды, менә ул болытка әйләнде дә, бәреп-бәреп биткә салкын яңгыр яварга тотынды, менә ул өермә булып бөтерелде, һәм Рифкать, шул өермәгә ияреп, күккә күтәрелеп китте.

Гәүдәсе мамык кебек җиңел, бары тик башы гына авыраеп аска таба сөйри. Җиргә егылып төшмәс өчен ул сул кулы белән ашыга-ашыга ишә. Ә уң кулын кыймшатмый. Уң кулда — граната. Ул дүрт секундтан шартлаячак. Күз кабакларын күтәреп торыр хәл дә юк, үлеп йокы килә. Яшел түшәк төсле дала өстенә төшәсе дә изрәп йокыга китәсе иде!

Ярамый!

Дүрт секунд!

Юк, өч, ике секунд кына калгандыр. Аста, тузгытылган кырмыска күчедәй, солдатлар йөгерешә. Әгәр хәзер граната шартласа, алар ба-

рысы да һәлак булачак. Рифкать сул кулы белән һаман-һаман ярсып иште. Полигон да күздән югалды. Югары күтәрелгән саен, җир дә шар кыяфәтенә керә барды, һәм берзаман бөтенләй олы карбызга охшап калды. Әнә, тегендә, аксыл зәңгәр җеп сыман гына булып күренгән елга буенда — аның туган шәһәре Түбән Кама булырга тиеш, ә монысы — Кара диңгез, Саша диңгезе, монысы — түтен бөркеп торганы — Казан, ә теге тракторчы абыйның авыллары бармак башы хәтле генә. Ә... граната?! Граната шартлаячак! Әгәр ул аны кулыннан ычкындырса, этисе дә, энисе дә, Әнфисә белән Азат та, дуслары, бөтен туганнары да шартлаячак, юкка чыгачак. Аста, җирдә чакта ул әле боларны күреп, аңлап бетермәгән. Аның гранатасы шартласа, бөтен җир шары челпәрәмә киләчәк бит! Ул күз иярмәс тизлек белән өскә үрләде, менгән саен сулыш алу да җиңеләйде, гәүдәсе дә, башы да сизелмәс булды. Хәзер инде кулны селкетәсе дә юк, ул, граната тоткан уң кулын алга сузган килеш, талпына-талпына күккә оча, җирдән һаман саен ныграк ераклаша бара иде.

## 23

— Операция булмәсенә кертегез! — дип дәште кемдер.

Аны иплэп кенә тәгәрмәчле өстәл өстенә салдылар да палатадан алып чыгып киттеләр.

## 24

Тау артыннан иң элек кояшның кызыл түбәтәе күренде, аннары ул әкрен генә, сакланып кына күтәрелә башлады. Кояш әле йокысыннан айнып җитмәгән, аның йөзе әле караңгы кызыл төстә иде. Ул, тушәгеннән аерылып китә алмыйча, беркавым эсәренеп карап торды да авырлык белән генә кузгалды, күзләрен ачты һәм, иң беренче эш итеп, үзенең биләмәләрен барларга, бер төн эчендә анда нинди үзгәрешләр булганын тикшерергә тотынды. Кояш нурлары дала кылганнарын сыйпап узды, өй кыеклары буйлап йөгерде, полигон читендә тезелешеп торган самолетларны санап чыкты, казармалар түбәсеннән атлап үтте һәм палата тәрәзәсе төбендә туктап калды. Сәрби куакларының шомлы кыштырдавына бераз колак салып торгач, ул тәрәзәдән эчкә таба үрмәләде, идәнгә шуышып төште, әкрен генә караватка якынлашты. Кояшның йөзе агарганнан-агара бара иде. Менә ул, караватка менәргә куркып, кырыйдагы тумбочка өстенә күтәрелде, кайнарланган нурларын суытырга теләгәндәй, стакан эчендәге суга төште һәм, анда да үзенә урын таба алмыйча, кинәт, түшәмгә сикерде дә тавышсыз гына ярсып-ярсып биергә тотынды. Ләкин бу хәл озакка бармады, кояш, аңына килеп, ашыга-ашыга караватт буйлап шуышты, анда Рифкатьне күргәч, бер мизгелгә тынычланды да, тагын сискәнеп, кулларын сыйпады, ачык яткан йөзен сыйпады, җылытырга теләгәндәй, кабалана-кабалана сыйпады. Ләкин Рифкатьнең күзләре ачылмады, кулларына, йөзенә җылы кунмады.

Кояш, аптыраудан, сәерсенүдән, һушсыз калып торды-торды да, үлгән баласын күреп акылдан шашкан ана төсле шаркылдап көлеп җибәрде. Аның көлү авазы баш өстендәге тургайлар сайравына, эшкә ашыгучы кешеләрнең уен-көлкесенә, машиналар гөрелтесенә әйләнеп, көчәйгәннән-көчәя барды. Җир өстендә якты көн тууын күреп, бар дөнья сөенде, ләкин кояшның күзләренә текәлеп караучы булмады. Кояш бүген сөенми, ә тилмереп, газапланып көлә иде.

Ноябрь — декабрь 1978 ел, январь — февраль 1979 ел.

## Марсель Галиев

# ТӨНГЕ КЫЮЛЫК

хикәя

I



Нишләп мин аны башта ук танымадым соң әле, профессор Сирматов ич бу. Нәкъ үзе. Ручкасын ирененә китереп сөйләшә торган гадәте дә бар аның. Сирматов шул. Бүген генә минем кабинетта булды, лекция сәгатьләрен тикшертергә дип килгән иде. Тавышы да таныш:

— Һәр кешедә Наполеон кодрәте бар, аны уятырга гына кирәк, — Сирматов әчке бер көлү тантанасын яшерергә теләгәндәй күзләрен кыса төште.— Максат һәм шуңа ирешү кешегә нәрсә бирә? Ләззәт һәм канәгатьләнүме? Әйтик, Наполеон Европаның астын-өскә китереп канәгатьләнү кичердеме? Кичерде: Мисалга Уразаевны алыйк: ул кызган баштан өенә кайтып өстәлне әйләндереп каплый икән, шулай ук канәгатьләнү кичерә. Болар икесе бер үк тойгы, тик масштаблар гына... Димәк, һәр кеше Наполеон кодрәтенә ия.

Шул минутта Уразаев сискәнеп уянды. Наполеон турындагы кичтән укып яткан китабы мендәр астыннан шуып идәнгә төшкән икән.

Төштәге күренеш мәгънәсен җуеп әллә кая, хәтер аръягына китеп таркалды. Уразаев хатынын уятмас өчен иплəп кенә торды, йомшак эчле чүәкләрен аякларына элеп тәрәзә катына килде. Борынгы сәгать гыжлавык тавыш белән төнге өчне сугып куйды.

Өнсез-хәрәкәтсез урамга карап ул бик озак басып торды. Өшеткеч ай яктысы утсыз тәрәзәләргә сыенган. Сыкылы төн аша саркып күренгән урам утлары да туңып, күшегеп калган кебек. Бозлы тәрәзәләр артында йокыга талган язмышлар, тын урам, пыскып кына янган ай Уразаев күңелендә олы сагыш, моңсулык уятты. Төннең шушы мизгелендә уянып, гүя беренче тапкыр дөньяга төбәлде. Урамда ичмасам бер генә тамчы тереклек чалымы булса икән: Уразаев күңеленә иңгән олы сагыш сискәнер дә таралып китәр иде. Әмма юк. Урам тын. Җансыз. Моңсу.

Бу олы сагыш артында, кар өстенә сузылып төшкән күләгәләр кебек, кискен бер хакыйкать ята иде. Аны бөтен чынбарлыгы белән тоюдан Уразаевның тәне өшеп, калтыранып куйды. Әйтерсең лә аяк ас-

тыннан йомшак келәм шуа башлады. Тормыш та шулай бит, дип уйлады ул. Аяк астыннан келәм шуа да шуа, ә син искәрмисең, дөнья мәшәкатьләреннән башыңны иеп һаман алга таба барасың. Һәм шулай итеп көннәр, айлар, еллар үтеп киткәне сизелми дә. Мәңге шулай барырсың да барырсың кебек, һәм кинәт... башыңны күтәреп карасаң... келәмнең инде очы күренә, бетеп килә икән бит... Хәер, кышкы төннең галәми өнсезлеге каршында бер язмышның моңаюы, сагышы бик тә кечерәеп кала түгелме? Һәм төнге дөнья булып каршына баскан хәтәр хакыйкать күзенә төбәлгән хәлдә, Уразаевны каты бәгырьле аеклык, сабыр тынычлык билән алды.

Элегрәк, үлем турындагы уйлар башына килсә, Уразаев нинди дә булса шөгыль табып, андый күңелсезлектән арынырга, онытылырга тырыша иде. Менә шушы кышкы төндә, бөтен омтылышларының артта калып, алда инде бары тик тыныч картлык торганына төшенүе, һәм әлеге котылгысыз хакыйкатьтән качарга теләмичә, киресенчә, салкын канлылык белән гел шул турыда гына уйларга тырышуы бер караганда гаҗәп тә иде. Бүген, бөтенләй битараф хәлдә, үзен язмышның соңгы хөкеменә буйсынырга да әзер кебек сизде ул.

Ә юк! Әнә, каршы йортның кырый тәрәзәсендә ут кабынды. Уразаев күзләрендә катып калган урам күренеше әнә шул сыңар тәрәзәдәге уттан тернәкләнеп, җанланып китте. Күңел түрендә сулкылдап уянган нindидер тойгы аны әллә нишләтеп җибәрде. Шул тойгыны таратудан курыккандай, ул ашыгып калын пәрдәне ябып куйды. Почмакларга ешынган караңгылык сыекланып бүлмәгә җәелде. Аның гомер-гомергә хәтеренә килмәгән, әһәмиятсез бер күренеш аңында яктыра, янара башлады. Һичкем белән дә бүлешеп булмый торган; ерак-та, бик еракта калган, чынбарлык һәм хыял белән аралашкан изге бер күренеш иде ул. Нигә дип бөтен ачыклыгы, бөтен рәхәтлеге белән нәкъ менә шушы минутта җанын биләп алды соң әле, кулларыңны суз гына — шулкадәрле ачык, сузылып ятарлык йомшак үләннәр, кулларыңны суз гына — шул үләннәрне күшәп йөргән алмачуар атның бөдрә ялын тоярсың шикелле...

«Тезгенне нык тот!»

«Кулыңны ычкындырма!»

«Тезгенне нык тот!»

Кем әйтте соң әле аны, кем әйтте?

Тояк астында җир тетри, тирә-юнь хәрәкәткә килә. Урманнар ага, болытлар, үзәннәр ага. Җил — зәңгәрлек. Җил — яшеллек. Тузгып киткән ат ялының биткә яңгыр сыман сибәләве. Малай чакның җанга сыймаган шатлыгы:

— Әһе-һе-һәәй!

Кайтаваз артта, тузанлы юлда аунап кала. Алда — юллар чаты. Экияттәгечә: «Уңга киткән кеше — бик бай булыр, урта юл белән киткән кеше — урта бай булыр, сулга киткән кеше — әйләнеп кайтмас»мы? Ул һич икеләнүсез уңга борылганмы, әллә инде атына: «Үзең теләгән якка бар!», дигәнме? Ә сул тарафка киткән хәвефле юл — тәвәккәллегеңне сынар өчен генә түгел иде микән?

Экият белән чыны буталган уйлар Уразаев өчен изге булган хатирә-истәлекләр тирәсендә чуалды.

Нигә дип йөрәген сулкылдатып авыл исенә төште соң әле аның? Әллә инде илле дүрт яшен тутырып илле биш ягына авышкан төнне канында гасырлар буе буыннан-буынга күчеп килгән крестьян рухы уяндымы?.. Ерак туган-тумачаларыннан башка якын кешесе калмаган авылына моннан ун еллар элек бер кайтып килгән иде бит ул. Хәтерендә кадерле эз калдырган сукмакларның, печән чабып йөргән тугайларның беткәнлеген, үзгәргәнлеген күргәч, рәнҗеп китеп барган иде, югыйсә. Кайтып карасаң — барысы да үзгәргән булып чыкты, ә

ерактан торып уйлаганда һаман да элеккечәдер шикелле. Әнә шул тугайлар төннәрен ишегеңне дә шакымыйча килеп керә, юрганыңнан тартып уята, күңелеңне барлый түгелме?

Уразаев кипкән иреннәрен ялап куйды. Киез табанлы чүәген идәнгә сак кына тидереп кухня ягына чыкты, йотлыгып салкын чәй эчте. Өстәлдә иртәгә буласы туган көндә ачыласы кыяр, помидор банкалары тора иде. Хәер, иртәгә түгел, бүген бит инде — таң атарга да ерак калмаган.

Уразаев өстәл читендә яткан пычакны шакмаклы шикәр савытына тереп куйды. Әйберләр бер-берсенә почмаклары белән туры тормаса кәефе тынычсызлана иде аның.

Кинәт шушы җайлы, рәхәт тормышын каймалап торган чиста стеналар, пөхтәләп җыештырылган, тәртип белән урнаштырылган әйберләр арасында нәрсәдәндер оят булып китте аңа. Йокларга, тизрәк йокларга кирәк, дип уйлады ул.

Өйнең җанны киереп торган ялангач тынлыгы күңел пышылдавын тотып кабатлады сыман:

«Йокларга, йокларга...»

## II

Сүнгән трубкасын капкан вахтер карт Уразаев белән исәнләште дә, стенадагы сәгатькә күз төшерде. Сигез туларга ун минут иде. Тәмәке төтененнән ысланып беткән мыегы астыннан елмаю саркытып вахтер карт башын чайкап куйды. Менә дистә еллар буена күзәтеп килә ул Уразаевны, ник бер генә минутка эшкә соңга калып килсен.

Уразаев вахтердан ачкыч алып кабинетына узды. Иң беренче эш итеп форточкаларны ачты, аннан кара саржадан тегелгән җиңсәләрен терсәгенә кадәр шудырып өстәл артына утырды. Тиздән башка хезмәткәрләр килер, уку-укыту бүлегендә һәр көндәгечә шаулы хәрәкәт башланыр. Төрле сәбәп таба белүче яшьләр генә, гадәттәгечә, соңгарак калырлар.

Уразаев кесәсеннән каты тышлы блокнот чыгарды. Анда, бөкләп тыгылган кәгазь битенә, юлын-юлга елыштырып вак хәрефләр белән исемлек язылган иде. Бүгенге туган көн мәҗлесенә чакырыласы кунаклар исемлеге. Бүтән еллардагыча туган-тумача белән түгел, ә галим-голәмә халкын чакырып (бик зурдан купмыйча гына) зыялылар мохитендә бер сөйләшеп утырасы килә иде аның. Җанына пәрәвез сарган хатыны да бәлки уянып калыр иде. Галимнәрне чакырабыз дигәч, табынга кирәк-ярак әзерләргә бик ясканып тотынды бит үзе.

Ләкин Уразаевның күңелендә иртәдән бирле тынгы бирмичә ниндидер шик-шөбһә баш калкытып тора. Кунакларның кадерен күрү өченниләр эшләргә кирәклеген кат-кат уйлап, алдан арып та куйды бугай ул. Бер карасаң, каушарлык чит кешеләр дә түгел югыйсә, ничә еллар инде эш буенча аралашып йөргән кешеләр.

Институт халкы уку-укыту бүлегендә методист булып эшләүче Уразаевның күз алдында бит. Исем-фамилияләре пөхтә итеп эш кәгазьләренә теркәлгән. Галим-укытучыларның кылган гамәлләре, дәрес сәгатьләре хисапланып, саннар сыйфатында кәгазьләргә күчә һәм бер-бер артлы Вакыт тегермәненә кереп китә бара. Айдан-айга, елдан-елга шулай... күзгә күренмәс куласа әйләнә тора. Әнә шул кәгазьдәге пәрәвез ятьмәсе кебек четерекле графаларга эләккән саннардан әз генә читкә тайпылу булдымы — әлеге күзгә күренмәс куласаның әйләнүе туктала, ягъни Уразаевның сабыр, әмма үҗәт тавышы телефон аша кафедралар белән тоташа. Шуңа күрә дә чамадан тыш дөреслек сагында торган юаш, ләкин үзсүзле методист белән бәхәс-

кә керми генә, әчке уен интеллигентларча яшерә белеп, кирәк санаган урында итагатьле генә елмаеп сөйләшәләр иде. Типография буявы кибәргә дә өлгермәгән фәнни китапларын төсле фломастерлар белән калын сүзләр язып бүләк тә иткәлиләр иде.

Уразаевның күңелендә һаман шебһәләнү тулгана. Йокысыз төннән соң арыганлык үзен сиздерәме әллә? Исемлекне ул тагын бер тапкыр барлап чыкты. Ике-өч көн элек туган көн дип түгел, болай, чәй мәҗлесенә, гәпләшеп утырырга дип кенә, ризалыкларын алган иде. Бүген төштән соң фәнни киңәшмәгә җыеласылар — күреп, исләренә төшерми булмас. Галим халкына дөнья мәшәкатьләреннән арынып үз күңеленә китү хас, онытып куюлары да бик мөмкин.

Бүлек хезмәткәрләре берәм-берәм килә торды, һәркем үз өстәле артында, кәгазьләр арасына чумып эш көнен башлап җибәрде. Уразаевны туган көне белән котларга да онытмадылар. Секретарь кыз чәчәкләр дә керткәч, Уразаевның күңеле бөтенләй нечкәрде. Кинчә җилкәле, беленер-беленмәс күкрәкле, кысып торган джинсына «Вранглер» мөһере сугылган бу кызны өнәп бетерми иде Уразаев. Җитмәсә, урынлы-урынсыз төртмә сүз дә әйтеп китә, кайсы чакта әйләнмәле сүзләренә тиз генә төшенә дә алмый Уразаев; әкрен кыймылдый торган аңында таркатып карап кына мәгънәсенә төшенә иде. Авыр эш күрмичә, креслога кырын яткан килеш рок музыка тыңлап үскән «сусыл» егетләргә охшаган бу кызга бер вакыйгадан соң бөтенләй үпкәләп куйган иде ул.

Институтка чит ил студентлары килергә тиеш иде. Секретарь кыз бүлеккә килеп керде дә:

— Кабинетыгыз тәртиптә булсын, сезгә, иптәш Уразаев, чит ил студентлары каршында чыгыш ясарга туры киләчәк,— дип белдерү ясады.

— Миңа?..

Уразаевның каушавы йөзенә генә түгел, ә бөтен гәүдәсенә чыккан иде.

— Сезгә шул!

— Безнең мөдир бар ич, нигә дип...

— Чөнки иң күп картотекалар, папкалар сезнең өстәлдә,— дип секретарь кыз җилләнеп чыгып та китте.

Башка хезмәткәрләрнең өстәлләренә иелә төшеп пышан гына көлүләрен искәрмәде Уразаев, әлеге хәбәрне белешергә дип, бик борчулы кыяфәт белән, ректор урынбасарына керергә әзерләнде.

Секретарь кызның урынсыз шаяртуын кабул итә алмаган иде ул. Ә менә бүген, елмаеп, чын күңелдән котлавына һәм чәчәкләр бүләк итүенә эреде дә китте. Бу яшьләрнең кәеф-холкы хәзерге һава торышы кебек үзгәрә дә тора, безгә, утырган акыллы өлкәннәргә, аңлашылып та бетми, дип уйлады ул.

Уразаевның язылмаган кагыйдәсе бар. Тышта буранмы ул, яңгырмы—өстән таш яуса да, төш алдыннан тиргә барып мылтыктан атарга тиеш. Ярым ташландык бакча түрендәге тирга ул һәр көнне килә. Ни хикмәттер, бу вакытта анда кеше аз була, яки бөтенләй булмый. Чират көтеп, артыңда кыбырсып торучылар югында ашыкмыйча тәмләп ату рәхәт бирә бит. Тир хуҗасы Гозәер карт Уразаевны аерым бер хөрмәт белән кабул итә: вакыт уздыру өчен очраклы рәвештә кергән кеше итеп түгел, ә атудан чын ләззәт алуын белгәнгә. Бүген кайсы мылтыктан (мылтыкның да вакытына карап холкы үзгәрә) атарга иқәнлеген дә күрсәтеп бирә иде. Сыңар куллы Гозәер карт, авызын бөрештереп сызгыра-сызгыра, Уразаев биргән тиеннәрне үзенә бер осталык белән чүеп-чүеп учына җыя, патроннарны исә алтын бөртекләрен тоткан кебек кадерләп кенә алдына сала, үзе туктаусыз русча-татарча сүзләрне әвәрә китереп катнаш бер телдә сөйләнә иде.

Ярым уенчык мылтыкны кулына алуга, Уразаевта җитди сабырлык канаты астында тыенкы дәрт уяна, күңеле кытыклана башлый. Үз гомерендә чебен дә үтереп карамаган Уразаев хәтта монда да кошкорт, җәнлек сурәтләренә атуны өнәп бетерми, ә инде самолетларга, бомбаларга килгәндә... Менә ул ашыкмыйча гына төзи, әчтә, каядыр бик тирәнгә кереп йомылган сабыйлыгы мәтәлчек атып уйный башлый, һәм шул хис тышка бәреп чыгып куллары калтырый башлаганчы ата да ата. Самолетлар жуылдап төшеп шартлый, колак тондыргыч тавыш чыгарып бомбалар өзелеп төшә. Чынбарлыктан аерылган шушы мәлдә Уразаевта кыргый бер хис уяна.

Самолетлар да, бомбалар да берәм-берәм коелып бетә. Инде нәрсәгә төбәргә? Ул беразга икеләнеп тора да, төзәп атып җибәрә — соңгысы... Бусы инде тими, җил тегермәненең канатлары хәрәкәтләнми кала.

Һәр пуля артыннан бөтен гәүдәсе белән суырылып очып китәр шикелле талпынып-талпынып куйган Гозәер картның (әйтерсең ул пуляларны очып барышлый турылап озата) сөенеч тулган күзләре кинәт сүнеп кала, йодрыгы белән һаваны кисә дә:

— Ә-әәх, бер пуляга калгач!— дип теш арасыннан яраткан сүзен кысып чыгара.— Умри вовремя! Вакытында туктый белергә кирәк шул...

Мылтыкны Уразаевтан тартып ала да, түтәсен тезләре арасына кыстырып, көбәген сындырып кора һәм мылтыкның астын өскә әйләндереп төзәмичә дә диярлек, шаярган кебек кенә атып җибәрә һәм... җил тегермәненең канатлары зырылдап әйләнә башлый. Аның шулай мылтык көпшәсен аска әйләндереп мәзәк итеп атуын тагын кабатлыйсы килә, ләкин, тотынса, ул һәрвакыттагыча бер генә тапкыр ата иде.

Соңгы пуляның тимәвен яхшыга юрамады Уразаев. Иртәдән бирле кыбырсып торган шиге дә юкка булмаган икән. Төштән соң ачыкланды: исемлектәге галимнәрнең берсе дә туган көн мәҗлесенә бара алмый булып чыкты. Профессор Сирматов ашыгыч командировкага китәсе икән. Уразаевның җилкәсенә кулын салып:

— Бик кызганыч, туган. Башка вакытта бер утырырбыз әле, гафу итәрсең инде, яме,— диде һәм эре тешләрен күрсәтеп нәкъ төшкә кергәнчә көлеп куйды.

Кул биреп, җылы сүзләр әйтешкәннән соң калганнарының да җитди сәбәпләре ачылды: берсенә кунаклар килеп төшкән икән, икенчесенең хатыны авырып киткән, өченчесенең...Уразаевның йөзенә күләгә йөгерде. Аңлый, әлбәттә, һәммә кешенең үз мәшәкате бар, тик шулай да... Бер караганда өстән нииндидер йөк төшкән шикелле җиңеләю сизде ул. Тәрбияле, иҗтиһадлы кешеләргә ошап булырмы, оятка калмаммы, дип күпме хафаланган иде — менә ничек килеп чыкты.

Уразаев һич кирәкмәгәнгә өстәл тартмасын бер ачып, бер ябып кәгазьләр арасында казына башлады. Тәртип белән яткан нәрсәләрне туздырып ташлыйсы килде аның. Заманында бар иде бит аның шәп өстәле. Бер гасыр элек билгесез оста тарафыннан имән агачына җан өреп ясалган ул өстәлнең һәр бизәге, һәр бөгелеше хәтерендә. Арыслан башлы җиз тоткаларыннан тартып, авыр гына шудырып чыгара торган тартмалары күп иде аның. Шундый чаклар була: еллар буе кагылынмаган тартманы ачасың, кәгазьләр арасыннан күптән инде кулга алынмаган берәр истәлекле әйбер килеп чыга һәм шул әйбер аша, хатирәләргә бирелеп, үткән вакытны кире кайтарган шикелле самими тойгы кичереп, үзеңә бер юаныч таба идең.

Ул өстәлне музейга алганнан соң, заманча эшләнгән, шома капкачлы өстәлләр бер-бер артлы алмашына торды, ләкин аларга күнегә алмады Уразаев. Шул өстәл белән аның үз-үзенә ышанычы, канәгать еллары да китте бугай.

Эш соңы якынлаша барган саен Уразаев кара коела барды. Хатыны, юан гәүдәсен авыр гына йөртеп өстәл почмакларына бәреләбәреләаш-су әзерләп йөридер. Ашыкканда кулы тотмый башлый аның — берәр рюмканы төшереп тә ваткандыр әле. Мәҗлескә дәрәҗәлеләрне чакыргач, гомер буе нәрсәдәндер канәгатьсез йөргән хатынының күңел читлеге ачылмасмы дип өметләнгән иде — булмады. Бүген, болай ялгызы гына кайтып кергәч, хатыны йөзенә саран гына аптырау чыгарып карар... ләкин сораштырып йөдәтмәс, битәрләмәс. Уразаев барысын күз алдына китереп чыраен сытты. Ни каршылар аны? Күңелендә эт өрсә дә, керфеген дә селкетмәс хатынының салкын битарафлыгымы? Сынаулы сүзсез карашмы? Ирен читләрендә тартышып куйган мыскыллы елмаюымы?

Эш сәгате бетәр-бетмәстән кабинет бушап калды. Уразаев төшкелеккә алданрак китеп сарыф иткән унбиш минут вакытны секундына кадәр тутырды да, кайтырга чыкты. Коридорның якты стеналары арасында ул кечерәеп калды. Соңгы моданы окаен артыннан искән җил белән эләктереп алучы ыспай фигуралы студентлар да берән-сәрән генә күренә. Стенага ышкына язып барган Уразаев буфеттан чыгып килүче Сәнҗапов белән чак бәрелешмичә туктап калды.

— Нихәл, профессор туган!

Һәркемне бер дәрәҗәгә куеп исәнләшүче, ябык гәүдәле, кечкенә буйлы, күңелсезләнүне белми торган бу кеше Уразаевның күңелен күтәреп җибәрде. Сәнҗапов кулында чын күннән эшләнгән утызынчы еллар портфеле. Һәрвакыттагыча, йөзендә битараф елмаю. Ләкин ул битараф елмаю — чатнап киткән җыерчыклар арасына кысылган хәнҗәр очы кебек күзләрдәге гамьне яшерү өчен генәдер сыман.

Кундәм, тыңлаучан булганга, галим-голәмә халкы аны хөрмәт итә, вакыты бик тар булганнары да тукталып, аңа бер-ике җылы сүз кушып китәләр иде. Чөнки Сәнҗаповның кәтмәгәндә кирәк булу мөмкинлеге чикләнмәгән иде. Ул булдыра алырдай күп сыйфатларның берсе — дөньяның төрле маркалы язу машиналарын төзәтә, рәтли белүе. Кыршылып беткән портфелендә елан мөгезеннән кала нинди генә кораллар йөртмидер.

Бүтән вакыт булса, Сәнҗапов авызыннан аңкып торган вино исен ятсынып Уразаев йөзен җыерып та куяр иде. Ләкин бүген очсызлы вино исе, киресенчә, аның аппетитын гына кузгатып җибәрде. Әле ни эшләргә кирәклеген тәгаен гына уйлап бетермәстән ул:

— Синең вакытың бармы? — дип сорады.

— Минем вакыт үзем белән,— диде Сәнҗапов.

— Әйдә алайса, миңа кайтабыз.

— Була ул,— дип Сәнҗапов портфелен бер кулыннан икенчесенә күчерде.

Уразаев нигәдер кызганып карый иде бу кешегә. Өйгә, хатыны янына ялгызы кайтып керергә уңайсызланудан гына түгел, ә шушы риясызлыгы йөзенә чыккан беркатлы кеше белән гәпләшеп утырасы килде аның.

Уразаевның фатиры шәһәр читендә үк иде, кайтып җиткәнче шактый вакыт узды. Звонок биреп тормыйча, үз ачкычы белән Уразаев ишекне шыпырт кына ачты да, Сәнҗапов аягын чишенгән арада җәһәт кенә олы залга үтте. Өстәл түрендә хатыны кулларын күкрәгенә кушырып йоклап киткән иде. Уразаев аның йомшак җилкәсенә сак кына төртеп уятты да:

— Кунаклар кайта алмады,— дип пышылдады.
— Э-әә.
Хатынының ирен читләрендә мыскыллы елмаю чагылып алды. Гомер буе аңа авыр сүз әйтүдән сакланган Уразаев юаш итеп:
— Без монда бер иптәш белән. Син борчылма, диванга барып ят, без үзебез... Калганын иртәгә аңлатырмын,— диде.
— Ярар,—дип хатыны урындыкны уфылдатып урыныннан торды.
— Син ят, борчылма.
— Ярар.
Тантаналы шартлап ачылырга кыҗрап торган шампанский янәшәсеннән Уразаев ак аракы алды, салфеткалар астыннан салкын закускалар әләктерде дә кухня ягына чыкты.
— Син гафу ит, монда утырырбыз инде, тегендә хатын йоклый икән,— диде аптырабрак басып торган Сәнҗаповка.
— Башта эшне бетерик, кая нәрсә төзәтәбез, машинкамы, үтүкме, радиоламы — миңа барыбер.
— Нинди эш ди ул, болай гына утырырга димәгәнмени?
— Ничек инде болай гына?
— Төзәтәсе бер әйбер дә юк.
— Кызык... Мине беркемнең дә тәккә генә чакырганы юк иде әле.
— Әйдә, утыр,— диде Уразаев. Сизелер-сизелмәс кенә калтыранган кулларын ул бер-берсенә ышкып куйды. Нечкә билле рюмкаларга аракы бүлә башлауга, Сәнҗапов аның кулыннан тотты.
— Син миңа, мөмкин булса, кырлы стаканга мөлдерәтеп сал инде, яме. Ваклап эчә торган заман үтте минем. Үзеңә дә шулай сал.
— Минем бөтенләй диярлек эчкән юк бит.
— Алай булгач!— Сәнҗапов урыннан ук тора башлады.— Нишләп мин үзем генә...
— Утыр әле, утыр, черт с ним, әйдә, мин дә тотам.
Чәкештерделәр. Сәнҗапов чыраен да сытмыйча эчеп куйды һәм хәмернең тәнгә сеңүен көтеп торгандай, азыкка кагылмыйча утыра бирде. Уразаев исә төбенә кадәр эчеп бетерә алмады, тончыгып ютәлли-ютәлли сулы стаканга үрелде. Бераздан соң аңга килеп:
— Ут. Яндыра,— дип куйды.
— Син чынлап та болай гына чакырдыңмы минә?— диде Сәнҗапов ваемсыз елмаеп. Уразаев баш какты.
— Гаҗәп...
Хәер, нәрсәгә соң әле төпченеп утырам дигән шикелле Сәнҗапов кулын селкеп куйды һәм шаян тонга күчеп:
— Беренче тапкыр күргәндә мин сине чынлап та профессормы әллә дип торам, — диде.
— Хе-хе-хе, карасаң, бик кечкенә кеше икәнменме?
— Алай димим. Хәрбиләрнең җайлы әнә, җилкәсенә күз төшерсәң, кем икәнен погоннары әйтә дә бирә. Шулай да бүген ялгыша яздым. Килә берәү урам тутырып, мәһабәт буйлы, карасам: прапорщик булып чыкты, йөри шунда, полковниклык гәүдәсе белән.
— Элек кешенең йөзе, киеме кем икәнен әйтеп тора иде, ә хәзер...
— Кесә калынлыгы бер түгел, кесә калынлыгы һәм менә монда,—Сәнҗапов маңгаен шакып куйды,—тыштан түгел, эчтән аермалык.
— Булмады шул, вакытында акыл бирүче булмады. Ничек җиңел иде ул чакта аспирантура бетерүләре дә... Хәзерге урта кул студентның диплом эше дә элеккеге диссертацияләрдән өстенрәк бит югыйсә. Үз вакытында уку турында уйланмаган. Бездән барыбер Эйнштейн чыкмый, имеш. Һаман шул түшәмгә карау...
— Анысы дөрес. Ләкин бер Эйнштейнны тудыру өчен меңнәрчә белгечсезләр гасырлар буе әзерләнергә тиешләр бит.

— Шулай икән шул. Эчеп куйыйкмы әллә?
— Хәзер инде кечкенә рюмкага салсаң да ярый.
Сәнҗапов рюмканы үзалдына тартыбрак куйды:
— Мин үзем дә кайчандыр фәннәр кандидаты булып йөргән кеше бит, — ул моны шулкадәр гадәти нәрсә кебек сүрән тонда әйтте ки, Уразаев гаҗәпләнүдән кычкырып ук җибәрде.
— Кит аннан!
— Югалттым. Катыргыны да, хатынны да, барысын да югалттым, — Сәнҗапов рюмкадагы аракыны тел өстенә сеңдереп куйды.
— Ничек югалттың?
— Шулай... — Сәнҗапов үз-үзе белән киңәшкәндәй бераз тын утырды да әкрен генә сөйләп китте,— адәм баласы барысына да күнегә, җайлаша ала икән. Философ башы белән ялан кырда берьялгызы көтү көтеп йөргән бәндәнең сыер башыннан сөя-сөя аңа дөньяви материялләр турында сөйләп юануын син күз алдыңа китерә аласыңмы? Мин аңа хәзер үзем дә ышана алмыйм.— Сәнҗапов кесәсеннән таушалган кулъяулык алып күзләрен сөртеп куйды.
— Син көзгегә еш карыйсыңмы?
Сүзнең мондый борылышын көтмәгән Уразаев аптырабрак:
— Еш дип, иртән инде, юынганда, — диде.
— Анысы хәзер мин дә шулай... Ә менә ул чакта... — Сәнҗапов калган аракыны уртлап куйды, җыерчыклары языла, ә күзләре ачыларак төште. — Бервакыт, ничектер очраклы уңайдан, газеталар бәйләме яткан бүлмәгә элэктем. Йотылып укып утырам шулай... кинәт, каршымда ниндидер шәүлә селкенеп куйды, карадым да, куркуымнан кычкырып ук җибәрдем. Җыерчыклы йөзле әллә нинди ят кеше миңа төбәлгән — танымадым, ә үзем, күңелемнең әллә кайсы төбәге белән сизенәм, аңлыйсыңмы, сизенәм! Ә ул, авызын ачкан да, мин бит — син! Син! Син! дип кычкыра, үзенең тавышы чыкмый... Ул чынлап та... мин идем. Үземне бит ел буе көзгедә күргәнем булмаган икән, көчкә таныдым. Менә шундый хәлләр дә була. Туган җиремә кайтып төшкәндә менә шушы портфель генә калган иде. Ул минем өзелеп торган гомерне тоташтыручы бердәнбер шаһит. Ә-әәх туган, — Сәнҗапов тагын йөзендәге бөтен җыерчыклары белән елмаюга көчте. — Шулай да бәхетле мин. Яраткан һөнәрем бар. Намусым чиста.
Ә ул чынлап та бәхетле бит, дип уйлады Уразаев. Беркайда да, беркайчан да югалып калмаслык һөнәре бар. Ә син монда... Кешене бит үз әшен тамырына кадәр белеп бетермәү картайта, графалар, саннар, нәтиҗәләр арасына посып хата, ялгыш калгандыр дигән уй, курку-икеләнү төшләреңә кереп җәфалый, елдан-елга көчә-көчә җанны кимерә түгелме?
Ниндидер шатлыклы көй чыгарырга азапланып утырган Сәнҗапов аның уйларын бер кул селтәве белән кисеп куйды:
— Ташлыйк әле күңелсез уйларны!
Аңа ияреп Уразаевта да көндәлек мәшәкатьләр астында онытылып яткан дәрт уяна башлады.
— Әйдә, җырла әле бер, үземнән булмый, мин шәһәрдә үскән кеше, безнең җырлар башка иде. Син авылдандыр бит?
— Авылдан. Җан тарта, ә тамырлар өзелгән. — Уразаевның күзләренә яшь бәреп чыкты.
— Җырла алай булгач. Башта салып куй, икенчесен тотмагансың ич.
— Болай да исердем инде, туган, исердем.
Сәнҗапов көлеп җибәрде:
— Мин кичә булып күренәм?
Уразаев бармак белән санарга кереште.

— Берәү, берәү, берәү. Берәр-берәр өчәү.

Сәнҗапов тагын гыжылдап көлде, Уразаев тутыккан тавышын яза-яза җырлап җибәрде:

Кызыл-кызыл бөрлегән,
юл буена тезелгән... —

һәм дәвам итәлмичә тукталды, ләкин Сәнҗаповның ялварулы карашын күреп, яңадан башлады.— Исмәле, җил, исмәле, җил... Исмәле, җил,— булмый, туган, иске җырлар онытылган икән... Ә яңалары...

Уразаевның башы өстәлгә иелде, сирәк чәчләре маңгаена таралып төште. Бераздан, Сәнҗапов кайтырга дип кузгала башлагач кына аңына килеп, аны ишеккә кадәр озата чыкты.

Эчәргә күнекмәгән Уразаев шактый изрәгән иде. Ул үзендә бөтен нәрсәне бер селтәнүдә үзгәртеп ташлардай көч, тәвәккәллек сизә, ләкин йокымсыраган акылы бу вакытлы гына баш калкыткан тәвәккәллеккә ышана алмый иде. Аның шул үҗәт акылын җиңәрдәй итеп шаркылдап көләсе килде. Гомер буена үзен борчып килгән эштәге, гаиләдәге мәшәкатьләр, кем алдындадыр курку, буйсынулар — уйлап карасаң, бик кечкенә булган бит. Бер талпынуда, җиңел генә хәл итәсе булган, ә шуңа күпме көч, акыл сарыф ителгән. Бу дөнья үзе дә бик бәләкәй икән бит лабаса...

Уразаев иртәгәдән көчле кеше буласын уйлап зал ишеген йодрыгы белән бәреп ачты. Хатыны, дөнья гамен сүрән генә гырылдауга күчереп диванда йоклый иде. Уразаев сәлкәү атлап өстәл кырыена килде, бер кулы белән шифоньер ишегенә тотынды.

— Ничек диде соң өле төштә, теге, кем... Һәр кешедә Наполеон кодрәте бар, дидеме? — Һәм ул авызын бүлшәйтеп уянырга исәбе дә булмаган хатынына карады.— Хы-хы-хы. Аннан каударланып килде дә, хатынының йомшак мендәр шикелле җилкәсенә бармакларын батырды:

— Тор диләр сиңа!

Хатыны сискәнеп күзләрен ачты һәм бөтен дәүләтен әкрен генә кузгатып күтәрелде. Аның йокылы күзләре иренең шулай тупас кычкыруын өнәмичә түгел, ә әчке бер соклану, гаҗәпләнү аша карыйлар иде сыман. Ләкин тәмам уяна төшкәч, ул иренең исерек икәнен абайлады.

— Табынны җый диләр сиңа!

Хатыны, карышасы да килмичә, өметсез кыяфәт белән өстәлгә таба китте. Уразаев креслога барып утырды. Гомере буе уен-көлкене өнәмәгән, җитдилектән йөзе җыерчыкланган Уразаев шаярып көлә-көлә, бармагын пистолет итеп, хатыны кулына күчә барган шешәләргә «ата» башлады. Атудан туктагач җырга күчте:

Сезгә — идән, безгә — түшәм,
безгә — идән, сезгә — түшәм.

Хатыны эшен бетереп йокы бүлмәсенә кереп киткәч ул торып басты.

— Әх син, кем әле... Сирматов, профессор имеш. Нәрсә, әллә мин өстәлне тибеп аудара алмыйммы?!

Аның исәбе чынлап та — шома һәм ялтыравыклы өстәлне бер тибүдә әйләндереп каплау иде. Ләкин... каршыдагы сервантта җемелдәп торган затлы хрусталь савытларны күреп туктап калды. «Бу якка типсәм... телевизор харап була. Ә бу якта... Бу якта үзем торам ич!»

Ул ачу белән кул аркасын тешләде.

— Мәйдан тар, шайтан алгыры, мәйдан! Югыйсә...

≈≈≈≈≈

## Рәфкать Кәрами

# КӘККҮК ТАВЫШЫ

хикәя

### I



Урман эченнән ялгыз юлаучы атлый. Машиналар, атлылар йөреп такырлаган киң юл булса да, ул саргылт туфлиләре белән кипкән үләннәрне, коелган яфракларны таптап, аяк астында шарт-шорт сынып калучы корыган агач ботакларына басып, юл читеннән бара бирә. Өстендәге болонья курткасына, тар кырыйлы эшләпәсенә карап, аны туган авылына кунакка кайтып килүче шәһәр кешесе дияргә булыр иде. Ул аркасына зур гына биштәр аскан, кулына чемодан тоткан. Күпне күргән солдат гимнастеркасы кебек төсен югалткан яшькелт биштәр капчыгы һәм кыршылган юл чемоданы бу кеше турында, сәяхәтче түгел микән, дигән уй тудыра. Ләкин аның аяк атлавында сәяхәтчеләргә хас нык, салмак адым сизелми. Күрәсең, күптәннән урман эчләп тә үткәне юктыр: еш кына битенә агач ботаклары бәрелә, аны күрүгә барлы-юклы урман кошлары фырылдап очып китә.

Биштәр капчыгында ниләр барын тәгаен генә әйтеп булмаса да анда кечерәк гармун сыман нәрсәне шәйләргә мөмкин иде.

Юлаучының ябык чырайлы коңгырт йөзен җыерчыклар яргалаган, күе кара кашлары түбән салынган, хәтта чалара башлаган калын мыегы да бераз шәлперәйгән. Аңа ничә яшь икәнен белергә теләп, эшләпә астыннан күренеп торган, бөтенләй диярлек агарган чәчләренә, кояшта янган йөзенә игътибар беләнрәк карасаң, кырыкны да, иллене дә биреп булыр иде.

Беравык шул рәвешле башын иеп баргач, ул коңгырт күзләрен тутырып тирә-юньгә карап алды.

Баеп килүче кояш нурлары агач башларын әкрен генә саргылт төскә манган. Ләкин берничә адым атлагач, юлаучы кәккүк тавышын ишетеп кинәт туктап калды. Бу тавыш бихисап агач кәүсәләренә, чатлы-ботлы ботакларга, саргылт-яшел яфракларга бәрелә-сугыла еракераклардан килгәнгә бик тә әгъҗәеп иде. Ләкин ялгышу мөмкин түгел, кәккүк тавышы иде бу. Менә: бер, ике, өч...

Юлаучының бу урманда иң курыкканы да шул тавыш иде. Чөнки әлеге авазның нәкъ үзенә төбәп әйтелгән кебек ишетеләчәген ул сизә иде. Аның ялан кырдан кергәч тә урман юлы буеннан әкрен генә, һәр авазга колак салып сак атлавы да шул тавыштан курку аркасында түгел иде микән? Тора бара аның борчуы басыла төшкән иде. Урман эченнән ул бер-ике чакрымлап юл үтте. Кәккүк тавышы ишетелмәгәч, бөрешкән гәүдәсе тураебрак киткән сыман булды. «Бу вакытта нинди кәккүк кычкырсын, юләр мәллә алар», — дип көлеп, үз-үзен юатып та карады. Әмма барыбер тыныч кына бару насыйп булмады...

Менә алда ачыклык күренде, урман бетеп килә икән. Агачлар сирәгәйде, тәбәнәкләнде һәм, ниһаять, алар да артта калды. Кәккүк тавышы да артта калды, ләкин юлаучы колагында ул әле бик озак яңгырап торды.

Урманнан чыгып бераз баргач бәрәңге бакчасы кадәр урынны биләп торган куаклык очрады. Монда ул яшь чагында чикләвеккә йөри иде. Юлаучы, юлын дәвам иткән хәлдә, башын югары күтәреп, киң яфраклар арасыннан, куак башларыннан чикләвек кишәнкесе эзләде. Юк, күренми, җыеп бетергәннәр. Аңа бер генә чикләвек тә калмаган икән.

## II

Пөхтә итеп, тигез койма белән әйләндереп алынган зур зират яныннан үткәндә юлаучы ирексездән йөрәге сыкрап куйганын тойды. Чөнки иң якын туганнарыннан аның монда ил азатлыгы өчен ерак Белоруссия җирендә башын салган әтисе дә, улы янына кыш чыгарга гына дип килгән һәм берничә ел шунда яшәп, читтә үлеп калган әнисе дә, армиядә чакта кинәт юлга йөгереп чыккан бер сабыйны таптатмас өчен машинасы-ние белән яр астына очкан энесе дә — беркеме дә юк иде. Әтисе белән энесенең үләр алдыннан башларыннан ниләр кичергәнен юлаучы белми, бәлки аларның күп уйланып торырга вакытлары да булмагандыр. Шулай да гомерләренең соңгы минутында икесе дә туган якларын, шушы изге туфракны искә алмыйча калмаганнардыр. Ничек кенә булмасын, моны хәзер беркем дә төгәл әйтә алмый иде. Әмма әнисенең ата-бабалары яткан изге туфракка бик кайтасы килгән иде. Ләкин малае аны алып кайтып шушында җирли алмады. Хәтта газиз әнкәсенең җаны өзелгәнен дә күрә алмады... Ул көнне эштән соң, гадәтенчә, кибет тирәсен урап, таныш-белешләре белән кибет артында гәп сатып, соң гына кайтып кергәндә, әнисенең күзләре мәңгегә йомылган иде инде. Аның әнисе кебек үк малайларына торырга килгән, һәрвакыт кергәләп йөрүче, ә соңгы көннәрне бөтенләй диярлек алардан чыкмаган күрше татар карчыгы: «И-и бала, гел җаның юк икән. Шушындый көнне дә өеңә туры кайта алмадың», — диде. Әнисенең дә йөзендә улына карата гомергә онытылмаслык шелтә бар шикелле иде.

Зиратка тоташып диярлек кечкенә чирәмлек җәйрәп ята. Элегрәк монда кичке уеннар була торган иде. Юлаучыга башын кыңгыр салып, тыпыр-тыпыр биегән яшьтәшләренә фуражка астыннан карап, гармун тартып утырган тар эскәмия әле һаман да шундадыр кебек тоела. Ләкин бу үз-үзеңне алдау гына, ул эскәмия инде күптән юк. Кичке уен ясый торган җиргә колхоз ниндидер бина салып куйган. Артезиан коесы булса кирәк, янында буровойныкыннан бермә-бер кайтыш челтәрле тимер вышка кукыраеп утыра, ә аның очында җил тегермәненекедәй дәү канатлары тымызык җилдә салмак кына әйләнә. Юлаучы: «Бу нәрсәгә инде? Әнә бит тегендә, йөз—йөз илле адым-

да гына яр астында мул сулы чишмә бар», — дип уйлады. Аннары, артезиан коесы артында тезелешкән озын-озын ферма каралтыларын күргәч: «Дөрес эшләгәннәр, чишмәне корытмас өчен шулай иткәннәрдер», — дип уйлап куйды. Аның суы бик тәмле, бөтен авыл халкы, хәтта ишек алдында үз коесы булганнар да шул чишмәгә суга килә торган иде бит. Әнисенең дә күп мәртәбәләр, шушы хлурлы су авыз тәмнәрен ала, и-и, бер генә кайтып үзебезнең чишмә сулары белән самавар куяр идем, дигән чаклары исендә. Әйе, бик исендә. Менә хәзер, сакал-мыегына чал төшеп, туган авылына кайткач, юлаучы әнисенең хәлен бөтен чынбарлыгы, бөтен газабы, эчке борчулары белән аңлый башлады шикелле һәм ихтыярсыздан, ичмаса, шушы зиратка кайтарып та җирли алмадым, дип үкенеп куйды.

— Улым, нишләп болай аптырашка калдың?

Тыныч, салмак һәм бераз көйләбрәк әйтелгән бу сүзләр юлаучыга башта әнисе тарафыннан иңдерелгән аваз булып яңгырады. Аннан, башын күтәреп карагач, бу сүзләрне каршында басып торучы бер карчык әйткәнен шәйләде. Өстенә кара жикет, башына ак яулык бәйләп аның өстеннән түгәрәк бүрек кигән, буена караганда озынрак күренгән кәкре таяк тоткан бу карчык аптырап, үзенең чепи күзләрен мелт-мелт йомгаклап, юлаучыга кызыксынып карап тора иде. Зәңгәрсу кан тамырлары бүртеп торган кулы белән таягын ул чак кына алга табарак күчерде, икенче кулын аркасы белән бил турына куйды да:

— Улым, син берәр узгынчы — мосафирмы, әллә безнең авылга кайтасыңмы? — дип сорады.

Юлаучы әлеге буразна-буразна җыерчык баскан, карасу-саргылт битле, түшенә сары гәрәбә муенса таккан карчыкны танып алды. Аның кара төкләр шыткан, бармак башы кадәр миңе дә булган бите юлаучыга сабый чактан ук таныш иде.

— Миңлекамал түти, әллә мине танымыйсыңмы?

Карчык, бу сүзләрне ишеткәч, бик таныйсы килеп, бөкре гәүдәсен турайта төшеп, озын буйлы юлаучының ят йөзенә астан өскә таба текәлеп карап торды. Ләкин күпме генә караса да каршында торган ир-атны таный алмады ул. Моны күреп, юлаучының йөзенә чыккан баягы елмаю сүрелде һәм тавышында туган якларына кайтып, әле авылга кермәс борын таныш-белешеңне очрату куанычы юкка чыкты.

Ул коры гына:

— Мин Нәгыйм бит, — диде. — Сезнең күрше.

Кем икәнен әйткәч, аны аермачык танымаса да, карчыкның йөзе яктырып киткәндәй булды.

— Ә-ә, Сәхибҗамал малае мени? И-и, гомерләр, — диде ул башын селкеп, — син дә олыгаеп беткәнсең икән.

Нәгыйм бу сүзләрне өнәп җиткермәде. Ә карчыкның анда гаме юк иде кебек. Ул беравык күз алдындагы авылдашын бөтенләй онытып, үз уйларына бирелеп, ике кулы белән дә таякка таянып басып торды.

— Сәхибҗамалны әйтәм, бик тилмереп үлгән, дип сөйләделәр. Ситдыйк, мәркүм, и-и, белгәннәр булсам, үзем алып кайтып шушында җирләгән булыр ием дип, чит-ят җирләрдә гүр иясе булган сеңлесен җәллəп сөйли торган иде.

— Ничек, Ситдыйк абый үлдемени?

— Әйе, ул да китте, — диде карчык түгәрәк кара бүрекле башы белән Нәгыйм артындагы зиратка ишарәләп.

Нәгыйм ирексездән борылып зиратка, аның колач җитмәс юан кәүсәле тупылларына, өем-өем утырган сирень, гөлҗимеш, сәрби куакларына, такта һәм тимер рәшәткәләр белән әйләндереп, зур-зур

ташлар куелган каберләренә карады. Ләкин ул анда аермачык бернәрсә дә күрә алмады.

Алар шулай тыныч кына инде әйтер сүзләре беткән кешеләрдәй тагын беркавым чишмә буендагы юлда басып тордылар да, икесе берьюлы диярлек авылга таба борылдылар. Ә чишмә юлыннан каршыга, чая үсмер кызлар һәм җитез яшь киленнәр йөгерә-йөгерә су ташыган юлдан, кыска гына аксыл плащ һәм киңчә балаклы кара чалбар кигән, кызыл яулыклы бер кыз төшеп килә иде. Эңгер-меңгер якынлашса да, кызның кара тутлы чибәр йөзе, чем кара кыйгач кашлары һәм күпереп торган алсу иреннәре генә түгел, аяк атлауларының җиңеллеге һәм сыгылмалы гәүдәсенең һәр хәрәкәте диярлек Нәгыймгә таныш кебек тоелды. Дөрес, ул үскән заманнарда хатын-кыз чалбар да, язлыкта кия торган чабата күтәрмәседәй биек табанлы туфли дә, менә бу кызныкыдай киң путалы, иңендә солдат погоны кебек калкып торган артык-портык нәрсәле аксыл плащ та кими иде. Ә шулай да бу кызның йөреше, ягымлы йөзе яшьтән үк таныш булган кемнедер хәтерләтә иде аңа.

— Гөлнисаның олы кызы, — диде карчык, юлдашының туктап, чишмәгә төшеп киткән кыз артыннан бирелеп карап торуын күргәч. «Гөлнисаның олы кызы? Димәк, ул минем кыз була бит. Әйе, чат әнисе. Нәкъ Гөлнисаның яшь чагы. Ә нигә соң бу карчык аны, Гөлнисаның олы кызы ди. Нигә, синең кызың дими? Әллә белми микән? Нишләп белмәсен. Ул бит зиһенсез түгел, барысын да белеп сөйләшә. Ә нигә соң ул карчык, синең кызың, дип әйтмәде?»

## III

Бу көнне Нәгыйм кайтып төшкән Ситдыйк абзыйлар өендә, хәзер инде кече малае Әкмәлетдин төп хуҗа булып калган йортта, төн уртасына кадәр ыгы-зыгы туктамады. Күптәннән җиз самаварны алыштырган олы чәйнек тә газ плитәсе белән өстәл арасында бертуктаусыз килеп сарып йөрде. Кунакны элегрәк авыл халкының табынына иң олы бәйрәмнәрдә, елына бер-ике генә куела торган, хәзер инде гадәти ашамлыкка әйләнеп баручы тәмле ризыклар белән сыйладылар. Ул да үз күчтәнәчләрен, бар булган бүләкләрен чемоданыннан чыгарды, өс-башын алыштырды. Тик биштәр капчыгындагы гармун гына, һаман иреккә чыгасы килеп, моңаеп бер почмакта ята бирде.

Иртәгесен килен-балакай иртүк мунча ягып җибәрде, сугым пычагы, тастымал һәм комган белән җылы су күтәреп чыккан иренә ике әтәч тотып бирде.

Нәгыйм боларны күрмәсә дә, авыл халкының борынгыдан килгән гореф-гадәтен белеп, идән сайгакларының һәм кое сиртмәсенең бик иртә шыгырдый башлавыннан, өйалды, мунча ишекләренең, бакча капкасының сак кына шапылдавыннан сизеп ята иде. Юл йөреп арыса да, түшәк-ястыкның гел мамыктан гына булуына карамастан, бүген ул начар йоклады. Кайберәүләр урын алыштыруны авыр кичерә. Яшьрәк чакта Нәгыйм дә шулай иде. Ләкин күп еллар читтә йөрү дәверендә бу гадәтен ташлады; күбрәк, йокы ястык сорамый, дип башын кая төртсә шунда (хәтта ерак Себер урманнарының үзе кискән кедр бүрәнәләре өстенә брезент бияләй генә салган килеш тә) йоклап китә торган иде. Ә менә бүгенге төнне ул начар үткәрде. Төрле төшләр күреп, саташып, әледән-әле сискәнеп уянды, сәгатьләр буе уйланып ятты.

Иртәнге чәйдән соң укытучы Әкмәлетдин мәктәпкә җыенды. Шаярып кына кунакка:

— Әйдә, Нәгыйм абый, алып чыгам үзеңне. Бер дөнья күреп кайтырсың,— диде.

Нәгыйм бу тәкъдимгә бик теләп риза булды. Дөрес, туган авылында аның шушы йорттан башка барыр җире юктыр, дип уйлау хата булыр иде, әлбәттә. Монда бик үк якын булмаса да, чыбык очы тигән туган-тумача шактый иде. Ләкин күпме еллар бер хәбәрсез диярлек читтә яшәп, менә хәзер кайтып төшкән Нәгыймнең таң тишегеннән кешегә барып керәсе килми иде. Әкмәлетдин белән булса бер хәл, ә үзе генә... юк. Әллә ничек күңеле тартмый иде аның.

Бүген беренче сентябрь. Укучылар белән урам тулган. Аркаларына каеш белән ранец аскан бәләкәйләр мәктәп формасыннан, кулларында чәчәк бәйләмнәре, йөзләре җитди, тантаналы, кайберәүләрен әти-әнисе җитәкләгән, кызыл галстуклы зурраклар төркем-төркем булып үзләре генә баралар, кызып-кызып, бер-берен бүлдереп сөйләшәләр, бәхәсләшәләр, сигезенче-унынчы класс кызлары бертөрле киемнән булса да, җиту чәчле, озын буйлы үсмерләр төрлесе төрле киемдә, аяк атлауларында ук мөстәкыйльлек сизелә. Нәгыймгә боларны күзәтеп бару кызык та, сәер дә иде. Аның авыл, мәктәп турындагы уйлары да ун-унбиш елга бер ноктада калган икән. Без үскән заман белән чагыштырганда бу яшьләрнең уй-фикерләре дә башкачарактыр, дип уйлап алды ул.

Ашыга-ашыга мәктәпкә агылучы балаларның һәрберсе аларны узып киткәндә:

— Исәнмесез,— ди.

Нәгыйм бу сәламләүнең укытучы Әкмәлетдингә адресланганын белә, шулай да күпмедер өлеше аңа да тигәнен сизә. Чөнки авылда элек-электән кече балалар олыларны хөрмәтләп, исәнлек-саулык сорашып китәргә өйрәнгәннәр, бу хәтта яшь кешегә карата да үз көчендә кала торган гадәт.

Менә алда пошмыйча гына атлаучы өч егет күренде. Бүген беренче сентябрь һәм кулларында портфель булмаса, болар укучылардыр, дигән уй башка килмәс иде. Чөнки алар өчесе дә үзен уртадан калкурак дип йөргән Нәгыймнән дә озынрак гәүдәле, киң җилкәле, инде тәмам егет булып җиткән үсмерләр иде.

— Егетләр, соңга каласыз.

Өчесе дә укытучы тавышына ялт итеп борылдылар, һәм берьюлы диярлек, ашыгып:

— Исәнмесез,— диделәр.

Әкмәлетдин сәламнәрен алды, ә Нәгыйм бер сүз әйтә алмады. Егетләрнең берсе аңа кичә чишмә буенда күргән кыз кебек, тагын кемнедер хәтерләтә иде. Юк, монысы кемнедер башка бөтенне түгел, ә аның яшь чагын хәтерләтә иде. Егетнең йөзе бер мәлгә генә күренеп китсә дә аның киң текә маңгае, бераз чыгыбрак торган яңак сөякләре, кәкрерәк борыны һәм юка иреннәре нәкъ Нәгыймнең яшь чагында төшкән сурәте кебек иде.

— Таныдыңмы?— дип сорады Әкмәлетдин бераз баргач.— Фәһимә җиңги малае.

Нәгыйм чак кына сүгенеп ташламады. Ярый, кичәге томана карчык, Гөлнисаның олы кызы, дигән икән инде, әйтсен, шуңа күрә дә ул карчык кеше. Ә Әкмәлетдин? Соң бит үз кеше — ир-ат. Ул булып ул да, авызын ерып, Фәһимә җиңги малае, ди бит.

Әкмәлетдин кунакның бу тойгысын, гасабилы уйларын белми иде, әлбәттә. Әйткән сүзенә Нәгыйм абыйсының җен ачулары чыгып барадыр дип исенә дә китерми иде. Шуңа күрә ул аны-моны уйлап тормыйча:

— Әнә, күрше авылдан йөреп укучылар килә, Сара җиңгинең кызын да күрерсең.

Нәгыйм бара торган җиреннән шып туктады һәм Әкмәлетдингә шундый итеп карады, бары хәзер генә туганнан туган энесе аның халәтен аңлады булса кирәк.

— Ярар, мин мәктәпкә барып йөрмим инде,— диде Нәгыйм һәм Әкмәлетдиннең сүз әйтүен дә көтмичә, уңга борылып, китеп барды.

...Нәгыйм шактый вакыт авылны карап йөрде. Ул үзенең туган авылында икәнен дә белә, һәр йортның кемнеке икәнен дә чамалый, мәктәп, клуб, кибетләрне дә таный кебек, ләкин шул ук вакытта ул аларны танымый да. Менә каршында, авылның нәкъ урта бер җирендә, Нәгыйм белә-белгәннән шушы урында торган клуб. Ләкин бу инде хәзер клуб түгел, ә культура йорты, ике катлы, таштан салынган, эче-тышы чын ясау итеп бизәлгән. Янәшәсендә ике катлы таш магазин, асты — азык-төлек өчен, өстә — кием-салым. Алардан бер читтә, Нәгыйм барып җитмәгән мәктәп. Анысы да ике катлы, ак кирпечтән. Ихатасында озын тимер торбалы котельнясына кадәр бар. Ә эчендә ниләр генә юктыр... Бу инде ул туган авыл түгел. Йортлары да элеккечә түгел — калай да шифер түбәле, нарат бүрәнәдән, алты почмаклы. Элек андый йортлар авылда берничә генә — барысы да байлардан калган йортлар гына иде. Ә хәзер авылда бөтенесе шундый йортлар, ихата, абзар-кура да төзек, өй аралаш ак мунча. Күңеленең кай төшендәдер, бер генә секундка, әллә шушында төпләнергәме, дигән уй йөгереп үтте. Әйе, йөгереп үтте, ләкин тукталмады. Чөнки бу мөмкин түгел иде. Кайчандер аны якын иткән, аның белән язмышларын бәйләгән кешеләр хәзер бүтәннәр белән башкача тормыш итә, ата-баба нигезе күптән башка берәүгә күчкән, анда бер генә каралтыкура да элекке хәлендә калмаган һәм Нәгыйм таныр лык түгел иде. Ул гына да түгел, аның үзен танып белүчеләр дә сирәгәя бара...

Нәгыйм әйләнеп кайтканда төш җиткән, килен-балакайның мунчасы да, ашы да өлгергән иде инде. Мәктәптә эшләрен тәмам иткән Әкмәлетдин:

— Абый, сиңа ничек җайлырак булыр? Башта мунча кереп, аннан ашарсыңмы, әллә киресенчәме? — дип сорады.

Билгеле, башка вакытта ул да, кунак та башта мунча кереп, аннан ашап-эчүне кулайрак күрерләр иде. Ләкин бу юлы кунак тартыныбрак кына булса да:

— Мунчага ашагач кына барырмын,— диде.

Ул кайтышлый кибеткә сугылган иде, кесәсеннән бер ярты алып өстәлгә куйды.

— Ачуланмасаң бераз төшерик әле.

Ашап-эчкәндә кунак үзен тынычсыз, сәер тотты. Бер-бер артлы өч рюмка җибәргәч, тиз генә ярты тәлинкә аш ашады да, почмактагы биштәр капчыгыннан биш планкалы, буяулары уңган, шактый таушалган тальян гармунын тартып чыгарды. Ашыкмыйча, үзенә күрә бер ләззәт белән аны тез өстенә куеп, каешын җайлап кына иңенә салды, янә бер төзәтеп куйды. Менә өйне моңлы, сагышлы, ләкин ниндидер эчке бер дәрте булган борынгы көй авазы тутырды. Бу йортның болай оста уйнаган гармунчыны да, бөтенләй онытылып төрле авазлар чыгарган гармунны да һәм аларга хәйран калып утырган йорт хуҗаларын да беренче мәртәбә күрүе иде. Гармун белән уйнаучы әйтерсең лә икесе ике әйбер түгел, ә бер җан, бер тән кебек иде. Бер карауга бу моң гармун телләреннән әллә кайларга агыла сыман, ө

икенче баксаң — моң уйнаучының сагышлы йөрәгеннән агыла шикелле. Мондый тәңгәллек озак еллар тату яшәгән, төс-битләре белән дә бер-беренә охшый башлаган ир белән хатын арасында була да, тормышның бөтен ачысын-төчесен бергә татыган аерылмас якын дусларда гына була торгандыр. Тыныч күңел белән тыңларга да, гамьсез күз белән карарга да мөмкин түгел иде моны. Ә Нәгыйм күзләрен кысып, башын яшь чагындагыча кыңгыр салып, гармун тарткан көйгә акрын гына җырлап та җибәргәч, Әкмәлетдиннең күзләренә яшь килеп, күз аллары томаланды. Чөнки бу җырны бары Нәгыйм генә менә шулай үзәккә үтәрлек итеп җырлый ала иде.

Ялгыз каен күлләрдә.
Ялгыз каеннардин ялгыз
Мин бүгенге көннәрдә.

Нәгыйм җырдан да, уйнаудан да туктады һәм тез башындагы гармунына ишарәләп:

— Әкмәл, истәлек итеп сакласын, моны, минем... Фәһимә малаена бир,— диде.

Аннан гармунны сак кына идәнгә куйды, тагын бер рюмка салды да, рөхсәт сорагандай әйтә куйды:

— Мунча кереп кайтыйм булмаса.

...Кулына кечерәк юл чемоданы, өстенә затлы соргылт плащ һәм өр-яңа туфли кигән Нәгыйм чишмә буеннан үткәндә Гөлнисаны беренче мәртәбә кочаклап үбүен уйлап алды. Кичке уен була торган җиргә якынлашкач, Фәһимәне яучылап йөрүен, чикләвек куакларына җиткәч, Сараны үзенә чыгарга бик авырлык белән күндерүен исенә төшерде. Ул куак башларына бер генә мәртәбә күз салды да, бүтән карамас булды, чөнки анда барыбер чикләвек кишәнкесен таба алмаячагын, ул агачларның җимешләрен күптән башкалар җыеп бетергәнлеген белә иде инде.

Урман эченә кергәч, аның колагына тагын көккүк тавышы чалынгандай булды. Ә чынында исә бернинди көккүк тә кычкырмый, бары тик аңа гына шулай ишетелә иде.




ТАТАРСТАННЫҢ
60 ЕЛЛЫГЫНА

Марат Әмирханов,
Рөстәм Кильматов

# ЮЛ



Юл салу сукмактан башлангандыр, мөгаен. Сукмаклар зураеп, юлга әйләнгән. Нәкъ шушы чорда (әйтүләренә караганда, Борынгы Вавилон шәһәрендә) кеше үзенең уттан кала иң беренче һәм иң мөһим ачышын ясаган — тәгәрмәч уйлап тапкан. Арба, автомобиль, паровоз, хәтта... луноходлар да дөньяга килүләре белән тәгәрмәчне уйлап тапкан борынгы кешегә бурычлы. Ә кеше һаман эзләнгән. Башта аны тирә-яктагы урман-таулар кызыксындырган. Тора-бара анда чит җирләр, ят илләр белән танышу теләге уянган. Шуңа күрә төзегән дә төзегән ул юлларны: очлары зәңгәр күккә ашкан кыя-ташлар да, күбекләнеп аккан дәрьялар да, баткак-сазлыклар да куркытмаган кешене. Чөнки белгән: аралашу — ул тормыш, үсеш, яшәеш.

Хәзерге атом заманында, зур тизлекләр чорында юл үзенең социаль әһәмиятен дә, экономик зарурлыгын да югалтмады. Киресенчә, производствоны кооперацияләү, концентрацияләү һәм специальләштерү халык хуҗалыгы тармакларының үзара бәйләнешен тагын да көчәйтте. Предприятиеләр, завод-фабрикалар арасындагы элемтәләр фән-техника прогрессының мөһим өлешенә әверелде. Бу бәйләнеш юллар аша тормышка ашырыла. Хәзер һәр 100 тонна халык хуҗалыгы йөгенең 80 процентын автомобильләр ташый. Барлык пассажирларның өчтән икесе автотранспортка туры килә. Шуңа күрә автомобиль юллары төзүгә дәүләт зур игътибар бирә. Татарстанда, мәсәлән, асфальт һәм шоссе юлларның озынлыгы 9223 километр тәшкил итә. Тиздән аңа 218 чакрымлы Казан — Чаллы юлы — КамАЗ юлы кушылачак.

# Тизлек

Галимнәрнең исәпләвенчә, конвейердан чыккан һәр яңа машина өчен чама белән бер чакрым юл төзергә кирәк. Безнең илебездә, әйтик, 1979 елда ике миллион ярым чамасы автомашина житештерелде. Шул исәптән зур йөк күтәрешле Кама автомобиль берләшмәсе капкасыннан 70 мең машина чыкты. Тәүлек саен 200—250 машина — КамАЗ йөрәге әнә шул тизлек белән тибә. Ул тулы куәтенә эшли башлагач, баш конвейердан минут ярым саен бер «КамАЗ» төшеп торачак.

Күп житештерелә машина. Әмма аңа булган ихтыяж мөмкинлекләрдән күпкә артык әле. Шулай да аның чиге бар. Чөнки автомобильләр дә тормыш киңлекләренә мохтаж. Дөресен әйтергә кирәк, хәзергә кешелеккә бу куркыныч янамый. Көн тәртибендә бары тик булган автопарктан нәтиҗәле файдалану бурычы тора. Моңа ирешүнең төп юнәлеше — тизлекне арттыру. Белгечләрнең фикеренчә, автомашиналарның тизлеген берничә километрга арттыру меңләгән автомобиль чыгару бәрабәренә тигез. Тиз йөрү исә бары тик яхшы юлларда гына мөмкин.

Чал Чулман буенда автогигант төзелә башлауга, Казан — Чаллы автомагистрален салу мөһим бурычларның берсе сыйфатында көн тәртибенә куелды. Шунда ук ике проект институты — ГипроДОРНИИ институтының Ленинград филиалы һәм Гипротранмост Казан — Чаллы юлының техник проектын әзерләүгә керештеләр. Булачак трассада экономистлар, геодезистлар, геологлар һәм башка белгечләр эшли башлады. Алар проектның иң оптималь вариантын тәкъдим итәргә тиешләр иде. Оясында ни булса, очканында шул булыр. Шуның кебек, транспортның юлдагы тизлеге, уңайлылык, автомобиль йөртүчеләрнең, пассажирларның кәефе, ахыр чиктә, аларның исән-иминлеге проектның ни дәрәҗәдә комплекслы башкарылуына бәйле.

Хәзерге заман автомобиль юлларын проектлауның мәҗбүри кануннары бар. Шуларның берсе: юл тирә-як мохит, ландшафт белән гармоник рәвештә ярашырга тиеш. Казан — Чаллы магистралендә бу таләп тулысынча исәпкә алынган. Автотранспорт бу шома юлдан күз иярмәслек тизлек белән йөри алырлык итеп сайланган. Бу, әлбәттә, машиналар шул тизлектә йөрергә тиеш дигән сүз түгел. Запас мөмкинлек көтелмәгән хәлләрдә куркынычсызлыкны тәэмин итәр өчен кирәк.

Борынгылар юл газабын гүр газабына тиңләгәннәр. Ә хәзер юл эш урыны, алай гынамы, юл йөрү — ял итүнең дә киң таралган бер төре. Шуңа күрә юл арытмаска тиеш. Бу исә табигать гүзәллеге бөтен тулылыгы белән юл кешесе алдында ачылса гына мөмкин. КамАЗ юлы бу яктан да ким-хур түгел. Сөзәк күтәрелешләр, ышанычлы саклагычлар һәм юл күрсәткечләре — болар барысы да машиналарга хәвеф-хәтерсез йөрергә мөмкинлек бирә.

Юл «киемен» проектлаганда төп ике таләп — ныклык һәм озын гомерлек беренче урынга куела. Бу очракта күчәргә төшкән авырлык белән юл «киеменең» калынлыгы арасындагы мөнәсәбәтне электрон-хисаплау машинасы хәл итте. Әйтик, каты өлешенең конструкциясе 64 сантиметр итеп билгеләнде. Бу МАЗ, КРАЗ, КамАЗ кебек зур йөк күтәрешле машиналарның юлда берниндн чикләүсез йөрүен тәэмин итә. Өслекнең конструкциясе шактый катлаулы. КамАЗ юлы шундый класстагы юллардан һич тә калышмый, бәлки, кайбер параметрлары белән узып ук китә. Аның өстенлеге, беренче чиратта, комплекслы булуында. Мәсәлән, проектта архитектура бүлегенә зур урын бирелгән. Һәм юкка гына түгел: күз уңында кеше. Аны юл ялыктыр-

масын, максимум уңайлык булсын. Максаты шул. Тәгәл алганда, кыска вакытлы ял өчен дүрт тукталыш, ун җиңел машинага исәпләнгән ике махсус мәйдан, утыру-төшү урыны һәм тизлекне үзгәртү полосалы 48 автопавильон җиһазландырылачак. Болардан тыш тирә-як мохит һәм ландшафт белән бердәмлектә төрле кече архитектура комплексы булдыру күздә тотыла. Аның үзенчәлеге шунда: ул милли традицияләргә нигезләнә.

Ике яктан сузылган яшел зона юл яны һавасын чистартып торачак.

... Унлаган елга һәм чишмәләр аша юл тасмасы Кама ярларына омтыла. Кино кадрларыдай, бер күренеш икенчесе белән алышына. Яшел үзәнлекләр, сулы уйсулыклар күзгә чалына, ялангач тау сыртлары, текә ярлар артта кала. Юлаучы тирә-юньнең бу катлаулылыгын тоймый да. Чөнки юл туры, тигез, уңайлы. Төзүче өчен исә бу шактый мәшәкатьле. Әйтик, Вятка һәм Мишә елгалары аша салынган күперләр. Магистраль Әгерҗе — Круглое Поле тимер юлын, Алабуга — Ижевск автомобиль юлын кисеп үтә һәм Түбән Кама гидроэлектр станциясе плотинасына килеп тоташа. Башкару технологиясе ягыннан шактый катлаулы эш.

Еш кына шундый сорау бирәләр: бер километр асфальт юл дәүләткә күпмегә төшә? Казан — Чаллы автомагистралендә ул ничек? Турысын әйтергә кирәк — кыйммәт. Чагыштыру өчен башка илләр юл төзү практикасына мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Америка Кушма Штатларында, мәсәлән, иң югары категорияле юлның һәр километры 700—800 мең доллар. Шулай ук кыйммәт. Әмма америкалыларда шундый әйтем бар: иң кыйммәт юл — иң очсыз юл. Ни өчен? Чөнки юл төзелешенә киткән чыгымнар үзләрен бик тиз каплый. Нинди генә налог уйлап тапмыйлар бу илдә! Әйтик, 1 литр ягулык алсаң, 1,1 центы юл налогы. Сатып алучы 1 килограмм шинга 25 цент күләмендә юл налогы түләргә тиеш. Автомобильләрне сату бәясенең 10 проценты да шул чыгымнарны каплауга китә. Моннан тыш түләүле шәхси юллар, күперләр тагын күпме.

Юл төзү елдан-ел кыйммәтләнә бара. Эш нәрсәдә соң? Сәбәбе ачык аның: хәзерге заман юлы — катлаулы корылмалар комплексы. Юл тасмасыннан тыш аңа, алда әйтелгәнчә, күп санда ярдәмче корылмалар кирә. Бу урында «ярдәмче» дип әйтү дөреслеккә дә туры килеп бетми. Чөнки юл комплексына төзәтү урыннары, пассажирлар өчен автостанцияләр, автомобильләргә техник карау үткәрү, бензин салу станцияләре кирә. Бу объектларны берәү дә кирәксез дип әйтергә җөрьәт итмәс, мөгаен. Автосервис — заман таләбе.

Автомагистральнең үзкыйммәте үсүгә йогынты ясый торган икенче сәбәп — төзү материалларының күп тотылуы.

Транспорт чыгымнарын шулай ук хәтердән чыгарырга ярамый. Чөнки юл төзүгә киткән барлык чыгымнарның 40 процентка якыны транспорт өстенә төшә. Урында алар юк: вак таш һәм цемент Уралдан, битум Уфадан, күпер конструкцияләре Мәскәү өлкәсеннән җибәрелә.

КамАЗ юлының әзер участокларында автомобиль хәрәкәте инде күптәннән ачылды. Каманы буу, Вятка аша күпер салу магистральнең масштабларын киңәйтте.

## Күпер

Мамадышка килеп керүгә, күпер эзлисең. Әле бер, әле икенче якны күзәтәсең. Әмма файдасыз: елга күренми дә күренми. Үч иткәндәй, юл боргаланыпмы боргалана. Чуалган йомгакмыни! Әнә ул ма-

шинаны бөтенләй кире якка алып китте — тау менәбез. Озын, сөзәк тау...

Менә кайда икән матурлык, чын табигый матурлык! Тау башыннан тирә-як самолеттан карагандай күренә. Аста җәйрәп Вятка ага. Ул тасма булып горизонт чигенә сузыла. Уң якта, биек яр башында шәһәр корылмалары. Кечке кояш аны ал төскә манган. Сулда әрәмәлекләр, болынлыклар. Салмак җил печән чабучы тракторларның тонык гүләвен алып килә. Рәссам өчен әзер күренеш. Тот та кәгазьгә төшер.

Күпер бу манзараны бозмый. Дөрес, ул үзенең төз, тигез, аз гына кырыс формалары белән елга буе пейзажына индустриаль төсмер бирә. Әмма менә мин дип кычкырып тормый, ипле генә итеп табигать кочагына кергән дә утырган.

Кайчандыр Алабуга ягына чыгу өчен икешәр сәгать паром көтеп яткан чаклар искә төште. Ә хәзер... машиналар выж итеп кенә кала. Тизлекне дә киметергә кирәкми. Ике минуттан аргы якта буласың. Хәер, аның аргы як икәнлеген уйлаучы да юк.

Күпернең озынлыгы 611 метр. Аны Мәскәү күпер трестының Рязаньдагы отряды төзеде. Тимер-бетон конструкцияләре дә Рязаньнан су юлы белән китерелде. Монтажны танылган инженер һәм оешты-ручы Иван Иванович Шмыга җитәкчелегендәге эре күперләр төзүче тәҗрибәле коллектив башкарды. И. Шмыга — илебезнең танылган күпер төзүчесе. Аның җитәкчелегендә Рязаньда Ока, Мәскәүдә Мәскәү елгасы аша төзелгән күперләр илебез төзелеш елъязмасына кертелде. Иван Иванович һәм үзләрен яхшы яктан күрсәткән башка монтажчылар ТАССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамоталарына лаек булдылар.

Күперне дәүләт комиссиясе «Бик яхшы» билгесенә кабул итте. Аны кору җиңел булмады. Елганың суднолар йөри торган өлешендә терәкләр кую катлаулы һәм четереклесе булды. Иң элек терәкнең тимер-бетон өлешләрен җыйдылар: бик зур «кое» барлыкка килде. Тик аны ничек утыртырга? Шундый карар кабул ителә: бетон «кое»дан суны суыртып алырга (су эчендә су суырту ай-һай җиңел түгел!) һәм корылманы вибробатыргыч белән төпкә утыртырга. Утырту гына булса бер хәл иде, аның эчендәге балчыкны алырга кирәк. Эш уйлаганча гына бармый, әлбәттә. Кодрәтле Нептун төзүчеләргә киртә артыннан киртә куя. Су патшасы белән бәйләнешле булмаган авырлыклар да җитәрлек: насослар сафтан еш чыгып тора, «кое» янә мөлдерәмә су белән тула. Нишлисең, барысын да яңадан башларга туры килә.

— Шактый җәфа чиктек,— дип искә ала ул көннәрне Иван Иванович.

Әмма осталык, кыюлык, тәвәккәллек җиңеп чыга. Нептун бабай бирелергә мәҗбүр була: «кое»лар проектта билгеләнгән тирәнлеккә төшеп утыра. Билгеләнгән тирәнлек исә елга төбеннән шактыйга түбәнрәк. Бу — дүрт катлы йорт биеклеге. Димәк, аңа шул кадәр үк биеклектә бетон тутырыла. Күпер әнә шундый нык, чыдам нигезгә корыла. Калган эшләр йөзмә краннар ярдәмендә башкарыла. Бу эш шулай ук җиңел булмый. Берсе-берсе уналтышар тонна авырлыктагы тимер-бетон өлешләрне җыю өчен бөтен көчне сарыф итәргә туры килә.

Күпер фән-техника казанышлары нәтиҗәсендә туган иң яңа технология нигезендә төзелде. Блок-секцияләр урында җыелды һәм кран ярдәмендә урнаштырылды. Шулай да иң хикмәтлесе бу түгел...

Гадиләштереп күз алдына китергәндә, күпер төзелешенең классик

үрнәге шуннан гыйбарәт: ул ике як ярны тоташтыручы балкаларга (аның формасы төрле) нигезләнергә тиеш. Ата-бабалардан калган традиция бу. Ныклыкны бары тик шул рәвешчә генә тәэмин итеп була дип исәпләгәннәр алар. Дөрес, зур транспорт күперләре төзегәндә катлаулы инженерлык исәп-хисаплары үткәрелгән, тирбәнү-калтырану, һава шартларының үзгәрүе искә алынган. Ләкин бу ысул нигездә үзгәрешсез калган. Хәзер исә хәл башка. Торыкларның бөтен авырлыгын тоташ балкалар түгел, корыч чыбыклар күтәреп тора! Вятка күперен, әйтик, 5 миллиметр диаметрлы 9100 чыбык үз «җилкәсендә» тота. Корыч чыбыклар 190 учмага җыелып, каплар эчендә калдырылган махсус юллар аша терәкләргә тоташтырыла, цемент белән катырыла. Корыч чыбыклар 120 тоннага исәпләнгән домкратлар белән тартылды. «Бу яңалык нәрсә бирә?» — дип сораулары ихтимал. Төп отыш: күпернең авырлыгы кими. Шулай булгач, аның үзкыйммәте дә кими.

— Күпер салу белән бергә аңа килү юлларын күтәрү турында да уйларга кирәк иде. Бу шактый каты чикләвек булып чыкты,— ди «Каздорстрой» тресты управляющие В. И. Усатенко.

Владимир Иванович сүзендә хаклык зур. Ник дисәң, Вятканың сул ягында тугайлар-үзәнлекләр җәелгән. Язын-көзен су астында кала. Арасы да шактый: өч чакрым ярым.

Моңа «Трансгидромеханизация» трестының Казан идарәсе белгечләре алынды. Әлбәттә, баш җитмәслек, аһ орырлык эш түгел иде бу. Чөнки су төбенә торбалар аша комлы су кудыру инде күптәннән кулланыла. Казанда, мәсәлән, элек сазлык булган урыннарга ком кудырып, күпме йорт салдылар! Биредә исә итәктән вакыт тотып тора иде. Гидромеханизаторлар ары чаптылар, бире йөгерделәр, әмма үзләренекен иттеләр, сүзләрендә тордылар. Биредә комлы су кудыруның иң яңа технологиясе кулланылды. Бер сезонда гына да (май — ноябрь) миллион ярым кубометр балчык өеме һәм җир өеме барлыкка килде. Чагыштыру өчен шунысын да әйтик: бу кадәр күләмле эшне башкару өчен 12 экскаватор һәм 90 зур йөк күтәрешле үзбушаткычлар кирәк булыр иде.

Эш тизлеген арттыруда, земснарядның нәтиҗәлелеген күтәрүдә рационализаторларның өлеше зур булды. Өлкән прораб Ж. К. Хисаметдинов һәм земснаряд начальнигы В. Ш. Сидаев кыру җайланмасын һәм балчык җәю схемасын камилләштерделәр. Яңалык сөючеләр тәкъдиме белән балчык утырма проектта каралган дүрт урынына ике яруста өелде.

Казан — Чаллы юлында күперләр төзү дә каралган. Моннан тыш уннарча чакрым җир тасманы бетон плитәләр белән ныгытырга, үлән чәчәргә кирәк. Боларның күп өлеше үтәлгән инде.

...Кич җитте. Елга буйларына, шәһәр өстенә төн пәрдәсе ябылды. Машиналар фараларын кабызды. Ерактан караганда бәйрәм аттракционына куелган йөгерек ут чылбырын хәтерләтә алар: бер якта ак ут, икенче якта — кызыл. Утлы чылбыр әйләнә дә әйләнә.

## Хәрәкәттә бәрәкәт

Магистральнең 159 чакрымы әзер. Алабуга — Мамадыш участогында хәрәкәт ачылуга шактый вакыт узды. Казан ягыннан 60 нчы километрга кадәр һич шөбһәсез машинада барырга мөмкин. Былтыр ел азагында тагын 36 километр ара файдалануга тапшырылды. Ә 1980 ел — җиңү елы булачак.

Юлны кем төзи соң?

Казан — Чаллы юлының генподрядчысы «Каздорстрой» тресты. Трест коллективы — тупланган, уңган, теләсә нинди бурычларны да башкарып чыгарлык сәләтле коллектив. Тәҗрибәсе дә зур. Аның Мәскәү — Минск, Мәскәү — Симферополь, Мәскәү — Ленинград югары класслы автомагистральләрен салуда катнашуы — моны исбатлый торган дәлил. КамАЗ юлын күтәрүнең иң кайнар көннәрендә тресттагы алты подразделениенең бишесе трассада эшләде. Төгәлләү чорында өч идарә катнаша. Казан ягыннан 913 һәм 928 нче төзү идарәләре коллективлары бара, Мамадыштан 856 нчы идарә кешеләре килә.

Күпме бу, азмы? Тарихчылар теге яки бу һөҗүмне тикшергәндә гадәттә анда катнашкан техника һәм корал санын җиңүнең бер сәбәбе итеп күрсәтәләр. Төзелеш — шул ук фронт. Тыныч фронт. Анда да меңәрләгән кеше, йөзләгән техника катнаша. Әлеге юлда хәзер 13 экскаватор, 22 бульдозер, 15 скрепер, 12 автогрейдер, 150 автомашина һәм күп санда башка техника эшли. Өч цемент-бетон һәм өч асфальт-бетон заводы магистральне асфальт һәм бетон белән тәэмин итә.

Юл — төзелеш объекты. Әмма башкалардан күпкә үзгә — күчеп йөри. Төзелеш мәйданы уннарча, йөзләрчә чакрымга сузыла. Бу очракта да аны фронт белән чагыштырырга мөмкин. Алдан күрүчән хәрби җитәкчеләр иң элек хәрби тәэминат хезмәтенең тоткарлыксыз һәм тиз эшләвенә ирешәләр. Юл төзелешендә нәкъ шундый хәл. Нәтиҗәле эшлим дисәң, производство базасының кул астында булуына ирешү. Трассада, мәсәлән, автомат идарә итәлә торган сәгатенә йөз тонна куәтле асфальт-бетон заводы өч мәртәбә урын үзгәртте: Алабуга, Колай, 60 нчы чакрым. Мондый күченүнең мәшәкатьләрен күз алдына китерү читен түгел. Былтыр март—апрель айларында безгә шундый урын алыштыруның берсен күзәтергә туры килде.

... Завод утырачак мәйданда ыгы-зыгы. Әмма бу беренче карашка гына шулай тоела. Бирелә һәркем үз вазифасын төгәл белә һәм аны җиренә җиткереп үтәргә тырыша.

— Вира! Вира!

Күтәрү кранының саргылт угы тимер җыелманы эләктереп ала да бер-бер артлы монтажчыларга җиткереп тора: җитеш кенә.

Операторның пыяла белән уратып алынган бүлмәсендә электрчылар В. Мякишев һәм А. Поспелов электрон җиһазларны урнаштыру белән мәшгуль.

Ашыгырга туры килә. Чөнки төзүчеләргә эш фронты кирәк. Завод тизрәк продукция бирә башларга тиеш.

Юл салуның ние бар: балчык сал да тигезлә. Йорт төзүгә карата ярымшаяру белән әйтелгән халык мәкален юлчылар шулай үзләренчә борып әйтә. Әмма хәзерге заман юл төзелеше югары дәрәҗәдә механикалаштырылган эш. Ул катлаулы инженерлык исәп-хисабына нигезләнә. Шуңа күрә һәр елга эшне оештыруның бик төгәл проекты булдырыла. Казан — Чаллы юлы төзүнең биелга кабул ителгән проектында, мәсәлән, эш күләме, аны уңышлы үтәү өчен кирәк булган кеше һәм техника эшне оештыруның иң төгәл алымнары, вакыты күрсәтелгән. Аның нигезендә комплекслы агым эшен нәтиҗәле оештыру ята. Чөнки төзелештә төп буын ул. Проектта субподрядчыларның вазифалары шулай ук төгәл билгеләнгән.

Шулай да хәл ителәсе проблемалар юк икән, барысы да ал да гөл икән дигән нәтиҗә ясарга бернинди нигез юк. Эшне оештыруның «авыр өлеше» булып, элекке еллардагы кебек үк, әле һаман автомобиль транспортының җитмәве кала. Юл төзелешенә автотранспорт күп

таләп итәлә. Чөнки ул төзелеш материаллары, ярымфабрикатлар һәм һәр төрле җыелмаларны бик ерак араларга ташу белән бәйләнгән. Әйтик, Казан—Чаллы юлының бер чакрымын төзүгә генә дә 30 мең тонна төзү материалы таләп ителә. Шуны да истән чыгармаска кирәк: трасса тимер һәм су юлларыннан 50—150 чакрым ераклыкта тора. Асфальт-бетон измә һәм бетонны озак вакыт саклап булмау да хәлне авырайта — сәгать-сәгать ярымда алар эшкәртелергә тиеш.

Трестның бу зур эшләрне башкарып чыгарлык автотранспорты юк. КамАЗ юлында, мисал өчен, барлык йөкләрнең 30 процентын Татарстан автотранспорт идарәсе машиналары ташый. Алар елга 18 — 19 миллион тонна-чакрым эш башкаралар. Бу күбесенчә кыш һәм яз айларына туры килә. Ә юл төзелешенең иң кызган чорында — җәй көне машиналар урып-җыюга китә. Төзелештә бушлык барлыкка килә. Урып-җыю шулай ук сезонлы, дәүләт күләмендәге әһәмияткә ия эш. Бу бушлыкны булдырмау әмәлен юлчылар үз транспортларыннан нәтиҗәлерәк файдалануда күрәләр. Мәсәлән, бортлы машиналарга контейнерлар урнаштырып, аларны измә ташуга көйлиләр. Моның белән генә мәсьәлә хәл ителми, әлбәттә.

Белгечләрнең әйтүенчә, җитәрлек кадәр автотранспорт даими бирелеп барылганда магистраль ике ел элек төзелеп беткән булыр иде. Һәр проблема үзе проблема китереп чыгара. Срокларның сузылуы экономикага суга. Сафка баскан һәр яңа объект дәүләткә доход бирергә тиеш: юлмы ул, заводмы, ателье яки культура йортымы—һәрберсе үзен акларга тиеш. Аның формалары күп төрле. Әйтик, начар юлда йөргән машина тиз ватыла, ягулыкны да күп ашый. Машинага чыгым каралганнан артык тотыла. Юлның «доходы» әнә шулардан туплана. Казан—Чаллы магистрале моннан ике ел элек сафка баскан булса, күпме дәүләт акчасы янга калган булыр иде!

КамАЗ юлын төзүчеләр финишка якынлашып киләләр. Быелның октябрендә асфальт тасма Татарстан башкаласы Казанны автомобиль төзүчеләр шәһәре — Чаллы белән тоташтырачак.

Төзелештә булсын дип, зур тырышлык сарыф итеп эшләүче алдынгылар бик күп. Менә аларның кайберләре: электр ярдәмендә эретеп ябыштыручылар Зарипов, Беляев, Николаев, бульдозерчылар Садыйков, Климин, Киволь, Сафиуллин, скреперчылар Далецкий, Солдатов, автогрейдерчылар Баженов, Осипов, Ваһапов, Җиһаншин, Попов, Бикмурзин, шоферлар Йосыпов, Белоусов, Абдуллин, Маслов, Кәримов, Хәлиуллин, Шакиров иптәшләр һәм башкалар.

Хәзерге заман юл төзелеше техникасы гаять катлаулы һәм аның белән идарә итү өчен әзерлекле кешеләр кирәк. Шуны истә тотып «Каздорстрой» тресты уку пункты ачты. Анда эшләүчеләрнең квалификациясен күтәрүдә системалы эш алып барыла.

Юл һәрвакытта да прогресс иярчене булды. Әмма үз чиратында юл фән-техника прогрессын үстерүгә, аерым төбәкләрнең экономик потенциалын күтәрүгә уңай йогынты ясады. КамАЗ юлының да бу яктан мөмкинлекләре зур. Чөнки магистраль республиканың индустрия «җиле» тимәгән районнары территорияләреннән уза. Трасса Питрәч, Саба, Балык Бистәсе, Мамадыш район колхоз-совхозларының промышленность үзәкләре белән элемтәсен ныгытачак, аларны шәһәрләргә «якынайтачак».

Казан—Чаллы автомагистраленең Татарстан, Урал яны һәм Урал буе өлкәләре өчен әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Ул бу өлкәләр һәм республикаларның экономик бәйләнешен тагын да арттырачак. Казан янында Идел аша күпер салгач исә илебезнең үзәк районнарына чыгу юлында яшел ут кабыначак. Ә Идел аша күпер унберенче бишьеллык бурычы. Әмма әзерлек эшләрен быел ук башлау планлаштырыла.

Кешеләрнеке кебек үк, һәр юлның үз тарихы, үз язмышы бар. Казан — Чаллы юлының язмышы — бәхетле язмыш. Чөнки ул исеме бөтен дөньяга билгеле автогигант — КамАЗ баһадир барлыкка китергән юл. Әгерҗе — Чаллы тимер юлы магистрале, традицион су юлы белән комплекста автомагистраль КамАЗның тышкы элемтәләрен тулысынча тәэмин итәчәк.

Автомобиль юлының сафка басуы зур йөк күтәрешле автомобильләр җитештерүче Кама берләшмәсенең икенче чираты сафка баскан вакытка туры килә. Бу — тиздән илебез юлларына һәр елны 150 мең «КамАЗ» машинасы чыгачак дигән сүз; бу — 1970 ел белән чагыштырганда автомобиль паркының 1,5 мәртәбә артуы дигән сүз. Ә алар өчен юллар кирәк, юллар кирәк...

# НЫГУ

Татарстан АССР элекке Казан губернасы территориясендә 1920 елда Ленин декреты нигезендә төзелде. Ул экономик үсеше ягыннан илнең үзәк промышленность районнарыннан гына түгел, урта дәрәҗәдән дә шактый артта иде. Әйтик, 1913 елда ил экономикасында промышленность продукциясе өлеше 42 процент тәшкил итсә, Казан губернасында 25 процентгаң артмады. Җан башына продукция җитештерү, илдә уртача алганга караганда, дүрт тапкыр диярлек азрак булды. Җитештерү средстволары җитештерү («А» группасы) күләме Россия промышленностенда 35 процент булса, Казан губернасында нибары 7,9 процент тәшкил итте. Губернаның шәһәр халкы саны да, Россиядәге уртача күрсәткеч белән чагыштырганда, ике тапкыр кимрәк иде.

Экономика үсешендәге мондый артталыкның төп сәбәпләре патша самодержавиесенең шовинистлык-колонизаторлык политикасы булды. Ул илнең милли районнарын нигездә рус капитализмына чимал куючы төбәккә әверелдерде, аларның табигый байлыклары да өйрәнелмәде. Россиядә тимер юл төзелеше киеренке темплар белән алып барылуга карамастан, Казан губернасында бердәнбер Тимирязево — Алатырь тимер юлы 1894 елда, ә Идел аша күпер 1913 елда гына салынды. Казан — Екатеринбург (Свердловск) тимер юлы төзелеше Октябрь революциясенә кадәр төгәлләнеп бетмәде.

Бөек Октябрь җиңүеннән соң Ленин партиясе җитәкчелегендә ил экономикасында тамырдан социалистик үзгәртеп корулар үткәрелде: җир һәр җир асты байлыклары, промышленность һәм банклар, тимер юл һәм су транспорты национализацияләнде, дәүләт һәм хуҗалык идарә аппараты органнары төзелде.

Татарстанда да беренче социалистик үзгәртеп корулар уңышлы рәвештә гамәлгә ашырылды. 1918 елның җәенә 30 дан артык эре промышленность предприятиесе, банклар, Идел флотилиясе судноолары национализацияләнде, губерна совет халык хуҗалыгы төзелде, промышленностьны демилитаризацияләү башланды.

Россия контрреволюциясе һәм халыкара империализм Советлар республикасына гражданнар сугышын һәм чит ил хәрби интервенциясен көчләп такты. Ил бердәм сугышчан лагерьга әверелде, хәрби коммунизм политикасы кертелде. Бөтен ил, шул исәптән Татарстан промышленносте дә фронтка хезмәт итүгә мобилизацияләнде. Эре һәм вак промышленностьның байтак өлеше Совет хөкүмәте кулына күчте. 1918—1920 елларда Татарстанда 350 гә якын эре һәм 100 дән артык вак промышленность предприятиесе национализацияләнде.

Совет иле эшчеләре һәм крестьяннары үзләренең героик хезмәтләре белән блокада, гражданнар сугышы һәм җимереклек шартларында Кызыл Армияне корал, кием-салым һәм азык-төлек белән тәэмин иттеләр.

Гражданнар сугышы җиңү белән тәмамланганнан соң Советлар иленең эшчеләр сыйныфы тырышлыгы белән ачлык һәм җимереклек тә әкренләп җиңелде, бер-бер артлы заводлар һәм фабрикалар, электр станцияләре, башка промышленность объектлары торгызылды һәм яңалары сафка кертелде. Татарстанда Карпов исемендәге Бондюг химия заводы эшчеләре тиңе булмаган хезмәт батырлыгы күрсәттеләр: алар 1920—1922 елларда электр станциясе һәм 3 километр озынлыгындагы тар линияле тимер юл, йөк йөртә торган 200 метрлы тимер аркан юлы төзеделәр. 1921 елда бирелә Советлар республикасында беренче радий заводы һәм аның эшчеләре өчен берничә торак йорт салынды.

Татарстанда 1921 елда тагын бер күренекле вакыйга булды. Беренче Май демонстрациясе вакытында Казан шәһәрендәге үзәк мәйданнарның берсендә көчле тавышлы рупорлар сөйли башлады. Аларны техниклар А. В. Дикарев һәм А. Т. Углов ясаган иде. Бу техник ачыш белән Владимир Ильич Ленин кызыксынды. Ул шундый ук рупорларны Мәскәү һәм Питерга да куярга тәкъдим итте. Һәм әлеге иптәшләр Ленин кушуы нигезендә бер айда рупорлар ясадылар, алар Мәскәүнең алты мәйданына куелды. Кешеләр диктор тавышын гаҗәпләнеп һәм таңга калып тыңладылар.

1922 елда Бөгелмә һәм Спас кантон электр станцияләре төзелде. Казанны һәм шәһәр промышленностен электр линиясе белән тәэмин итүдәге кыен хәлне исәпкә алып, көзен Халык Хуҗалыгы Югары Советы һәм РСФСР Госпланы электрлаштыру буенча, эре промышленность һәм политик үзәк буларак, шәһәрне беренче категориягә кертү турында карар кабул итте. Халык Хуҗалыгы Югары Советы шул ук вакытта Ульяновск губернасындагы Сенгиль цемент заводындагы мең киловатт куәтле двигатель һәм җиһазларны Татарстан совнархозына бирү турында карар чыгарды һәм аны сүтү, Казанга күчерү өчен алтын белән 300 мең сум акча җибәрде. 1923 елның 25 июнендә — Татарстан АССРның өч еллыгы көнендә Казандагы 2 нче электр станциясен төзеп бетерү һәм монтажлау башланды. Шушы вакыйга хөрмәтенә ул «Татарстан республикасының өч еллыгы» исемендәге станция дип аталды. Электр станциясен төзү ике ел дәвам итте һәм ул республиканың бишьеллыгы алдыннан файдалануга тапшырылды. Шушы чараларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 1921—1925 елларда Татарстан электр станцияләренең куәте 1,1 мең киловаттан 8,5 мең киловаттка җитте, ягъни 8 мәртәбә артты.

Яңадан җиһазландырылган Казан мастерское 1925 елда татар шрифты белән беренче язу машиналары чыгара башлады. Әлеге предприятие беренче бишьеллык чорында язу машиналарының заводына әверелде. 1926 елда яңадан җиһазландырылган Казан сукно һәм киез итек фабрикалары сафка кертелде. Вахитов исемендәге, Карпов исемендәге Бондюг заводлары, байтак кына башка предприятиеләр салынды.

Гражданнар сугышы чорында ике тапкыр хәрби хәрәкәтләр аренасы булган Татарстан территориясенең бөлгенлек кичерүе, шулай ук 1921—1922 еллардагы корылык һәм ачлык республика халык хуҗалыгын торгызу темпларын нык тоткарлады.

Татарстанда социалистик индустрияләштерүнең беренче адымнары 1927—1928 елларда башланды. Беренче ике елда 17 эре предприятие, шулар арасыннан Ленин исемендәге Казан текстиль фабрикасы, күн заводы һәм «Спартак» аяк киемнәре фабрикасы, «Урак һәм чүкеч» механика, Богородск алебастр, Васильеводагы «Победа труда» пыяла заводлары, Кукмарадагы «Кызыл текстильче» киез аяк киеме фабрикасы һәм башкалар яңартып корылды. Шул ук елларда сигез яңа промышленность объекты салына башланды.

Социалистик үзгәртеп коруларга нэпман буржуазиясе, кулаклар һәм башка сыйнфый дошман элементлар нык комачаулык итте. Татарстан партия оешмалары бер үк вакытта троцкийчыларга, уң оппортунистларга һәм буржуаз милләтчеләргә каршы да кискен көрәш алып бардылар. Югары Халык Хуҗалыгы Советы һәм Төньяк химтресты аппаратларында утырган кайбер элеккеге белгечләр дә индустрияләштерү темпларына каршылык күрсәттеләр. Алар Бондюг химия, Вахитов исемендәге Казан сабын кайнату заводларын яптырырга, шулай итеп, республикада химия промышленносте үсешен туктатырга маташтылар. Бондюг химия заводы өчен биш ел киеренке көрәш барды. Республиканың партия һәм совет оешмалары 3800 эшчесе һәм хезмәткәре булган (шуларның 50 процентка якыны татарлар) эре химия предприятиесен бетерүгә каттый каршы чыктылар. Бу вакытта әлеге завод илебез өчен бик кирәкле химия продуктлары (күкертле натрий, алюминий ачуташы, күкертле глинозем, хлор, сульфат кислотасы һ. б.) җитештерә иде. Ул чорда Бондюг заводы кислоталар һәм химик тозлар җитештерүдә илдә беренче урыннарда тора иде.

Заводның язмышы хәл ителгән менә шундый чорда, үз партия оешмасы җитәкчелегендә эшчеләр коллективы түземлелек һәм ныклык, хезмәт батырлыгы үрнәкләре күрсәтте, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм продукциянең үзкыйммәтен кимету, хезмәт тәртибен ныгыту өчен көрәшеп, зур уңышларга иреште.

Шул елларда партиянең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре булып эшләгән М. М. Хатаевич, М. О. Разумов, ТАССР Совнаркомы председателе Х. З. Габидуллин заводны саклап калу өчен зур көч куйдылар. Татарстан партия оешмасы позициясен партиянең күренекле эшлеклəре В. В. Куйбышев һәм С. В. Косиор яклап чыкты. Бондюг заводы язмышына бәйле мәсьәләне карап, ВКП (б) Үзәк Комитеты һәм Совет хөкүмәте аны саклау, хәтта тулысынча яңадан кору турында карар да кабул итте. 1930 елда заводны яңарту эше СССР химия промышленностен үстерүнең бишьеллык планына кертелде.

Беренче бишьеллык елларында Татарстанны индустриаль үстерү темплары шактый артты. Ленинчыл милли политиканы тормышка ашыра барып, ВКП(б)ның XV съезды Директиваларында милли республикалар һәм өлкәләрнең экономикасын өстенлекле темпларда үстерү максаты куелды. Шушы күрсәтмә нигезендә Татарстан АССРның беренче бишьеллык планында республиканы аграр өлкәдән беренче бишьеллык ахырына индустриаль-аграр республикага әверелдерү бурычы куелды.

Төзелешнең гаять зур күләмдә алып барылуы нәтиҗәсендә 1932 елда республика халык хуҗалыгында промышленность продукциясе өлеше 60 процентган артты. Беренче бишьеллык чорында Татарстан индустриаль үсеше өчен өч үзенчәлек характерлы. Беренчедән, ул гаять югары темплар белән үсте. Әйтик, бишьеллыкта СССР промышленностенда тулай продукция җитештерү 219 процентка күтәрелеп, Татарстанда—377 процентка артты. Икенчедән, беренче бишьеллыкта ил күләмендә авыр промышленность өстенлекле үстерелсә, Татарстанда исә, җиңел промышленность шулай үстерелде. Өченчедән, республиканың эшчеләр сыйныфы, аеруча татар эшчеләре саны артты. 1928—1932 елларда татар эшчеләр саны 3102 дән 18690 кешегә җитте, ягъни 6 тапкырдан күбрәккә үсте.

Татарстан промышленносте структурасында икенче бишьеллык чорында да әһәмиятле сыйфат үзгәрешләре булды. Бу бишьеллык тулаем алганда СССР өчен промышленностьта яңа предприятиеләрне үз-

ләштерү чоры булса, Татарстанда ул нигездә авыр индустриянең яңа предприятиеләрен төзү еллары булды. Бу чорда республикада күп кенә машина төзелеше һәм химия промышленносте предприятиеләре салынды. Шуның белән бергә куәтле энергетика базасын булдыруга да нык игътибар ителде. Республика халык хуҗалыгына 1,1 миллиард сум капитал салынып, шул исәптән 703 миллион сумы промышленностька җибәрелде. Бу — беренче бишьеллыктагыга караганда 6 тапкыр артык. Партиянең XVII съездында чыгыш ясап, В. В. Куйбышев Татарстан АССРны индустриальләшү процессы аеруча кызу темплар белән бара торган районнар рәтенә кертте.

Татарстанда икенче бишьеллыкта ясалма каучук (СК-4), авиация, мотор төзү, фотожелатин, ясалма күн һәм карбол кислотасы заводлары, кинофототасма фабрикасы, Казандагы 2 нче ТЭЦ кебек эре промышленность предприятиеләре, Аксубай, Алексеевск һәм Чистай район электр станцияләре — барлыгы 24 эре һәм дистәләрчә вак предприятиеләр салынды.

Икенче бишьеллык планны уңышлы үтәү нәтиҗәсендә Татарстан Советлар Союзының иң нык үскән индустриаль республикаларының берсенә әверелде.

Өченче бишьеллыкның тыныч елларында да темп кимемәде. 1940 елда Татарстан эре промышленностенда 106 мең эшче, шул исәптән 35 мең татар эшчесе эшли иде. 1937—1940 елларда СССРда промышленность продукциясе җитештерү 52 процентка арткан булса, Татарстанда бу күрсәткеч 71 процент тәшкил итте.

Сугышка кадәрге өч бишьеллыкның барысы да, гомумсоюз темплары белән чагыштырганда, Татарстан промышленносте өчен өстенлекле үсеш булды. В. И. Ленинның социалистик индустрияләштерү планы гамәлгә ашырылды. Бу исә Татарстанның экономик артталыгын бетерү проблемасын хәл итәргә мөмкинлек бирде. Әйтик, гомумроссия күләме белән чагыштырганда, 1913 елда җан башына промышленность продукциясе җитештерү 4 мәртәбә диярлек ким булса, 1941 елга Татарстан бу күрсәткечтә гомумсоюз дәрәҗәсенә якынлашты.

Татарстан республикасы экономикасын һәм культурасын үстерү өлкәсендәге казанышларга Коммунистлар партиясенең ленинчыл милли политиканы эзлекле үткәрүе, илебездәге барлык туганлаш халыкларның фидакарь ярдәме белән ирешелде. Сугышка кадәрге бишьеллыклар чорында партия һәм хөкүмәтебез Татарстан территориясендә табигый байлыкларны һәрьяклап тикшерү, эре промышленность предприятиеләрен төзүне планлаштыру, промышленность төзелешенә зур финанс ассигнованиеләре җибәрү, төзелә торган предприятиеләрне җиһазлар белән тәэмин итү, эшче һәм инженер-техник кадрлар, аеруча милли кадрлар әзерләү һәм башка мәсьәләләрне хәл итүгә зур ярдәм күрсәтте.

Эшчеләр сыйныфы, инженер-техник работниклар һәм республиканың барлык хезмәт ияләренең героик хезмәте, аларның югары политик һәм производство активлыгы социалистик индустрияләштерү бурычын тормышка ашыруның хәлиткеч нигезе булды. Болар массовый социалистик ярышның төрле формаларында чагылыш тапты.

Республиканың яңа төзелешләрендә социалистик ярыш аеруча киң җәелдерелде. Әйтик, 1930 елда 1 нче ТЭЦ төзелеш мәйданында 20 дән артык удар бригада оештырылды. Алар арасында киң танылган Л. Миңнуллин бетончылары, В. Стрельков арматурчылары, Н. Колесников һәм М. Кузнецов монтажчылар бригадалары бар иде. «Казгрэсны җибәргәнче төзелештән китмәбез» дигән лозунг белән эшләүче

Л. Миңнуллин бетончылар бригадасы аеруча яхшы күрсәткечләргә иреште. Ул производство нормасын даими рәвештә 250—270 процентка үтәп барды. Шушы бригада бер үзе 17 мең кубометр бетон салды һәм Татарстан рекордын куйды. Су басудан саклап, бу коллективның икешәр тәүлек берөзлексез эшләгән чаклары булды.

1933—1935 елларда Казанның иң эре төзелеш коллективлары — авиация, ясалма каучук заводлары, кинофототасма фабрикасы һәм кролик комбинаты төзүчеләре арасында социалистик ярыш җәелдерелде. 1935 елның көзеннән башлап, республиканың яңа төзелешләрендә һәм промышленность предприятиеләрендә стахановчылык хәрәкәте киң җәелдерелде. Казан авиация заводы төзелешендә нормаларын 3—4 тапкыр арттырып үтәгән коммунистлар Князев, Клистратов һ. б. беренче стахановчылар булдылар. Әйтик, коммунист Камышев сменага 600 данә урынына 2300 данәгә кадәр кирпеч салуга ирешкән. 1936 елда 3 нче төзелеш участогында производствода эшләүче коммунистларның 81 проценты стахановчы булды. 1936 елда төзелешләрдә меңнән артык стахановчы яңа производство нормаларын 150 һәм артыграк процентка арттырып үти башлады.

Казан мех комбинатының 8 меңле коллективы эшчеләре арасында да стахановчылык хәрәкәте гаҗәп тиз җәелде. Алексей Васильев һәм Абделхак Нигъмәтҗанов, Василий Силуянов, Нияз Хәсәнов һәм башкалар нормаларын 8—10 һәм күбрәк тапкыр арттырып үти башладылар. Абделхак Нигъмәтҗанов исә 1936 елның 31 августына — стахановчылык хәрәкәтенең беренче еллыгы көненә производство нормасын 2775 процентка үтәде, Бөтенсоюз һәм дөнья рекорды куйды. Сугышка кадәрге бишьеллыклар чорында СССР промышленностенда бер новатор да бу рекордны яңарта алмады.

Совет кешеләре социалистик төзелешнең бөек бурычларын зур хезмәт энтузиазмы белән үтәү өчен көчләрен кызганмадылар. Өченче бишьеллыкның тыныч елларында стахановчылык хәрәкәте һәм социалистик ярышның башка формалары нык үстерелде. Промышленностьның техника белән тәэмин ителеше шактый яхшыру, эшчеләр сыйныфының осталыгы үсү, аның культура-техник дәрәҗәсе күтәрелү социалистик ярышның күп станокларда эшләү арадаш һөнәрләрне үзләштерү һәм төрдәш эш башкару кебек формалары таралуга булышлык итте.

Эшчеләр сыйныфының һәм республика хезмәт ияләренең фидакарь хезмәтен Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте югары бәяләде. 1934 елда ук Татарстан АССР Ленин ордены белән бүләкләнде. 20 нче еллар ахырында һәм 30 нчы еллар башында күренекле хезмәт уңышлары өчен Совет хөкүмәте Татарстан эшчеләр сыйныфы һәм совет интеллигенциясенең 25 вәкиленә «Хезмәт Герое» дигән мактаулы исем бирде. 1931—1937 елларда производствода һәм җәмәгать эшчәнлегендә ирешкән уңышлары өчен республиканың Татарстан АССР Үзәк Башкарма Комитеты 172 кешегә «Татарстан социалистик төзелеш герое» дигән мактаулы исем бирде.

Сугышка кадәр һәм сугыштан соң илнең халык хуҗалыгын горгызуга ун еллап вакыт китте. Социалистик индустрия сугыш һәм сугыштан соңгы авыр вакыт имтиханын уңышлы тотты.

50 нче еллар ахырында ил үсешендә яңа этап башланды. КПССның 1959 елның башында үткәрелгән чираттан тыш XXI съезды Совет власте культура үсешенә йомгак һәм СССРда социализм тулысынча һәм тәмам җиңде дигән нәтиҗә ясады. Съезд эшчеләр сыйныфы һәм илебезнең барлык хезмәт ияләре алдына коммунизмның материаль-техник базасын төзү, илнең экономик потенциалын тагын да көчәйтү,

хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү тизлеген арттыру һәм шушы нигездә совет халкының тормыш хәлен нык яхшырту бурычын куйды.

Партиянең XXI съездында кабул ителгән җидееллык план уңышлы үтәлде. Промышленностьта җитештерү күләме 84 процентка үсте, халык хуҗалыгының барлык тармакларында фән-техника прогрессы нык алга китте.

Шушы ирешелгән дәрәҗәдән чыгып һәм реаль мөмкинлекләрне исәпкә алып, КПССның XXIII съезды 1966—1970 елларны эченә алган сигезенче бишьеллыкта халык хуҗалыгын һәм культураны үстерүнең яңа бурычларын билгеләде. Халык хуҗалыгы яңадан тиз арада техник кораллану, аның структурасы прогрессив үзгәрү, искергән продукцияне яңа белән алыштыру юнәлешен алды. КПССның XXIV съезды бу бишьеллыкка йомгак ясады һәм халык хуҗалыгын үстерү планының уңышлы үтәлүен билгеләп үтте. Бишьеллык ахырына ил промышленность предприятиеләренең күпчелеге планлаштыру һәм экономик стимуллаштыруның яңа системасына күчерелгән иде. Татарстанда 1970 ел ахырына 485 промышленность предприятиесе, ягъни гомуми күләмнең 94 проценты яңача эшләүгә күчте. Алар сигезенче бишьеллыкның соңгы елында республика промышленность продукциясенең 96 процентына якынын җитештерделәр. Үсеш тугызынчы бишьеллыкта уңышлы дәвам итте. Бу чорда җитештерүче көчләрнең территориаль экономик элементләрен тагын да ныгыту һәм рациональ урнаштыруга, союздаш һәм автономияле республикалар халык хуҗалыгын интенсив үстерүгә аеруча нык игътибар ителде.

Татарстан 1956 елда ук нефть чыгару буенча илебездә беренче урынга чыкты һәм 1958 елда 30 миллион тонна сыек ягулык бирде. 1965 елда исә республика нефтьчеләре 80 миллион тонна чамасы «кара алтын» алуга ирештеләр. Бу елларда Татарстанда нефть чыгару ел саен 7 миллион тоннага үсеп барды. Ул вакытта илебезнең бер генә нефть районы да мондый үсешне белми иде. Татарстан нефть чыгару күләме, аны чыгаруның тизлеген арттыру һәм башка техник-экономик күрсәткечләр буенча Советлар Союзында 15 елдан артык беренчелекне тотты. 1970 елда Татарстан промыселларында 101,9 миллион тонна нефть алынды. Республика нефтьчеләре сигезенче бишьеллыкта 463 миллион тонна, тугызынчы бишьеллыкта 519 миллион тонна нефть, шул ук чагыштырмада 17 миллиард һәм 21,4 миллиард кубометр газ чыгаруга ирештеләр. Татарстан нефть промышленносте үсеш темплары һәм техник яктан тәэмин ителү буенча алга киткән капиталистик илләрне дә күпкә артта калдырды. Әйтик, Америка Кушма Штатларында шушы тармактагы бер эшчегә 2,5 мең тонна чамасы нефть чыгарылса, Татарстан АССРда бу күрсәткеч 5 мең тонна чамасы тәшкил итте. Республика нефтьчеләренең 50 меңлек коллективының героик хезмәте югары бәяләнде. Социалистик Хезмәт Геройлары К. Вәлиев, М. Гринь, Н. Драцкий, Г. Баһманов, А. Гобәйдуллин, М. Гыймазов, З. Зәйнагов, М. Миңнекаев, П. Савельев, А. Тимченко, Ф. Шәрәфетдинов, З. Шәрифуллин, Р. Саттаров һәм башка күп кенә хезмәт батырларының исемнәре республика нефте елъязмасына мәңгегә язылып калды.

Татарстанда куәтле нефть чыгару һәм газ промышленносте барлыкка килү нәтиҗәсендә индустриянең яңа тармагы — нефть химиясе промышленносте туды. Җидееллык чорында ук нефть химиясенең Казан органик синтез заводы (хәзер «Оргсинтез» производство берләшмәсе), Түбән Кама нефть химиясе комбинаты (хәзер «Нефтехим» производство берләшмәсе), Миңлебай газ эшкәртү заводы һәм башка зур предприятиеләре төзелә башлады. Хәзер алар үз тармагының ин эре промышленность комплексларына әверелделәр.

◆ НЫГУ ◆ У. БЕЛЯЛОВ

Республикада машина төзелеше темплары да гаять тиз үсә барды. «Урак һәм чүкеч», газ аппаратлары, «Теплоконтроль», компрессор заводлары һәм башка предприятиеләр киңәю һәм яңартып корылу белән беррәттән, соңгы бишьеллыклар чорында Кама буенда зур йөк күтәрешле автомобиль заводлары комплексы төзелде. КамАЗ — чыннан-чыннан уникаль предприятие. Аңа охшаш предприятиеләрнең бездә дә, чит илләрдә дә төзелгәне юк. Биредә иң яңа, иң прогрессив техника тупланган. 100 квадрат километр мәйданга яңа шәһәр һәм 6 баһадир завод урнашты. Тугызынчы бишьеллыкның төп төзелеше булган КамАЗны төзүдә барлык союздаш республикалар вәкилләре, аны проектлауда һәм коруда 25 министрлык һәм ведомство, 80 нән артык проект институты, 150 дән артык төзү-монтаж идарәсе катнашты. Советлар Союзының 5 меңнән артык предприятиесе КамАЗ заказларын үтәде. Комплекс тулы куәтенә эшли башлагач, елына 150 мең зур йөк күтәрешле автомобиль һәм 250 мең дизель моторы җитештерәчәк. Инде 1979 елда ук ул илебезгә 70 меңнән артык автомобиль бирде.

Республикада электр энергетикасы да кызу темплар белән үсә. Казанда 3 нче ТЭЦ, Түбән Кама һәм Чаллы ТЭЦлары, Зәй ГРЭСы һәм Түбән Кама ГЭСы төзелү республика электр станцияләре эшләп чыгара торган электр энергиясе куәтен бик нык арттырды. Әйтик, 1957 елда Татарстанда аларның гомуми куәте 467,5 мең киловатт тәшкил итсә, тугызынчы бишьеллык ахырына 4 миллион 643 мең киловаттка җитте.

Республика промышленностеның барлык тармаклары да шулай нык үсү нәтиҗәсендә үсеш темплары, гомумсоюз күләме белән чагыштырганда, шактый өстен булды. Әйтик, 1913—1977 елларда СССРда промышленность продукциясе җитештерү 145 тапкыр арткан булса, Татарстан республикасында бу күрсәткеч 655 мәртәбә үсте. Бу — Татарстан республикасы шартларында КПССның ленинчыл милли политикасының тормышка ашырылуының гүзәл чагылышы.

**У. Б. БЕЛЯЛОВ,**
тарих фәннәре докторы.

# СОЛДАТ КӨНДӘЛЕК ЯЗА

*Кави Гыйльметдин улы Гыйльмиев Татарстанның Арча районының Штерә авылыннан. Рядовой артиллеристтан башлап, капитан дәрәҗәсенә күтәрелә, батальон штабы начальнигы була. Бөек Ватан сугышында Кави Гыйльмиев Мәскәү яныннан Бреслаугача авыр сугыш юллары үтә, өч тапкыр яралана, Кызыл Йолдыз, I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, күп кенә медальләр белән бүләкләнә.*

*Хәрби хезмәткә керешү белән Кави көндәлек алып бара башлый һәм аны сугыш елларында да ташламый. Көндәлекнең күп кенә битләре турыдан-туры сугыш кырында — окопта, траншеяда — баш очында пуляләр сызгырганда, тирә-якта бомба-снарядлар шартлаганда язылганнар.*

*Көндәлекләрдә гади бер совет солдатының эчке дөньясы — бай рухы, нык ихтыяры, җиңүгә булган какшамас ышанычы ачык чагыла. Алар авыр елларның бер документы булу нисбәтеннән игътибарга лаек дип уйлыбыз.*

*
* *

**1941 ел 15 май.** Безнең 82 нче укчы мотодивизия Монголиянең Баян-Төмән[1] шәһәреннән 360 чакрым ераклыктагы Ундурхан шәһәрчеге тирәсендә урнашты. Игътибарны җәлеп иткән беренче нәрсә бу якларның табигате булды. Кай тарафка карама—сусыз шыр дала. Ник бер агач, я булмаса зәгыйфь куак күзгә чалынсын! Эч пошарлык дәрәҗәдәге бертөрлелекне хисапсыз сопкалар да җуя алмый хәтта. Дөрес, сопкалар арасында беркадәр яшеллек бар барын, ләкин Татарстан табигате белән чагыштырганда бу якларның яшеллеге ифрат ярлы: чәчәкләр анда-санда гына күзгә чалына, үләннәр дә сирәк.

Туган авыл, аның урман-сулары искә төшә. Хәзер анда бөтен җир яшеллеккә чумгандыр, ә алмагачлар шау чәчәктәдер. Елга буендагы әрәмәдә иртә-кичләрен сандугач, ә басу өстендә тирбәлә-тирбәлә тургай сайрыйдыр. Кырларда күкрәп үскән игеннәргә карап шулай куана ул. Яшьрәкләр исә көндезләрен рәхәтләнеп су коеналар, ә кичләрен егетләр-кызлар, гармунга кушылып җырлый-җырлый, көймәдә йөрiләрдер...

**22 июнь.** Сәгать кичке сигезләр тирәсе иде. Нарядтан кайтып керүгә хат китереп тоттырдылар. Авылдан. Зәйнәп язган. Бу минем өчен әйтеп бетергесез шатлык булды. Хәтер җепләре кирегә таба сүтелеп, үткән көннәргә барып тоташты, аерылышкан көн, саубуллашу минутлары күз алдына килеп басты...

Киткәндә безне бөтен авыл озатты. Гармун тартып, җырлар җырлап, ике тапкыр урам әйләндек. Авылны чыгып бераз җырлап баргач атны туктаттык. Безнең арбада унбишләп егет бар иде. Авылда калырга тиешле кешеләр арбадан төштеләр. Гармун, зур кайгыга юлыккан кеше кебек, авыр ухылдап, соңгы тапкыр тынын чыгарды да хуҗасының култык астына кереп сыенды. Егетләр белән озаклап саубуллаштык. Алар безгә хәерле юл, хезмәтебездә уңышлар теләп калдылар.

[1]Хәзер Чайболсан шәһәре.

Әткәй, сеңел, Зәйнәп мине Арчага кадәр озата килделәр. Менә Давыт юлын, Закир умарталыгын үттек. Кызыл сарай да артта калды. Урманга керер алдыннан соңгы тапкыр каерылып авыл ягына карадым. Штерәнең өй түбәләре белән моржа башлары гына күренә иде инде. Менә алар да күренмәс булдылар. Хуш, туган авыл!..

Арчада комиссия булды. «Ярыйсың» диделәр. Комиссиядән чыккач Зәйнәп белән икәүләп рәсемгә төштек. Аннары Арча урамнары буйлап йөрдек, кабат-кабат вәгъдәләр бирештек. Зәйнәп: «Мин сине ике ел гына түгел, унике ел көтәргә дә риза, тик син генә мине онытма!»—диде. Хатына да шундыйрак сүзләр язган: «Кара аны, вәгъдәңдә тор, башкалар белән чуалып китеп, мине калдырма!» — дигән. Чуаламмы соң! Син бит минем бердәнберем. Тик син генә көтә күр, Зәйнәбем! Хезмәт срогым туларга инде күп тә калмады. Озакламый кавышырбыз да, мәңге бергә булырбыз!

**23 июнь.** Сугыш! Немец фашистлары кичә безнең илгә бәреп кергәннәр. Бу коточкыч хәбәрне мин бүген иртәнге дүрттә кече лейтенант Кукса авызыннан ишеттем. Башта һич кенә дә ышанырга теләмәдем. Кызганычка каршы, хәбәр дөрес булып чыкты.

Сугыш хәбәре безнең барыбызда да фашистларга карата чиксез ачу уятты. Күп кенә иптәшләр үзләрен кичекмәстән фронтка җибәрүне сорадылар. Мин дә гариза бирдем.

**3 июль.** Бүген өченче яртыда радио аша иптәш Сталин чыгышын тыңладым. Ул фашизмның чын йөзен ачты, Ватан өстенә килгән афәттән бергәләп котылу өчен Коммунистлар партиясе, Совет хөкүмәте тирәсенә тагын да ныграк тупланырга чакырды. «Безнең эшебез хак, без җиңәрбез!»—диде ул чыгышының ахырында. Бу сүзләр бездә җиңүгә ышаныч уятты, фашизмга каршы көрәшкә рухландырды. Әгәр рөхсәт итсәләр, мин бүген үк, хәзер үк җыенып, сугыш кырына китеп барыр идем. Әйе, сугышның уен түгеллеген мин яхшы беләм. Минем җаным газиз, гомерем кыйммәт. Минем яшисем, тормыштан тәм, яшәүдән ямь табасым килә. Исән-сау илемә кайтып әти-әнине, туганнарны күрәсем, сөйгәнемне кысып кочаклыйсым, суырып-суырып үбәсем килә. Ләкин фашизмны җиңү өчен минем гомерем кирәк икән, мин аны корбан итәргә әзер. Юк, бу шарлатаннарча коры шапырыну гына түгел. Үз сүзләремнең җитдилеген мин сугыш кырында расларга әзер!

**4 июль.** Көнбатыш Европадан күтәрелгән аждаһа елан Вильно, Львов, Гродно, Белосток, Брест, Каунас шәһәрләрен йоткан, күпме авылларны көлгә әйләндергән. Их, тизрәк сугышка китәсе, аждаһаның башын чабып өзәсе иде. Кызганыч, җибәрмиләр. «Сез монда кирәк»,—диләр. Хәер, үзебез дә күреп торабыз: япон самурайлары һич тынгы бирмиләр, әледән-әле чикне бозалар. Менә-менә сугыш башлана дип көтәбез.

**24 сентябрь.** Илебезнең Көнбатыш өлкәләрендә кан дәрьялары ага. Кеше ашаучы фашистлар үзләре басып алган районнардагы халыкны бандитларча талыйлар, үтерәләр. «Героическая» газетасы үзенең бүгенге санында шундый профессиональ кеше үтерүчеләрнең берсе обер ефрейтор Иоганс Гердер көндәлекләреннән түбәндәге юлларны китерә: «Авылга килеп керүгә, без торак йортларга гранаталар томырабыз. Йортлар шырпыдай гөлт итеп яна башлый. Ялкын бик тиз күрше йортларга күчә. Искиткеч күренеш! Кешеләр елашалар, ә безгә кызык, без көләбез генә. Шул рәвешчә унлап авылны яндырдык инде».

Ах син, канэчкеч бандит! Кайсы ана тапкан да, кем шулай үстергән сине?! Ярый, көлегез, көл. Тик соңыннан җавап бирәчәгегезне онытмагыз. Эшләгән кабәхәтлекләрегез өчен совет кешеләре алдында гына түгел, бөтен Европа каршында җавап бирергә туры киләчәк сезгә. Ул чагында инде үзегез дә яшь урынына кан түгәчәксез!

**7 октябрь.** Күңелле яңалык: Япония безгә каршы сугыш башламаска булган! Бүген 23 сәгать 30 минутта, вагоннарга төялеп, Көнбатышка юл алдык. Ниһаять, безгә дә чират җитте! Тизрәк, тизрәк фронтка, кеше ашаучы аждаһа белән көрәшүче ватандашларыбызга ярдәмгә!

**26 октябрь.** Звенигород шәһәрендә вагоннардан төштек. Безне машиналарга төяп Можайск юнәлешенә алып киттеләр. Дороховога җитеп, позицияләргә урнашырга өлгермәдек, дошман көчле ут ачты. Шактый мөшкел хәлдә калдык. Дошман калкулыктагы урман эчендә урнашкан, ә без түбәндә — ялангач үзәнлектә. Немец безне уч төбендәге кебек күреп тора. Җир куенына кереп сыеныр идең — көрәк тыгуга, су бәреп чыга.

Беренче сәгатьләрдә үк батальон командиры өлкән лейтенант Иванов белән рота командиры Дейнеко яраландылар. Минем отделениедән наводчик Быков җәрәхәтләнде. Бер миномет сафтан чыкты.

**28 октябрь.** Дошман артиллериядән туктаусыз безнең позицияләргә ата, өстән бомбага тота, танклар белән һөҗүм итә. Ротада югалтулар шактый. Ләкин әлегә фашистларның барлык атакаларын кире кайтара торабыз. Һәр сугышчы соңгы сулышына кадәр көрәшә. Чөнки артка юл юк. Артта—Мәскәү!

**2 ноябрь.** Дошманга каршылык арткannан-арта бара. Үзебез дә көнегә, кыюлана төштек. Хәзер инде без, оборонада гына ятмыйча, контратакага да күчкәлибез. Бу җәһәттән командирлар шәхси үрнәк күрсәтәләр .Полк командиры полковник Соловьев безне берничә мәртәбә үзе атакага алып барды.

**9 ноябрь.** Ур-ра! Безнең 82 нче дивизия һөҗүмгә күчте. Фашистларны Көнбатышка куабыз. Күп кенә авылларны азат иттек. Гитлерчылар аларның барысын да яндырып киткәннәр. Кая карама—күмер, көл өемнәре, кеше гәүдәләре. Нинди вәхшилек!

**20 декабрь.** Десантчылар итеп әзерләү өчен безне тылга чыгардылар.

**21 январь.** Майор Солдатов җитәкчелегендәге безнең 250 нче аерым һава десант волкын Смоленск өлкәсендәге Знаменск районында дошман тылына төшерделәр. Бурыч: немецларга резервларын, хәрби техникаларын фронтка китертүгә комачаулык итү, көтелмәгән ударлар белән дошманны каушату, аның сафларына буталчыклык кертү. Максат: Знаменск—Вязьма юнәлешендә һөҗүм итүче безнең гаскәрләргә уңышлы шартлар булдыру.

Дошманга көтелмәгән ударлар ясап, аның коммуникацияләрен өзеп, алга барабыз. Берничә торак пунктны азат иттек, Угра станциясен алдык. Нәтиҗәдә Вязьмага бара торган тимер юлга хуҗа булдык. Мондый кыю һөҗүмне көтмәгән дошман зур югалтулар белән тәртипсез рәвештә чигенә, кача.

**27 январь.** Безнең батальон Харьково авылы янында оборонага күчте.

Көндез 11 ләр тирәсендә күзәтчеләр урман ягыннан авылга таба немецлар колоннасы килгәнен хәбәр иттеләр.

Без алдан билгеләп куелган нокталарга кадәр ут ачтык. Немецлар колоннасы таркалды. Фашистлар сул яктагы урманга кереп качтылар. Күп тә үтмәде, каты атыш башланды. Ул арада безгә ярдәмгә полк артиллериясе килеп җитте. Көчле ут өермәсенә юлыккан немецлар йөзләрчә үле һәм яралы солдатларын ташлап качарга мәҗбүр булдылар.

**19 январь.** Стогово, Ивлево авылларын азат иттек.

**5 март.** Немецлар безне кысалар, камап алырга уйлыйлар. Ивлеводан Покрово авылына китәргә приказ алдык.

**6 март.** Полк—чолганышта. Бәҗраны өзү максаты белән Островкига һөҗүм итәбез. Әмма һөҗүм барып чыкмады. Яңадан Харьково авылына кайттык.

**7 март.** Немецлар Харьковога артиллерия, минометлардан туктаусыз атып торалар. Безнең взводтан өлкән сержант Эглит яраланды. Яков Романов һәлак булды. Әх, нинди батыр, шат күңелле малай иде Яша! Җырларга ярата иде. Һаман шул бер үк җырны җырлап йөрер иде мәрхүм:

**Весна, весна еще вернется,**
**Вернется громкий соловей...**

Ә үзе мена язны көтеп ала алмады...

**10 март.** 14 сәгатьтә, чолганыш боҗрасын өзеп, Эдвижка авылына килеп чыктык. Юлсыз-нисез күкрәк тиңентен кар ерып барабыз.

**19 апрель.** Яз килә, яз! Табигать көннән-көн ямьләнә. Бүген көн аеруча матур. Күктән кояш кыздыра, кар эри, күзгә күренеп кими. Басулар инде алалы да колалы. Елгада боз өстендә су чыккан. Кошлар кайта башлады. Аларның ара-тирә сайраган тавышлары күңелләрне җилкендерә.

Җиде ай инде туганнардан, дус-ишләрдән хат-хәбәр алган юк. Күңел борчыла...

**21 апрель.** Фашистлар тылына төшүебезгә бүген нәкъ өч ай булды. Рейд дәвам итә. Дошманга өзлексез ударлар ясыйбыз, аның солдатларын, сугыш техникасын сафтан чыгарабыз, әһәмиятле коммуникацияләрен өзәбез, фронтка китәргә тиешле күп кенә көчләрен тоткарлап торабыз. Дошман тылында булсак та, үзебезне чын хуҗа-

лар итеп сизәбез. Чөнки без—үз җиребездә. Без ялгыз түгел. Безнең полктан тыш биредә тагын парашютчылар бригадасы, генерал Беловның гвардейский атлы корпусы һәм чаңгычылар отрядлары хәрәкәт итәләр. Алар һәммәсе җирле партизаннар белән тыгыз бәйләнештә торып сугышалар.

Шул рәвешчә, күмәк көч белән Смоленск өлкәсенең күп кенә административ районнары дошманнан азат ителде. Аларда Совет власте торгызылды. Район һәм авыл Советлары эшкә кереште. Алар безне азык-төлек, транспорт белән тәэмин итүдә зур булышлык күрсәтәләр. «Олы җир»дән дә ярдәм алгалыйбыз.

Җирле халык арасында аңлату эшен җәелдереп җибәрдек. Әңгәмәләр, җыелышлар, митинглар үткәрәбез, фашистларның ерткычлыкларын фаш итәбез. Хәер, немец тырнагы астында калган кешеләр үзләре дә җитәрлек күргән. Кайсы гына авылга барып кермә, үтереп ташланган кеше өемнәре—картлар, хатын-кызлар, бала-чага... Ә кайбер авылларның исемнәре картада гына сакланып калган. Барысына да гитлерчы фашистлар һәм алардан алданган, аларга юл куйган немец халкы гаепле. Ләкин мин ышанам: иртәме-соңмы немец халкы үз язмышын аңлар, үзен баскан кара чумадан котылыр.

**30 апрель.** Зур Калпита авылында 1 Май бәйрәменә багышланган тантаналы җыелыш булды. Политрук Новоселов доклад ясады. Кызылармеецлардан тыш җирле халык та күп иде. Шунда ук берничә кешене комсомолга алдык. Соңыннан күңел ачу кичәсе булды. Туйганчы биедек. Халыкның күңеле шактый күтәрелде.

**16 май.** Бүген бер иптәш самолет белән «Олы җир»гә оча. Аның артыннан өйгә хат җибәрдем.

**25 май.** Немецлар авиация һәм танклар ярдәмендә һөҗүмгә күчтеләр. Годуновканы калдырып чигенергә туры килде.

**26 май.** Немецлар Желанье, Гряда, Великополье торак пунктларын һәм Угра станциясен алганнар. Бабенконы бомбага тоталар. Хәл катлаулана бара. Азык-төлек, сугыш кирәк-яраклары җитешми. Яралылар шактый.

**5 июнь.** Дрогобуж юлы белән чигенәбез. Кая гына борылсак та немецларга барып төртеләбез. Инде чигенер урын да калмады. Батальон—чолганышта. Фашистлар тирә-юньдәге барлык авылларны яндыралар, халыкны үтерәләр яки үзләре белән куып алып китәләр.

**10 июнь.** Өске өзлексез бомбалар ява. Үлем дигән нәрсә сагалап тора. Ләкин ул турыда уйларга вакыт юк. Көньяк-Көнчыгышка таба чигенәбез. Глинки, Якимовск, Ельно районнары аша үттек. Тирә-як—сазлык. Ашарга юк.

**17 июнь.** Генерал Беловтан боерык алдык: кечкенә группаларга бүленеп, үзебезнекеләр ягына чыгарга.

Караңгы төн. Коеп яңгыр ява. Сазлыклы урман аша барабыз. Минем бөтен тәнем кызыша. Арыдым. Хәлсезләндем.

**18 июнь.** Кара урман уртасында ялга туктадык. Ашыйсы килүдән эч тартып-тартып авырта. Каяндыр бер сыер табып алып килделәр. Әмма ни файда—ут ягарга ярамый. Үзебез белән чи ит алдык.

Атлыйбыз. Бара торгач, Мәскәү-Варшава шоссе юлына килеп терәлдек. Немец юлны бик нык саклый. Үзенең барлык артиллериясен, пехота коралын шунда туплаган. Өч танк шоссе буйлап йөреп тора.

Ләкин ничек кенә булмасын, безгә юлны үтеп чыгарга кирәк. Кирегә юл юк!

Каршыбызда котырган ут давылына карамастан, «Ура» кычкырып, фашистлар өстенә ташланабыз. Мондый тәвәккәллекне көтмәгән дошман бер мәлгә каушап кала. Шул минуттан файдаланып, шоссе аша чыгып өлгерәбез.

**24 июнь.** «Олы җир» булдыра алганча безгә ярдәм итәргә тырыша. Бүген самолетлардан азык-төлек, корал ташладылар. 4—5 көнгә тәэмин ителдек дигән сүз.

Безнең алда катлаулы бурыч: немец позицияләре аша 28—32 километр юл үтеп, үзебезнекеләр ягына чыгарга.

**26 июнь. Тагын** карурманга килеп кердек. Аяк асты тоташ су. Басып торырлык та коры җир кисәге юк. Ә урманнан чыгарга ярамый—немец шунда ук бомбага тота башлый. Көнне сазлы урманда үткәрергә туры килде. Адәм баласы бәлага тарыса да өмет өзми бит. Без дә җаен таптык: яшьрәк агачларны кара-каршы бәйлибез дә шунда менеп «кунаклыйбыз». Егылып төшмәс өчен бер-беребезне каешлар белән

беркетеп куйдык. Агач ботакларына элеп, киемнәрне һәм аяк чолгауларын киптердек. Хәер, «киптердек» диюебез беркадәр җилләтү булды инде. Караңгы төшү белән юлны тагын дәвам иттердек.

**27 июнь.** Урман-сазлыкларны үтеп, ниһаять, бүген таң алдыннан Киров шәһәрчеге янында немецларның алгы позицияләренә килеп чыктык. Кыска гына, әмма каты бәрелеш булып алды, һәм без, дошман оборонасын өзеп, арыш басуы аша үзебезнекеләргә таба йөгердек. Немецлар арыш кырыена миналар куйганнар икән. Күп кенә иптәшләр миналарга эләгеп харап булды. Рота командирыбыз Сергеенко да шунда ятып калды.

Безне Киров шәһәрчеген саклаучы сугышчылар каршы алды. Кочаклашып күрештек, күпләрнең күзендә яшь иде...

Дошман тылында 5 ай да 6 көн дәвам иткән рейд әнә шулай тәмамланды.

**15 январь, 1943 ел.** Безнең 1140 номерлы полк (ул 340 дивизия составына керә), Воронеж өлкәсендә хәрәкәт итеп, каты сугышлар белән көнбатышка бара.

**5 февраль.** Иске Оскол шәһәрен алдык.

**15 март.** Немецлар, зур көч туплап, һөҗүмгә күчтеләр.

Минем взвод сугышчан сакта иде. Кичкә батальон белән элемтә өзелде. Штаб белән элемтә урнаштыру максатында берничә сугышчыны җибәреп карасам да, алар кире әйләнеп кайтмадылар.

**22 март.** Үзәннәр, куаклыклар аша үзебезнекеләрне эзләп барабыз. Хәл гадәттән тыш авыр. Җирдә кар эреп беткән, аяк асты баткак. Ә без әле һаман кышкы киемнәрдән: башта бүрек, өстә тун, аякта киез итекләр. Әледән-әле немецларга юлыгып, кыска, әмма кискен бәрелешләр булып ала.

**1 апрель.** Ниһаять, үзебезнекеләрне эзләп таптык. Алар, безне инде беткәнгә санап, өйгә үк хәбәр итәргә җыенган булганнар.

**17 апрель.** Бу көн минем тормышымда иң истәлекле көн булып калыр. Толстое дигән авыл янындагы иманлектә мине партия сафына кабул иттеләр. Сугышчан иптәшләрем коммунист булуым белән кайнар котладылар. Мин исә фашистларны дөмектергәнче сугышырга ант иттем.

**1 Май.** Миңа икеләтә бәйрәм бүген! СССР Верховный Советы Президиумы исеменнән мине «Батырлык өчен» медале белән бүләкләделәр.

**8 август.** Безнең часть Серны шәһәре янында дошман ныгытмаларын өзү өчен сугышлар алып бара иде. Кинәт, шартлагыч пуля тиеп, кулбашым җәрәхәтләнде. Кан күп агып, аңымны җуйганмын. Мине КП га китергәннәр, аннан санбатка озаттылар.

**1 декабрь.** Госпитальдән чыгуга, Уфадагы «Выстрел» курсларына җибәрделәр.

**30 март 1944 ел.** Укулар яхшы бара. Билгеләр барлык фәннәрдән «яхшы» һәм «отлично» гына.

Фронттан да сөенечле хәбәрләр килә. Безнең гаскәрләрнең уңышлы рәвештә алга барулары, Прут елгасы буенда дәүләт чигенә җитүләре мине генә түгел, барлык курсантларны куандыра. Һәркайсыбызның сугыш беткәнче тизрәк фронтка эләгеп, фашистларны дөмбәслисе, безнең җирдә кылган кабахәтлекләре өчен үч аласы килә.

**11 май.** Табигать көннән-көн матурлана: тупыл, каен яфрак яра, чирәмнәр күтәрелә. Күңелләр әсәрә, йөрәк туган як кырларына ашкына. Бу каһәр суккан сугыш булмаса, мин бит тыныч тормыштан ямь табып, рәхәтләнеп яшәгән булыр идем. Күпме кешеләрнең газиз гомерен өзде, тормышын, киләчәген җимерде бу сугыш. Шуларны уйлаган саен, күңелдә ачу кабара.

**27 август.** Фронтка җибәрүләрен сорап ике тапкыр үтенеч язсам да, барып чыкмады. Әйе, хәзер фронтка эләгүе көннән-көн кыенлаша бара.

Безнең гаскәрләр Польшада, Румыниядә, Балтик буе республикаларында уңышлы сугышлар алып бара. Кичә Румыниядә яңа хөкүмәт оештырылып, безнең ил белән ике арада килешүгә кул куелган. Болгариянең Анкарадагы вәкиле, үз иленең нейтралитет тотачагын белдереп, нота игълан итте. Союзниклар Франциядә һәм Италиядә хәрәкәт башладылар. Озакламый фашизм тар-мар ителер, халыклар иркен сулыш алыр.

**8 ноябрь.** Без Польшадагы Демба хәрби лагерында. Менә икенче көн инде Октябрьның 27 еллыгын бәйрәм итәбез. Быелгы юбилей көненә Ватаныбыз дошманнан чистартылды. Бары Балтик буенда гына немецларның чолганышта калган 30 дивизия-

се каршылык күрсәтеп маташа. Әмма алар да соңгы сәгатьләрен кичерә. Румыния, Болгария, Финляндия сугыштан чыктылар. Алай гына да түгел, Румыния белән Болгария үз коралларын Германиягә каршы бордылар. Кызыл Армия Югославия һәм Чехословакия халыкларына да үзенең ярдәм кулын сузды, Польшада, Норвегиядә каты сугышлар бара. Шулай итеп, сугыш театры безнең илебездән читтә инде.

**21 ноябрь.** Мине 1194 нче полкның 3 нче батальонына штаб начальнигы итеп билгеләделәр. Эш авыр һәм җаваплы булса да, минем өчен әллә ни куркыныч түгел, нигездә таныш эш.

**15 январь, 1945 ел.** Польшадагы Сандомир плацдармында оборона тотабыз. Безнең артиллерия сәгать ярым чамасы инде дошман позицияләренә ут яудыра. Тиздән һөҗүмгә кузгалабыз.

Башланды! Безнең сугышчылар, тоташ бер дулкын булып, дошман өстенә ябырылдылар. Зоркин батальоны фашистлар оборонасының беренче сызыгын яулап алды. Инде безнең бурыч: уңышны ныгытырга, аңын җыярга ирек бирмәстән, дошманны куарга да куарга!

Комбат Андреенко, аның ярдәмчесе Сологуб һәм мин батальон сафлары алдында барабыз. Модлибожица авылын алдык, тагын бер авыл... Дошман, барлык нәрсәсен ташлап, табан ялтырата.

**17 январь.** Дошман оборонасын өзүдә күрсәткән батырлык өчен мине Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләделәр.

Икенче тәүлек инде фашистларны куа барабыз. Көнгә 40—45 километр үтәргә туры килә. Сугышчылар йончыды.

**18 январь.** Паршов авылы янындагы калкулыкта немецларның алдан әзерләп куелган позицияләренә юлыктык. Фашистлар каты ут ачтылар. Авылны дошманнан чистартырга, безнекеләргә юл ачарга кирәк иде. Парторг Радченко белән икәүләп, бер төркем сугышчыны ияртеп тә, канаудан шуышып барып, авылның сул як кырыендагы йортка килеп җиттек. Тиз генә шунда гранаталар томырдык та алга ташландык. Ниһаять, авыл безнеке! Көнбатышка юл ачык!

КПга кайттым. Комбат Андреенко кулымны кысып:

— Рәхмәт!—диде.—Әмма моннан соң КП дан китәсе булма!

**21 январь.** Чатлама суык. Сулиев шәһәрчеге янындагы урманда ял итәргә туктадык. Моменттан файдаланып, партия җыелышы үткәреп алырга булдык. Көн тәртибе: «Совет солдаты—халыкларга азатлык алып килүче!» Әйе, без илбасарлар түгел, Европа халыкларын фашизм тырнагыннан коткаручылар, аларга азатлык илтүчеләр! Җыелышта совет солдатының мораль йөзе, аның җирле халык белән мөнәсәбәте кебек мәсьәләләр дә кузгатылды. Чыгышлар кызып кына барганда «Тревога» игълан иттеләр. Бездән 200—250 метрлар ераклыкта гына немецлар колоннасы килә икән. Дозорлар башта аны үзебезнең обоз дип уйлаганнар. Бу ялгышу шактый кыйммәткә төште. Без позицияләргә урнашып өлгергәнче, гитлерчылар барлык артиллерия һәм пехота коралларыннан рәхимсез ут ачтылар. Немецларның кайбер төркемнәре урман буйлап безне әйләнеп үк үтә башладылар. Аларның юлын бүлү өчен уң флангка Кленин ротасын һәм Говорухинның ике взводын җибәрдек. Ләкин көчләр тигез түгел иде. Озакламый фашистлар Кленинны кысрыклый башладылар.

Бу хәлне күргәч, түзмәдем, Андреенконың кисәтүенә карамастан, ординарецым Жиров Василийны алдым да, Кленин янына ашыктым. Ротаны танкка каршы казылган чокыр буйлап тараттык та, кинәт «Ура» кычкырып, дәррәү дошманга ташландык. Немецлар тәртипсез рәвештә урманга качарга тотынды. Көтүе-көтүе белән әсир бирелә башладылар. «Рус гут!» имеш, «Гитлер капут!» Ниһаять, барып җиткән тегеләргә. Аңлаганнар эшнең ни белән бетәчәген. Бик соң шул, бик соң, иртәрәк кирәк иде.

Дошман обозы юк ителде. Сугыш кырында 218 немецның үле гәүдәсе ятып калды. Монда минем дә шәхси өлешем бар: 12 сен «теге дөньяга» озаттым. Уйлап карасаң, 12 гомер киселде дигән сүз. Һәм моны мин эшләдем. Ә сугышка чаклы тавык суярга да кулым бармый иде! Нишләмәк кирәк, без чакырып китермәдек. «Әгәр дошман бирелмәсә, аны юк итәләр!»

**31 январь.** Бүген 11 сәгать 30 минутта, Польша чиген үтеп, Германия җиренә аяк бастык. Күңелдә шомлы сагаю катыш сәер кызыксыну.

Германия! Нинди ил син, нинди җир?! Кемнәр яши синдә? Ничек яши? Кайдан килде сиңа шул кадәр явызлык?! Мин бит гади совет кешесе, корал тотып, синең чигеңне атлап үтәрмен, җиреңне солдат итекләре белән таптап йөрермен дип башыма да китермәгән идем. Менә шушы җирдән — синең җирдән фашизм чумасы таралды. Минем Ватаныма, Европа халыкларына күпме бәхетсезлек китердең син! Карап торуга шундый ук җир, шундый ук кешеләр, югыйсә!

**8 февраль.** Батальон берничә көн инде Одер елгасының Көнбатыш плацдармында сугыша. Дошман позицияләренә әледән-әле һөҗүмнәр ясап торабыз. Шундый атакаларның берсендә рота командиры Кленинны үтерделәр...

Ниһаять, ярдәмгә танклар килеп җитте. Бергәләп каршыдагы авылны һәм тактик яктан әһәмиятле 120,5 биеклеген алдык.

Караңгы төште, төн җитте, ә без һөҗүмне һаман дәвам иттерәбез.

Кинәт авылның көнбатышындагы урманнан немецлар көчле ут ачтылар. Батальон шактый кыен хәлдә калды. Хәлнең авырлыгы тулысы белән комбат Зоркин намусына төшә. Чөнки ул гафу ителмәслек гамьсезлек күрсәткән: разведка һәм поход сагы җибәрмәгән.

**3 март.** Одер плацдармындагы сугышлар өчен миңа II дәрәҗә «Ватан сугышы» ордены бирделәр. Шуннан соң Франкинталь, Херманcдорф тирәләрендә каты бәрелешләр булды. Инде менә 24 февральдән бирле Бреслауда урам сугышлары алып барабыз. 575 нче кварталда туктадык. Безнең юлны яртылаш җимерек бер йорт бүлеп тора. Фашистлар исә йортка якын да җибәрмиләр. Саперлар группасын җибәреп караган идем дә, алар куелган бурычны үти алмадылар. Аптырагач, өч саперны алдым да үзем киттем. Кайда йөгереп, кайда шуышып йортка якынлашабыз. Инде ике метр чамасы гына калды.

Немецлар безнең ниятне сизеп алдылар булса кирәк—фауст патроннан аттылар. Снаряд килеп тиюгә, стена безнең өскә җимерелеп төште. Бер сапер һәлак булды, ике сапер һәм мин яраландык.

**7 март.** Госпиталь...

**8 апрель.** Бреслау шәһәрендә чолгап алынган фашистларны дөмбәсләү дәвам итә. Мин дә шунда.

**8 май.** Полк командиры Шелковников үзенә чакырып алды. Мин барып кергәндә анда полк командиры урынбасарлары, штаб начальнигы, дивизиянең политбүлек начальнигы һәм батальон командирлары җыелган иде инде.

Дивизиянең политбүлек начальнигы безгә немецлар армиясе командованиесенең капитуляциягә кул куярга ризалык белдергәнен хәбәр итте.

Менә ул миллионнар зарыгып көткән көн! Димәк, сугыш бетте! Фашизм җиңелде!

Беренче шатлык дулкыннары басыла төшүгә, күңелне төрле уйлар биләп алды: ә нинди булачак ул сугыштан соңгы тыныч тормыш? Дөньяда ниләр үзгәреп, нәрсәләр элеккечә калыр? Немец халкының киләчәк язмышы нинди булыр? Минем, Германиядә фашизмның тамыры тәмам корытылыр. Немец дәүләте кораллану хокукыннан мәхрүм ителер. Бөтен дөньяда тынычлыкны яклау буенча махсус оешма булдырылыр, һәм бу оешма, әгәр аңа реаль көч һәм хокук бирелсә, агрессив көчләргә авызлык, ә тынычлык тарафдарларына зур таяныч булып әверелер. Тынычлыкны яклау мәсьәләсендә без, әлбәттә, Англия, Америка белән, башка дәүләтләр белән союзда торып эш итәчәкбез. Әмма шул ук вакытта бу илләрдә капитал хөкем сөрүен, реакцион көчләрнең шактый йогынтылы булуын да онытырга ярамый. Бу сугышта да бит алар үз дәүләтләренә куркыныч яный башлагач кына фашистлар Германиясенә мөнәсәбәтләрен үзгәртергә мәҗбүр булдылар.

Ә безнең позициягә килгәндә исә, безнең максат һәрвакыт ачык, теләк бер— дөньядагы барлык халыкларга азатлык һәм тынычлык! Һәм бу теләкне берничек көч тә баса алмый, юкка чыгара алмый. Әле ныклап тынырга да өлгермәгән бу сугыш — безнең өчен җиңүле тәмамланган сугыш — моның тагын бер ачык дәлиле.

**Көндәлек язмаларны матбугат өчен Ю. ӘМИНОВ әзерләде.**

≈≈≈≈≈≈

## «ВАКЫТ ҺӘМ КЕШЕЛӘР» КОНКУРСЫНА

**Камил Кәримов**

# КАЙТУ

ОЧЕРК

Шәһәр туфрагына җайлашып киләм. Туган авылымнан киткән чакта авылдашларыма мин үсеп кайтыр өчен китәм дип сүз биргән идем. Кеше, агач кебек, гомер буе үсә бит.

Бөтенләйгә әйләнеп кайта алмам инде... Ә яшьтәшләр авылда.

Минә тагын кайтучылар күп; бер уйласаң, ялга каршы көн дә түгел. Кояш та кыздырмый, чәчәкләр дә тамырдан төште инде. Мишә ярының мич башыдай җылы «Шәвәли комлыгы» да бәс белән капланды.

...Инде менә алгы тәрәзәдән Шәле наратлары күренә башлады — пассажирларның теле ачылды.

«Карале, Җәмилә, каладагы улың нихәл соң, тәүфикълы гынамы?»

«Шөкер генә. Әле менә үземне дә үгетлиләр. Улым әйтә, кайтам да алып китәм сине машинага төяп, ди. Мин әйтәм, мине алмага кайтсаң, зур машина белән кайт — авылыбыз сыярлык булсын дим. Җәннәттәй Шәлене ташлап таш арасына барып керергә диванамыни мин?»

Алдагы рәттә җитмеш ике яшьлек Нурания әби белән күршесе Хәдичә.

«Суң, Хәдичә, калага барганым юкка биш былтыр ич инде... Менә шул, машинадан төшкәч, сорыйм берәүдән: «Кызым, дим, икенче Горки поселогына ничек барасы? Бәхетемә күрә миһербанлы булып чыкты. «Менә, әби, утыз икенче, утыз сигезенче автобусларга утырырга кирәк»,— ди. Мин әйтәм, кызым, икесенә дә берьюлымы дим? Кызым рәхәтләнеп көлеп алды да: «Утыз сигезенчесенә генә утырыгыз, әнә туктый торган җирләре»,— ди. Тукталышта ярты көн буе басып тордым. Бер заман ни күрәм, теге кызым яныма килеп баскан. «Әби, ник шул гомердән бирле басып торасыз, автобуска утырмыйсыз?— ди. «Утыз сигезенчегә генә утырырга куштың ич. Менә утыз җиде автобусны үткәреп җибәрдем инде, киләсенә утырам»,—дим. И көлде кызым, и көлде. Горки ягында тора икән үзе дә, бергә кайттык».

Шәледә күзгә ямансулык юк. Авылны чолгап алган нарат урманы аша көзнең сары төсе үтеп керә алмый. Шулай да, күчмә кош-

ларга ияреп, җәй китә бугай: «Норма» кашлыгына кыр казлары тезелешкән.

Колхозда урып-җыюлар тәгәлләнгәч, киеренкелекнең сүрелгән чагы. Һәркем кышка әзерләнә, үз хуҗалыгы тирәсендә кайнаша. Урманнан дыңгычлап нарат ылысы төялгән сарбалар[1] кәрваны чыкты. Нигез ипләсәң дә, баз авызына тутырсаң да, мич кабызып җибәрим дисәң дә, ылыс гел кул астында булсын.

Анда-санда балта кайраган тавышлар ишетелә. Шәледә һәр ир кеше — балта остасы. Ә Мөхәммәт абый кебекләрнең гаиләсендә — бишәр-алтышар малай. Балта остасының йорт салып карыйсы килми димени?.. Мавыга торгач, Шәледә тугыз йөздән артык йорт салынган. Шуның өстенә — икешәр катлы ике мәктәп, утыз алты урынлы больница, административ үзәк, алты кибет, терлекчеләр бинасы, ике дистәләп терлек фермасы һәм башкалар... Төзүчеләр бригадасының җитәкчесе инженер-төзүче Харис Әлмиев — минем яшьтәш. Бу — аларның да эше.

Егет булган өйдә «чүлмәк утыртсалар», кызлы өйдә сандык малы әзерлиләр. «Коры сыра» өлгертү — туй хәстәрлегенең башы. «Сосласын» авыз итим дисәң — баш кода бул.

Шәледә өйләнешү дигән нәрсә еш кына «кыз урлау» сүзе белән алышына. Без һәр нәрсәне үз исеме белән атарга күнеккән. Шәледә кыз урлауны, «килешенеп урлану», дип, бик дөрес әйтәләр. Ник дисәң, бу тамашаның планын, ягъни сценариен кавышасы кыз белән егет үзләре төзи... Авылга кунакка дип кайткан купшы шәһәр кызлары! Юкка гына куркасыз, кем урласын сезне!?. Әгәр берәр кызны «урлаганнар» икән — димәк, ул Шәледә туып үскән. Җәйләүләрдә җыр җырлаган: «Түгәрәк каенлык» җиләгедәй кызарып пешкән; «Кояшка каршы чишмәдән» су эчеп, сафлык алган; ул егетенең армиядән кайтуын сагынып көтеп торган; әнисеннән рөхсәт сорагач, «үз теләгең белән барсаң, кызың кияүгә ябышып чыкты диярләр, берүк йөземә кызыллык китермә» дигән җавап ишеткән. Шуннан соң толып табылыр, кыз белән егет сөйләшенгән урында тарантас я түрле чана көтеп торыр... Иртәгесен чишмәләрдә чиләк тулган арада, колактан-колакка хәбәр таралыр: Галимәнең Наиләсен урлаганнар».

«Урлаганнар». Кызыл туйлар үткәч, килен төшкән өйдә бизәкле сандык ачылыр. Ул сандыктан бер өзлексез чигүле кашагалар, зур-зур чәчәкләр чигелгән чаршаулар, тәрәзә пәрдәләре, күзгә өслекләре, стена бизәкләре чыга торыр — килен төшкән өй эче чәчәк атар. Тора-бара матчадагы чөйгә сиртмә эленер, ә сиртмәдә талдан үрелгән тирән бишек тирбәлер, бишектә Шәленең биш меңенче кешесе аваз бирер...

Ә шулай да бер ат юлына аркылы төшкән идем. Толып эчендәге кыз ярдәм сорап кычкыргач, йөрәгем түзмәде. Тавышы да таныш — толыпны ачып җибәрсәм, бергә укыган кызыбыз Зөлфия. Ул арада дус-ишләрем килеп җитте. Зөлфияне арбадан йолкып алдык... Хәер, соңыннан барыбер кавыштылар үзләре. Мин генә менә шул көннән бирле алар өчен чит кеше булып калдым.

...Җәй көне өйләнүчеләр: «Без өйләнгәч, төн кыскара», — диганнәр. Ә Шәледә — көз. Яше җиткәннәр туйга әзерләнә. Яше житәр-җитмәс кызлар «Сәфәри чүннигә»ндә чикләвек җыя. Базда — бәрәңге, келәттә — икмәк. Җил тегермәне эчендә — мотор гөрелтесе.

---

[1] Сарба — тирән эчле арба.

## Күзәтү

Мин атлый торган поши сукмагы урман авызында юк булды. Каршымда — ак җирлектә агач авыл, минем генә түгел, тагын бик меңгә якын кешенең туган авылы.

Агач чанасын җитәклэп Низам килә.

— Исәнмесез.

— Исән чакка туры килдең.

— Ник як-ягыңа каранып алдың?

— «Сез» дисең ич. Әллә миңа тагын берәрсе ияргәнме дип торам.

— Кичкырын урманда нишләмәкче буласың? «Арешкино» аркылы гына җәяүләп калага китеп барышың түгелдер ич?

— Безгә калган ди тагы калага җәяү йөрү. Күршегә керер өчен дә матайга атланабыз хәзер... Делянка егучылар янына барыш. Кәҗә-сарыклар кимерергә нарат ботаклары алып чыгасые.

— Караңгы төшеп килә, курыкмыйсыңмы?

— Че![1] Кеше куркытырлык нәрсә бар соң инде хәзер урманда? Син Шәленекеме соң? Кем малае дип әйтим икән?..

— Әдһәмнеке.

— Кайсы?

— Корыч!

— Ә! Таныйрлыгың калмаган. Авылда кигән тиреңне салгансың. Кала-кала инде ул. Анда килеп кергәч, безнең хөрәсән сарык тиресе затлы тунга әйләнгән ди. Ә көтүче малаеның министр буласын көт тә тор.

— Әти көтү көтмәгән лә.

— Ат дохторы гына инде... Ярый, караңгыга калам бугай.

Ничек танымас итте соң әле ул мине? Кушаматымны сорап торган була. Шәле белән аймыл булган ун ел эчендә нәрсәм үзгәрде икән? Өстемдәге чүпрәкләрем? Мин бит инде калада сырган чалбар, чусынка, биленә эзер буып бушлат, колакчасын артка каерып бәйләп, күн бүрек киеп йөри алмам. Әле дә инде, монда кайткач, мөмкин кадәр шул киемнәр эченә керергә тырышам. Югыйсә, авыл бөтенләй үги итәр.

Шулай бервакыт силос курганы өючеләр янына килдем. Төшкелеккә утырган чаклары. Курган түбәсенә менеп утырган да, дистәгә якын ир-ат фикер өләшә. Сиздермичә генә алар янына күтәрелэм.

«Гәҗиткә наруш үзем өчен генә язылам: радиобыз ябылмый, боргычы да кителеп төшкән; телевизорга да күз-колак — каршысында йокыга китсәм-китәм, программалары бетмичә ычкындырмыйм».

«Шуннан?»

«Никтер бер генә хатын-кыз да министрлар постына сайланмаган».

«Нишләп икән?»

«Белсәм әйтерием».

«Ә мин беләм: хатын-кыз — ул ирләргә караганда да катлаулы, ягъни катлаулырак маймылдан азынган. Ну...»

Агайның фикере шушы җирдә өзелеп калды. Мине, шәһәрчә киенгән авыл малаен күргәч, җеп очын бөтенләй башкача төенләде:

«Шаккатарлык бер ние дә юк: минем хатын күп сөйләшә. Күршегә кереп китсә дә, икешәр сәгатьсез әйләнеп чыга белми. Әгәр дә мәгәр, йомыш белән күрше дәүләтләрнең берсенә җибәрә калсаң... ел буе көтәрсең үзен».

---

[1] Че — сәерсенүне аңлатучы ымлык.

Икенче кайтуымда чанага җигелгән тракторга очрадым. Туктале, дим, кая бара икән, мине дә алып китсен... Бара торгач, Питрәч юлы өстендәге торфлыкка килеп чыктык. Өстемдә сырма, арзанлы чалбар, башта малахай бүрек, кулда йон бияләй, аякта олтанлы итек. Җитмәсә трактор чанасындагы торф тузаны да ягылган иде. Учак тирәсенә тезелгән агайларның урталарына ук килеп утырдым. Ә алар мине сизмәделәр дә...

Низам танымады. Мин аларны миллионлы кала халкы арасына килеп керсәләр дә эзләп табам; таныйм, сәламнәремне амәнәт итеп җибәрәм.

Күк йөзе — юылган тәрәзә. Шул тәрәзәгә кунган кар бөртекләре төсле йолдызлар кабынды. Җилләр нарат урманында адашып калган. Яңа ай нурыннан йолдызлар яктырып китте. Җирдә ак шәүләләр хәрәкәтләнә. Төнге тынлык якынлашыр алдыннан авылда ыгы-зыгы.

Әгәр яшьләр культура йортыннан зур-зур төркемнәр булып таралса,ияр дә кит берсенә. «Икәмән очындагы Мәһирә апай итек басты-рырга киткән». «Әпри Саҗидәсен кызлар үгетләгәннәр»..

Егетләр сайлана — «Кич утыру» булгач, күңеллерәгенә барыйк, әйдәгез, лутчы Татцикка. Анда «Бер-ике-өч!» не күбрәк уйныйлар, шул хәйлә белән матур-матур кызларын кинәнәбез үбеп».

Урам ягыннан тәрәзә саен бала-чага ябырылган. Аларны тыйган кеше юк: йөрсеннәр, күрсеннәр әйдә, барыбер гармун тавышы тирәюньгә йокы бирми. Өй эчендәге абый-апалар да заманында тәрәзә артыннан гына карап йөрүчеләр иде. Хәзер әнә нинди өлгереп пешкәннәр, өзелеп төшәргә генә торалар.

Ә өй эчендә — бәйрәм! Стена тирәли икегә бүленеп утырган егетләр һәм кызлар, такмак әйтешеп, «Кич утыруны» башлап җибәрәләр.

Такмакларны язып тормыйк, тыңлыйсы килгән кеше кич утырырга үзе керсен.

«Йөзек салдык», барыбыз да «күгәрчен тамагы туйдырдык». Хәзер «күз бәйләш» уйныйбыз. Менә яулык, бәйлә күзеңне. Тукта, таң әтәче кычкырды түгелме? Һай, хәерсезләр, егетләр тагын сәгатьне кирегә борып куйганнар. Нинди таң әтәче кичке унда кычкырсын ди юкса!

Җыр, уен-көлке урамга таралгач, өй эче бушап калды.

Ах, бу тулган айга пәрдә корып куярга! Йокыга китәргә ирек бирми Сәлимәгә. Ике бит алмасы кызыша. Әллә искә алаларммы? Ай нурына өстәл фонареның сабыр яктысы кушылды. Тәрәзә артындагы караңгылык куергандай булды. Тынлык. Сәлимә. Кыш. Салкын бушлыкта этләр өрүе. Ничек җиңәргә шушы бушлыкны? Сәлимә кулында киергечкә тарттырылган ак түгәрәк яктырды. Исламның күзләре зәңгәр икән ләбаса... Ак сатинда зәңгәр җепләрдән пар кыңгырау чәчәк атты...

Тамагы карлыкканчы кычкырмаса, әтәч — әтәч буламыни ул?! Шәленең мең әтәчле хорында таң ата. Таң яктысында караңгылык эреп, биш мең тәрәзәдән көн яктысы килеп кергәч, берәм-берәм капкалар ачыла. Эш кешесе ашыга.

Төркемнең бер өлеше мәчеткә ашыга. Шәле «мәчете» ике сменада эшли. Иртәнге җидедән кичке өчкә кадәр бер смена, өчтән унбергә тикле икенчесе. Мәчетнең «мөгаллимәләре» дә, «шәкертләре» дә хатын-кызлар. Хәзер мәчет йортын «Кызыл күн» берләшмәсенең тегү цехы иттеләр.

Ашыгучыларның меңнән артыгы — мәктәп укучылары. Трамвай-троллейбуслар юк бит; дәресләргә өлгерим дисәң, өч чакрымлы авыл-

ны үтү өчен ярты сәгать алдан кузгалырга кирәк. Бүген февральнең беренче шимбәсе — мәктәп карлыгачларының очрашу көне. Кемнәр килер икән? Әгәр Шәле мәктәбен тәмамлаган барлык кеше бергә җыела алса!?. Әле дә ярый җыелмыйлар — очрашу кичәсе ике йөз кешелек залда гына үткәрелә. Ә нигә җыелмыйлар? Залда урын җитмәсә, культура йорты бар, анда кысан дисәң — урам иркен.

Бу мәктәпне без дә тәмамладык. Чыгарылыш кичәсеннән соң класс җитәкчебез Сәкинә Мөхәммәтовна һәрберебезгә характеристика таратып чыкты. Бу шәхес белешмәсендә һәр Шәле кешесенә хас уртак сыйфатлар әйтелгән иде: хәрәкәтчән, көчле, принципиаль, кайнар канлы, хезмәт сөючән. Раслау өчен Сәкинә апамның имзасына өстәп мәктәпнең түгәрәк мөһере дә сугылган. Сәкинә апа безне соңгы кат урамга кадәр озата чыкты. Саубуллашып, таралышып та өлгермәдек, укытучыбызның тавышын ишеттек.

«Туктагыз!»

Туктадык, яңадан җыелдык.

«Бөтенегез дә мондамы? Тагын бер кат карыймчы үзегезгә».

«Фатих күренми».

«Фатих!»

«Фа-тих!!!

Хушлашып та өлгермәдек, ә инде беребез юк. Кайда ул? Нишли? Ник югалды? Мең-мең сорау тагы. Мәктәпне моннан егерме-утыз еллар элек тәмамлаучылардан кемне көтәргә?..

Агач авыл көн агышына кушылды. Биш мең тәрәзәдә кояш яктысы. Мәчеттә — кызлар җыры...

## Шәле ни дигән сүз?

Мин — кеше, язны яратам. Ә язлар Шәледән башлана. Язның иңиң беренче тамчысы мондагы мең түбәнең берсеннән өзелеп төшәдер. Кар астында гөрләвекләр челтер-челтер. Бу гөрләвек — иң беренчесе, беренче булып инешкә килеп төшәр. Баш өстендә төсле болытлар кар белән яңгырны бергә бутаган. Болытларны пыр туздырып, кояш килеп чыга. Барлык җан иясе көн җылысына күмелеп нурга сыена.

Юл башымда — кояш.

Бу кайтуымда мин үзем генә түгел. Бер-беребезне шактый күптән белсәк тә, туган авылымның исеме асылда аны кызыксындырмый иде. Кайтып төшкәч, хәл үзгәрде.

— «Шәле» ни дигән сүз ул?

— Миңа калса, бу әлегә шартлы исем генә, башка авыллар белән бутамас өчен.

— Кеше исемнәре дә тиктомалдан гына куелмый, Шәле — поселок хәтле авыл.

— Авылдашларның өлкәнрәкләреннән дә, шәһәрдәге белгечләрдән дә сораганым бар. Күбесе шәл бәйләү сүзенә кайтарып калдыра, чөнки Шәледә, мамык кәҗә асрап, шәл бәйләүчеләр шактый. Кемгәдер ул шаяру сүзеннән килеп чыккандыр төсле. Шәле — ягъни русчалап әйткәндә — Шали — Шальной халык.

Шәледә яз.

Җигүле атларны өркетеп, «Кировец» тракторы үтеп китте. Тояк тишкәләгән чана эзен баһадир көпчәкләр тигезләде.

Авыл халкы, кояш эреткәнче дип, туры түбәләрдән кар төшерә, өй тирәсендә адашып туктап калган гөрләвекләргә юл ачып бирә. «Мәдрәсә» бакчасындагы тупыл-таллар сусылланып кулга-кул тотынышканнар.

Һәр чор үз агачын утырта. Ә менә авыл уртасында инеш тирәли тезелгән таллар — безнең яшьтәшләр. Аларга утыз яшь чамасы; гәүдәгә таза, тамырга нык, баш очлары болыт. Яшьрәк чакларында аларга кошлар биектән генә карап үтәләр иде. Хәзер исә ныграк ботак саен — карга оясы. Инеш тирәсендәге таллар — каргалар каласының олы урамы.

Кичен, каргалар тавышы тынгач, мәдрәсә бакчасына яшьләр җыела. Кояш яшьләрне артыграк ярата бугай — иң беренче булып шушы аланны кардан арындыра ул. Кайда ничектер, Шәледә кичке уенга чыгуны «Авыл артына чыгу» дип атыйлар: аулакка, олылар күзеннән читкәрәк, ягъни уенга иң элек кызлар җыела.

Кызлар җыелып бетүгә, уенга, гармун күтәреп, егетләр килеп кушыла. Шәле гармунчылары ялындыра белми: ник дисәң, монда һәр егет — гармунчы. Гармун уйнарга өйрәнмичә торып, кыз күзләргә чыкмый чын Шәле егете. Уенда елдан ел үзгәреш. Хәзер инде без яраткан «Наза», «Зәкәрия», «Миләүшә», «Йөзек салыш» уеннарын кысрыклап, магнитофон тавышлары, «Кем ничек булдыра» дигән танцалар килеп керде. Хәер, кичке уенга бар да килешә. Яшьләр үсә — мәдрәсә бакчасы кебек тагын дүрт җирдә берьюлы кичке уен гөрли.

Авыл уртасында яңа культура сарае өлгерә. Иске клубны нишләтерләр икән?..

Төн хисабына көн озая. Председатель Фәйзерахман Сафин колхоз колачы буйлап язгы тәртипләрне тикшереп йөри: силос чокырларының төбенә төшеп җитмәгәннәрме? Яңгыр дигәннәре кырга буразналар ермаганмы? Пилорамда мотор тавышы яңгырыймы?.. Барысын да санап бетереп буламыни инде...

Ул автопаркка килеп керде. Кырык алты трактор, уналты комбайн, егерме җиде автомашиналы уңыш working парады аның әмерен көтә иде. Әйтер сүз бер генә — сынатмагыз!

Язлар тиз үтә. Таллар көр үсә. Әле кайчан гына... Алтмышынчы еллар уртасында колхозның бер отчет-сайлау җыелышы өч көнгә сузылды. Колхозчылар, сайлана торгач, 30 яшьлек Сафинга — син булырсың безнең яңа председателебез диделәр... Инде күпме язлар үткән. Ул рәис булган елны дөньяга килгән сабыйлар хәзер үзләре колхозны әйдәп баручы хезмәт батырлары.

Тракторлар юлга чыкты. Җылы туфрак эчендә орлык назлана. Орлык шыта — җыр дәвам итә. Колхозның алты мең гектар җиренә яшел төс иңә. Игенчеләр көч сынаша. Ислам Гайнетдинов кебек кыр батыры булам дисәң — кыр иркен; Мәрфуга Шәйхиева кебек Социалистик Хезмәт Герое булыйм дисәң — фермалар көтә. Участок больницасында РСФСРның атказанган врачы Мәрзия Мөхәммәтҗанова, мәктәптә ТАССРның атказанган укытучысы Йосыф Садыйков... Кыскасы, көрәш мәйданы җитәрлек!

## Тормыш сәхнәсе

Кала юлында йөрүчеләрне өч төргә бүләргә мөмкин.

Беренчесе — кайтып-китеп йөрүчеләр. Алар тумышлары белән Шәленеке булып, җае чыккан саен, мин Шәледә тудым дип масайсалар да, авыл эчендә никтер ял көннәрендә, бәйрәмнәрдә генә күренәләр.

Кайтып-китеп йөрүчеләр арасында язучылар, рәссамнар, артистлар да бар. Шәһәр белән якын торгангамы, әллә тамашачылар күпкәме, Шәлегә артистлар еш килә. Килгәне берсе залны сокландырырга теләп сайрарга керешә. Кайберләре сайрый-сайрый да гамьсез халык ла бу дип китеп бара. Шәле кешесе бер үк җырчыны да ике төрле алкышларга мөмкин, дөресрәге, җырына карап җырчысына кул чаба. (Шәле халкының таләпчән булуына ышанмасагыз, әдәбиятыбыздагы Шәле премиясе лауреатлары язучылар В. Нуруллин белән Х. Хәйруллиннардан сорап карагыз.)

Халык туган авылына охшаса да охшар икән. Инеш озынлыгы, алты урам җилкәле Шәленең кешеләре Харис Якупов полотноларына чак сыйган. Сынлы сәнгать музеена кергән кеше: «булган бит элек көчле кешеләр» дип сокланыр. Ә бит М. Галиуллина, Ф. Гәрәева, М. Исламова, С. Сәгдиева, Н. Җиһаншиннар — колхозның бүгенге кешеләре. Әйе, әйе, хәтта дүрт почмаклап япкан яулыклары, бәби итәкле күлмәкләре, челтәрләп керфекләнгән алъяпкычлары, хәтта беләкләрендәге көмеш беләзекләре дә бүгенгечә. Театр сәхнәсендә мондый киемнәрне күрсә, әй шатлана бит шәһәр кешесе. Әллә Шәле тормыш дигән олы театрның бер сәхнәсе микән?

Юлда йөрүчеләр арасында кайтыр өчен китүчеләр дә бар. Болары инде канатлы өметләр. Мәктәпне тәмамлагач, шәһәргә укырга кергәннәрне дә, армиягә китүчеләрне дә кайтырга тиешләр дигән өмет белән озаталар. Һәм алар кайтып та керерләр. Тик соңгы сугышка китүчеләрнең генә 272 се әйләнеп кайтмады...

Юл кешесенең өченче төре — китмәскә дип кайтучылар. Болары — күпчелек. Каладан әрдәнәләп төяп кайтса да, автобус Шәледән ярты-лаш буш китә. Китмәскә дип кайтучылар — Шәленең җитәкче көчләре, укытучылар, белгечләр, игенчеләр.

Мин гел юлда. Ни чаклы гына тырышсам да, китмәскә дип кайтучылар төркеменә кушыла алмыйм. Кайтам-китәм, кайтам-китәм... Ләкин бөтенләйгә беркайчан да китмәм.

Ринат Мөхәммәдиев

# ШИГЪРИ СҮЗНЕҢ ҖЕГӘРЕ

Шигырь!.. Ул нәрсә? Кеше күңеле нигә берөзлексез аңа тартыла. Шатлыгын да, моң-зарын да нигә ул икәүдән-икәү генә калып кош теледәй китап битенә сыйган шигырь юллары белән уртаклаша. Аңарга үзенең эч серләрен чишә, иң изге хисләре, хәтта мәхәббәте белән уртаклаша—киткән мәхәббәте, еллар томаны артында калып югалган мәхәббәте, җанын һәм йөрәген телгәләгән мәхәббәте белән.

Шигырь!.. Ул нәрсә? Нигә иң элек аны утта яндырганнар, ә ул янмаган, сандыкларга салып суга батырганнар — ул батмаган, дарга асканнар — үлмәгән, палач балтасы астында да киселмәгән—исән калып исән кайткан. Нигә ханнар һәм тираннар элек-электән (һәм бүген дә) иң элек шигырьләрне буарга омтылган, шигырьдән үч алган, ә ул бирешмәгән, яшәгән—көрәшкә чакырган.

Шигырь!.. Ул нәрсә? Ничек аңа бу дөньяның бөтен матурлыгы сыйган, каян аңар барлык сайрар кошлар моңы тулган. Ул ничек кышларын күңелләргә июнь кичләренең кабатланмас гүзәллеген алып килә, ничек итеп нәфис канатларында чәчәкләр һәм болыннарга илтә, ай нурларында иркәли, җылы яңгыр булып күңелдәге талгынлыкны юып үтә...

Шигырь!.. Ул нәрсә? Дөньяда һичбер әйбер мәңгелек түгел дибез, ә шигырь еллар, гасырлар белән исәпләшми яши бирә. Буыннардан буыннарга, илләрдән илләргә, телләрдән телләргә, күңелләрдән күңелләргә күчеп яши. Саргаюны, картаюны белми яши. Югыйсә, билгеле бер тәртип белән килгән сүзләр тезмәсе генә ич үзе.

Әмма нинди сүзләр! Мәңгелекнең сере дә шунда түгелме!?. Менә шул урында шигырьнең, шигъри сүзнең илаһилыгына сокланудан аның бүгенге татар поэзиясендәге халәте, идея һәм эстетик җегәре турындагы кайбер уйлануларга күчәргә исәп. Күпгасырлык бай традицияләре булган татар поэзиясенең бүгенге торышы, шигъри сүзнең җегәре (файдалы эш коэффициенты) канәгатьләнерлекме? Ул укучының рухи дөньясында нинди урын алып тора? Шагыйрьләребез шигъриятнең, шигъри сүзнең замандаш алдындагы авторитетын күтәрүдә нинди нәтиҗәләргә иреште һәм алар аны һәр очракта да саклыйлармы?

Каршымда татар шагыйрьләренең соңгы елларда дөнья күргән әсәрләре—калын томнар, җыйнак һәм пөхтә җыентыклар, яңа табадан төшкән дигәндәй, газета һәм журнал битләрендә басылган шигырьләр. Илледән артык автор, күпмеңләгән шигырь, дистәләгән поэма. Уйлый калсаң үзе бер гаҗәп—монда күпме рухи байлык, чорыбызның сулышын киләчәккә алып китәчәк күпме хәзинә. Һәм шунда ук укучыга тәкъдим ителеп тә, аның өчен бар суретендә юк булган, һәм идея, һәм эстетик кыйммәте бик чамалы булган, шигырь исемен күтәрә алмаслык күпме буш сүз поскан. Боларны менә хәзер генә сортларга аерып, аларга уңай яисә тискәре тамга куеп чыгу прак-

тик яктан мөмкин дә түгел һәм андый йөкне үз өстенә алу хата булыр иде. Чөнки һәр шагыйрьнең үз җыры, үз моңы булган кебек, үз укучысы да бар. Әмма һәр шигырьнең түгел, һәр шигырьнең үз укучысы бар дип әйтергә җөрьәт итеп булмый. Чөнки каршымдагы шигъри «калкулыкта» чын поэзия үрнәкләре булуына инанганым кебек, анда шигъри кыйммәткә ия булмаган, Тукай әйтмешли «холостой выстрел»ны хәтерләткән язмаларның да байтак булуына иманым камил. Менә шунда инде телисеңме-теләмисеңме шигъри сүзнең җегәре хакындагы сөйләшүнең урынсыз түгеллеген, актуаль булуын танырга туры килә.

Шигъри сүзнең җегәре мәсьәләсе бүген генә көн кадагына килеп басмады, әлбәттә, ул элек-электән әдәбият турында хөкем йөртүче фикер ияләрен генә түгел, һәр шагыйрьне тирәнтен уйландыра килгән, борчыган мәсьәлә. Үз җырларының эчтәлеген һәм сәнгатьчә эшләнешен берөзлексез чарлый килгән—тирәнәйтә, камилләштерә барган халык та шигъри сүзенең (җыр сүзләренең) күңелләргә якынлыгына, йөрәкләргә үтеп керү сәләтенә, димәк, җегәренә, битараф булмаган. Әйтик, бер төбәктә:

**Алтын йөзек табып алдым**
**Койма буе утлыктан;**
**Мин җырламыймын мутлыктан,**
**Җырлыйм хәсрәт күплектән,**

—дип җыр чыгарганнар икән, аның эчтәлегендә күңеленә аваздашлык тапкан икенче берәү җырны шундук эләктереп алган, һәм аның музыкальлеген камилләштерә төшеп, эчтәлегенә яңа төсмер өстәп җырлый башлаган:

**Былтыр җуйган уймагымны**
**Быел таптым утлыктан;**
**Мин җырламыймын мутлыктан,**
**Җырлыйм бәхтем юклыктан.**

Җырда нибарысы берничә сүз алышынган, әмма аның мәгънәви сыйдырышлылыгы, сәнгать әсәре буларак җегәре сизелерлек дәрәҗәдә уңай якка үзгәргән. Мәсәлән, беренче варианттагы «алтын йөзек табу»ны берничек тә хәсрәтне көчәйтүче деталь дип әйтеп булмый, шулай ук андагы рифмалашучы сүзләрнең дә таләпчәнрәк җырчыларны канәгатьләндермәве табигый. Шигъри сүзнең җегәре, камиллеге һәм мәгънәви сыйдырышлылыгына омтылышның шул характердагы мисалларын без җырларда гына түгел, халык авыз иҗатының башка жанрларыннан да күпләп таба алыр идек. Хәер, үз әсәрләренең шигъри камиллеге, тирән эчтәлеге һәм укучы күңеленә юл табарга сәләтле булуы хакында кайгыртмаган шагыйрь һәм әдип гомумән юктыр да. Дөнья халыклары әдәбияты һәм, аерым алганда, татар әдәбияты тарихына, бүгенге әдәби процесска күз салганда да без моның шулай икәнлеген—авторның үз-үзенә таләпчәнлеге чын шигъри әсәр туу өчен беренче шарт булуны күрәбез. Берничә еллар элек миңа шагыйрь Нури Арслановның кайбер шигырьләренең язылу тарихы һәм аларның камилләшү процессындагы вариантлары белән танышу насыйп булган иде. «Кәрәкәү икмәге» шигыренең вариантлары (ялгышмасам, 7—8 вариант) аеруча хәтергә кереп калган. Аларда шагыйрьнең шигъри сүзгә талымлылыгы, синоним булып йөргән сүзләрнең дә мәгънә төсмерләрен күңеле белән тоеп эш итүе, шуны укучыга җиткерергә омтылуы, иҗади рухланып эзләнүе, төпченүе дип әйтергә дә мөмкиндер, документаль чагылыш тапкан иде. Ул вариантларда тамырдан үзгәртүләр юк югын, әмма шагыйрьнең шигъри сүзнең җегәрен арттырырга омтылышы варианттан вариантка уч төбендәгедәй ачык күренә килә. Әлбәттә, төрле шагыйрь төрлечә эшли, әмма Нури Арслановның менә шушы сыйфаты миңа аның шигърияттендәге өзлексез үсеш, сыйфат үсешенең табигатен ачыкларга ярдәм итте.

Сүз дә юк, шигырьнең уңышын яисә уңышсызлыгын, шигъри сүзнең җегәрен вариантлар күплеге генә билгели алмый, әлбәттә. Барыннан да элек, шигырь үзе булырга тиеш, беренче укыганда ук укучының күңеленә, уйларына үтеп керергә сәләтле шигырь.

Җирдә яз... Таллар исе...
Һавада кошлар өне...
Кай елда иде икән
Гомернең шушы көне!..

«Ленин»,—дип беренче кат
Кем әйтте! Әни микән!
Апрельнең үземе соң,
Тургае әйтте микән!..

(Х. Туфан. «Җирдә яз»).

Бу юлларны шагыйрь, әйтерсең, укучының үз күңеленнән әләктереп алган, аларда һәммәбез дә әйтергә теләгән уй, һәммәбезгә якын исем—даһи Ленин хакында сүз. Ләкин һәммәбез дә түгел, күп кенә шагыйрьләр дә әйтә алмаган шигъри сүз. Аның җегәре нидә дигәндә, иң элек, әлбәттә, шагыйрьнең гомумиләштерү сәләтендә, шагыйрь уйларының укучы уе белән тәңгәл килүендә. Һәм шунда ук шагыйрьнең шигъри сүзгә булган таләпчәнлеге һәм талымлылыгын, сүзләрнең мәгънәләрен генә түгел, эчке рухын, хәтта җылылыкларын да нечкә тоемлавына сокланмый мөмкин түгел. Игътибар итик: Җирдә яз... Таллар исе... һавада кошлар өне... Әни... Апрель... Тургай... һәм Ленин. Бары да үз һәм кадерле, бары да балачактан ук күңелләргә мәңге онытылмаслык булып кереп калган җылы һәм изге төшенчәләр. Шул рәвешчә талымлылык һәм сайланган сүзләр—күңелгә якын һәм үз сүзләр—бер бөтенне тәшкил итеп йөрәкләргә сабый чактан ук кергән кадерле кеше—Ленин образын тудыралар. Монда шигъри сүзнең җегәрлеге, берсүзсез, әлеге бөтенлектә, чама белеп кенә сайланган сүзләрнең эчке һәм тышкы мәгънәләре белән дә бер-беренә бәйле булуында, бер-берен баетып, тулыландырып килүендә.

Инде башка бер өлкән шагыйребезнең күләмлерәк әсәреннән алынган өзеккә мөрәҗәгать итик:

Әти—Әтнә базарыннан.—
Бәйрәм!
Чана башын тизрәк актардым,
Ат печәне, салам арасыннан,
Арасыннан чиста ак карның
Күмәч чыкты, китап—Тукай чыкты.
Әкиятләре белән, кар белән
Тукай керде өйгә, казанда аш,
Бөтен дөнья тулган пар белән.

(С. Хәким. «Кырыгынчы булмә» поэмасыннан).

Сүз татар укучысына шулай ук үтә кадерле булган шәхес, колагыбызга исеме бишек җыры белән бергә кергән Тукай турында бара. Тема башка, шагыйрьнең язу стиле бөтенләй башка, әмма һәр шигъри сүз урынында, һәр шигъри сүзнең үз функциясе бар. Стильдәге сабырлык һәм билгеле бер дәрәҗәдәге кырыслык артыннан тиз арада авторның Тукайга булган үтә җылы мөнәсәбәте калкып чыга. Шунда ук шигъри детальләргә, сурәтләү чараларына игътибар итик—алар гади һәм гаять дәрәҗәдә халыкчан, татар укучысына, бигрәк тә авыл кешесенә, алар тудырган картина һәм тойгыларны кабул итү һәм кичерү һичнинди кыенлык тудырмый, алар аның яшәү рәвеше һәм табигате. Нәтиҗәдә, шигъри юлларның файдалы эш коэффициенты гаять зур, шагыйрь шул рәвешле беренче строфадан ук укучының күңеленә юл таба, мавыктырып аны үзе белән бергә поэма буйлап сәяхәткә әйди.

Күпме еллар инде бер урында
Искә төшереп шомлы ел турында
Гармун тора.
Телләре бар—берни сөйләми ул,
Көйләре бар—никтер көйләми ул.—
Тып-тын тора.

(Илдар Юзеев. «Һаман көтә»)

Шигырьдә күз явын алырлык берни юк. Шагыйрьнең стилен шулай ук гадилек, табигыйлек, тормышчанлык характерлый. Сүзләрнең бизәкләре белән дә, үтә акыллы гыйбарәләр белән дә, яңгырап торган рифмадаш сүзләр белән дә һичкемне шаккатырырга теләү сизелми. Бер урында тик кенә торган гармун кебек шигырьнең агышы да тыныч һәм салмак. Сүзләрдә сабырлык, ләкин алар артында ниндидер бер драматизм, күңелгә тынгылык бирмәгән язмыш, ярсу үй барлыгы да төсмерләнеп тора. Шигъри сүзләр укучы күңеле тоемларлык талгын бер моң белән өретелгән. Сүз һаман гармун турында, ләкин тора-бара күз алдында аның хуҗасы—Ватан өчен көрәштә җанын да кызганмаган ир-егет образы калка башлый. Һәм шигырьнең соңгы юллары, уяу булырга чакыргандай, кинәт сискәндереп җибәрә:

**Гармунчыны бик нык сагынганда,**
**Көмеш телләренә кагылганда—**
**Дертләп китә.**
**Егет тиздән кайтып җитәр кебек,**
**Көмеш телләр биеп китәр кебек —**
**Һаман көтә.**

Баштагы тынлык, баштагы сабырлык шартлап юкка чыгамы—шигырь укучыны кичерешләр, уйлар һәм истәлекләр чоңгылына бөтереп алып кереп китә.

Шигъри сүзнең җегәре дигәннән, соңгы елларда нигәдер аны барыннан да элек кыска форма белән чикләргә, фикере прессланган фәлсәфи лирика үрнәкләрендә генә күрергә омтылу тенденциясе бар (Зиннур Мансуров, «Социалистик Татарстан», 1979, 14 январь һәм «Казан утлары», 1979, 3 сан, Мансур Вәлиев, «Социалистик Татарстан», 1979, 21 январь мәкаләләре). Аларда сүз поэзиябезгә алтмышынчы еллар уртасында килгән бер төркем авторлар иҗаты турында бара. Һәм, әйтергә кирәк, җитди сүз. Гомумән, тәнкыйть әлеге буын вәкилләренә соңгы елларда чагыштырмача игътибарлы булды һәм шигърияттебездә кыска вакыт эчендә лаеклы урын яуларга өлгергән шагыйрьләрнең новаторлыгы һәм иҗат үзенчәлеге инде шактый тулы ачыкланды. Сүз дә юк—талантлы буын!

**Танкларны таптап,**
**генерал итекләреннән атлап,**
**үз түмгәген эзли**
**бер кырмыска.**

**(Р. Фәйзуллин. «Полигонда»)**

**Ә Казанда соңлаган көз.**
**Карлы яңгыр канлы күз яшедәй авыр.**
**Авыр култык таякларына—**
**Бер аяк бәрабәренә җиңеләеп кайткан солдатларны**
**Йөртү авыр.**
**Аталары бәрабәренә бер тамакка кимегән**
**Гаиләләргә авыр,**
**Әтисез калган балаларга,**
**Ирсез калган җиләк хатыннарга,**
**Георгий тәресе тагып үйнаган сабыйларга,**
**Георгий тәресе тагып хәер сораган агайларга,**
**Шуларны күргән күзләргә авыр,**
**Кешедән кешегә шатлык илтә алмаган**
**Сүзләргә авыр.**

**(Р. Харис. «Рәссам» поэмасыннан)**

Шигъри сүздәге әлегедәй киеренкелеккә, аның җегәрлелегенә чынлап та сокланмый мөмкин түгел. Һәр сүз урынында, һәр сүзгә аерым бер фикер һәм сәнгатьлелек йөге күтәртелгән. Шигырьләрнең салмак агышы да моны көчәйтә кебек. Күз ал-

дына зур гомумиләштерүләр, драматизм тулы картиналар килә. Һәрхәлдә конкрет бу очракта шагыйрьләрнең эчтәлеккә туры килеп торган шигъри формага тукталуларына сокланырга гына кала.

Ә инде мәгънәви тирәнлек һәм рациональлек белән чамадан тыш мавыгып китеп, чама дилбегәсен кулдан ычкындырулар башка нәрсә. Шуңа күрә андый әсәрләр хакында сүз дә башка:

**Әгәр кеше җитсә бер чиккә...**
**Саный башлар каныңдагы ак шарлар**
**исәбен,**
**ышанып бары күзләрдә язылганга.**
**Сапер кебек сагаеп, тын кысып,**
**Васыятьтә әйтер сүзләр эзләр**
**дөньялыктан.**

**(Р. Фәйзуллин)**

**КЫСКА ҖИЛ**

**Мин бер мизгел,**
**Кыска бер җил—**
**Салмак башлап, кинәт бетәм...**
**Ә шулай да нәрсәнедер**
**Фәкать алга,**
**Алга этәм.**
**Аһ,**
**Бер вак әйбер булмасын,**
**Мәгънәсез булмасын юлым...**
**Көнне**
**Төн аша**
**Яктыга**
**Чыгарышкан бер җил булыйм...**

**(Р. Харис)**

Бу шигырьләрне дикъкать белән укып чыксак, без шулай ук шагыйрьләрне сүзләргә талымсызлыкта гаепли алмыйбыз. Һәр сүзгә мәгънәви бер йөк ышанып тапшырылган һәм алар янәшә килеп кеше табигатенең кабатланмас бер халәтен (беренче мисал) яисә изге максат, омтылышны (икенче мисал) тасвирлаган кебек. Әмма бу мисаллар күңелләрдә нинди тойгы, нинди хис уяталар соң, укучыны алар нинди фикер, уйга этәрергә сәләтле? Алардан бу сорауга җавап алу өчен башта башны кашып бер уйланырга, баш ватарга туры килә. Ярар—уйлана торгач җавап та табыла. Әмма аларның шигырь булуына шулай да шик туа. Һичшиксез, җегәрле сүзләр, ләкин алар шигъри сүзләр микән!.. Монда сүзләрнең мәгънәви җегәре эстетик җегәргә әйләнә алмый кала, шигырьнең сәнгать әсәре буларак кабул ителүен кыенлаштыра. Акыл белән ясалган андый сүз конструкцияләре шагыйрьнең күңел түреннән бәреп чыккан тирән бер хис белән ныгытылмаган, берекмәгән тәкъдирдә тырышлык кына шигырь тудырмас. Шуңа күрә дә шигъри сүзнең җегәре мәсьәләсен мин шигырьнең кыскалыгы, строфа һәм юлларның азлыгы, фикернең башваткычтай прессланган булуы белән генә бәйләргә ашыкмас идем. Хәтта ул шагыйрьләрнең поэзиябездә шигъри сүзнең эффективлылыгы һәм сыйфаты өчен борчылып, янып иҗат итүләрен таныган тәкъдирдә дә.

Һәр яңалык—ул күптән онытылган үткәннең кайтуы, диләр бугай. Әмма шигырьдә кыска формага омтылуны күптән онытылган, яисә онытылып торган тенденция дип аңлату белән һич килешеп булмый. Халык «Аз сүз—татлы сүз, күп сүз—буш сүз» дигән булса, Каюм Насыйри бабабыз «Аз сөйләмәк гакыллык галәмәтедер, күп сөйләмәк наданлык галәмәтедер» дип өстәп куйган. Димәк, шигъриятка генә түгел, гомумән, халкыбызның эстетик табигатенә үк хас сыйфат икән кыскалыкка омтылу. Һәм

безнең татар шагыйрьләре (сүз Шагыйрьләр (!) турында бара) бу хакыйкатьне кайчан да булса онытып, хәтерләреннән чыгарып торганнар дип әйтергә нигез юк. Кыска итеп әйтергә мөмкин уй һәм хисне озынга сузмый шигырь юлларына күчерү—шигъри сүзнең җегәрлегенә омтылу кырыгынчы, илленче, алтмышынчы еллар поэзиясенең дә яхшы үрнәкләренә хас булган. Ә инде бүгенге поэзиябездә кыска формалар нык күзгә ташлана икән—моңа куанырга гына кирәк һәм ул табигый хәл. Шулай да, югарыда искәртелгәнчә, чаманы онытырга гына ярамас. Кыскалыкта—осталык, дип әйтү әле һич кенә дә «Дәверләр капкасы» (С. Хәким) кебек киң колачлы, шигъриятебез үсешендәге тулы бер дәвернең күп кенә казанышларын үзенә сыйдырган һәм тупланган күләмле поэманы

**Гаҗәпсенмәгез, тапсалар**
**Айда гамәл дәфтәре,**
**Чыккалый куныл бурычка**
**Анда Галләм яшьләре.**

**(С. Хәким)**

— кебек, кат-кат укыганда да нәрсәдер аңларга кыен булган дүртьюллыклар алыштыра дигән сүз түгел.

«Сүз синең колың, авызыңнан чыкса—син аның колы»,—ди Кавказ халыклары әйтеме. Шагыйрьләргә аның мәгънәсе хакында уйлану һич зыян итмәс иде. Дөрес, олы талантлар да кайбер иҗади уңышсызлык һәм урынсыз мавыгулардан гел азат булмас. Шулай да шагыйрь һәм язучы үз иҗат йөзенең укучыга тәкъдим ителгән барлык әсәрләре суммасыннан хасил булганлыгын онытмаса иде. Очраклы әсәрләр, ашыгычлык белән укучыга тәкъдим ителгән язмалар һичсүзсез халык тарафыннан танылган талантларның да иҗади мирасын бизәми.

Әледән-әле шигъри сүзнең югары миссиясен хәтердән чыгарып кую, кызганычка каршы, шагыйрьләребезнең күбесенә хас. Шагыйрьләребез илһам киләме-юкмы, йөрәктәге хисләр, башта әһәмиятле бер уй бармы-юкмы язарга ашыгалар. Нәтиҗәдә ни әлекте, шуны да язып куйгалыйлар — эч пошканны басу өченме, язарга кирәк булгангамы, китап яисә газета укып утырган җирдән очраклы бер фикер килепме. Белмим, әмма язалар. Төрлесе буладыр, безгә—укучыга бары тик нәтиҗәсе тәкъдим ителә. Укучы нишләргә тиеш? Шигырьдән һәм шагыйрьдән йөз чөерергәме... Шул рәвешле шигъри талымсызлык белән очрашкан укучыда поэзиягә мөнәсәбәт үзгәрә, ул суына төшә, ә шигъри бум һаман дәвам итә. Шул урында шагыйрьләрнең җаны теләгән нәрсә хакында җаны теләгәнчә язарга хокуклы булып та, язган бер әйберен матбугатка чыгарып укучыга тәкъдим итәргә хокукы булмауны искәртергә кирәк.

**Алтын пәке көмеш саплы,**
**Агач башын сырламам;**
**Өч көн, өч төн җырласам да,**
**Бер җырны ике җырламам,**

—дип җырларга халык кына булдыра ала. Талантның да үзенә күрә бер чиге булмый мөмкин түгел, ул да өстәл артына утырган саен сүзләрдән җәүһәр тезә алмас. «Язуда иң беренче шарт: әйтәчәк нәрсәнең үз миеңдә, үз йөрәгеңдә кайнап, аның тышка чыгарга сорап торуы»,—дип искәртә килгән әдәби иҗат психологиясен үтә нечкә аңлаган һәм тирән сиземләгән әдибебез Г. Ибраһимов.

Шигъри сүзнең җегәре өчен көрәш, шигырьгә мөнәсәбәттә үтә нечкә зәвыклы һәм талымлы булу—көн тудырган мәсьәлә. Халкыбызның рухи тормышындагы үз позицияләрен шигъриятебез югалтмасын дисәк, безгә моның өчен бүген борчылырга, бүген көрәшергә кирәк, иртәгәсе көнгә калдырмыйча. Томнарга ни әлекте шуны тутырмый, хет югында эре иләк аша үткәрү, юка шигырь җыентыкларына да таләпчәнрәк булу зыян итмәс иде. Китапларның тиражы артсын, сыналган әсәрләр, классиклар күбрәк басылсын, яхшы шигырь чират көтеп ятмасын, кат-кат басылсын, тик тәс-

сез-хиссез, тонык һәм әчпошыргыч шигырьләрдән саклыйсы иде бит укучы зәвыгын. Шагыйрь әйтмешли:

Әмер булсын иде, шигырьне тик
Ташка гына чокып язарга...
Буш сүз тезүчеләр бетәр иде!
Һәй, бер шуны сынап карарга!
(Ш. Галиев)

Алдымда яткан китапларны кат-кат күздән кичергәндә шундый уй китми газаплый.

Менә «Яшьлеккә кайту» (Тәүфикъ Камалиев) дип исемләнгән җыентык. Аны күрмәмешкә салышып үтү мөмкин түгел. Китап пөхтә һәм матур, кулга алгач үзен укыйсы килеп тора. Аннотациясе дә зурлап, җылы итеп язылган. Анда түбәндәге юллар бар: «...Т. Камалиев кайнап торган завод тормышы һәм эшче яшьләр турында бик яратып яза... Туган як моңнары белән табигать күренешләрен дә үзенең каләменә хас матур һәм якты буяулар белән тасвир итә». Ләкин җыентыкны җентекләп укып чыгып та шагыйрьнең «яратуын», «үз каләменә хас матур һәм якты буяулар белән тасвир итү»ен тоя алмагач, сәер булып китә. Ә ул бит кемгә дә булса түгел, урта һәм олы яшьтәге мәктәп балаларына тәкъдим ителгән. Киләчәк өметебез булган үсмер укучының зәвыгы өчен шул дәрәҗәдә җавапсызлык нигә кирәк иде икән... Югыйсә, тәнкыйть әлегедәй шигырь җыентыкларына үзенең мөнәсәбәтен бер генә тапкыр белдермәде инде (аерым алганда, Мансур Вәлиевнең Т. Камалиевның элгәрге китабына рецензиясе күздә тотыла). Юк дигәндә, алар белән дә исәпләшергә кирәктер, әдәби тәнкыйть сүзенең иҗтимагый авторитетын санга сукмау була түгелме бу...

Тагын бер җыентык—болын чәчәкләреннән җыйган гүзәл бәйләмне хәтерләткән «Кызлар җыры». Андагы әсәрләр белән танышканда шагыйрәләребезнең хисләре сафлыгы һәм кайнарлыгына сокланмау мөмкин түгел, һәрхәлдә ир-егетләрне битараф калдырмый кызлар җыры.

Йөгерә-йөгерә судан кайткан чакта,
Чиләгемдә суым чайпалды.
Ай төште дә чумды чиләгемә—
Күңелем минем шуңа таң калды.
Ай бии дә бии сикереп-сикереп,
И шатлана, итә тантана!
«Синең белән бергә китәм,—дидер,—
Ташлый күрмә,—дидер,—ятларга!»
Ә мин аңа бер сүз әйтәлмәдем...
Баскан җирем куйды чайкалып.
Китеп булса икән туган яктан
Чемоданга тулган ай салып!..
Әй, түгелде суым! Ай күмелде...
Күңелләрем ярсып айкалды!
Тугрылык һәм хыянәткә шаһит,
Сарыларга сабышып ай калды.
Ятка калды... Судан кайткан чакта
Чиләкләрем шуңа чайпалды...

(Нурия Измайлова. «Авылда соңгы кич»)

Сүзләрдән түгел, шагыйрәнең күңел түреннән чыккан хисләрдән төзелгән юллар. Шуңадыр ул шигырьне әйтерсең лә күзләр түгел, күңел үзе укый.

Ләкин әлегедәй матур тойгылар уяткан җыентыкта да укучыны сагаерга мәҗбүр итәрлек урыннар бар. Мәсәлән:

Тәрәзәмнән каерып давыл керде,
Дер селкетеп тынган күңелне.
Йокы баскан күзне чагылдырып,
Яшен утте телеп күгемне.

Тәрәзәмне каерып давыл керде,
Давыл аңлый минем җанымны.
Тәрәзәмне барып ябып куйдың,
Тик туктатып кара давылны.

[Халисә Мөдәррисова. 118—119 битләр]

Өермәләр керде тәрәзәмнән,
Дер селкетеп тынган күңелне.
Давыл булып кердең йөрәгемә,
Яшен булып телдең күгемне.

Мәхәббәтем өчен яна идем,
Бар җылысын биреп җанымның...
Тәрәзәмне шунда ябып куйдың,
Тик туктатып кара давылны.

[Илсөяр Ганиева. 53 бит]

Күңелем арчып шулай җырлар эзлим
Чишмәләрнең телен чишәрлек.
Чылтырап аккан чишмә суы чыксын—
Сусаганда халкым эчәрлек.

[Илсөяр Ганиева, 64 бит]

Я табармын шундый татлы чишмә:
Йотылып-йотылып һәркем эчәрлек.
Я табармын шундый серле бер җыр:
Чишмәләрнең телен чишәрлек.

[Лена Шакирҗанова. «Чишмә эзләп», «Казан утлары», 1974, № 3.]

Ә мин әле җирдә бер нарасый:
Иреннән бал, күздән нур тама...
Еласам да, тормыш,
Елама дип,
Алсу алма биреп алдама.

[Рәшит Әхмәтҗанов, «Ак канатлар» җыентыгы, 1972]

Тормыш, синнән кайчак гөлләр тама,
Алларыма кайчак ал тама...
Яздырма тик әче хакыйкатьтән —
Алсу алма биреп алдама.

[Илсөяр Ганиева, 41 бит]

Шагыйрьләрнең күңел дулкыннары бер юнәлештә хәрәкәт итүе, ике шәхеснең үзара охшаш уй һәм кичерешләргә бирелүе бик мөмкин. Дөньяда бер үк вакытта үзара бер-берен белешми, бер үк проблема өстендә эшләп, бер үк характердагы ачышлар ясау очраклары да бар. Әмма шигърият, бу очракта татар шигърияте, шушы көнгәчә мондый охшаш һәм тәңгәл мисалларны белмәгәндер. Боларны очраклы тәңгәллекләр дип кенә аңлыйсы килә дә, тик башны тилегә салу гына булмасмы бу!.. Ничек кенә акларга, ничек кенә акланырга маташсак та, яшерен-батырын түгел, сәбәп бер—«шигырь ясау» галәмәте болар, иҗат җимешләре түгел. Кулга кәгазь һәм ручка алып өстәл артына утыргач кына ясалган шигырьләр, күңелдә, җанында туып бөреләнеп чыккан ихлас хисләр түгел. Кеше күңеле, минем белүемчә, бер-берен сүзгә-сүз кабатларлык дәрәҗәдә бертөрле һәм ярлы түгел. Ә шагыйрьләр турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Бит болар барысы да поэзиябезнең киң җәмәгатьчелек алдындагы авторитетына, шигъри сүзнең җегәре мәсьәләсенә суктыра!..

Шигъри фикерләүдәге шаблон һәм стереотипларның ишәя баруы да уйлануларга чакыра.

Шарлавыктай агып тора
Синең кырык толымың.

[З. Мансуров]

Чәчләреңнең шарлавыгын
Аралыйдыр башка куллар.

[М. Галиев]

Кошын очырган оя кебек
учымда нәүмиз салкының кала...

[М. Галиев]

Егет учында—кыз кулы,
Кош кебек оядагы.

[Ф. Яруллин]

Тәлгәшләнеп төшә беренче кар.

[З. Мансуров]

Куакларда тәлгәш-тәлгәш карлар.

[М. Галиев]

Кайнап-кайнап чирәм чыккан.

[З. Мансуров]

Төртеп чыккан яшь бер үлән
Кара карны кайнатып.

[Р. Миңнуллин]

Тартыш атны тарткан күк тезгенне—
Туп хәтле бер малай.

[Р. Фәйзуллин]

Туп кадәрле генә малай
Ат тышаулый яланда.

[З. Мансуров]

Бүгенге поэзиябезне күздән кичергәндә шул характердагы кабатланулар белән байтак кына шигырьләрдә очрашырга туры килә. Монда аерым бер исемнәрнең еш кабатлануы, әлеге тенденциянең бары тик алар иҗатына гына хас булуы турында сөйләми. Шигъри сүзнең кыйммәтен төшергән (инфляцияләгән) мондый охшашлыкларны һәм бәлки тагы да гыйбрәтлерәк мисалларны, үз алдыңа максат куеп махсус эзләнгәндә, байтак кына табарга мөмкиндер—эш анда түгел, аны мәйданга чыгарган сәбәпләрдә. Кайбер яшь шагыйрьләр әдәбиятка тормыштан бигрәк, әдәбиятның үзеннән килләләр кебек. Үз тормыш тәҗрибәләрен, кичереш һәм хисләрен үзенчә итеп тасвирлап (иҗат итеп) газапланмый гына, яңа гына укылган әдәби әсәрләрдән (бу татар әдәбияты белән генә дә чикләнми) илһамланып, рухи ләззәт алып, шулар тәэсире астында шигырь язып куялар. Нәтиҗә төрлечә булырга мөмкин, ләкин барыбер ярымфабрикатлар белән эш иткәндәй мондый «иҗат»ны уңай бәяләү мөмкин түгел. Шигъри деталь күпме генә уңышлы булмасын, кулдан-кулга киткәч аның кадере бетә. Ирексездән, мич артындагы җылыга елышып бер үк җырны такмаклаган чикерткәләр искә төшә. Ә укучы бит һәр автордан үз сүзен, үз җырын көтә.

Әдәбият һичкайчан үзмаксат булып тормаган, элек-электән көрәшкә әйдәгән, чор сулышының бөтен кайнарлыгын, җиңелмәс оптимизмын һәм моң-зарын үзендә чагылдыра килгән. Бүген дә заман укучысы һәр әсәрдән үзенең кичерешләре, омтылышларына аваздашлык эзли. Аерым очракларда проза һәм сәхнә әдәбиятында мавыктыргыч сюжет һәм гадәти булмаган вакыйгалар, интригалар белән укучыны беркадәр «алдарга», кызыксындырырга җай булса да, шигырьдә бу мөмкин түгел. Шигъри сүздә аз гына ясалмалылык яисә фальшь сизелә икән, таләпчән укучы аңардан шунда ук йөз чөерә, аны канатлы сүзләр һәм югары пафос белән генә, үтә акыллы кыяфәтле конструкцияләр белән генә «алдау» мөмкин түгел.

Сүз дә юк, соңгы елларда шагыйрьләребезнең профессиональ осталыклары, шигъри сүзгә таләпчәнлекләре күзгә күренеп үсә, арта бара. Бу актив рәвештә иҗат иткән һәр буын шагыйрьләргә дә хас уртак сыйфат, уртак тенденция. Ә инде әдәби процесстагы шундый хәрәкәт шартларында формалашып, үсеп килгән яшьләрдә ул аермачык күзгә ташлана. Зөлфәт һәм Мөдәррис Әгъләмов иҗатлары шуның иң матур үрнәкләрен тәшкил итә. Алар поэзиябездә нинди дә булса «переворот» ясарга дәгъва итми генә, шигъри сүзнең җегәре артыннан омтылып бер чиктән икенче чиккә ташланмый гына, гасырлар буе чарланып камилләшә килгән традицияләргә ихтирамлы булган тәкъдирдә, сыйфат ягыннан яңаны тудырган шагыйрьләр. Һәрхәлдә шуңарга сәләтле шагыйрьләр. Боларга «Елның бишенче фасылы» җыентыгы белән Эдуард Мостафин да якын тора сыман. Ләкин алмагачның яхшысына корт төшүчән булган кебек, бу өч авторның башка яшьтәшләренә караганда да җиңелрәк профессиональләшеп китү ихтималы да бар.

Ашыгыгыз, болыннарда
Чәчәкләрне коткарырга—
Чалгы чыңлый.
Ашыгыгыз коткарырга,
Ике йөрәк ялгыш юлда—
Сөю соңлый.—

[Э. Мостафин]

—кебек эчке байлыгы, потенциаль мөмкинлекләре чикләнгән, бер селтәнүдә ясап куелган гадәти шигырьләрнең аларда да сирәк булса да күренгәләп торуы сагаерга

мәҗбүр итә. Шунда ук кайбер шигырьләрдәге күтәренке рухның, ярсуның, сүзләрдә яну-көюнең тышкы сыйфат билгесе булып калуы, кешелекле хисләр, күңелгә сеңеп калырдай гомумиләштерүләр белән ныгытылмавы җитди уйлануларга нигез булып тора. Андый шигырьләрне укучы зур өмет белән укый башлый, мавыгып укый, чөнки шигъри форма камиллеге күпне вәгъдә итә. Әмма күңел көткән, өмет ителгән табылмый, аллы-гөлле бизәкле сабын куыгыдай буш шигырь тиз арада юкка чыга. Күз явын алып торган тышкы купшылык белән генә, талант һәм профессиональ осталык белән генә канәгатьләндереп булмый укучыны. «Шигырь тормышның эченнән кайнап туса, шагыйрьнең активлыгы, гражданлыгы белән бергә туса, профессиональ осталыкка сокланасың, ул күркәм, ул табигый, тормыш чынлыгы матур итә аны...» (Сибгат Хәким).

Беренче укыганда алай игътибарны артык җәлеп тә итмәгән, әмма укыган саен күңел һәм рухыңны акрынлап яулый барган шагыйрьләр дә бар. Гадәттә алар җәмәгатьчелек күзенә ташланып тормыйлар, тәнкыйть игътибарыннан да читтәрәк кала бирәләр. Чөнки үзләре дә, иҗатлары да мин монда дип кычкырып тормый, шулай да алар белән очрашу һичкайчан ялыктырмый да, сабыр холыклы зирәк авыл картларыдай алар күңелгә рәхәт бер җиңеллек, җылы өстәп торалар (Хисам Камалов, Рәшит Гәрәй, Гәрәй Рәхим, Фәнис Яруллин).

**Егет учында—кыз кулы,**
**Кош кебек оядагы:**
**Я кинәт сискәнеп куя,**
**Я тынып кала тагы.**
**Талпына кошның җаны.**

**Бер кайнарланып китә ул,**
**Бер салкынаеп ала:**
**Кыз бала үзенең язмышын**
**Егет учына сала,**
**Уйларга кала-кала.**

**(Фәнис Яруллин. «Җәйге төн...»)**

Бары да табигый, бары да тормыштагыча, шигырь һичнинди каршылыксыз кабул ителә. Җиңел кабул ителә, ләкин тиз генә онытылмый. Гадәттән тыш чагыштыру һәм сокланулар юк, ә күз алдында гүзәл картина туа. Димәк шигырь—сүзләр белән үтә акыллы трюклар ясауда гына түгел, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән чагыштыруларда гына да түгел, ә гадәтилек һәм гадилекнең үзе белән янәшәдә генә икән. Әлеге шагыйрьләрнең иҗаты моңа ачык дәлил булып тора.

Әлбәттә, бу поэзиябездәге стиль төрлелекләрен кире кагу яисә кабул итмәү булып аңлашылмас. Поэзиябезнең олылыгы да шул бер-берен кабатламаган, бер-беренә бөтенләй охшамаган стильләрнең күплеге белән билгеләнәдер. Шигъри сүзнең җегәре төшенчәсен дә без стиль төрлелекләреннән чыгып аңлату ягында. Үзенең уй һәм хисләрен укучыга җиткерүдә һәр шагыйрь бер үк тел байлыгы булган сүзләрдән файдаланса да, алар бер үк сүзләргә төрле мәгънә төсмерләре бирә, кулыннан килгәнчә, аларны үз акылы һәм хисләренә буйсындыра, үз стиленә хас җөмләләр, ритмик буыннар төзи. Конкрет сүзләрнең теге яисә бу шагыйрь иҗатындагы үзенчәлекле кулланылышы, төрле авторларның бер үк сүзләргә төрле мәгънә төсмерләре өстәве һәм шигъри сүзнең җегәрлегенә төрле чаралар белән ирешүләре, уйлавымча, шулай ук кызыклы һәм әһәмиятле мәсьәлә. Әмма ул җентекле анализлар һәм махсус өйрәнүләрне сорый. Бу мәкаләдә исә без шигъри сүзнең җегәре хакында, аны саклау һәм арттыра бару хакында, барыннан да элек, шагыйрьләрнең әдәби иҗатка мөнәсәбәтләре һәм иҗат процессындагы җаваплылыкны аңлаудан чыгып кына сүз йөрттек. Һәм ул әдәбиятыбыз, шигъриятебезнең престижы, иҗтимагый тормышыбыздагы урыны турында алга таба уйланулар өчен билгеле бер күләмдә нигез бирә кебек.

**Шәмси Хамматов,**

доцент, тарих фәннәре кандидаты

# ИДЕЛ БӨРКЕТЕ, ИЛ БӨРКЕТЕ

*(МУСА ҖӘЛИЛ КУРСК ҖИРЕНДӘ)*

**Җирдә кеше торса торсын,**
**Эзе калсын тирән булып.**
**Үзе үлсә, эше калсын**
**Мең яшәрлек имән булып.**
**Муса Җәлил**

Ниһаять, мин Курск җирендә. Күптән инде Муса Җәлилнең Курск өлкәсеннән, Бөек Ватан сугышы барган фронт бусагасыннан язган хатлары, шигырьләре Марьино поселогында политик работниклар курсында укып политик-хәрби чыныгу алуы сәяхәткә чакырып тора иде. Муса Җәлилнең дәһшәтле көннәрдә Казанга, дусты Гази Кашшафка язган хатында: «Әле хәзергә фронт тирәсенең авыр шартларында, тылда яшәгәндә, мин үземне алдагы сугышлар өчен чыныктырам», — дигән сүзләре бу кызыксынуны тагын да куәтли иде.

Муса Җәлил—халкыбызның горурлыгы. Аның турында төрле телләрдә күп язылган. Аның тормышы, иҗаты, батырлыгы—әдипләр, публицистлар, журналистлар өчен илһам чыганагы. Шәйхи Маннур бик дөрес әйтә: «Муса Җәлил... язучылар өчен илһам чыганагы булып торыр. Шулай булмый мөмкин дә түгел, чөнки Мусаны нинди дер томанлы ераклыкка киткән, юлларына яшел чирәм үскән тарихи шәхес итеп кенә күзаллап булмый. Ул һаман мәңгелек көлемсерәп, җырлары белән янып-дулкынланып, зур омтылышларга өндәп каршыбызда басып тора...» [1]

«Социалистик Татарстан» газетасында «Шагыйрь чыныгу ала»[2] исемле сәяхәтнамә басылгач, бу юллар авторына теләктәшлек белдереп, тәкъдимнәр әйтеп газета укучылардан, әдипләрдән, әдәбият белгечләреннән, журналистлардан, партия работникларыннан хатлар килде, очрашып сөйләшүләр булды.

Менә бер хат. Аны Чистай сәгать заводы технологы Вазыйх Шәрипов яза. «Муса Җәлил турындагы мәкаләне без дулкынланып укыдык. Аннары «Социалистик Татарстан» газетасының әлеге номерын заводка, үзебезнең цехка алып бардым. Язма белән хезмәттәшләрем дә кызыксындылар. Шулай да, безнең фикеребезчә, бу мә-

---

[1] «Социалистик Татарстан», 13 февраль, 1966 ел.
[2] Шунда ук, 28 август, 1979 ел.

калә шагыйрьнең Бөек Ватан сугышы чорында фронтка кергәнче тормышын, бигрәк тә ул йөргән эзләрдән үтеп иҗатын яктыртуда башлангыч адым гына. Автор аны тагын да киңәйтебрәк, тулыландырыбрак язса, без, укучылар, канәгать булыр идек. М. Җәлилнең кордашлары, аны күрүчеләр, белүчеләр исән чакта бу эшләнсә, бигрәк тә әйбәт булыр иде».

Дөрес, М. Җәлилнең сугыш чорындагы тормышы һәм иҗаты бездә шактый өйрәнелгән. «Хәзерге вакытта Җәлил иҗатын өйрәнүчеләр,—дип яза әдәбият белгече Азат Әхмәдуллин,—язучының Бөек Ватан сугышы елларындагы тормышын һәм иҗатын җентекләп өйрәнүгә зур тырышлык куялар. Һәм бу закончалыклы» [1].

Бу изге эшне Муса Җәлилнең иң якын, ышанычлы дусты, тәнкыйтьче, әдәбият белгече, публицист Гази Кашшаф башлап җибәрде. Ул М. Җәлилнең әдәби варисы иде. Хәтеремдә, «Совет Татарстаны» (хәзерге «Социалистик Татарстан») газетасының 30 апрель, 1953 ел санында «Ялкынлы патриот шагыйрь Муса Җәлил» дигән баш белән Моабит дәфтәреннән «Кичер, илем!», «Җырларым», «Ышанма», «Корыч», «Яңа ел теләкләре», «Хөкем алдыннан», «Кошчык» исемле шигырьләре беренче тапкыр дөнья күрде. Газетаның шул ук санында Гази Кашшафның «Корыч ихтыярлы шагыйрь» (Муса Җәлилнең соңгы шигырьләре турында) исемендә күләмле мәкаләсе басылды. «...Гомере кыл өстендә калганда да, коммунист шагыйрь, совет көрәшчесе үзенең кешелек горурлыгын, рухи ныклыгын, ихтыяри көчен батырларча саклаган һәм, үлемгә нәфрәт белдереп, үзенең иҗат эшен дәвам иттергән» [2],—дип рухланып язды Г. Кашшаф.

Ул көннәрдән бирле байтак вакыт узды. Җәлил хакындагы фән тулыланганнан тулылана барды. Әмма шулай да бөек шагыйрь тормышының барлык чорлары да бердәй тулылыкта өйрәнелгән дип әйтергә, мөгаен, иртәрәктер. Курск җиренә сәяхәтем мине шул фикергә китерде. Бу юлъязмада М. Җәлилнең сугышның беренче авыр айларындагы хәлен, иҗатын, аеруча солдат-шагыйрь тормышының Марьино чорын тулырак итеп чагылдырырга омтылыш ясала.

*

* *

Коммунистлар партиясе Бөек Ватан сугышы көннәрендә Совет Армиясен политик тәрбияләүгә зур игътибар бирде. Армиянең җитәкче составын марксизм-ленинизм идеяләре рухында чыныктыру өчен политработниклар әзерләү курслары оештырылды.

1941 елның июль аенда Муса Җәлил армиягә алына. Башта ул Казандагы хәрби лагерьда тора, артиллерия полкында рядовой солдат булып хезмәт итә башлый. Ул авырлыклардан курыкмый, хәрби белемнәрне тырышып өйрәнә, артиллерист-тупчы һөнәрен бик тиз үзләштерә. «Тупчы анты» шигыре армиядә хезмәт итү нәтиҗәсе буларак язылган дип расларга мөмкин. Аннары Муса Җәлил политработниклар әзерли торган алты айлык курска тәкъдим ителә.

Бу турыда ул вакытта аның белән бергә хезмәт иткән артиллерия полкы пропагандисты, соңыннан озак еллар «Татарстан коммунисты» журналында җаваплы секретарь булып эшләгән, СССР журналистлар союзы члены Г. Беляев үзенең истәлекләрендә болай дип яза: «Мин полк командирына һәм комиссарына Мусаның кем икәнлеген, аның татар әдәбиятында нинди урын тотуын сөйләп бирдем. Шуннан соң без Муса Җәлилне демобилизацияләү турында мәсьәлә күтәрмәкче булдык... Ләкин Муса моңа үзе каршы килде: «Минем урыным—армиядә, сугышчылар арасында. Минем бурыч—фронтта булу, фашистларны кыйнау»,—диде ул. Күп тә үтмәде, безнең полкка яхшы хәзерлекле һәм тормыш тәҗрибәсе булган ике рядовой коммунистны политруклар курсына җибәрергә кәгазь килде. Муса Җәлил бу курсларга барырга бик теләп риза булды...» [3].

---

[1] Муса Җәлил. Материалы Всесоюзной научной конференции, посвященной 70-летию со дня рождения поэта-героя. Казан, 1978, 105 бит.
[2] «Совет Татарстаны», 30 апрель, 1953 ел.
[3] «Социалистик Татарстан», 13 февраль, 1966 ел.



*Муса Җәлил курсларда укыган Марьино сарае.*

Политработниклар әзерләү мәктәбе Курск өлкәсе, Рыльск районы Марьино сараенда урнашкан була.

Без Муса Җәлилнең Курск өлкәсенең Марьинода оешкан политработниклар курсында укуын тәгәлрәк ачыклау өчен СССР Оборона Министрлыгының Үзәк архивына мөрәҗәгать иттек. Аннан 1979 ел, 12 сентябрендә язылган хат-документ алынды. Ул документта мондый юллар бар: «Партия комитетларының җитәкче работникларын хәрби әзерләү һәм яңадан әзерләү курсларының 1941 ел, 5 августтагы 231 номерлы приказында.

«Урта политсостав әзерләү курсларына килүчеләрне 1941 елның 19 июленнән курслар исемлегенә курсантлар итеп теркәргә һәм барлык төр нәрсә белән тәэмин итәргә...

798. Залилов Муса Мустафович»[1] диелгән.

Димәк, Муса Җәлил Марьинодагы урта политсостав әзерләү курсларында уку өчен 1941 елның 19 июленнән теркәлгән булган. Күрәсең, Казанда торган артиллерия полкы җитәкчелегенең тәкъдиме кабул ителгән. һәм М. Җәлилнең 1941 елның 17 июлендә Казандагы хәрби лагерьдан Әминә Җәлиловага язган хатында чагылыш тапкан, «...югары белемле, партия стажы зур, партия-комсомол җитәкчелеге эшендә зур тәҗрибә тупланган... ВЛКСМ Үзәк Комитетының элекке работнигы, хәзер дә җаваплы партработник, депутат буларак»[2] политсоставка күчәргә омтылу теләге үтәлгән. Шу-

[1] СССР Оборона Министрлыгының Үзәк архивы, 316159 тасвирламасы, 4 эш, 214 бит (күчермә).
[2] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда. 3 т. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1976, 545 бит.




*Марьино сараенда М. Җәлилгә мемориаль такта.*

лай итеп, М. Җәлил 1941 ел июленең икенче яртысында политик работниклар курсына укырга җибәрелгән.

Марьино. Бу мәһабәт сарай һәм парк ансамбле Россия тарихында күптән билгеле. Аны XIX йөз башында Курск җирендә, табигатьнең бик күркәм урынында ун меңләгән крепостной крестьян кулы белән төзиләр. Бу сарай бакча ансамблен Россиядә иң бай кешеләрнең берсе князь И. И. Барятинский салдыра. Аны үз хатыны хөрмәтенә «Марьино» дип атый. Аның кулында Курск губернасының 35 мең крепостное, 100 мең дисәтинә җире була.

Марьино сарай-паркы архитектор К. И. Гофман җитәкчелегендә 1815—1816 елларда төзелеп бетә. Бу поселок тирәсендә яшәгән картлар үз бабаларының сарай-парк янына төрле-төрле агачлар утыртуларын, буалар, ясалма күлләр барлыкка китерүләрен, каналлар казуларын, һәйкәлләр, күперләр, юллар салуларын, тирә-яктан кошлар, җәнлекләр аулап, аларны урманнарга җибәрүләрен сөйлиләр. Крепостной крестьян хатыннары байларның эт балаларын имезеп үстергәннәр. Князь токымнарының, патша ялчыларының әнә шулай күңел ачуларын ачынып искә алалар.

Сарай-йортның эче гаҗәеп матур бизәкләр белән тулы, аның түгәрәк биек залы, хрусталь люстралары, кунак бүлмәләре үзенә генә хас стиль белән аерылып тора.

Октябрь революциясеннән соң сарай-парк тарих һәм культура һәйкәле итеп саклана. 160 елдан артык элек төзелгән сарай-бакча ансамбле Марьино әле дә безне сокландыра.

Менә шушы сарай-паркта Бөек Ватан сугышы алдыннан В. И. Ленин исемендәге ял йорты, Кызыл Армиянең пропагандистлар әзерләү училищесы була, ә сугыш башлангач биредә политработниклар курслары ачыла. Анда хәзер «Марьино» санаторие эшли, хезмәт иялəре ял итә.

Мәһабәт сарайның парад-фасадында мемориаль такта:

**«Бу йортта 1941 елның көзендә политик работниклар курсларында татар халкының патриот шагыйре, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил укыды».**

Бу юлларны дулкынланып, горурланып укыйсың. Истәлек тактасы безне—совет кешеләрен, халкыбызны, тынычлык өчен көрәшүчеләрне авыр сынау елларын онытмаска чакыра. Ул—М. Җәлилнең үлемсезлеге билгесе.

Шул чак мин бу үлемсезлекнең сәбәпләре турында уйланып йөрдем. Хәтеремә 1966 елның февраль-март айларында шагыйрьнең 60 еллыгын бөтен ил күләмендә бәйрәм иткән көннәр, ул вакытларда сөйләнгән һәм язылган сүзләр килде.

...Казан. Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры. Анда зур тантана. Олы тантанага М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре» шигырьләре кулъязмасын коткарып калган Бельгия гражданины Андре Тиммерманс, шагыйрьнең туганнары, әдипләр, дуслары,

кордашлары, җәмәгатьчелек вәкилләре килгән. Җыелышта чыгыш ясаучы Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе М. Әмир, РСФСР культура министры Н. А. Кузнецов, РСФСР Язучылар союзы секретаре, шагыйрь В. Д. Федоров, Башкортстан халык шагыйре Мостай Кәрим, казакъ шагыйре Жубан Молдагалиев, чуваш халык шагыйре Педер Хузангай, балкар шагыйре Кайсын Кулиев, шагыйрь Сибгат Хәким, М. Җәлилнең рабфакта бергә укыган иптәше З. И. Муратов һәм башкалар шагыйрьнең поэтик һәм гражданлык батырлыгына сокклануларын, аның иҗатының интернациональ рухта булуын калку итеп күрсәттеләр.

Республика вакытлы матбугатында юбилей уңае белән бирелгән махсус саннар, сәхифәләрнең берсендә «Коммунист шагыйрьнең үлемсез батырлыгы» дигән мәкаләдәге юллар да хәтергә килде: «Кабатланмас гражданлык һәм поэтик батырлыкның нәкъ менә Җәлил өлешенә туры килүендә тирән закончалык бар. Бу батырлыкка ул үзенең бөтен биографиясе һәм иҗади үсеше белән әзерләнде. Аның биографиясе — үз тормышының һәр көнен, һәр сәгатен Совет власте өчен, партия интереслары өчен, коммунизмның җиңүе өчен көрәш эшенә биргән сугышчы һәм гражданин, ялкынлы җәмәгать эшлеклесе биографиясе ул.»[1] Менә кайда шагыйрьнең үлемсезлеге сәбәпләре.

М. Җәлилгә Марьинода мемориаль такта кую тарихы түбәндәгечә булган. Октябрь социалистик революциясенең 50 еллык юбилее уңаеннан мемориаль тактаны сарай фасадына 1967 елның 15 июлендә Бөтенсоюз «Родина» моторалливендә катнашкан Татарстан АССР командасы кадаклый, һәм анда митинг үткәрелә. Якташлары санаторий китапханәсенә М. Җәлилнең 1962 елда Казанда басылган җыентыгын түбәндәге автограф белән бүләк итәләр: «Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты М. Җәлилнең мемориаль тактасы ачылу истәлеге итеп. 15.06.67».

«Марьино» санаториендә китапханә мөдире булып эшләүче Валентина Кировна Тарасевич-Панфилова политработниклар курсларында укыган Муса Җәлилне яхшы хәтерли. Фашистлар Курск җиренә бәреп кергәч, курсантлар белән бергә Минзәләгә күчеп килүләре турында сөйли. Ул М. Җәлил белән бергә укыган кешеләрне исенә төшерә. Курста төрле милләт вәкилләре, шул исәптән татарлар да укый. Сарай паркының ясалма күле артына, урманлыкта палаткалар корыла, курсантлар көн буе шунда—лагерьда булалар, аларның тактик занятиеләре шунда үтә. Китапханәче курсантларга газета-журналлар, хатлар илтеп тора.

Курсантлар ике еллык хәрби училище программасын бик аз вакытта — биш-алты айда үтәргә, марксизм-ленинизм идеяләрен ныклап өйрәнергә, политик, физик яктан үзләрен чыныктырырга, сугыш алып бару сәнгатенә өйрәнергә тиеш булалар. Һәм Муса Җәлил куелган бурычны намус белән үти: хәрби һәм политик белемнәрне тырышып үзләштерә, шагыйрь үзе язганча, «бөтен предметны «отлично»га биреп, алдынгы булып»[2] чыга. Шагыйрь-коммунист партия, җәмәгать эшендә актив катнаша, курсантлар белән политик темаларга әңгәмәләр үткәрә, стена газетасын чыгара, аңа мәкаләләр, шигырьләр яза, гитлерчыларга карата нәфрәт тәрбияләшә, изге көрәшкә өнди. Ул курсантлар өчен оештырылган танцаларга да йөрергә вакыт таба, китапханәдән китаплар да алып укый[3].

1941 елның 14 декабрендә ротаның партбюро секретаре тарафыннан Муса Җәлилгә бирелгән партия характеристикасында болай дип язылган: «Ипт. Җәлилев М. М. урта политсостав курсларында үзен бары тик яхшы яктан гына күрсәтте, уку алдынгысы булды. Ипт. Җәлилев партия-масса эшендә актив катнашты, ротаның партия бюросына сайланды, стена матбугаты редакторы булды, эшне яхшы башкарды, партия заданиеләрен төгәл үтәде...»[4].

---

[1] «Социалистик Татарстан», 15 февраль, 1966 ел.
[2] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда. 3 том. 552 бит.
[3] «Марьино» санаториесе китапханәсендә М. Җәлил әсәрләре аз булуны исәпкә алып, «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе анда шагыйрь әсәрләрен һәм аның турындагы китапларны җибәрде. Хәзер китапханәдә М. Җәлил тормышына һәм әдәби эшчәнлегенә багышланган стенд бар.
[4] «Совет әдәбияты», 4 сан, апрель, 1962 ел, 149 бит. А. Җәләлов. «Муса Җәлил биографиясенә караган яңа документлар».

Китапханәче Валентина Кировна Муса Җәлилнең кешеләргә гаять игътибарлы, тактлы булуына аеруча басым ясый. Курслар Марьинодан Курск өлкәсенең Щигры шәһәренә күчеп, Бөгелмә аркылы Минзәләгә эвакуацияләнгән дәвердә (ул күчеңү бер ай чамасына сузыла) М. Җәлил алар белән бергә булган, хәрби булмаган гражданнар семьяларына, аларның балаларына ярдәм иткән, азык-төлек табарга булышкан. Юлда хәрби мәктәп үз эшен дәвам иттергән, курсантлар сугыш коралларын өйрәнгәннәр, зачетлар тапшырганнар, аттестациягә әзерләнгәннәр.

Муса Җәлил дусты Г. Кашшафка язган хатында: без укуны чын практика белән бергә кушып алып барабыз, сугышны инде күреп, хис итеп торабыз, һәрвакыт фронтның алгы позициясенә басарга әзербез, дип хәбәр итә. «...Мин бервакытта да армиядә булмавыма һәм тәҗрибәм юклыкка карамастан, хәрби белемне тырышып үзләштерәм һәм сугышчан бурычларны начар башкармыйм», [1] — дип яза ул. М. Җәлил, чыннан да, биредә беренче хәрби чыныгу мәктәбе үтә, үзен алдагы сугышлар өчен чыныктыра.

Курсларда укыганда Муса Җәлилнең иҗат активлыгы көчәя. Сугыш шартлары яңа фикерләр уята, аның шигырьләрендә хәрби-патриотик ялкын көчәя. Аның белән Марьинода укыган курсант Б. Х. Зязиков үзенең истәлегендә болай ди: «Кыска вакытлы ялга туктаганда, мин күбесенчә ялгыз уйланырга ярата торган Муса Җәлилне бер кырыйда үзе генә утырганын күрдем. Аның иреннәре кыймылдый һәм карандаш кисәге белән дәфтәргә нидер яза иде. Мин аның нәрсә эшләве белән кызыксындым. Муса бернечә минут эндәшми торды, аннан соң мәктәп дәфтәрен җәеп салды да шигырьләрен күрсәтте. Шул чакта гына мин аның шагыйрь икәнен белдем. Кич белән мәктәпкә кайткач, Муса үзенең русчага тәрҗемә ителгән шигырьләрен миңа бирде. Шул вакыттан алып минем Мусага булган ихтирамым тагы да үсте. Без бит фронт тормышы кебек үк каты шартларда яши идек.

Тактик занятиеләр вакытында привалларда яки буш минут табылган вакытта, Муса миңа үзенең шигырьләрен татар телендә укый иде. Ул сугыш турында фашистларга нәфрәт белән язды, ерактагы Татарстан һәм Бөек Ватан сугышының беренче геройлары турында язды. Халык белән бергә, аның кайгысы белән яшәгәнлеге, аның белән бергә сулаганлыгы ул шигырьләрдән бик нык сизелеп тора иде. Сугышчы һәм шагыйрьнең дошманга нәфрәте бик көчле иде.

Муса еш кына Татарстанны, әдәби хезмәтне һәм семьясын искә ала иде. Бервакыт ул миңа бик нык дулкынланып «Кызым Чулпанга» исемле шигырен укыды» [2].

Марьинода курсларда укыган көннәрдә М. Җәлилнең вакыты бик аз булса да, ул дистәләп шигырь яза. Әсәрләренең күбесен 1941 елның икенче яртысында «Кызыл Татарстан» газетасында һәм «Совет әдәбияты» журналында бастыра. Хатларының берсендә ул: «Мин моннан, һичшиксез, октябрьга кадәр ун (ким түгел) шигырь һәм җырлар җибәрәчәкмен» [3] дип хәбәр итә. Соңга табарак, 1941 елның 6 декабрендә, Г. Кашшафка язган хатында ул шигырьләрнең исемнәрен дә атый. Менә алар: «Әминәгә», «Чулпанга», Г. Кашшафка багышланган «Окоптан хат», «Әмирхановка истәлек» шигырьләре, «Госпитальдән», «Каска» һәм башка әсәрләр.

Фронт Курск өлкәсенә якынлаша, фашистлар август ахырына аның территориясенә бәреп керәләр. Сентябрь башларында дошман Курск өлкәсе шәһәрләренә бомбалар ташлый: Муса Җәлилләр укыган Марьино сарае фронт янындагы төбәккә әверелә. М. Җәлил дусты Г. Кашшафка язган хатында фронт яны хәлләрен болай тасвирлый:

«Аерым шартлар килеп чыкканлыктан, без хәзер икенче пунктка күчтек. Без хәзер Щигры шәһәрендә, Курск өлкәсендә... Без монда бик начар шартларда күчтек, көне буе яңгыр коеп торды. Һәркайсыбызда 40 килограммга кадәр йөк бар иде. Билгеле, шоссе юлыннан барырга туры килмәде. Шуңа күчү шактый авыр булды, ләкин безнең беребез дә артка калмады, арымады да...

Шигырьләр язарга вакытым юк. Безнең вакыт бик тыгыз. Шулай да язарга һәм

---

[1] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда. 3 том, 548 бит.
[2] Муса турындагы истәлекләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1964, 110 бит.
[3] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда. 3 т. 549 бит.

-ларны җибәрергә уйлыйм. Берничәсе башланган килеш тора. Темалар һәм материаллар күп»[1].

Соңрак язган икенче бер хатында М. Җәлил Марьинодан «киткәннән бирле бик авыр, бик мәшәкатьле, озын юл үттем. Тик бер генә ай тынычлап укырга мөмкин булды. Анда да немец самолетлары һаман өстә очып тордылар... Без шунда ук Марьинодан киттек. Аннан тагын бик күп юллар үттек, шәһәрләр алмаштырдык, фронт эпизодларын да күрдек»[2], ди.

Шәйхи Маннур «Муса» романында Курск җирендә булган ул көннәрне түбәндәгечә сурәтли: «Аларның курслары фронт дүрт-биш чакрым калгач кына урыныннан кузгалды. Инде сугышка керәбез дип әзерләнгәч кенә, бу якка кайтып, укуларны тәмам итәргә боерык булды.

Немец самолетларыннан яуган бомбалар астында күпме авылларның, күпме шәһәрләрнең сәгать эчендә җимерелеп, янып көл булуларын, күпме карт-коры, бала-чага, хатын-кызларның шул җимерекләр астында калуын, күпме мал-мөлкәтләр, ил хәзинәләре тәтенгә очуын һәм, гомумән, хәлләрнең никадәр авыр, никадәр хәтәр булуын Муса үз күзләре белән күреп кайтты».

Марьинодан эвакуацияләнгән политработниклар курсы Татарстанның Минзәлә шәһәрендә үз эшен дәвам итә. Ул курсларны 1941 ел ноябрь аенда тәмамлап чыгучыларга хәрби исемнәр бирелә. Оборона халык комиссарының 1941 ел, 30 ноябрьдәге № 04407 приказында болай язылган:

«ССР Союзының Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы 1935 елның 22 сентябрь карары белән расланган «РККАның команда һәм начальниклар составының хезмәт тәртибе турындагы положение» нигезендә запастагы урта политсостав (Марьино) курсларын тәмамлап чыгучыларга хәрби исемнәр бирергә:

**«Өлкән политрук»**

908. **Залилов Муса Мустафаевич»**[3]. Муса Җәлилнең исеме һәм атасының исеме приказда шулай дип язылган.

Муса Җәлил белән бергә Марьино курсларын 900 дән артык кеше тәмамлый. Менә ул курсларны тәмамлаган кайбер кешеләрнең исемлеге:

**Мингазов Фатих Мингазович**
**Юзефов Евсей Моисеевич**
**Галимов Хай Нуруллович**
**Хапсироков Амин Папович**
**Корчаев Хадис Абдуллаевич**
**Мурзаханов Роман Улханович**
**Байчаев Магомет Жашаевич**
**Гуреев Ашанмур Михайлович**
**Мыздриков Михаил Александрович**
**Фазлеев Ахмет Фазлеевич**
**Файзуллин Фалил Зайнуллович**
**Газизов Назыр Миннникаевич һәм башкалар.**

Приказда күрсәтелгән кайбер кешеләрнең фамилияләре, исеме һәм атасының исеме ялгыш язылуы ихтимал. «Казан утлары» журналын укучылардан бу кешеләрне белүчеләр турында булган мәгълүматларын язманың авторына яки редакциягә хәбәр итүләрен үтенәбез.

*
* *

Муса Җәлил Марьино чорында язган шигырьләрендә ватандашларын илебезне басып алырга дип, халкыбызны үтереп бетерергә дип килгән немец фашистларын тар-мар итәргә чакыра. Шигырьләрен өзелеп яраткан гаилә әгъзаларына—кызы Чулпанга, хатыны Әминәгә, шулай ук каләмдәш дусларына, хәрби хезмәттәшләренә ба-

---

[1] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда. 3 т. 547—548 битләр.
[2] Шунда ук, 551 бит.
[3] СССР Оборона Министрлыгының Үзәк архивы, 136477 тасвирламасы. 1 эш, 408 бит (күчермә).

гышласа да, аларда совет кешеләренә, туган илгә сүнмәс мәхәббәт, дошманга аяусыз нәфрәт ташып тора, җиңүгә ышаныч яңгырый.

Шунысы бар: аларның күбесе 1941 елның җәйге-көзге айларында (август-ноябрь) курсларда укыган чакта, лагерьдагы тәнәфес вакытларында, Марьинодан эвакуацияләнеп походта барган, Льгов—Щигры—Тамбов—Пенза—Ульяновск—Бөгелмә станцияләре аша Минзәләгә күчеп килгән борчулы юл газабы көннәрендә язылган.

1941 елның августында язылып, «Кызыл Татарстан» газетасында басылган «Әйдә, җырым!» шигырендә Муса Җәлил:

**Вакыт җитте...**
**хәзер ярты юлда**
**Куеп торып тыныч эшемне,**
**Багышларга Ватан сугышына**
**Үземне һәм каләм көчемне...**

—ди.

М. Җәлилне Казандагы дусты Г. Кашшафтан хат алуы аеруча дулкынландыра. Ул Курск җиреннән язган бер хатында болай ди: «Синең хатың беренче булып килде һәм мин бөтен йөрәгемнән игътибарың һәм чын дуслыгың өчен сиңа рәхмәт белдерәм. Мин һәрвакытта да синдә үземнең иң яхшы һәм сизгер дустымны күрдем һәм мине бервакытта да онытмавыңа тирәннән ышана идем. Синең хатың бик җылы язылган һәм мин анда үземнең сагынган йөрәгемә кирәкле нәрсәләрнең барысын да таптым. Рәхмәт, кадерле дус!» [1] М. Җәлил дусты Гази Кашшафка багышлап «Окоптан хат» исемле шигырен яза.

Шигырьләрендә дә, хатларында да М. Җәлилнең үзенең дә, лирик героеның да рухи ныклыгы калку гәүдәләнә. «Куркыныч хәлләргә очраган чакларда, мин үлем турында котым очып уйлап утыруымны белмим,—дип яза ул политработниклар курсын тәмамлаган көннәрдә. —Бөек патриотизм хисе, үзеңнең җәмгыять функцияңне тулысынча аңлау кешене шәхси курку хисләреннән өстен күтәрә... Дөньяда шундый итеп яшәргә кирәк, үлгәннән соң да үлмәслек булсын—яшәүнең бөтен максаты шунда түгелмени?

...Без тормышны бик яратабыз, яшәргә телибез, һәм шуңа күрә дә үлемгә җирәнеп карыйбыз. Әгәр дә синең үлемең кирәк икән (Ватан өчен сугышта), һәм Ватан өчен үзең теләп кабул иткән бу данлы үлем картлык көннәреңә кадәр булган утызкырык еллык тыныч хезмәттә үткән гомереңне каплый ала икән (ягъни әһәмияте белән аңа тиң икән), мин иртә һәлак булдым дип кайгырырга һичбер сәбәп юк.

Әгәр мөнә шулай уйласаң — мин шулай уйлыйм — үлем һич тә куркыныч түгел» [2].

Күрәсез, шагыйрь, үзе нинди генә авыр куркыныч хәлләрдә калса да, Ватан өчен халкыбыз дошманнары—фашистлар белән аяусыз көрәшкә әзер торуын белдерә. М. Җәлилнең фашистлар тоткынлыгындагы, Моабит төрмәсендәге батырлыгы, үлемсез иҗаты моңа шаһит. «Минем турыда сөйләячәкләр, язачаклар, ихтимал, рәсемнәремне дә басып чыгарырлар» [3], — дип язарга М. Җәлилнең хакы бар иде.

...Без Марьинода курсант-шагыйрь Муса Җәлил укыган аудиторияләрне, алар торган бүлмәләрне карыйбыз, ул йөргән парк аллеяларыннан үтәбез. Мин шагыйрь исән чагында аның үзен күрү бәхетенә ирешә алмадым. Әмма аның әсәрләрен яшьтән үк укып үстем, аның дусларын якыннан белеп яшим. Шуңа күрә аның образы күз алдында тора. Муса Җәлил бүген дә безнең арада, безнең белән бергә тормыш юлларыннан атлап бара кебек. Марьинода булганда мин еш кына күңелемнән Коммунистлар партиясенә, үз халкына тугрылыклы курсант-шагыйрь Муса Җәлил белән «сөйләшеп» йөрдем.

Әнә йөз еллар буе мәгърур торган мәһабәт имән агачлары. Алар арасыннан акрын җилдә яфраклар лепердәвенә кушылып шагыйрьнең илһамланып шигырь укуы ишетелә сыман.

---

[1] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда, 3 т. 547 бит.
[2] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда. 3 т. 555—556 битләр.
[3] Шунда ук, 556 бит.

**Мең ел элек кемдер монда**
**Җир казыган, тир тамызган.**
**Һәм беренче кат иманнең**
**Яшәү иртәсен кабызган.**

Төрле үсемлекләр, агачлар дөньясына бай серле бакча. Түгәрәк буа-күл ярында, ясалма биек таш кыяда бронзадан коеп утыртылган зур бөркет сыны. Аның янында кешеләр өзелми. Зур осталык белән эшләнгән бу бөркет сыны—Марьино усадьбасы хуҗасы князь Александр Барятинскийның Кавказдагы хәрби уңышлары символы. Бөркет куркуны белмәс тау баһадиры Шамилне хәтерләтә. Менә ул ярсый, көрәшкә ташланыр кебек. Әмма куәтле бөркетнең озын, көчле канатлары, үткен тырнаклары киселгән, үткен күзләре сүрелгән. Ул инде упкынга төшеп китәр дә, мәңгегә юкка чыгар кебек.

Шул чак Муса Җәлилнең фашист тоткынында, Моабит читлегендә йөрәгеннән әрнеп чыккан «Кичер, илем!» исемле шигырь юллары искә төшә.

Әмма Муса Җәлилнең мәңге үлмәс җыры Идел бөркете, ил бөркете булып Ватаныбызга әйләнеп кайтты. Ул шигырь юллары аша янә безнең күңел түребезгә уазы:

**Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә**
**Һәм үләргә кыю ир булып.**
**Гомрем минем моңлы бер җыр иде,**
**Үлемем дә яңрар җыр булып.**

*
* *

Муса Җәлил — чын коммунист, патриот шагыйрь, халыклар дуслыгы җырчысы. Халкыбызның олы җанлы, батыр улын, бөек гражданинын бөтен прогрессив кешелек зур ихтирам белән телгә ала. Курск якларында сугышның әле башланып киткән айларында политик хәрби чыныгу алган бөркет гитлерчылар төрмәсендә тоткында яшәгәндә дә баш имәде, ахыргы сулышына кадәр Ватаны, халкы бәхете хакына фашизмга шигъри хөкем карары язды. Шагыйрь фашистларга «каршы соңгы сүзне без әйтербез хөкем залында» дип чаң сукты.

**Килер ул көн, халык хөкем итәр,**
**Карар булыр кискен һәм кыска.**
**Каным белән язган соңгы җырым,**
**Бул гаепләү акты фашистка.**

Ул көн килде, прогрессив кешелек фашизмга инде күптән гаепләү акты, үлем хөкеме чыгарды.

Муса Җәлил эзләреннән йөрү тагын бер кат бездә патриотик тойгы уята, аның утлы еллардагы иҗаты йөрәкләребездә мәңге онытылмас хатирә булып саклана.

**МАРЬИНО—КУРСК—КАЗАН.**

**Миләүшә Маннурова,**
филология фәннәре кандидаты

# ГЕРОИК СИМФОНИЯГӘ ТИҢ ГОМЕР

Икенче бөтендөнья сугышы барышында көчле һәм явыз дошман итеге астында калган халыклар һәм илләр фашизмга каршылык күрсәтүне дәвам итәләр. Оккупацияләнгән илләрдә, дошман тылында Каршылык күрсәтү хәрәкәте, аның идеологиясе туа. Бу көрәштән язучылар да читтә калмый, билгеле. Аларны көрәшче итеп формалаштырган, идея бердәмлеген, фикер уртаклыгын тәрбияләгән бик мөһим факторлар бар: язучыларның әлеге буыны оккупация, төрмә, концлагерьларны күрә, дошман алдында баш ими, Каршылык күрсәтү хәрәкәтендә катнашучылар сафына баса. Үзләренең әсәрләре белән дә алар мәкерле дошманны фаш итә. Алай гына да түгел, кайберләре, Муса Җәлил кебек, яшерен оешмалар төзеп, гомуми эш өчен бөтен җаваплылыкны үз өстенә ала, бик күпләре Ватаны, халкы өчен гомерләрен корбан итә.

Бер үк чор, охшаш тарихи шартлар, уртак максат—болар барысы характерлы бер тип, көрәшче-шагыйрь тибын тудыра. Шуңа күрә Каршылык күрсәтү хәрәкәтенә катнашкан төрле ил язучыларының поэзиясе аваздаш була, аларның үзәк мотивлары тәңгәл килә, әсәрләре аһәңдәш яңгырый. Элемтәләр һәм бәйләнешләр турыдан-туры булмаса да, гомуми, охшаш идеяләр төрле илләргә тарала.

Каршылык күрсәтү хәрәкәтенең эчке һәм психологик рухын шигъри сүз белән аеруча кискен чагылдырган Муса Җәлил иҗатына Европа шагыйрьләренең поэтик тавышы да килеп кушыла. Арада иң көчлесе—Польша шагыйрьләре иҗаты.

Поляк поэзиясе һәрвакыт милләт язмышы белән үрелеп барган. Азатлык идеалларына чын күңелдән бирелгәнлек, туган ил язмышы өчен һәр даим көрәшкә әзер торү романтик күтәренке рухлы шигърият тууга китергән.

Польшада фашист оккупациясе алты ел дәвам итә. Гитлер полякларны кырып бетерү политикасы алып бара. Ил канлы төрмәгә әйләнә. Польша җирендә бу елларны 1900 үлем лагерьлары, хәрби әсирләр өчен лагерьлар, төрмә, геттолар булдырыла. Дәһшәтле Освенцим, Майданек, Треблинка «үлем фабрикалары»н кем генә белми икән?!

Сугыш елларында Польшада алты миллион кеше—милләтнең дүрттән бер өлеше—һәлак була. Бу елларны «крематорийлар чоры» дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Милләт буларак поляк халкын юк итү юлында гитлерчылар беренче чиратта илнең культурасын бетерергә һәм милләтнең дәрәҗәсен төшерергә тырышканнар. Оккупацияләнгән Польшаның идарәчесе Франкка Гитлерның мәгариф министры: «Моннан соң әдәбиятта Польша тарихы, Польша культурасы, поляк милләте дигән төшенчәләр булмаска тиеш», — дип язган [1].

---

[1] История Польши в трех томах. Т. 3. 533 бит.

Культура өлкәсендә эшләгән кешеләрнең язмышы аяныч була. Меңләгән язучы, артист, художник, фән эшлеклеләре үтерелә, концлагерьларда җәзалана, ачтан үлә... Ләкин шушы авыр шартларда да илбасарларга каршы көрәш тукталмый, партизаннар хәрәкәте колач җәя.

Польшадагы Каршылык күрсәтү хәрәкәте турында сөйләгәндә, әлбәттә, Муса Җәлил һәм аның иптәшләренең поляк эшчеләре, партизаннары белән элемтәдә булулары турында әйтмичә мөмкин түгел. Җәлилнең исән калган иптәшләре, бу бөек һәм куркыныч көрәшнең җанлы шаһитлары көрәшнең интернациональ характерда булуын сөйлиләр. Поляклар белән төрмәдә, заводларда бергә булганда җәлилчеләр алар белән дуслашканнар, агитация алып барганнар, поляк телендә листовкалар чыгарганнар, бергә диверсияләр оештырганнар, корал әзерләгәннәр, поляк партизаннары аркылы украин партизаннары белән элемтәгә керергә тырышканнар. Җәлилчеләрнең берсе—Р. Хисаметдинов болай дип яза: «Мин Мусаның бик күп җирләрдә яшерен сөйләшүләр алып барганын беләм. Минем күзәтүем буенча, Крушинода аның оешмасы бик көчле иде, шундагы бүлекләр аша ул поляк партизаннары белән бәйләнеш тоткан булырга тиеш. Коралллы восстание ясагач, без шул Крушино аркылы китәргә тиеш идек. Анда төрле милләттән эшче батальоннар бар иде»[1].

Әдәбият бу чорда халыкны көрәшкә өнди, үзе дә бу көрәштә көч таба, поляк халкының буйсынмас рухын, аның характерын чын йөрәктән чыккан сүзләр белән әйтеп бирә, гомумиләштерелгән әдәби типлар тудыра. Халык иңенә төшкән фаҗиганең авырлыгын, кулыннан коралын төшермәгән көрәшчеләр образын күрсәтү—оккупация чорында язылган әсәрләрнең үзенчәлекле ягы иде.

Меңләгән тере кешеләр күмелүдән кыймылдап торган каберләрне, Освенцим, Майданекның еллар буе сүнми янган мичләрен күрү гаделлек, намус кебек тиңдәшсез бөек сүзләрнең мәгънәсен тирәнрәк аңлау мөмкинлеген бирә. Әдәбиятта да бу төшенчәләр чагылыш таба.

Бу газаплы еллар һәр кеше өчен мораль сынау була, һәр шәхес алдына: «чын кеше син, әллә куркып, өметсезлеккә бирелеп җинаять юлына тәгәрәүче түбән җанмы?»—дигән кискен һәм кырыс сорау куя.

Польша трагедия кичергән елларда яшәгән һәм иҗат иткән язучыларның берсе Камил Бачинский була.

Куркытып халыкны буйсындырырга теләгән фашистларга ул кыю каршы чыга. Басып алучыларның тупаслыгыннан, явызлыгыннан, пычраклыгыннан рәнҗегән, кыерсытылган шагыйрьнең җаны әрни һәм ул кулына корал ала. Варшава восстаниесендә катнаша һәм 1944 елның 4 августында көрәшчеләр сафында һәлак була. Адам Мицкевичның «Залимлык бер генә карыш җиргә хуҗа булганда да кулыгыздан коралны ташламагыз», дигән сүзләренә ул шулай җавап бирә. Аның үле гәүдәсен бары 1947 елда гына хәрабәләр арасыннан табалар, дуслары һәм анасы кадерләп туганнар каберенә күмәләр, кабер ташына шагыйрьнең үз шигырен язалар.

**Сезнең янга исән кайта алмам,**
**Кайта алмам...**
**Корбан булырымны тоям...**
**Бәхет миңа**
**Бу дөньядан китү**
**Һәм ышану: яшәрмен, дип**
**Герой булып — мәңге үлмичә...**

(«Бәхилләшү» — юлга-юл тәрҗемә)[2]

Бачинский үзенең шигырьләрендә халык тойгыларын белдерә алганга күрә, зур политик фигура булу дәрәҗәсенә ирешә. «Үз халкымның язмышын, аның хәсрәтләрен әйтеп бирә белүче булырга телим»,—дигән шагыйрь.

---

[1] Муса Җәлил турында истәлекләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1961. 156, 188 битләр.
[2] Бачинский К. Прощание стрелка. — «Писатели против фашизма». М., «Прогресс», 1975, 261 бит.

Фашизмның котыруына шаһит булган шагыйрь халыкның нәфрәте үсүен сизә, шуңа күрә аның шигырьләре дә каршылык рухы белән тулы.

К. Бачинскийның иң нечкә хисле шигырьләренә дә мәрхәмәтсез көннәрнең шәүләсе төшә. Восстаниедә катнашып һәлак булган хатыны Барбарага багышлап язган шигырендә нәфис назлау һәм соклану сүзләре белән бер рәттән үзләре кичергән хәсрәтле хакыйкать турында да ачык һәм кырыс сүзләр бар.

Кешелекне таптаучы кара көчләр арасында авыр уйлар борчыган язучыга тормышка мәхәббәт хисе көч бирә, аның җанын чыныктыра.

Еракта, йөзләгән километрлар ары төрмәләрдә интеккән татар шагыйре Муса Җәлил иң тирәндә яткан тойгысын укучының рухи дөньясына барып җитә алырлык, аның хисләрен кузгатырлык куәтле һәм үтемле сүзләр белән әйтә. Үзенең «Ышанма» дигән шигырендә ул хатынына иң матур, җылы сүзләр белән мөрәҗәгать итә. Ләкин күңелендә булган шомлы уйлары кара шәүлә булып назлы сүзләр артыннан киләләр:

**Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,**
**«Алмаштырган илен»,—дисәләр,**
**Син ышанма, бәгърем! Мондый сүзне**
**Дуслар әйтмәс, мине сөйсәләр.**

**Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,**
**«Муса инде үлгән»,—дисәләр,**
**Син ышанма, бәгърем! Мондый сүзне**
**Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр.**

Муса Җәлилнең бик күп шигырьләрендә хәрби бурыч, патриот анты турында сүз бара. «Егет көче» исемле шигырендә:

**Егет үткән юлда сафлар сынды,**
**Туплар ауды, танклар ватылды.**
**Кайдан алды егет мондый көчне,**
**Кайдан алды мондый ялкынны!**

**Байрак итеп илгә турылыкны,**
**Утны-суны кичте бу егет.**
**Автоматы түгел, аты түгел,**
**Анты белән көчле бу егет,**

— дип раслый ул.

Бу шигырьдә егетнең рухи сафлыгы күренә. Аның халык язмышын хәл итүче вакыйгаларда катнашып, иле өчен соңгы тамчы канына кадәр көрәшергә биргән антында торуы мактала. Егет образына язучы художестволы фантазия өчен хас булган буяулар сала, аның батырлыгын романтик югарылыкка күтәрә. Шагыйрь халыкның бөеклеген, көчлелеген күрсәтә.

Үзенең патриотик һәм хәрби бурычын аңлау К. Бачинский шигырендә дә ачык күренә:

**Польша кабат яши алсын өчен**
**Без үлемгә хәзер барабыз.**

Польшада аны «югары талант иясе» дип йөртәләр. Хәзерге көндә аның әсәрләре чех, итальян, француз, немец, рус телләрендә чыга, композиторлар аның сүзләренә җырлар язалар.

«Сугыш шуны аңлатты,—дип яза Збигнев Залуский,—иң авыр, тормыш бик югары таләпләр куйган көннәрдә миллионнар үзләренең кешелек дәрәҗәсен саклап кала алды. Сугыш чоры батырлык, фидакарьлек, тугрылык үрнәкләре бирде. Яшь буын шул идеаллар үрнәгендә тәрбияләнергә тиеш»[1].

[1] Писатели против фашизма. М., «Прогресс», 1975, 16 бит.

Иң авыр, тормыш зур сынаулар куйган көннәрдә дә үзенең кешелек дәрәҗәсен саклап калган, батырлык күрсәткән, иленә, халкына тугры хезмәт иткән, Каршылык күрсәтү хәрәкәтенә катнашкан кешеләрнең тагын берсе—шагыйрь Тадеуш Боровский.

Утыз яшендә һәлак булган бу язучы әсәрләренең төп темасы—үлем лагерьлары, фашистларның вәхшилекләре. Шушы трагик темага багышланган әдәбиятта Т. Боровский иҗаты күренекле урын алып тора. Совет тәнкыйтьчесе И. Юзовский да үзенең «Польский дневник» исемле әсәрендә Т. Боровский китаплары турында «аларга кан һәм ачу сеңгән» дип язды.

Т. Боровский фашистларга каршы яшерен эштә актив катнаша. Беренче шигырьләр җыентыгы чыкканнан соң ике ай үткәч, ул гестапо кулына эләгә һәм аны Освенцимга озаталар. Башка язучылар кебек Т. Боровский концлагерьда да шигырьләр язуын дәвам итә. Поэзия үлем белән рәттән яшәгән. Фашист богауларында да поэзия яшәргә, көрәшергә һәм:

**Чәнечкеле чыбык бәйләсә дә... шагыйрьнең аяк-кулларын,**
**Бер көч тә юк җирдә богауларлык аның кайнар йөрәк моңнарын**

...дип язарга көч тапкан шагыйрь.

Т. Боровский: «Фашизмның гаебе һәркайда үлем чәчү генә түгел, кешеләрнең күңелен әдәп һәм әхлак ягыннан харап итәргә тырышуында да»,— дип язган. Төтен чыгарып утырган крематорийлар һәм мәетләрне яндыра торган базлар янында Т. Боровский сөйгән кызы турында шигырьләр яза. һәртөрле газаплар да үтерә алмаган сөю хисен шагыйрь лагерь еллары аша саклап килгән. «Сөю һәм сагыну турында җыр», «Караңгы болытлар», «Сөеклемә» исемле шигырьләрендә аның хәсрәтләре һәм өметләре чагыла. Аның шигыре рухы белән дә, хәтта исеме белән дә М. Җәлил шигыренә якын.

Бергә булган бәхетле көннәр еракта, алар инде кабатланмаячак. Сөйгән кешеләрнең мәхәббәте дә үлә бара. Рәхимсез сугыш давылы кешеләрне төрле якларга ыргыткан һәм һәркайсын имгәткән.

Ләкин Муса Җәлил дә, Т. Боровский да үлемнән курыкмыйлар, чөнки алар ни өчен үләчәкләрен беләләр һәм «бәлки менә шушы үлем безгә мәңге бетмәс яшәү китерер» дип ышаналар. Туган илдә аларның хыяллары чәчәк атачак, алар шуңа инанганнар һәм шуның белән юаналар.

Т. Боровский да, Муса Җәлил дә фашизмның гайре табигый асылын әкәмәт фантастик, гарип-көлке стильдә, күпертелгән формада, Гойя офортларындагыча сурәтлиләр. Т. Боровскийның «Биркенау төне» шигырендә күзләре ялтырап торган крематорийлар космогоник бер күренеш итеп бирелә.

Муса Җәлилнең «Таш капчык» исемле киная белән язылган шигырендә гитлерчыларның дәүләте кеше тәнен тартучы тегермән итеп, «Серле йомгак»та фашистик Германия Куркыныч патшалыгы итеп күрсәтелә:

**Дию өчен көн дә йөз үчакта**
**Кәбаб кыза адәм итеннән;**
**Шушы йортта икән кара бәхтем,**
**Мине илдән тартып китергән.**

Дошманның сатирик образын бирү публицистик хөкем белән бергә бәйләнеп бара.

Миллионлаган кешеләрне харап иткән сугыш турында сөйләүче мемуарлар, көндәлекләр бик күп басылды, андый китаплар әле дә чыга. Ләкин үзе хәсрәт күргән һәм корбан булган кешеләрнең шигырьләрендә калган авазларын һичбер башка сүзләр белән чагыштырып булмый, билгеле.

М. Җәлил һәм Боровский шигырьләрендә—кеше түзә алмастай интегүләр, иптәшләренең һәлак булуы, хәлдән тайдыра торган эш, авырулар, ачлык, фашистларның мыскыл итүе, атап әйткәндә, концлагерьның көндәлек чынбарлыгы. Аларда үлем чигенә җиткән кешеләрнең психологиясен төшенү күренеп тора. «Мин хәзер кешенең чын интегүләрен аңлыйм»,— дип яза Боровский. Бу шигырьләр — чынбарлыкны документаль теркәү генә түгел, ә әрнүле һәм көрәшкә сусаган йөрәк авазы.

Т. Боровский әсәрләренең күбесендә дөньяның барлык шагыйрьләрен җилкендергән «күк йөзе» образы инде һичбер вакытта да татый алмаслык ирек символы булып китә.

Т. Боровский үзенең үткән гомере ераклаша барганын тоя. «...Атылган дусларым минем йөрәк төбендә, исәннәре дә инде шунда таба төшә баралар...»—ди ул. Әмма каһәрләнгән шартларда да тормышны сөяргә көч таба, башка кешеләрнең бәхетле булуына шатлана белә. «Әй, тыныч илләрдә яшәүче кешеләр! Сезне хәзер ачык итеп күз алдыма китерә алмасам да, сез бәхетле булганга мин дә бәхетле!»—дип яза ул.

Лагерьдә яшәгәндә аның күңелендә корбан булганнар өчен үч алу көннәре киләсенә, гаделлекнең өстенлек алачагына ышану туа:

**Мин ышанам, кешеләр күңелендә**
**Онытылмаслык нәфрәт сакланыр,**
**Вакыт җитәр,**
**Вәхшәт корбаннары**
**Каберләрдән кубып үч алыр...**

Татар шагыйре М. Җәлил халыкта уянган каршылык көчен, дошманны җиңү турындагы уйларын, азатлык идеалларын чагылдыра. Халыкның рухи дөньясын тирән белүче һәм җанлы итеп ача алучы шагыйрь рухына азык биреп торган хыялларын, өмет һәм ышанычын белдереп:

**Килер ул көн, халык хөкем итәр,**
**Карар булыр кискен һәм кыска.**
**Каным белән язган соңгы җырым,**
**Бул гаепләү акты фашистка,**

(«Хөкем алдыннан»)

—дип яза.

Концлагерь һәм төрмәләрдә үлем сәгатьләрен көткәндә шагыйрьнең иҗат көче сүнми генә түгел, киресенчә, соңгы минутларга кадәр яктырып яна, шул иҗат ялкынында җитлеккән һәм гүзәл җырлар туа.

Муса Җәлилнең һәм башка көрәшчеләрнең гомере—героик симфония. Аның соңгы аккордлары искиткеч бер мәһабәт һәм трагик моң булып яңгырый. Бу симфония сагышлы, ләкин дәрт, көч бирүче финал белән тәмамлана. Ул кешеләрнең җанын тетрәтә һәм көрәш кырында туган җырларның һәрвакыт сугышчан сафта калуы турында сөйли.

## Фәрит Солтанов

# ХӨР ФИКЕРЛӘҮ ЮЛЫНДА...

XX йөз башы алдынгы татар иҗтимагый фикере тарихында сизелерлек эз калдыручы шәхесләр байтак. Галиәсгар (Гафуров) Чыгтай — шуларның берсе.

Г. Чыгтай 1867 елның 16 сентябрендә хәзерге Аксубай районының Яңа Ибрай авылында дөньяга килә. Авыл һәм Чистай мәдрәсәләрендә укыганнан соң, мөгаллимлек кылып йөри, бераз вакыт Бозаулык шәһәрендә мулла булып та тора. Ләкин алдынгы көнчыгыш әдәбияты, Заһир Бигиев, Муса Акъегет-задә, атаклы мәгърифәтче Каюм Насыйри әсәрләре белән танышу, рус теле һәм әдәбиятын өйрәнү Галиәсгарның тормышка карашын нык үзгәртә. Гомумән, Чыгтай — татар дин әһелләре арасында беренчеләрдән буларак, ислам дине өйрәтмәләрен ачыктан-ачык шик астына куйган кеше. Диннең чын йөзен ачуга ул «Исабәт» әсәрен багышлый. Хөр фикерләү юлында «мин уйлана, чокчына торгач, «Корьән»нең үзен дә аңлап, аны тәүге мөселманнарның тарихларына чагыштырып укый торгач, ислам диненең «күк» белән һичбер бәйләнеше булмаган, ялгыз бер халыкның тарихи китешеннән килеп чыккан ясалма нәрсә икәнен белдем... Ислам диненең ясалма икәнен аңлау белән миндә бөтен диннәрнең ясалмалыгына канәгать итү табылды. Мин бу хәлгә 1904—1905 елларда килдем. Ул вакытта мин «Исабәт» дигән бер рисаләмнең нигезен салдым» [1],— дип яза Г. Чыгтай соңыннан.

Үз вакытында татарлар арасында зур шау-шу күтәргән «Исабәт» [2] китабы аерым бер язучының иҗатында гына түгел, бөтен татар иҗтимагый фикере тарихында да күренекле урын алып торырга лаеклы. Алдынгы карашлы Г. Чыгтай бу китабына карата зур таләпчәнлек күрсәтә һәм аны 1902—1908 елларда дүрт мәртәбә эшкәрткәннән соң гына басарга бирә.

Әлеге хезмәтендә ул, мөселман дине алла тарафыннан күктән иңдерелгән дип раслаучы өйрәтүләргә капма-каршы буларак, исламның барлыкка килүе һәм урнашу сәбәпләрен җирдән — ислам чорына кадәрге гарәпләрнең социаль-экономик тормыш шартларыннан эзли.

Ислам диненең барлыкка килү сәбәпләрен Г. Чыгтай гарәп җирендә яңа социаль-экономик мөнәсәбәтләрнең тууыннан һәм аларга җавап бирә алырлык яңа әскормә таләп ителүеннән китереп чыгара.

Г. Чыгтай шулай ук, мөселман тарихчыларына капма-каршы төстә, ислам диненең буш җирдә тумаганлыгына басым ясый. Бу җәһәттән ул, Мөхәммәткә кайтарып калдырылган дингә ышануның һәм әхлакның гарәпләр өчен яңа бер нәрсә булмыйча, бәлки аңа кадәр үк «мәгълүм вә мәгъруф» [3] леген әйтә. Автор гарәпләрдә ислам дине урнашу өчен социаль-экономик алшартлар туса да, аның озакка сузылган көрәшләр аша гына нык җитүенә игътибар итә, карашын тарихи материаллар, фактлар җирлегендә нигезли.

Г. Чыгтайның «алла илчесе» Мөхәммәт пигамбәр хакында булган күзәтүләре шулай ук игътибарга лаек. Аның раславынча, Мөхәммәт — шул чорның каршылыкларын ачык күрә алган гади бер шәхес. Ул, бер

---

[1] Чыгтай Г. Мин ничек динсезләндем. М., 1924, 8—9 битләр.

[2] Чыгтай Г. Исабәт. Казан, «Юл», 1910. (Исабәт — эштә, сүздә дөреслеккә ирешү).

[3] Мәгъруф — танылган.

аллага табыну идеясенең гарәп кабиләләрен мөстәкыйль, көчле дәүләткә туплау чарасы булуын аңлап, үзен пигамбәр дип игълан итә.

Г. Чыгтай гарәпләрдә үз җитәкчеләрен пигамбәр дип атауның гадәти хәл булуын күрсәтә һәм Мөхәммәтнең халык арасында танылып китеп, зур көч туплый алуының сәбәпләрен дә ачыкларга тырышып карый.

Г. Чыгтай ислам дине өйрәтүләренең төп чыганагы булган «Корьән»не дә җирдәге сәбәпләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән, борынгы гарәпләрнең тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, җәмгыять төзелеше, җитәкчеләре һ. б. турында сөйләүче тарихи китап дип кенә карый. Г. Чыгтай «Корьән»нең Мөхәммәт исән чакта ук тулысынча язылуын кире кага һәм аның төрле яктан, төрле вакытта җыйналган текстларны эченә алуын, Мөхәммәт үлгәннән соң озак еллар үткәч кенә хәзерге хәленә китерелүен күрсәтә. Ул, дин әһелләренең «Корьән» «мәңге үзгәрешсез», «алла тарафыннан иңдерелгән» дип раслауларына каршы чыга һәм, конкрет-тарихи хәлләргә, факторларга таянып, әлеге өйрәтүнең уйдырма булуын, «Корьән»нең төрле чор кешеләре тарафыннан язылуын билгеләп үтә.

Чынбарлыкны, табигатьне танып-белүдә Г. Чыгтай стихиячел материализм позицияләрендә тора һәм бу аңа диннең гносеологик нигезләрен күрә алуга юл ача. Г. Чыгтай фикеренчә, өстен көчләргә ышануга китерүче сәбәпләрнең берсе — табигать үсеше законнарын белеп җиткермәү. Ул бу турыда: «иман ноктаи тәхәйер [1]дән башланыр. Кеше бер хадисә [2]нең сәбәбенә төшенә алмады исә, «алла», ди. Ул сәбәпләр кирәгенчә аңлашылмаганга, әлеге гадәттән тыш хәлләр «күккә иснад кылынмак кабул күренгән», дип яза һәм «гыйлем вә фән куәте илә бу дөньядагы һәр нәрсәнең бер сәбәбе барлыгы беленә барса да», әле кеше затының байтак кына күренеш, хәлләрнең асылын аңлаудан ерак торуын күрсәтә.

Г. Чыгтай, тәкъдир турындагы дини өйрәтмәләргә капма-каршы буларак, кешене табигать законнарына буйсынып яшәүче, табигатьнең органик өлеше итеп карый. Адәм эшчәнлегенең табигать һәм җәмгыятькә карата шартлы һәм, бер үк вакыт, чагыштырмача чикләнгән булуына ишарәләп, ул, табигать законнары эчтәлегенә тирән төшенеп хәрәкәт иткәндә, кешенең дөньяны үз файдасына буйсындыра алу мөмкинлеге гаять зурлыгын, киңлеген раслый («Исабәт», 27 бит). Шуңа күрә, Г. Чыгтай татар халкын дөньяви фәннәрнең нигезләрен нык үзләштерергә, аң-белемне күтәрү өстендә даими эшләргә чакыра. Бу җәһәттән, аның «Татар теле кем кулында һәм кайчан ислах булыр» (1901) дигән кулъязмасы аеруча игътибарга лаек. Автор анда татарлар өчен дә аң-белемле булуның зарурлыгын белдерә. Ул татарлар арасыннан да башка мәмләкәтләрдә белем алып кайткан Ломоносов, Тургеневтай укымышлылар пәйда булуын тели һәм кардәшләрен югары уку йортларына барырга өнди.

Безне чолгап алган әйләнә-тирәне ничек бар, шулай танып белергә, кешене табигатьнең аерылгысыз бер өлеше итеп санарга һәм дөньяви фәннәрне өйрәнергә чакырган фикерләре Г. Чыгтайның дини карашларга фәлсәфи нигездә каршы чыгуын күрсәтә.

Дин әһелләре гасырлар буе дингә ышанучыларның мөселман культын (иман китерү, биш вакыт намаз уку, ураза тоту, зәкат бирү, хаҗ кылу) дөрес һәм җиренә җиткереп үтәп килүен таләп итәләр. Әлбәттә, әлеге күренеш хәр фикерле Г. Чыгтайның игътибар үзәгеннән читтә кала алмый. Аның белдерүенчә, мөселманнар арасында киң таралган төрле йолалар, дини бәйрәмнәр, мәҗбүри саналган җәмәгать намазлары мөэминнәрне оештыру, аларны даими күзәтү астында буйсындырып тоту өчен хезмәт иткән һәм әле дә булса шуңа хезмәт итә («Исабәт», 38 бит).

«Тутам» әсәрендә Зәет хаҗи образы аша Г. Чыгтай хаҗ кылуның күпләр өчен байлыкка ирешү юлы икәнлеген күрсәтә. Шәфкатьсез, кешелексез, намуссыз Зәет Мәккәгә барган җиреннән ишан булып кайта. Бу хәлдән соң аңа ишекләр ачылганнан-ачыла бара, хәер-сәдакалары да атнадан-атнага күбрәк керә башлый. Хаҗи баеп китеп зур йортлар салдыра һәм, шул рәвешчә, илнең мөхтәрәм кешесенә әйләнә. Димәк, мөселман культы халыкны рухи коллыкта тотучы һәм сыйнфый җәмгыятьнең өстен катламнарына гына хезмәт итүче нәрсә икән.

Реакцион мөселман руханилары ислам дине исеменнән хатын-кызның көнкүреш, гаилә, җәмгыятьтәге хокукын чикләп киләләр. Бу мәсьәләгә дә Г. Чыгтай битараф кала алмый. Аның «Тутам» әсәре тулысы белән хатын-кыз азатлыгы проблемасын күтәрүе һич тә очраклы күренеш түгел,

---

[1] Н о к т а и — тәхәйер — ис китү.
[2] Х ә д и с ә — күренеш, хәл.

Автор ярлы татар хатын-кызларының уенкөлкегә бай, саф мәхәббәткә һәм искиткеч тыйнаклыкка ия булуларын зур соклану белән сурәтли. Хатын-кызның ирләр кебек үк кеше булуын раслап, ул хатыннарда «ирләрдә булган истигъдад[1] булуына», аларның һәр нәрсәгә куллары ятышып торуга сокланып яза. Шуңа күрә дә аның таләбе катгый: «Ирләр хатыннарга уенчык вә ирексез кол дип гөман итмәсеннәр! Бәлки һәр хокукка ия булырлык вә һәр төрле авырлыкларны күтәрерлек инсаннар дип белсеннәр» («Тутам», 44 бит).

Г. Чыгтай хатын-кызга азатлык таләп итеп кенә калмыйча, аның изелеп яшәве сәбәпләренә дә игътибар итә һәм мөселман хатыннарының хокуксызлыктан газап чигүләрен реакцион «муллаларның дин исеменнән фанатизм һәм наданлык» таратуларыннан, әлеге дини моральне аклап һәм яклап килгән әшәке җәмгыятьтән күрә. Аныңча, хатыннарның хәлләрен күреп «зарлану—булдыксызлар эшедер». Акыллы кешеләр «һәр дәрткә бер дәрман табу»ны алты планга куярга тиешләр. Һәм Г. Чыгтай турыдан-туры әлеге «дәрманны» табу юлларын билгеләргә, күрсәтергә омтыла. Ул хатын-кыз азатлыгына түбәндәге чараларны үтәгәндә генә ирешергә мөмкин, дип уйлый: а) хатыннарны, ирләр белән берләттән, матди байлыклар җитештерүдә катнаштыру; б) кызларга тәрбия бирүнең иске формаларын тулаем үзгәртеп кору; в) хатын-кызның дөньяви җирлегендә аңбелемен күтәрү, кыз балаларны ир балалар белән берлектә укыту, аларга рус телен өйрәтү һәм укыту процессын җәдитчелек ысулы белән алып бару; г) яшәп килгән иске җәмгыять тәртипләрен яңалары белән алыштыру. Г. Чыгтайның мөселман хатын-кызының тулы хокуклы кеше булуын раславы, аны азатлыкка чыгару юлларын күрсәтүе, әлбәттә, XIX гасыр татар мәгърифәтчеләренең шушы юнәлештәге идеяләрен дәвам иттерү, аларны тагын да үстерү һәм камилләштерү иде.

Г. Чыгтай капитализмның соңгы үсеш стадиясенә кергән чорда яши. Бу вакытта татарлар арасында революцион фикер формалашуга һәм үсүгә зур йогынты ясаган социал-демократик партиянең булуы да мәгълүм. Шул шартларда Г. Чыгтайның, буржуаз җәмгыятьне тәнкыйть итеп, «һәркем үзенең эше вә мәшәкате микъдаренчә рәхәт күрә торган» строй турында хыяллануы игътибарга лаеклы («Тутам», 15 бит). Алдынгы фикер иясенең шуңа ирешү юлында дингә мөнәсәбәте кызыклы. Аныңча, яңа строй өчен көрәштә дин проблемасы үзәк мәсьәләгә әверелергә тиеш түгел, ә бәлки «күпме гомер иткән явыз хөкүмәткә каршы милләтләр кузгалып китсә, бу сугышта безнең мөселманнар баһадирларча катнашырлармы?» дигән сорауга җавап эзләү, татар халкын революцион күтәрелешкә әзерләү мәсьәләсе торырга тиеш («Тутам», 69 бит). Шулай да, яңа стройда дин, әхлакый чара буларак, бәлки үзенең яшәвен дәвам итәр, дигән фикерне дә үткәрә автор. Шушы чорга һәм әлеге мәсьәләгә караган уйларын искә алып, ул соңыннан: «Мин инде дингә ышанмый, әмма аның яшәвенә ышана идем»[2],— дип яза. Г. Чыгтайның яңа җәмгыять, социализм һәм дин мәсьәләләренә караган фикерләре, әлбәттә, татарлар арасында революцион караш үсешенә йогынтысыз калмагандыр.

Шул рәвешчә, Г. Чыгтайның ислам диненең төп өйрәтмәләрен, фанатиклыкны кире кагуга, чынбарлыкны танып-белүгә, яңа җәмгыять төзүгә караган фикерләре XX йөз башы татар дөньясын дини сөремнәрдән арындыруга юнәлдерелгән. Аның эшчәнлеге, билгеле, болар белән генә чикләнми. Г. Чыгтайның Бөек Октябрь революциясенә кадәр «Кояш», «Тормыш» газеталары, «Сөембикә» журналы редакцияләрендә эшләве, балалар өчен дәреслекләр төзүе шул турыда сөйли. Совет власте урнашкач, Г. Чыгтай Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Фән һәм дин» журналының редакторы була. Шушы чорда ул «Мин нидән динсезләндем» (1924), «Корьәннең килеп чыгуы һәм аның мөндәриҗәсе турында» (1925), «Минем дәһрилегем тарихчысы» (1927) кебек хезмәтләрен яза.

Г. Чыгтай 1942 елның 20 августында Аксубай районының Иске Ибрай авылында дөнья куя. Аның бай фәлсәфи, әдәби мирасы киләчәктә киңрәк һәм җентекләбрәк өйрәнүне көтә.

---

[1] Истигъдад — сәләт.

[2] Чыгтай Г. Мин нидән динсезләндем. 13 бит.

# СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

## ТАҢ ҖЫРЧЫСЫ

Сәгыйть Рәмиев (1880—1926)—XX йөз башында, бигрәк тә 1905 елгы революция чорында халык хәрәкәтләре мәйданга китереп чыгарган, катлаулы һәм үзенчәлекле иҗат юлы үтеп, демократик татар әдәбияты һәм культурасы үсешенә әһәмиятле өлеш керткән зур шагыйрь. Бу дәвердә татар халкы тормышында барган тирән тарихи үзгәрешләр, иҗтимагый тетрәүләр әдәбиятка, реализм үсеше белән бергә, романтизмны да алып килде. Татар әдәбиятында бөтен бер юнәлеш рәвешен алган романтизм, иң башлап, аеруча С. Рәмиев иҗатында калку гәүдәләнде.

Шагыйрь иҗаты татар иҗтимагый җирлеге туфрагында шытып, тирән тамырлары белән борынгы көнчыгыш һәм рус-Европа романтизмы катламнарына да тоташкан хәлдә, Россия һавасында уйнаган җил-давылларда, халкыбызның «таң вакыты»нда шаулап күтәрелде. Рәмиев әдәбиятка яңа герой—буржуаз-демократик революция уяткан, кара көчләр алдында баш имичә, алла, патша һәм, гомумән, күк һәм җир золымына, һәртөрле явызлыкка каршы ялкынлы протест белән күтәрелгән романтик бунтарь лирик герой образын алып килде. Аның кайнар лиризм белән сугарылган шигырьләре татар поэзиясен дидактизмнан, үгет-нәсихәтчелектән арындыруга зур өлеш керттеләр. Романтик лиризм XX йөз башы татар әдәбиятының зур бер эстетик казанышы булды. Шул ук вакытта Рәмиев, татар шигырь төзелешендәге яңа мөмкинлекләрне ачып, традицион көйле шигырьдән интонацион шигырьне, сөйләү шигырен үстереп чыгарды. Татар шигыренең алга таба үсешендә моның әһәмияте ифрат зур булды.

Әдипнең пьесалары, повесть һәм хикәяләре дә татар драматургиясе һәм прозасы хәзинәләренә билгеле бер өлеш булып керде.

Шагыйрь рус һәм дөнья әдәбияты классиклары әсәрләрен тәрҗемә итүгә күп хезмәт куйды. Аның зур осталык белән эшләнгән тәрҗемәләре, үз иҗатының органик өлешен тәшкил итеп, татар әдәбиятын яңа идея-тематик казанышлар белән баетуда, интернациональ бәйләнешләрне ныгытуда әһәмиятле роль уйнадылар.

С. Рәмиев — шулай ук публицистика, әдәби тәнкыйть, музыка һәм театр сәнгате, шигырь төзелеше һәм тәрҗемә теориясе, тел белеме һ. б. өлкәләргә күп игътибар биргән, культура һәм җәмәгать эшләренә актив катнашкан язучы иде.

*
* *

Әдәбият һәм матбугат мәйданына С. Рәмиев 1906 елда:

**Булмас артык, олуг бер эш**
**Илгә хезмәт итүдән;**
**Илгә хезмәт хөрмәтенә**
**Үскән җирдән китүдән,—**

дигән девиз белән, халыкка ирек һәм бәхет яулау идеалы белән рухланып чыкты. Үзе редактор булып эшләгән «Таң йолдызы» газетасындагы публицистик мәкаләлә-

рендә ул ил, халык язмышы кебек зур мәсьәләләрне күтәрә, илдә ачлык, ялангачлык, эксплуатация һәм террор хөкем сөрүен күрсәтә, иске идарәне бетереп, дәүләт идарәсен бөтен халык кулына бирү, җир, ирек таләпләрен яклый. Публицистикасында күтәрелгән фикерләр аның поэтик иҗатына кереп үрелә. «Бел телен, эзлә юлын», «Әгәр баксак газеттәге хәбәрләргә...» кебек шигырьләрендә ул патша Россиясендә халыкны рәхимсез изү һәм эзәрлекләү күренешләрен бөтен шыксызлыгы һәм дәһшәтлелеге белән күз алдына бастыра:

**Тор, уян, тирә-ягың кан булган,**
**Бел телен, эзлә юлын: нидән бу болай булган.**
**Авылларда өйләр җимерелгән, балалар бар да**
**ач калган,**
**Кырлар көйгән, көл булган, әйтерсең лә яу**
**алган,**
**Заводлар-фабрикаларга солдат куелган,**
**Урамнар-йортларга жандарм, шпион тулган,**
**Бел телен, эзлә юлын: нидән бу болай булган.**

Беренче рус революциясе эшчеләр сыйныфының бетмәс-төкәнмәс куәтен, халык хәрәкәтләрен эзлекле әйдәп баручы бердәнбер көч икәнлеген күрсәтте. Шуңа бәйләнешле рәвештә татар демократик поэзиясендә эшчеләр, промышленность пролетариаты, аның хезмәте һәм көрәше темасына игътибар артты. Татар хезмәт ияләре арасында революцион җырларга зур ихтыяҗ туды. Ләкин әле татар поэзиясенең бу темаларны яктырту тәҗрибәсе юк диярлек иде. Шагыйрьләр рус поэзиясе хәзинәләренә, рус телендәге революцион җырларга мөрәҗәгать иттеләр. Революциядә төрле милләт хезмәт ияләренең изүчеләргә каршы интернационалистик бердәмлеге рус теленнән тәрҗемә ителгән яисә файдаланып язылган революцион җырларда искиткеч көчле гәүдәләнешен тапты. Татарча шундый җырлар иҗат итүгә С. Рәмиев зур өлеш кертте. 1906 елда ул «Марсельеза», «Кыю атлагыз, иптәшләр!» («Смело, товарищи, в ногу!») «Бәхилләшү» (Матәм маршы) кебек җырларны тәрҗемә итте һәм өлешчә-өлешчә булса да, мәкаләләренә кушып бастырды. Мәсәлән, халык арасында киң таралган «Татарча Марсельеза» дагы:

**Ташлыйк, туганнар, иске тормышны,**
**Ул тормыштан илгә файда юк.**
**Булса байлар илә тик түрәләр**
**Аркабызда рәхәт күрәләр.**
**Кирәкми, ташлыйбыз иске юлны!**
**Кирәкми, яңа юл башлыйбыз!**
**Яңа юл, яхшы юл, бер җәберсез,**
**Тигез рәхәт тора башлыйбыз!—**

кебек юлларда ярсулы революцион хис бөркелеп торды. Рус хезмәт ияләренең көрәшләре эченнән ургылып килгән бу ялкынлы тойгылар шагыйрь йөрәге аша үтеп, татар халкының да рухи хәзинәсенә әверелделәр.

Массовый революцион җырлар татар поэзиясендә бөтенләй яңа күренеш булып, С. Рәмиев хезмәте аңа зур өлеш булып керде. Мондый эшчәнлеге өчен С. Рәмиев 1906 елда берничә мәртәбә кулга да алына һәм төрмәдә М. Горькийның «Тормыш төбендә» пьесасыннан «Кояш чыга да, бата да, төрмәм мәңге караңгы...» җырын тәрҗемә итеп, камера стенасына яза, бер мәкаләсендә бастырып та чыгара.

Ярсулы йөрәк ялкыны белән илһамланып иҗат ителгән, саф татарча образлы тел белән язылган бу тәрҗемә әсәрләр татар халкының үз күңеленнән чыккан әдәби җәүһәрләр дәрәҗәсендә иде. Шуңа күрә дә аларны татар халкы, күп вакыт авторы кем икәнен дә белмәстән, үз моңы, үз җыры итеп кабул итте, кулъязмаларда, телдә саклап, көрәш коралы итеп йөретте.

Әдәби һәм журналистлык эшчәнлеге белән бер рәттән С. Рәмиев, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Коләхметовлар белән бергә, татар театрын булдыру һәм аның эшләрен юлга салып җибәрүдә турыдан-туры катнаша. 1906 елның 22 декабренда та-



тар театры тарихында беренче спектакльне ачып җибәреп речь сөйләүче дә С. Рәмиев була. «Беренче татар театры куелган чакта, — дип искә ала М. Укмасый, — Сәгыйть искиткеч рухлы, шат, һәр җиргә җитә, өстенә кырыйлары чиккән күлмәк кигән, билгә матур итеп чуклы ефәк билбау бәйләгән иде».

Беренче рус революциясе еллары С. Рәмиевнең иҗтимагый публицистик һәм әдәби иҗат эшчәнлегендә әһәмиятле беренче этап булды.

Илдә кара реакция башлангач, С. Рәмиев эшләгән газеталар туздырылды, шагыйрь эшсез, бик кыен шартларда кала. 1907 елда үткәрелгән бер тентүдән соң Рәмиев «дәүләт җинаятьчесе» сыйфатында жандарм идарәсенә чакыртыла. «Ләкин ул чакта Казаннан китеп юкка чыкты», — дип яза Казан жандарм идарәсе начальнигы соңыннан.

1907 елның 17 декабрендә «Әльислах» газетасында басылган «Юк, үлмим! Торам әле!» дигән мәкаләсеннән күренгәнчә, үтә нечкә хисле романтик шагыйрь реакция һөҗүмен бик тә авыр кичерә.

Мондый шартларда Рәмиев иҗат илһамын нинди иҗтимагый хәрәкәттән алды соң? Бу хәрәкәт—демократик мәгърифәтчелек хәрәкәте иде. Революция җиңелде, ул феодализм тәртипләрен нык кына какшатса да, аларны тәмам себереп түгә алмады. Шул ук вакытта ул бездә мәгърифәтчелек хәрәкәтен нык үстереп җибәрде. Милли телдә көндәлек матбугат, театр һ. б. культура учакларының кабынуы, хатын-кызларның да үз хокукларын кыю яклый башлаулары аңа яңа куәт өстәде. «Ихтыярсыз җанландым,—дип яза Рәмиев югарыда искә алынган мәкаләсендә.—Яңадан торасым килә башлады, кул селтәгән өмидләрем яңадан кайттылар. Мин тагы зур өмидләргә чумдым».

Революция чорында үзе катнашкан вакыйгаларның кайнар эзләренә кабат кайтып, әдип «Низамлы мәдрәсә» һәм «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» пьесаларын иҗат итә. Беренчесе—аның «Хөсәения» мәдрәсәсендәге, икенчесе Казандагы эшчәнлеге белән бәйләнгән бу әсәрләр иске тәртипләргә, кара көчләргә каршы килешмәүчән көрәш рухы, халыкны якты, бәхетле тормышка чыгару, шул юлда хезмәт итү идеяләре белән сугарылган. «Яшә, Зөбәйдә...» әсәренең баш герое Сөләйман дин башлыкларын, аларның, алла исеменнән сөйләп, халыкны караңгылык, наданлык коллыгында тотарга маташуларын нәфрәтләнеп фаш итә. Пьесаның дөнья күрүе карагруһлар, динчеләр арасында зур шау-шу кузгата, аның тиражы утта яндырыла.

1907 елның көзендә Г. Тукай белән күрешеп дуслашу, Ф. Әмирхан җитәкчелегендәге «Әльислах» газетасына якынаю Рәмиевнең иҗаты тагын да үсеп, күтәрелеп китүгә уңай тәэсир итә. Ислахчылар белән бергә әдәбият кичәләрен оештыруга актив катнашып, шагыйрь үз әсәрләренең күбесен сәхнәдән сөйли. Шуннан соң алар «Әльислах» газетасында басыла. Замандашлары С. Рәмиевнең сүзгә гомумән бик оста булып, шигырьләрен гаҗәеп бер нәфислек белән сөйләвен искә алалар.

С. Рәмиевне киң җәмәгатьчелеккә шагыйрь итеп таныткан әсәре—«Таң вакыты». Бу шигырен ул беренче мәртәбә 1908 елның 2 гыйнварында әдәбият кичәсендә укый. Таң атып килү күренеше ярдәмендә шагыйрь татар халкы тормышында, кешеләр аңында каршылыклар көрәше аша барган зур үзгәрешләрне, бөтен бер тарихи дәверләр алмашыну процессын сурәтли. Әсәр үтәдән үтәли тарихилык белән сугарылган. Аның лирик герое, «Яшә, Зөбәйдә...» әсәрендәге Сөләйман кебек үк, зур иҗтимагый ниятләр белән янучы, тирәлектән аерылып, «күтәрелеп» торучы романтик герой. «Татар йоклый» әле, ә бу герой инде уянган. Кайнар тойгылы, көчле һәм темпераментлы кеше булып күз алдына баса ул. Ил, халык язмышы, халыкны гасырлар буе

хорафат йокысында тоткан сәбәпләр турында тирәнтен борчылып уйлана ул. Ниһаять, зур бер нәтиҗәгә килә: моңа дин, алла гаепле:

**Башларын ваткан татарларның тик шул бер алла!**
**Бетәрләр микән татарлар, алла, ди-ди,**
**Әллә белерләр микән хаталарын бер алда!**

Ләкин шул ук вакытта аның күңелендә иске, дини карашлар да баш калкыта: «Әй син, Габдулла! Мөселман булсаң, уйлама юкны, ят, йокла!»— ди. Геройны янә ашкынулы, ярсулы тойгылар биләп ала: «Юк!.. Юк!.. Мин шашам, яталмыйм урынымда, күккә ашам. Менә таң атты! Әнә кояш чыкты!»—ди ул. Аның монологында каршылыклы тарихи процесс тудырган дулкын-дулкын хисләр коллизиясе, тирән психологизм, җан диалектикасы ачыла. Шигырьнең азаккы юллары искелеккә ярсулы нәфрәт белән янган, мәгърифәткә юл ачарга теләгән трибун шагыйрьнең халыкны уянырга, актив хәрәкәткә чакырып набат кагуы булып яңгырый:

**Бетмә надан, туг яңадан**
**Мәгърифәтле анадан!**
**Бул кеше, үзең тырыш, өмид итмә,**
**Хата ул өмид алладан!**

Күз алдына китерик: шигырь сәхнәдән әһле исламның «изге корбан гаете»н бәйрәм итеп йөргән көннәрендә укыла! Бу үзе зур вакыйга булып, консерватив даирәләрне тәмам ярсыта, прогрессив көчләр тарафыннан хуплап каршы алына. «Бу кичәдә бу вакытка чаклы кеше эченнән генә әйтергә курыккан сүзләр дә сөйләнде, язулар да укылды»,— дип билгеләп үтте большевик Хөсәен Ямашев.

«Татар шагыйрьләре» китабында Г. Ибраһимов «тирән мәгънәле, гаҗаиб дәрәҗәдә шигърияте «Таң вакыты»н анализлауга бер бүлекчә багышлый. «Хәзерге вакытны — татарның таң вакыты дип атарга мөмкин,— дип яза ул.— Чөнки безнең халыкның гасырларча дәвам кыйлган йокысыннан, өстен каплаган кара төннән яңа дөньяга, якты кояшлы мәдәният галәменә чыгарга торган замана».

С. Рәмиев «Мин» шигырендә кешенең үзен, галәм патшасы итеп, югары күтәрә:

**«Мин!» димен мин, «Мин» дидисәм,**
**Миңа бер зур көч кирә,**
**Аллалар, шаһлар, кануннар**
**Булалар бер чүп кенә.**
**Бер үзем хөр каламын киң**
**Җир йөзе һәм күктә дә.**

Шагыйрьнең лирик «мин»е, реакция көчләренә каршы горур басып, барлык хокуклардан, җир-сулардан мәхрүм ителгән кешенең хакыйкый бәхетен даулый:

**Дөньяда бар су минеке,**
**Бар кара җир минеке,**
**Бар тау, урман, бар матур кош—**
**Барысы да минеке.**

«Маҗид сүзе» шигырендә шагыйрь аллага каршы ярсып баш күтәрә, бөтен күк патшалыгын җимереп кол иту белән яный. Шагыйрь өчен иң бөек зат—кеше.

С. Рәмиев әсәрләре тирәсендә шау-шулы бәхәсләр барган көннәрдә А. Пинкевич шагыйрьнең «Таң вакыты», «Мин», «Син», «Ул» дигән шигырьләрен кульязмадан тәрҗемә итеп, русча бастырып чыгара. Сәгыйть Рәмиевнең шигырьләре татар тормышында барган кискен үзгәрешләрнең «иң характерлы күрсәткече булып торалар», дип яза ул. Аның әлеге тәрҗемәләрен, гомумән, татар язма поэзиясенең рус телендә дөнья күргән беренче үрнәкләреннән санарга мөмкин.

Реакция елларында капиталистик мөнәсәбәтләрнең шыксызлыгы, кешелексезлеге тагын да шәрәрәк булып ачылды. С. Рәмиевнең мәгърифәт һәм бәхет идеалларын, «тигезлек, дуслык, мәхәббәт» турындагы «саф көмеш кебек ак өмидләр»ен реаль

чынбарлык челпәрәмә китерде. Шагыйрь 1908 елның мартында «Алданган» шигырен яза.

**Бетте. Төштем. Үлде рухым,**
**Калмады һич рәхәтем...**
**Ачынам, ачуланам һәм**
**Каш җыерам дөньяга,**

—дип, кургаштай авыр өзек-өзек сүз-гыйбарәләрне градация тәртибендә тезеп, җан ачысы белән үкси-үкси язылган бу әсәр изге идеал белән явыз чынбарлыкның кискен бәрелешеннән туган газаплы кичерешләрне гаять көчле чагылдырды. Әйтергә мөмкин: шушы шигырьдән башлап шагыйрьнең бигрәк тә 1908—1910 еллардагы иҗатында җәмгыять белән, дөнья, «җиһан» белән тирән каршылыкта булган лирик геройның трагик образына игътибар артты.

Реакция дәвеpeнeң гомумиләштерелгән романтик сурәтен Рәмиев «Минем төн» шигырендә (1909) тудырды. Бу чорның җан өшеткеч шыксыз кыяфәте, яңа «таң»ны зарыгып көтү ифрат куе буяулар белән тасвирланды:

**Караңгы һәм дә таңы ерак,**
**Уты сүнгән җәһәннәм минем төн...**

Шагыйрь әнә шундый караңгылык шартларында өстенлек алган буржуаз моральне, икейөзлелекне ярсый-ярсый фаш итте:

**Бозыклык, ялган, ачу күрәм**
**Хәкыйкать, гыйффәт, мәхәббәт эчендә!**

«Дөньяга», «Пигамбәр», «Көлсеннәр», «Күңелле булмадым...», «Кеше» һ. б. кебек әсәрләрендә дә чорның көчле трагик авазы яңгырады. Рәмиевнең герое пассив рәвештә газапланып яшь түгүче итеп түгел, ә явызлыкка ләгънәт очкыннарын бөркеп, актив рәвештә протест белдергән ярсулы герой итеп тасвирланды «Рәмиев трагик героеның җир һәм күк золымына нәфрәт белдергән горур тавышы татар поэзиясендә кеше, шәхес ирекен яклауның көчле бер мисалы булып, кыска бер вакыт эчендә яңгырап кына калмады, ә зур традициягә әверелеп, безнең поэзиядәге романтик герой үсешенә юнәлеш тә бирде»,— дип яза Гали Халит («Яңа гасыр поэзиясе», Казан, 1979, 102 бит).

Рәмиев шигырьләрендә бу титаник геройны сурәтләү шул ук вакытта аның үтә дә нечкә кичерешләрен, күңелендәге сизелер-сизелмәс хәрәкәт-үзгәрешләрне, нюансларны рәсемләп бирү белән аралаша («Минутлар»). Аның күңелендә бертуктаусыз елышынып торган капма-каршы хисләр өермәсе бөтерелә:

**Торам, әрним, кинәт сөйнәм,**
**Тагы каным кибеп көйнәм;**
**Елаганда елый алмый,**
**Кара кан-яшемә тойләм.**

(«Кеше», 1909)

Туктаусыз янып, сызлап торган күңел көче аңа өмет, юаныч һәм дәрт бирә («Сызла, күңлем!» һ. б.).

Кешене рухи гариплэндергән мөнәсәбәтләргә каршы эмоциональ дөньясы бай булган гүзәл кеше идеалын алга сөреп, Рәмиев музыка сәнгатен киң пропагандалады, бу турыда күп кенә мәкаләләр язды.

Рухи сферага, кешенең күңел дөньясына зур игътибар бирү, хис-тойгы культы сүз сәнгатендә эмоциональ башлангычның кискен көчәюенә китерде. Ә бу хәл исә чынбарлыкны чагылдыруда экспрессия, гипербола, сурәтне гадәттән тыш көчәйтү, үткенәйтү принципларын үзәккә куйды.

С. Рәмиев поэзиясендәге кайнар лиризмның шушы үзенчәлегенә игътибар итеп, Г. Ибраһимов болай дип язды: «Хәятта булган бер вакыйга, бер күренеш тәэсире илә аның йөрәген ут ала, рухына ялкын тулып, күңеле ашкына; шуннан соң ул, шигырь чыгаруны уйламастан, үзен-үзе оныткан хәлдә, кулына каләм ала да язарга тотына. Шуннан соң аның укучының рухын да ялкынга әйләндерер дәрәҗәдә куәтле булган шигырьләре туа... Сәгыйтьнең бөтен шигырендә гомуми булган бер сыйфат бар: аның хиссиятенең һәр тугрыда һәрвакыт үтә куәтле, үтә югары булучылык» (Әсәрләр, сигез томда, 5 т., Казан, 1978, 78, 89 бб.).

Заман никадәр генә караңгы, өметсез булып күренмәсен, шагыйрь күңелендә өмет чаткысы сүнми, әсәрләрендә якты көннәрнең килүенә ныклы ышаныч яңгырый:

> **Бу яшем, юк, җиргә сеңмәс,**
> **Бу калыр, бу ялтырар!**
> **Һәм караңгы көн бетеп бер**
> **Мәңге якты ай туар!**
>
> («Дөньяга»)

Рухы көчле геройларны эзләп, Рәмиев рус һәм Европа романтик поэзиясенә дә мөрәҗәгать итте. М. Ю. Лермонтовның Ф. Шиллердан алып язган «Перчатка» балладасы тәрҗемәсе (1910) шундыйлардан иде. Рәмиев поэзиясенең Байрон, Шиллер, Лермонтов кебек романтик шагыйрьләр иҗаты белән типологик охшаш, уртак яклары байтак. Бу хәл белгечләрнең игътибарын күптән җәлеп итеп килә. Рәмиев поэзиясе, дип язды академик П. С. Коган 1927 елда,—«Леопардиның кайгылы җырларын, яисә Байронның ләгънәтләрен хәтерләтә торган поэзия... Аңарда кайчакларда Кабил белән Прометейның баш күтәрү һәм протест рухы кузгала». Соңрак (1914 елда) Рәмиев Лермонтов шигырьләреннән янә берничә парча тәрҗемә итте һәм аның тормышы, иҗаты турында мәкаләләр бастырды.

1909—1910 елларда С. Рәмиев прозага да мөрәҗәгать итте: хикәяләрендә, тәмамланмый калган автобиографик повестенда байларның муллык эчендә типтерүләре белән ач-ялангач хезмәт ияләренең, җирсезлектән интеккән крестьяннарның ачы язмышы арасындагы контрастны сурәтләде. Аларда гади халыкка тирән теләктәшлек сизелеп торды. «Минем халкыбызга булган бигрәк артык мәхәббәтем һәм минем халкыбызда күргән бер матурлыкка бигрәк артык гыйшкым,—дип язды әдип 1910 елда,—ихтыярымны үз кулымнан ала һәм шундый кыяматләр булып, гарәсатлар купканда да, мин рухымда тулган хиссиятемне телем белән дә кычкырып зикер итмичә сабыр итә алмыйм. Мин аны әйтәмен һәм кабат-кабат әйтәмен».

Бу елда аны Әстерханга, «Идел» газетасына секретарь итеп чакырып алалар. Ул тиз арада бу газетаның фактик редакторына әверелеп, аның телен халыкка якынайта, газета битләрендә милләтләр дуслыгы, мәгърифәт, әдәбият-сәнгать һ. б. мәсьәләләр буенча киң эшчәнлек җәелдерә. Әстерханда сөргендә булган әзербәйҗан революционеры, драматург, врач Н. Нәриманов һ. б. алдынгы яшьләр белән якыннан аралашып, иҗтимагый-культура эшләренә актив катнаша. Н. Нәриманов, Х. Ямашев кебек ленинчы революционерларның эшчәнлеген, Л. Н. Толстой, М. Горький, Г. Ибраһимов кебек язучыларның иҗатын пропагандалый. Г. Тукайны үз янына чакырып алып, аны дәвалау, сәламәтлеген ныгыту өчен күп тырышлык куя.

1914 елда «политик ышанычсызлыгы белән танылган эшлекле» дип, Әстерханнан сөрелгән Рәмиев Уфага күчә. Бирегә аның поэтик иҗаты янә сизелерлек активлаша. «Аң» журналында, «Тормыш» газетасында басылган шигырьләрендә ул кешенең ирекле уй-фикер йөртергә, бертуктаусыз хакыйкать эзләргә хакын даулый, тарихның алга таба туктаусыз хәрәкәт итүен һәм деспотизмның һәлакәте котылгысыз булуын раслый. Ул янә рус әдәбиятына мөрәҗәгать итеп, татар поэзиясен яңа идея-тематик казанышлар белән баетты. Аның Н. А. Некрасовтан һәм Щепкина-Куперниктан алып язган «Аналар» һәм «Күлмәк җыры» шигырьләре талау сугышына карата нәфрәт, сугышка көчләп куылган гади кешеләр өчен тирәнтен борчылу тойгысы белән сугарылган иде. Большевик шагыйрь Демьян Бедныйдан тәрҗемә ителгән «Сука белән Пушка» мәсәлендә иҗади хезмәт һәм ерткычлык, җимерү көчләре арасындагы ба-

хәстә сугыш, ерткычлык көчләренең җиңеләчәге, тыныч хезмәтнең җир йөзендә мәңге тантана итәчәге күрсәтелә, хезмәт иясенә дан җырлана.

Бу тәрҗемәләр татар поэзиясендә империалистик сугышка каршы агымны башлап җибәргән әсәрләрдән иде. «Рус әдәбият даһиларының шигырьләре С. Рәмиев каләме аша татарча яңгырап киткәндә тәрҗемә булып түгел, бәлки чын-чыннан оригинал, тәэсирләре белән үз күңел түреннән кайнап чыккан чын үз тойгысы, үз кичерешләре булып гәүдәләнә,— дип яза Х. Госман. Шигырьләрнең пөхтәләп эшләнгән һәм андагы сүзләрнең, энҗе бөртекләредәй, нәфисләп тезелгән булулары — болар барысы бергә укучыда тирән эстетик ләззәт тойгысы, күңел рәхәтлеге уята», С. Рәмиевнең бу шигырьләре «халык арасында бик нык таралып, популяр җырга әйләнеп киткән иде»,— дип искә ала Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи Кудаш.

Социалистик революциядән соң Рәмиев Верхне-Уральск, Чиләбе, Уфа шәһәрләрендә совет оешмаларында җаваплы эшләрдә эшли, азатлык идеяләре белән рухланып, Р. Джованьолиның «Спартак» романын, халыкара эшчеләр хәрәкәте гимны «Интернационал»ны тәрҗемә итә, «Мәсихы хөррият» һ. б. әсәрләрен яза.

Ләкин озакка сузылган каты авыру аның гомерен кисә. Шагыйрьнең вафаты турында «Правда», «Известия» (1926, 21 март) һ. б. үзәк газеталар язып чыгалар. Төрле милли телләрдәге газета-журналларда басылган күп санлы мәкаләләрдә Рәмиевнең вафаты татар әдәбияты өчен зур тарихи югалту итеп карала. «Әдәбият күгендәге күп йолдызлар арасында синең йолдызың да һәрвакыт ялтырап торыр. Шуны күргән саен сине искә төшерерләр, онытмаслар...» дим, тыныч бул, Сәгыйть!»—дип язды халык шагыйре М. Гафури.

С. Рәмиев әсәрләренә Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Гобәйдуллин, Ш. Әхмәдиев, Д. Юлтый, С. Кудаш һ. б. әдипләр, А. Н. Самойлович, П. С. Коган кебек күренекле галимнәр югары бәя бирделәр. Аның иҗат мирасын барлау һәм өйрәнүгә Г. Сәгъди, М. Гали, М. Гайнуллин, Җ. Вәзиева, Х. Госман, Г. Халит һ. б. белгечләр зур өлеш керттеләр. Күп кенә шигырьләре төрле елларда тәрҗемә ителеп басыла килде, «Татар поэзиясе антологиясе»ндә, Бөтен дөнья әдәбияты китапханәсе сериясендә урын алды.

Шагыйрьнең романтик мотивлары, аның шигырь төзелешенә керткән яңалыклары С. Сүнчәләй, Ш. Бабич, Н. Исәнбәт, аеруча Һади Такташ иҗатында үстерелде.

С. Рәмиевкә багышлап язган шигырендә С. Сүнчәләй болай дигән иде:

**Син дә үлдең, әй бөек, дәртле шагыйрь!**
**Син дә күз йомдың вә киттең дөньядан.**
**Сагышың ямьле, кадерле матәмең.**
**Шигырең онтылмас күңелдән күп заман.**
**Гөл чәчәкләр кабрең өстендә үсәр.**
**Күп дәверләр җилләр искәндәй үтәр.**
**Ни заман иршер сәгадәткә җиһан—**
**Яд итәр сагынып сине шунда бәшәр.**

Бу сүзләрнең хаклыгын тарих раслады инде. С. Рәмиевнең «инсаният вә хөррият» турындагы, бәхет, гүзәл кеше турындагы гуманистик романтик идеаллары безнең социалистик Ватаныбызда тормышка ашты, чынбарлыкка әверелде. Сәгадәткә, бәхеткә ирешкән илебез, халкыбыз, үзенең атаклы әдип һәм шагыйрьләре белән бергә, С. Рәмиевне дә күңелендә саклап киләчәккә илтә.

**ШӘЙХИ САДРЕТДИНОВ,**
**филология фәннәре кандидаты, доцент.**

Сәвия Михайлова

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МӘГЪРИФӘТЧЕ УЛЫ

Мәдәниятебезне һәм мәгърифәтебезне үстерү юлында фидаиләрчә эшләгән, исемнәре тарихыбыз сәхифәләрендә алтын хәрефләр белән язылырга лаеклы шәхесләр бар. Бөтен тормышын һәм эшчәнлеген халыкка намуслы хезмәт итүгә багышлаган, татарлардан беренче булып адъюнкт-профессор дәрәҗәсенә ирешкән Ибраһим Исхак улы Хәлфин — әнә шундыйларның берсе. Ул зур традицияләре булган укытучылар гаиләсендә тәрбияләнә. Бабасы Сәгыйть һәм әтисе Исхак кул астында бик яхшы белем алган 22 яшьлек Ибраһим Казанның I нче гимназиясенә татар теле укытучысы итеп билгеләнә. Университет ачылгач, анда татар теле буенча лекцияләр укый, ә 1823 елда адъюнкт-профессор дәрәҗәсен ала. Бу мәртәбәне Хәлфин үзенең фән һәм мәгариф өлкәсендәге фидакарь хезмәтләре белән аклый.

Хәлфин үз чоры өчен алдынгы педагогик ысулларны кулланып, татар теле һәм башка көнчыгыш телләре укытуны яңа баскычка күтәрә. Аның гадәттән тыш күпкырлы эшчәнлеге Сәгыйть, Исхак һәм Исмәгыйль Хәлфиннәрнең мәгърифәт тарату өлкәсендәге утыз еллык тәҗрибәсе белән, алар төзегән уку әсбаплары һәм кулланмалар белән тыгыз бәйләнгән.

Гади укытучы гына булмый Ибраһим. Күңелләрне агартучы остаз дәрәҗәсенә халык аны үзе күтәрә. Хәлфин халкының милли горурлыгы һәм алдынгы омтылышлары гәүдәләнеше булып, рус белән «тел, логать, әхлак вә гадәт алмашып» яшәвенә турыдан-туры булышлык итә.

Яшь укытучыга Казан гимназиясенең чәчәк аткан еллары, Россиядә дөньяви белемнәр бирүче башка урта уку йортлары арасында лаеклы урын алып торган бер чоры туры килә. Ул иң әүвәл татар классында белем алучыларның санын арттырыга игътибар итә. 1803 елда гимназиядәге 159 укучының 12 се татар классына йөри. Бу сан 21 гә, хәтта 35 кә җиткән чаклар була. Гимназия советы да Хәлфиннең укытучылык сәләтенә, башкарган эшләренә күз йомып кала алмый. 1804 елда Казан укыту округы попечителе С. Румовский аны тырыш хезмәте өчен бүләкләүгә тәкъдим итәргә мәҗбүр була.

Татар теле укытуны ачыктан-ачык тыя алмасалар да, патша чиновниклары бу дәресләргә, күп дигәндә, 6—8 кешене генә җәлеп итәргә, «файдасыз фән»гә өйрәтеп башкаларның вакытын алмаска кушалар. Аңлашыла ки, патша хөкүмәте татар классы укучыларын җирле халыкның аң-белемнәрен күтәрү, фән һәм культурасын үстерү эшендә файдалану турында уена да китерми, фәкать тел белүче эшкуарлар һәм миссионерлар әзерләү максатын гына күздә тота. Мондый шартларда укучылар санын арттыра бару, өстәвенә аларны гарәп, төрек телләренә дә өйрәтүгә күпме кыюлык һәм тәвәккәллек кирәк булгандыр!

И. Хәлфин зур тырышлык куеп, татар теле дәресләренең атнага дүрт тапкыр укытылуына ирешә. Уку әсбапларының азлыгын истә тотып, ул 1804 елда «Шаһиншаһның Казан гимназиясендә лисан төрки вә хатт гарәби үгрәтелә торган әлифба илә кечекчә нәху вә сарафыдыр» исемле дәреслек төзи. Попечитель бу китапны гарәп, төрек һәм фарсы телләрен өйрәтү өчен бик кирәкле, бик ышанычлы кулланма дип бәяли һәм бастырып чыгарырга тәкъдим итә. Дәреслектәге материалларның русчага тәрҗемә белән бирелүенә дә игътибарны юнәлтеп, попечитель мондый китапларның Казан, Оренбург, Әстерхан училищеларында укыту өчен генә түгел, көнчыгыш халыклары белән сәүдә эшләрен оештыруда да файдалы икәнлеген күрсәтә.[1]

1804 елның 2 маенда Ибраһим Хәлфиннең беренче хезмәтен бастыруга рөхсәт алына. Тиздән «Азиат» типографиясендә 1200 данә «Әлифба илә кечекчә нәху...» басылып чыга. Ул заманнар өчен мондый тираж, әлбәттә, бик зур. Бу китап озак еллар дәвамында татар телен өйрәнү буенча төп

[1] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 92 нче фонд, I нче тасвирлама, саклау берәмлеге 46, 2 нче бит.

уку әсбабы вазифасын башкара. Хәлфин аны татар классы укучыларын гарәп һәм төрек телләренә өйрәткәндә дә куллана.

Мәгълүм булганча, бөтен дөньяга танылган гарәп теле белгече Сильвестер де Сасиның «Гарәп грамматикасы» 1810 елда гына Парижда басылып чыга. Гомумән, XVIII гасырның икенче яртысында һәм XIX гасыр башында Көнбатыш Европада көнчыгыш телләре буенча дәреслекләр һәм уку әсбапларына зур кытлык сизелә. Шуңа күрә И. Хәлфиннең әлеге үзенчәлекле китабы, Сагыйть Хәлфин хезмәтләре белән бергә, Европада шушындый төрдәге иң беренче һәм мөһим басмаларның берсе була. Ул чорда татар теле бик күп көнчыгыш телләрен өйрәнүгә ачкыч хезмәтен үти. Аны төрки телләрнең «алтын урталыгы», дипломатик мөнәсәбәтләр теле дип тә саныйлар.

Ибраһим Хәлфин — туган телен генә түгел, рус, гарәп, фарсы һәм латин телләрен яхшы белгән, зур мәгълүматлы һәм киң карашлы галим. Берничә тел белү аңа дәресләрне кызыклы, җанлы итеп, югары фәнни дәрәҗәдә үткәрергә мөмкинлек биргән. Хәлфин татар телен милли киртәләр белән чикләнмәгән хәлдә, башка телләр белән бәйләнештә һәм комплекслы рәвештә өйрәнү бердәнбер дөрес юл дип санаган. Укучыларына тәрҗемә күнекмәләре бирү өчен ул дәрестә русча текстларны актив кулланган, татар теле закончалыкларын тирәнрәк үзләштерү максатында төрек теленә күнегүләр эшләргә тәкъдим иткән.

Хәлфин методикасын башкалардан аерып торучы янә бер сыйфат — тел дәресләрен тарих белән бәйләнештә өйрәнүгә зур игътибар бирелүе. Ул халыкның теле белән тарихы табигый рәвештә бәйләнгән дип саный. Ләкин мондый караш патша хөкүмәте куйган киртәләрдән чыга, көнчыгыш телләре укытучысы тарих белән әдәбиятны урап үтәргә тиеш, дигән катгый күрсәтмәләргә каршы килә.

Устав һәм инструкцияләр нигезендә, белем бирү системасы укучыларда христиан диненә тугрылык, патша хөкүмәтенең аллә кодрәте белән урнаштырылуына иман тәрбияләүгә буйсындырыла. Казан укыту округы попечителе карагруһчы Магницкий, шәрык телләрен бары Россиягә сәүдә һәм политик элемтәләр урнаштыруда булышу максаты белән генә өйрәтергә мөмкин, дип кисәтә. Аның күрсәтмәсе буенча, укучыларга гарәпләрнең тарихы кеше ышанмаслык буш риваятьләрдән тора, аларның бөтен гыйлеме греклардан гына үзләштерелгән, дип аңлатырга кирәк була [1].

Менә шундый шартларда да Ибраһим Хәлфин югалып калмый, Илья Яковкинның Россия тарихына багышланган китабын һәм үзенең тарих буенча язмаларын турыдан-туры уку әсбаплары итеп файдалана. Гарәп, фарсы һәм төрек китапларының катлаулы эчтәлеген аңлатканда ул аларның язылу тарихына, иле һәм халкы тарихына җентекләп туктала. Әлбәттә, мондый эшкә алдын-артын карап йөрүче һәм инспектордан: «Лектор Хәлфиннең укучылары барысы да тырышып укый. Укытучы үзе бик әйбәт»,— дигән нәтиҗә ясата алырлык кеше генә батырчылык итә ала. Хәтта патша хөкүмәтенең тышкы эшләр министры да көнчыгыш телләрен укытуда Хәлфиннең зур осталыгын танырга мәҗбүр була.

И. Хәлфин халкының теле һәм рухи байлыгы белән горурланган, тарихына зур хөрмәт белән караган, борынгыдан калган истәлекләрне кыйммәтле хәзинә дип атаган. Аның тарафыннан «Азиат» типографиясендә бастырылган күп санлы мөрәҗәгать һәм игъланнар да шул турыда сөйли. Хәлфин татарларны үз телләрен һәм тарихларын өйрәнергә, белем алырга өнди, гимназиядә һәм университетта үткәрелә торган тантаналы кичәләргә, концертларга чакыра. Бу тырышлык бушка китми. Инде XIX гасырның 20 нче — 30 нчы елларында татар, башкорт, калмык, бурят, монголлар арасыннан беренче укучылар һәм студентлар барлыкка килә.

Бер үк вакытта Ибраһим Хәлфин укыту процессын камилләштерү юллары турында да даими кайгыртучанлык күрсәтә. Аның татар классын өч сыйныфка бүлү тәкъдиме, мәсәлән, әлеге юнәлештә тагын да нәтиҗәлерәк эшләү юлларын ача һәм соңыннан университетта төзелгән Көнчыгыш факультетына ышанычлы нигез була.

Көнчыгыш телләрен укыту, билгеле, төрле дәреслекләр булдыруны, тарихи һәм лингвистик хезмәтләр иҗат итүне дә көн тәртибенә куя. Әнә шуңа күрә Ибраһим Хәлфиннең укытучылык эшчәнлеге белән фәнни эзләнүләре аерылгысыз бәйләнгән. Ул Көнчыгыш һәм шул җөмләдән татар китапларын бастыру, пропагандалау эшенә зур өлеш кертә. Галим татар халкының кыйммәтле тарихи һәм әдәби ядкарьләрен саклап калу һәм фәнни тикшерү уе белән яна, төп иҗади эшчәнлеген шул ниятка юнәлдерә.

Хәлфиннең «Әхвәли Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» исемле кулъязмасын тикшерүдә Казандагы Көнчыгыш белгечләре бик кызыксынып катнашалар. Х. М. Френ шәкерте Я. О. Ярцев аңа югары бәя бирә: «Бу хезмәт — тарихи язмаларны бастырып чыгаруы белән дә, аларны укуны җиңеләйтү белән дә төрек вә татар телен өйрәнүчеләр өчен гаять файдалы һәм кирәкле. Сүзлек өлешендә инде гамәлдән төшеп калган, яңа төрки китапларда очрамый торган борынгы сүзләр һәм тәгъбирләрнең дөрес һәм тулы аңлатылуы белән дә хезмәт әһәмиятле... Моннан тыш бу хезмәт үзенең яңалыгы белән генә дә Советның (университет Советының — С. М.) игътибарына һәм югары бәясенә лаеклы» [2].

«Әхвәли Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» 1819 елда татарча, 1822 елда русча басылып чыга һәм көнчыгыш телләре өйрәтелә торган уку йортларында дәреслек рәвешендә тәкъдим ителә. Әмма әлеге китапны бастыруда Ибраһим Хәлфин фәнни һәм иҗтимагый яктан да мөһимрәк мак-

[1] Ленинградның Үзәк Дәүләт тарихы архивы, 733 нче фонд, 39 нчы тасвирлама, саклау берәмлеге 312, 34—35 битләр.

[2] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 92 нче фонд, саклау берәмлеге 377, 32 нче бит.

сатны күздә тота: ул халыкның төрле катлауларында тарихи үткәнебез белән җитди кызыксыну, борынгыдан калган ядкарьләрне җыю һәм саклау теләге уятырга омтыла. «Әхвәли Чыңгыз хан...» мөселман халыклары тарафыннан зур кызыксыну белән кабул ителә.

Хәлфин хезмәтенең гадәттән тыш фәнни кыйммәте — борынгыдан килгән бик мөһим һәм сирәк очрый торган тарихи язмаларны туплаган җыентык характерында булуында. Шуңа күрә Х. М. Френның Хәлфин кульъязмасы белән танышканда ук андагы борынгы әсәрләр белән кызыксынуы, алардан өзекләр алып үзенең Болгар дәүләте һәм Биләр каласы турындагы мәкаләсенә кертүе дә очраклы хәл түгел. (Ул мәкалә 1816 елда Көнбатыш Европа ориенталистларының Венада чыга торган журналында басыла.) Ләкин, аянычка каршы, Френ соңрак, инде Петербургтан торып, әлеге өзекләрне Хәлфиннең үз китабына керттерми.

Н. Г. Чернышевский һәм Н. А. Добролюбов җитәкчелегендәге революцион-демократик рухтагы «Современник» журналы да өлешчә Хәлфиннең әлеге җыентыгындагы материаллардан файдаланып язылган мәкалә бастыра (1860 ел, XXXI том).

И. Хәлфин борынгы чыганакларны бик яхшы белә. Бу аның Френ белән бергә шул ук Вена журналында Тимер Котлыг тархан ярлыгын бастыруга әзерләвендә дә, гомумән, барлык фәнни эшчәнлегендә дә ачык күренә.

Ибраһим Хәлфиннең фәнни-тикшеренү хезмәтләре Көнбатыш Европада да киң тарала һәм таныла. Уникаль тарихи документлар җыелмасы буларак аның хезмәтләре Көнчыгышны өйрәнүчеләр өчен кыйммәтле фәнни чыганакка әверелә. Татар галименең тикшерү эшчәнлеге Россиядә генә түгел, Көнбатыш Европада да татар тарихи язмаларын бастырып чыгару эшенә нигез сала. И. Хәлфин тапкан һәм фәнни яктан эшкәрткән «Әмәт дастаны» исемле борынгы әсәр Көнбатыш Европа белгечләре тарафыннан аеруча югары бәя ала.

Күренекле немец ориенталисты Иозеф Һаммер, мәсәлән, борынгы көнчыгыш чыганакларын эзләп табуда һәм фәнни шәрехләүдә И. Хәлфиннең хезмәте Френныкына караганда зуррак булуын күрсәтә. Ул борынгы язма истәлекләрне җыю һәм фәнни эшкәртү принциплары мәсьәләсендә әлеге ике зур галим арасында барган бәхәсне белә һәм Хәлфинне хаклырак дип саный. Эш процессында Һаммер үзе татар галиме билгеләгән принципларга таяна. Аның хезмәтләре аша Карл Маркс һәм Фридрих Энгельс та Ибраһим Хәлфин эшчәнлегенең кайбер нәтиҗәләре белән таныш булалар.[1]

Борынгы төрки-татар һәм башка көнчыгыш телләрендәге чыганакларның күбесе Россиядә булганлыктан, Хәлфин хезмәтләре Көнбатыш Европа галимнәре өчен беренче чыганак булып та торалар. Профессор Р. И. Нәфиков 1861 һәм 1863 елларда Н. И. Ильминскийга төрек һәм татар телләрен өйрәнүче Америка галиме Отто Рериг язган ике кызыклы хат табылуы турында хәбәр итте. Отто Рериг бу хатларында Көнчыгышны өйрәнүче Казан галимнәренең, аерым алганда, Ибраһим Хәлфиннең хезмәтләрен җибәрүне үтенгән.

Үзенең фәнни-тикшеренү эшчәнлеге белән И. Хәлфин Россиядә дә киң танылган абруйлы галим була. А. Казембек, Ф. Эрдман, И. Н. Березин, Н. Ф. Катанов аның хезмәтләренә еш мөрәҗәгать итәләр. И. Хәлфин дөньяга чыгарган тарихи истәлекләр бүген дә зур фәнни әһәмиятен җуймый.

Галимнең бик күп алдынгы карашлы чордашлары белән таныш булуы һәм хезмәттәшлек итүе дә мәгълүм. Атаклы профессор Карл Фукс белән элемтәсе аның иҗади эшчәнлегендә зур урын алып тора. Ике галимне татар халкының тарихы һәм тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре белән кызыксыну, гади халык интереслары белән яшәү берләштергән.

И. Хәлфин Казан университеты китапханәсенә Көнчыгыш галимнәренең һәм язучыларының сирәк очрый торган әсәрләрен, кульъязмаларын туплау юнәлешендә дә зур эш башкара. 1826 елда, мәсәлән, ул китапханәгә башка гарәп-төрек-татар китаплары белән бергә бөек Әбу Гали Ибн-Синаның табылдык һәм фәлсәфи хезмәтләрен алдыру хәстәрен күрә. Димәк, укытучы-галим әлеге хәзинәдән үзенең дәресләрендә дә уңышлы файдалангандыр дип фараз кылырга урын бар.

Совет академигы, Россиянең революциягә кадәрге тарихы буенча күренекле белгеч М. Н. Тихомиров: «Идел буе татарлары һәм болгарларының тарихы искиткеч зур мәгънәгә ия. Без аны өйрәнми торып, Россиянең Шәрык белән элемтәләрен беркайчан да аңлый алмыйбыз,— дип яза.— Гүзәл, көчле, талантлы, эшчән, кыю татар халкының тарихы уртак, халыкара тарихтагы зур әһәмияте белән бергә җәлеп итә».

Менә шушы халык үткән юлны өйрәнүдә киң карашлы галим Ибраһим Хәлфиннең дә өлеше бик зур.

И. Хәлфиннең гыйлеме, фәнни эрудициясе, кайнар йөрәге патша хөкүмәте мәнфәгатьләренә түгел, халыкка хезмәт итә. Бу аның иҗтимагый-политик, мәгърифәтчелек эшчәнлегендә аеруча ачык күренә.

Мәгърифәтчелек хәрәкәте үзенең башлангычында халык белән якынаю, аның киң катламнары арасында аң-белем тарату, борынгыдан килгән матур йола-гадәтләрне өйрәнү һәм үстерү максатын күздә тота. Ә Ибраһим Хәлфин милли кысаларда гына чикләнеп калмыйча, интернациональ рухтагы гадәттән тыш кыю һәм мөһим бер идеяне алга үткәрә: университетта татар теле өйрәнүче студентларны халык арасында мәгърифәтчелек эше алып баруга җәлеп итәргә кирәк дип саный. Бер үк вакытта әлеге студентлар татар бистәләрендә яшәп, халыкның телен һәм гореф-гадәтләрен яхшырак үзләштерү мөмкинлеге дә алырлар иде, ди ул. Бу идея, безнең уебызча, укытучы-галимнең беренчеләрдән булып мәгърифәтчелек эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә

[1] Бу хакта «Казан утлары»ның 1971 елгы 7 нче санында басылган мәкаләбездә тулырак мәгълүматлар китерелә.

омтылучылар сафына басуын раслый. Ул конкрет тәкъдим кертеп кенә калмый, аны тормышка ашыру өчен дә зур тырышлык куя. 1820 елның 9 февралендә Хәлфин университет ректоры профессор Солнцевка һәм аның аша университет Советына мөрәҗәгать итеп, татарлар арасында дөньяви белемнәр таратуның төп юлларын күрсәтә һәм милли мәктәпләр ачу мәсьәләсен күтәрә.[1]

Россия югары уку йортларында дөньяви белем алган татарларның азлыгы халыкның үз гаебе белән түгел, ә патша хөкүмәтенең колониаль политикасы нәтиҗәсендә килеп чыгуын аңлаган хәлдә, И. Хәлфин мәгърифәтчелек эшендә татар телен белүче руслардан файдалану мөмкинлегенә зур өмет баглый. Ул шушы максаттан чыгып, университетта көнчыгыш телләрен үзләштерүче студентлардан Петр Юнаков һәм Александр Бовинны сайлап ала, аларга татар бистәсендә яшәү өчен шартлар тудыруны үтенә. Ректор һәм университет Советы тарафыннан Хәлфиннең тәкъдиме хуплана. Әмма Магницкий моңа кискен каршы чыга: «Мин хәтта гаҗәпкә калам: ничек инде ул галим-голәмәләр җыелышында император университеты студентларын татарларга өйрәнергә бирү хакында фикер туа һәм шул фикер бердәм килешү белән кабул ителә алган!»— дип яза ул.

Попечительнең катгый ризасызлыгына карамастан, үз уеннан кире кайтмау өчен чын мәгънәсендә нык ихтыяр көче, изге максатка бөтен күңелеңне баглау кирәк.

1822 һәм 1824 елларда Тобол һәм Томск губернаторы рухани эшләр һәм халык мәгарифе министрыннан берничә кешене укытучылык һөнәренә һәм татар теленә өйрәтү өчен Казанда укытырга рөхсәт сорый. Хөкүмәт интересларына туры килгәнлектән, бу үтенечләргә уңай җавап бирелә. Ләкин шуңысы игътибарга лаек, патша хезмәтчесе— губернатор ике хатында да адъюнкт-професссор Ибраһим Хәлфинне гыйлем иясе һәм укытучы буларак танырга мәҗбүр була, нәкъ менә ул җитәкләгән татар классын сайлап ала. Шул үтенеч нигезендә Казан гимназиясенә кабул ителгән укучылар арасында ике мөселман баласы да була. Әмма патша чиновникларының «мәрхәмәте» бик тиз чикләнә: университет тәртипләре буенча мөселманнар христианнар белән бергә тора алмый дигән булып, Бикмаев белән Корбанаковны гимназия торагына урнаштырмыйлар. Шундый катлаулы вакытта, материаль хәле бик авыр булуга карамастан, И. Хәлфин аларны үз өендә яшәтергә, татар теле буенча өстәмә дәресләр дә бирергә теләвен белдерә. Губернатор Канцевич моңа каршы төшми төшүен, шулай да укытучының артык илтифатыннан һәм йогынтысыннан куркып, гимназия җитәкчелегеннән Бикмаев белән Корбанаковка күз-колак булып торуны таләп итә [2].

Хәлфин Казан комендантына үзе барып әлеге укучылар өчен кием-салым юллый, аларны көнчыгыш телләренә бик яхшы өйрәтә һәм университетка керүләренә һәръяклап ярдәм итә.

Ибраһим Хәлфиннең әтрафлы һәм кыю мәгърифәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәсендә татарларның бер өлеше иске мәдрәсәләргә тәнкыйди күз белән карый башлый, заман сулышына сизгеррәк күңелләрне югары белем алуга юл ачарлык татар мәктәпләре төзү идеясен били. XIX гасырның 20 нче — 30 нчы елларында гына да татар халкы өчен дөньяви мәктәпләр оештыруның биш проекты тәкъдим ителә, ләкин аларның һәркайсы патша хөкүмәтенең каты маңгаена бәрелеп чәлпәрәмә килә.

Университет профессоры П. С. Кондырев проектын гамәлгә ашыру өчен Ибраһим Хәлфин дә бик тырышып йөри, шунда ук татарча башлангыч белем дәреслекләре өчен тәрҗемә эшенә керешә.

Кондыревның сүзләренә караганда, Ибраһим татар балаларын булачак училищега керергә әзерләү өчен үзе пансион оештырырга да уйлап йөргән. Ләкин бу проектка халык мәгарифе министры А. Голицын каршы төшә.

Билгеле, милли мәктәпләр ачу өчен көрәш әле гомуми, стихияле рәвештә бара, сыйнфый характерда үсми. Әмма И. Хәлфиннең үз чоры өчен прогрессив булган һәр адымны хуплавы, шул көрәшнең алгы сафында атлавы зур игътибарга һәм хөрмәткә лаек.

Галим һәм укытучы Ибраһим Хәлфин үзенең гаҗәп тыйнак һәм мәрхәмәтле кеше булуы белән дә сокландыра. Бер вакытта да шәхси мәнфәгатьләрен беренче планга куймаган ул. Гомере буе киеренке эштән аерылмаса да, хезмәт хакы очын-очка ялгап барырлык кына була.

1829 елның январенда, 51 яшендә, иҗади көчләре чәчәк аткан бер чорда Ибраһим Хәлфин вафат була. Аның гаиләсе шундый ярлылыкта кала ки, университет ярдәменнән башка җеназа уздырырлык та хәле булмый. Ректор Н. И. Лобачевский моны белгәч, «Хәлфинне күмү өчен 100 сум акча бирергә» куша [3]. Татар халкының галим улын соңгы юлга озатырга дуслары, хезмәттәшләре, студентлар һәм бистә кешеләре белән бергә университет ректоры профессор Лобачевский да килә.

Ибраһим Хәлфиннең күпъеллык эшчәнлеге эзсез югалмый. Вафатыннан соң да студентлар аның дәреслекләрен һәм хрестоматияләрен укып белем алалар, күренекле галимнәр кыйммәтле фәнни чыганак буларак аның хезмәтләренә таяналар.

Мәгърифәтче, галим, укытучы Ибраһим Хәлфин шәхесе татар халкының культурасы һәм алдынгы иҗтимагый фикере үсү юлында якты маяк булып тора.

---

[1] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 92 нче фонд, 1 нче тасвирлама, саклау берәмлеге 1186, 1 нче бит.

[2] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 92 нче фонд, 1 нче тасвирлама, саклау берәмлеге 1277, 22 нче бит.

[3] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 92 нче фонд, 1 нче тасвирлама, саклау берәмлеге 3003, 1 нче бит.

# КӨЛКЕНЕҢ ХИКМӘТЕ БАРДЫР

Соңгы елларда китап кибетләренә берсе артыннан берсе һәйбәт кәгазьдә басылып, яшькелт лидерин белән тышланган калын-калын китаплар чыга башлады. Алар—әкиятләр, табышмаклар, җырлар дип исемләнгәннәр. Менә күптән түгел генә үзенең кардәшләренә тагын берсе килеп кушылды. Монысы «Мәзәкләр»[1]. Боларның уртак исемнәре дә бар — «Татар халык иҗаты». Бу китапларны хәзерләп чыгаручыларның вәгъдәләренә караганда, татар халык иҗаты әсәрләре барысы унике том тәшкил итәргә һәм шушы якын елларда ук басылып тәмамланырга тиеш икән.

Халык иҗаты әсәрләренең аерым жанрлары махсус китапларга тупланып бездә сирәк кенә булса да узган гасырлардан бирле үк басылып килә. Сугыштан соңгы чорда татар халык әкиятләре икешәр том булып та чыккалады. Күпме генә тираж белән чыкмасын, халык иҗаты әсәрләре сатуга чыгу белән, комга сибелгән су кебек, шунда ук таралып бетәләр.

Әмма татар халык иҗаты әсәрләренең барлык жанрын да эченә алган тулы җыелманың моңа кадәр беркайчан да берьюлы басылганы юк иде әле. Бу хәл, ягъни халкыбызның тиңе булмаган күңел байлыгын җыеп алып, аны мәгълүм бер тәртипкә салып, фәнни аңлатмалар белән тәэмин итеп яңадан халыкның үзенә бүләк итеп кайтару мәдәни тормышыбызда гаять дәрәҗәдә истәлекле бер вакыйга дип әйтер идем. Шул ук вакытта моның гомуми культурабызның үсүен, аерым алганда нәшрият өлкәсенең ярыйсы ук алга атлавын раслый торган күркәм бер хезмәт булуын әйтеп үтәргә тиешбез.

Халыкның мең еллардан бирле күңелендә сакланган янсә Каюм бабай кебек халык җанлы, батыр йөрәкле мәгърифәтчеләр тарафыннан үз вакытында кәгазьгә теркәлеп калган бу җәүһәрләрнең тарихи әһәмияте һәм эстетик кыйммәте ифрат зур. Аларга халыкның гасырлар буенча буыннан буынга җыелып килгән рухи байлыгы, тормыш фәлсәфәсе, көнкүреш тәҗрибәсе һәм эстетик зәвыгы тупланган. Без аларны җентекләп өйрәнәбез, алардан әле хәзер дә эстетик ләззәт алабыз. Бу җыелмада басылып чыккан кайбер халык иҗаты жанрлары, мәсәлән, әкиятләр, дастаннар, легендалар, бәетләр яңадан тормышта беркайчан да кабатланмый торган кадерле уникаль әсәрләр булып калачаклар. Бу аларның кыйммәтен тагын да арттыра, аларга мөнәсәбәттә сак булырга, игътибарлы булырга тиеш икәнлегебезне искәртеп тора.

Билгеле, халык иҗаты әсәрләренең барлык жанрларын да бергә туплап һәм бер фәнни системага салып чыгару өчен аларны әүвәл башта халыктан җыеп алырга кирәк булды. Элекке елларда күбесенчә аерым галимнәр һәм язучылар тарафыннан башкарылып килгән бу җаваплы һәм катлаулы хезмәт кырыгынчы еллар башында бер үзәккә тупланып, аны мәгълүм бер системага кертүгә ирешелде. Казанда тел, әдәбият һәм тарих институты оешканнан соң, фольклор җыю шөгылен оештыруда филология фәннәре докторы Хәмит Ярминең хезмәте зур булуын искә алып үтәргә тиешбез. Гәрчә институт хезмәткәрләре булмасалар да, халык иҗатын җыюда һәм аны популярлаштыруда язучылардан Г. Толымбай (әкиятләр, бәетләр), Нәкый агз Исәнбәт (мәкальләр, мәзәкләр, балалар фольклоры) күренекле эшләр башкардылар. Бу мәкаләнең авторы да институтның күп санлы экспедицияләренә катнашкан һәм фольклорны үзлегеннән җыеп аларны китаплар рәвешендә халыкка җиткерү чарасын күрган иде.

«Мәзәкләр» китабын мин аеруча кызыксынып һәм, әйтергә кирәк, хәтта берникадәр шигаеп кулыма алдым. Чөнки мәзәкләр минем күптәнге «танышларым», мин аларны яшьтән үк җыя башлаган идем. Миңа бу бик оригиналь жанрның үзенә генә хас нечкәлекләренә кадәр өйрәнергә, халыктан җыелган «чи» хәлендәге мәзәк материалын әдәби эшкәртеп, аларны классик әдәбиятта яшәп килгән чын мәзәк стиленә буйсындырырга туры килгән иде. Шулай булгач, бик табигый, хезмәтем кергән һәр мәзәк миңа үз әсәрем кебек үк кадерле, мин аларның бозылып басылуын теләми идем. Шунлыктан, бу китапны кулыма алганда яшь галимнәр хезмәтенә билгеле бер шик һәм тәнкыйть күзе белән ка-

---

[1] Мәзәкләр. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы. Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты. Төзүчеләре Мәтмутов Х. Ш., Садыйкова А. И. Татарстан китап нәшрияты, 1979 ел.

равым бик табигый бер хәл булса кирәк. Бәхеткә каршы, китап белән танышу барышында күңелемдәге шигем акрынлап тарала барды. Гомумән алганда китапның эчтәлегеннән дә, шулай ук Хуҗиәхмәт Мәхмутовның кереш сүзеннән дә канәгать булып калдым. Урыны-урыны белән кайбер читкә тайпылуларны, мавыгып китүләрне искә алмаганда, китап яхшы оештырылган, тәгаен шушы жанрга хас үзенчәлекләргә ия булган, эчтәлеге һәм формасы ягыннан чын мәгънәсендә мәзәк дип аталырлык әсәрләрдән төзелгән. Китапка электән үк фольклор фондында саклаңган яисә борынгы басмаларда теркәлеп калган мәзәкләрдән башлап хәзерге заманда иҗат ителгәннәренә кадәр меңнән артык мәзәк кергән. Кыскасы, бу җыентыкка зур хезмәт куелган, нәтиҗәдә иземе җисеменә лаек булырдай бер кирәкле китап дөнья күргән.

Шулай да «Мәзәкләр» җыентыгын бер җәһәттән дә тел тидермәслек дәрәҗәдә камил эшләнгән дип үк әйтеп булмас иде. Мөмкин кадәр күбрәк мәзәк сыйдыру белән мавыгып кителгәнме, әллә мәзәкләрне сайлаганда игътибар җитенкерәмәгәнме, анысын әйтүе кыен, әмма кайбер бүлекләрдә бер үк эчтәлекле мәзәкләр күп кабатланган. Мәсәлән, «Чит тел белмәүчеләр» дигән бүлек бу яктан аеруча күзгә бәрелә. Бу китапка, кагыйдә буларак, халык иҗаты әсәрләренең тирән эчтәлекле, идея-эстетик кыйммәте ягыннан иң камилләре генә сайланып алынырга тиеш иде. Бер үк эчтәлеккә берничә әсәр туры килгән сурәттә, кагыйдә буларак, арадан иң яхшы дигәне генә китапка кертелә. Хәлбуки, бу бүлектәге кырык өч мәзәкнең уналтысы бер үк алым белән бер үк эчтәлекне кабатлый, уналтысында да вакыйга базарда бара, уналтысында да мәзәкләрнең эчтәлеге татар кешесенең рус сүзләрен ялгыш аңлавыннан көлүгә кайтып кала. Руб сорок — орып сугып (329 нчы мәзәк), овса — тапса (334 нче мәзәк), пшеница—печән исе (337 нче мәзәк) h. б.

Төзүчеләр һәр мәзәкнең хикмәтле эчтәлеге булырга тиешлегенә кирәгенчә әһәмият бирмәстән, мондый арзанлы көлүгә корылган куыш эчле мәзәкләргә башка бүлекләрдә дә шактый урын биргәннәр. Мәсәлән, ювелир магазины—юләр мәзин (1020 санлы мәзәк), Бибилятыйфа—библиотека (352 нче мәзәк), чәйнек-мәйнек, котелок-мателок, караваг-маравар (1150 нче мәзәк)ләрдәге кебек аваздаш сүзләрне үзара «чәкәштереп» көлке ясарга тырышылган. Дөрес, ара-тирә боларга охшаш мәзәкләр дә кайбер кешеләрне көлдерергә мөмкин. Шулай да мондый җитди китапта андыйлар белән мавыкмаска кирәк иде. Чөнки китапны чыгарудан максат ул түгел, чөнки акыллы фикергә, хикмәтле нәсыйхәткә нигезләнгән һәм тапкыр әйтемнәргә, үткен сүзләргә корылган чын халык мәзәкләре белән мондыйларның һич уртаклыгы юк. Мондыйлар кайбер озын телләр сөйли торган урам анекдотларына якын торалар. Мәгълүм булганча, урам анекдоты, мәзәк кебек, хикмәтле сүз әйтүне, теленең образлылыгы һәм тапкырлыгы белән тыңлаучыга эстетик ләззәт бирүне максат итеп куймый. Урам анекдотының эчтәлеге никадәр затсызрак, әдәпсезрәк булса, гадәттә ул шулкадәр эффектлырак исәпләнә. Ул шаркылдап, каһкаһалап көлүгә, көлдерү өчен көлүгә генә хезмәт итә. Кызганычка каршы, андый анекдотлар бу китапта да очрый. Моңа мисал итеп «Ихма» (593) дигән мәзәкне китерергә мөмкин:

«Базарда бер поп йөри икән. Кулларына икона тотып, ике карак шушы поп янына киләләр.

— Батюшка, менә бу алла анасы[1] бит?— ди берсе.

Икенче карак:

— Юк, бу «ихма»!—дип аңа каршы төшә.

Поп сумкасын куя да иконаны карый.

— Әйе, бу алла анасы,— ди ул. Шул арада беренче карак попның сумкасын эләктереп тә китә. Поп борылып карый да.

— Их-ма!— дип куя.

Икенче карак әйтә:

— Әйтәм бит мин сиңа, батюшка, «их-ма» бу дип,— ди.

«Ышанмаслык ялган» (502) дип аталганы да шундый ук. Монысында балыкчының үзе белән алып барган аракысын эчмичә кире алып кайтуы ышанмаслык хәлгә мисал итеп китерелә. Укучы исә шуннан көләргә тиеш була. Шуның өстенә, безнеңчә, поп турындагы мәзәкнең татар халык иҗаты булуын расларлык бер дәлил дә юк. Икенче мәзәккә килгәндә, эчкечелек турындагы мәзәкләр арасында шундый җиңелчә көлә, шаяртып бармак янау белән генә чикләнә торган битарафлары моннан башка да шактый күп очрый. Хәлбуки, бөтен дөнья статистика мәгълүматларына караганда, хәзерге заманда эчкечелек чире рак һәм кан юллары белән йөрәк авыруларыннан кала өченче урынга менгән. Димәк, бу инде җитди мәсьәлә, аңа карата болай җиңелчә шаяртып узу белән генә чикләнә алмыйбыз. Исереклеккә, эчүчелеккә карата көчле юмор, көйдергеч сатира кулланырга тиеш булабыз. Кызганычка каршы, җыентыкта бу принцип сакланып җитмәгән.

Гомумән, мәзәкләрне сайлаганда әнә шундый арзанлы сүз уйнатуга корылганнарын, «тешсезләрен», художество эшләнеше ягыннан сәнгать һәм әдәбият бакчасына керергә хаклары булмыйча, бусаганың тышкы ягында калырга тиешле куыш эчләрен китапка кертмәскә кирәк иде.

Билгеле, Фәннәр Академиясе филиалы исеменнән чыгарылган мондый җитди басма һәр җәһәттән җентекләп эшләнгән булырга, анда кимчелекләр, төгәлсезлекләр, гомумән һәр төрле җитешсезлекләр берничек тә җибәрелмәскә тиеш иде. Ләкин, кызганычка каршы, кимчелекләрнең бөтен төрләре дә очраштыргалый. Шундыйларның берсе төзүчеләргә вариантлар сайлаганда таләпчәнлек җитеп бетмәүдән килә дип әйтер идем. Мәсәлән, «Үзе белмәгәч» дигән мәзәк (659 нчы) 260 нчы биттә «Аңлаганга аңларлык» дигән исем белән кабат-

[1] Татар халкында алла анасы түгел, Мәрьям ана дип йөртелә.

лап басылган. Житмәсә, икенче вариант әдәп кагыйдәләренә дә җавап бирердәй түгел.

Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, китапка әсәрнең мәзәккә хас булмаган артык детальләр һәм буш сөйләнүләрдән арындырылган, чын халык мәзәге стилендә әдәби эшкәртелгән җыйнак, тапкыр телле вариантын сайлап алу кирәк иде. Монда исә шуның нәкъ киресе, әдәби яктан эшләнеп җитмәгән, кирәкмәгән сүзләр, детальләр белән чуарланган вариантны кертү очраклары күренгәли (780 һәм 898 нче мәзәкләр).

Хуҗа Насретдин мәзәкләре узган гасырлардан бирле үк гадәттә аерым басылып киләләр иде. Китапка мәзәкләрнең бу төре дә кертелгән. Кереш сүздә бу хакта шундый юллар укыйбыз: «Хуҗа Насретдин, Җирән Чичәннәр татар халкының үзе тарафыннан тудырылган образлар булмасалар да, алар безнең фольклорда нык үзләшеп, милли персонажлар булып киткәннәр.. Хуҗа турында безнең халыкта да яңа мәзәкләр туа торуын соңрак чор материаллары белән тәгаен раслап була. Мәсәлән, «Хуҗа Насретдин фронтта» циклы һ. б.

Шул караштан чыгыптыр, күрәсең, бу бүлектә борынгыдан үк Хуҗа исеме белән йөртелгәннәргә байтак кына яңалары да өстәлгән. Мәсәлән: «Мә бишне!» (1017 нче мәзәк), «Исерүең җитмәгән» (1080 нче мәзәк), «Дөрес әйтмисең» (1078 нче мәзәк). Исеме телгә алыну белән үк күз алдыбызга чапан-чалмасы белән килеп басучы борынгы Хуҗа Насретдин боларның беренчесендә нәкъ хәзерге кайбер яшьләрнең вульгар кыланышларын кабатлый, «Мә бишне!» дип кулы белән шапылдатып сугып күрешә. Тагын берсендә базарда үзеннән ит алучыга, нәкъ хәзерге исерекбашларга дәшкәндәй: «Исерүең житмәгән!» ди. Өченчесендә тагын да арттырыбрак җибәрә: русчаның нечкәлекләрен үзләштергән хәзерге заман кешесе булып «безобразие түгел бу, разнообразие!» дип куя. Никадәр генә тырышсам да мин моңа һич ышана алмыйм. Әсәр ышандыру көченнән мәхрүм икән, ул инде үз вазифасын үти алмады диган сүз.

Менә шундыйлар белән танышканнан соң, табигый рәвештә сорау килеп туа: Урта гасырның бу хикмәт иясе диванасын, ясалма рәвештә безнең аңыбыз белән коралландырып, үз заманыбызга, фән-техника революциясе чорына тартып кертү урынлы микән соң, бу «тырышлык» Хуҗаның «иҗат үзенчәлегенә» хилафлык китермиме? Чөнки бөтен Көнчыгышка танылган бу мәзәкченең фәкать аның үзенә генә хас «иҗат мәйданы», иҗат мохиты, үз заманы (сыйнфый җәмгыять), үз тематикасы (дин әһелләреннән, сәүдәгәр һәм хаким даирәләрдән көлү), үзенә генә хас дирбиялары, кием-салымы (ишәк, чалма-чапан, кәвеш һ. б.) бар. Гомумән Хуҗа үзенең фәлсәфәсе, дөньяга карашы, әгәр шулай дип әйтергә яраса, индивидуаль йөзе белән мәзәкче геройлар арасында иң аерылып торганы дип әйтер идем. Аның беренче карашка бик тә беркатлы һәм хәтта мәгънәсез бер нәрсә булып күренгән тинтәк кыланышы артында да һәр вакыт нинди дә булса бер хикмәт ята. Мин аларны хикмәтле тинтәклек дип атар идем. Әмма алар һәммәсе дә үз заманнарына хас кыланышлар. Минем карашымча, тылсымлы әкиятләрнең, дастаннарның үз заманнары булган кебек үк Хуҗаның да үз заманы булган. Ул заманның мохиты да, сулышы белән гореф-гадәте дә бөтенләй башка. Шул сәбәпле, мисал итеп китерелгән һәм шуларга охшаган бүтән мәзәкләр Хуҗага «ябышмыйлар», анык булып кабул ителмиләр, чит булып күренәләр. Шуннан чыгып мин борынгы Хуҗаны безнең заман өчен яңа мәзәкләр иҗат иттереп борчымаска кирәктер дигән фикердә торам.

Хуҗиахмәт Мәхмутовның кереш сүзен мәзәкләр турында моңа кадәр язылган мәкаләләрнең иң бай эчтәлеклесе, әтрафлысы һәм остарак язылганы дияргә нигез бар. Мәзәкнең жанр билгеләрен, төрләрен, идея-эстетик кыйммәтен, художество үзенчәлекләрен ул тирәннән өйрәнеп язган. Автор бу хезмәтенә сирәк табыла торган төрле чыганаклар җәлеп иткән, мәзәкнең моңа кадәр өйрәнелмәгән күп якларын ачыклап биргән (кереш сүзнең фәкать Хуҗа Насретдин турындагы өлеше генә бәхәсле).

Кереш сүзнең фәнни хезмәт буларак тагын бер кыйммәтле ягы шунда ки, анда моңа кадәр мәзәкне җыю һәм аны матбугатта басып чыгару тарихы узган гасырлардан ук башлап күзәтелгән, бу эшкә катнашучыларның эшчәнлегенә, мәзәк жанрын өйрәнүгә багышланган хезмәтләргә объектив күзлектән чыгып гадел бәя бирелгән, ул хезмәтләрнең татар фольклористикасында тоткан урыннары дөрес билгеләнгән. Юкса бит кайвакыт аңлашылмаучылыклар да чыгып куйгалый. А. Садыйкованың «Уйнап әйтсәң дә уйлап әйт» дигән мәкаләсендә[1], мәсәлән, бу мәсьәлә шактый үк буталган, элгерләрнең хезмәте инкарь ителгән иде. А. Садыйкова үзе бәлки болай килеп чыгуын теләмәгәндер дә, әмма ул мәкалә укучыда ялгыш фикер калдыра, мәзәкләрне узган гасырда Шиһабетдин Рәхмәтуллин җыеп бастырган булса, безнең заманда исә бу хөрмәтле вазифаны А. Садыйкова гына башкарган булып аңлашыла.

Х. Мәхмутовның бу тәфсилле кереш сүзе мәзәкләрне җыю тарихын да төрле ягыннан яктыртып, ачыклап уза. Чыннан да халык иҗатының бу жанрын җыю һәм матбугатта чыгаруның бездә ярыйсы ук бай тарихы бар. Ул кайчандыр мәзәк дип аталмыйча, кайбер китапларда «латыйфа» дип исемләнеп, башкаларында «кыйссадан хыйсса» итеп китерелеп йөртелсә дә бу жанр безнең әдәбиятта борынгыдан ук яшәп килә. Аны җыю һәм халыкка җиткерү эшенә, А. Садыйкова раслаганча, Шиһабетдин Рәхмәтуллин белән ул гына түгел, бәлки Каюм Насыйри, Таип Яхин, М. Васильев һ. б. хөрмәтле галимнәр дә катнаша. Х. Мәхмутовның кереш сүзендә: «Мәзәкләрне җыю һәм матбугатта чыгару буенча Н. Исәнбәтнең хезмәте зур. Аның 3 томлык «Татар халык мәкальләре» җыентыгында 400 ләп

[1] «Казан утлары» 1979 ел, 6 нчы сан.

мәзәк тексты китерелә» дип әйтелгән. Шулай ук бу мәкаләнең авторы Г. Бәшировның 900 гә якын мәзәк җыйнап, аларны татарча һәм русча китап итеп бастырып чыгаруы да телгә алынган.

«Мәзәкләр» китабының кереш сүзе ансат укыла торган гади, үтемле, җиңел тел белән язылган. Бу да аның игътибарга лаеклы булган бер уңышлы ягы дип әйтер идем. Гомумән бу кереш сүз татар фольклористикасына мөстәкыйль әдәби һәм фәнни кыйммәте булган игътибарга лаеклы махсус бер хезмәт булып өстәлде дип уйлыйбыз.

Инде «Халык иҗаты» томнарының гомуми әһәмияте турында берничә сүз. Бу 12 томлык җыелмага халык күңел байлыгының иң кадерле, иң талантлы әсәрләре туплану турында башта ук әйтеп узылган иде. Нәшрият эшләренең елдан-ел катлаулана барачагын, нәшриятның эш күләме дә артачагын алдан ук искәргәндә, халык иҗаты әсәрләренең якын елларда гына яңадан басылуын көтү урынлы булмас иде. Димәк, бу томнар басылып чыгуга берничә ай үтү белән сирәк табыла торган уникаль китаплар булып калачаклар. Чөнки халык иҗаты әсәрләре беркайчан да үзенең эстетик кыйммәтен югалтмаячак, һәркемнең китап шүрлегендә иң кадерле урынны алачак. Шуны истә тотып, халык иҗаты әсәрләре дөньяга чыгуга көндәлек матбугатта булсын, радио һәм телевидениедә булсын, аларны актив рәвештә популярлаштыру чарасын күрергә, бу китапларның мәдәниятебез тарихында һәм тормышта тоткан урыннарын халыкка киңрәк, тырышыбрак аңлатырга кирәк булыр иде.

Шулай итеп, укучыларыбызның китапханәсе халыкның күңел җәүһәрләрен тупланган тагын бер китапка баеды.

«Халык иҗаты» әсәрләрен чыгаручыларга ихтирамга лаеклы бу эшләренә киләчәктә тагын да җаваплырак карап, тагын да зуррак нәтиҗәләргә ирешүләрен теләп калыйк.

**ГОМӘР БӘШИРОВ.**

# ҮЛЕМСЕЗЛЕК ЮЛЫ

Бөек Тукаебыз турындагы әдәбиятка күптән түгел тагын бер җитди китап кушылды. Сүз профессор Ибраһим Нуруллинның «Габдулла Тукай» китабы турында бара[1].

Китапның гомуми эчтәлеге белән укучылар ике ел элек беркадәр танышканнар иде инде: 1977 елда шул ук авторның Мәскәүдә «Жизнь замечательных людей» сериясендә рус телендә «Тукай» исемле китабы дөнья күрде.

Әдәбият тарихы белән кызыксынучылар, поэзия сөючеләр, Тукай иҗатын махсус өйрәнүчеләр бөек шагыйрьнең моңсу тормышын моңа кадәр дә ярыйсы ук яхшы беләләр иде. Тукайга багышланган дистәләрчә монографияләр, йөзләрчә мәкаләләр, истәлекләр, шагыйрь томнарындагы әсәрләргә бирелгән күп санлы һәм тәфсилле аңлатмалар шагыйрьнең тормыш юлын ярыйсы ук тулы итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

Гомумән, бүген Тукайның тормышы һәм иҗаты турында нинди дә булса яңа сүз, яңа фикер әйтүе ярыйсы ук катлауланды. Автор мәсьәләнең бу ягын истә тоткан, үз бурычының никадәр җитди булуын яхшы аңлап эш иткән. Һәм әйтергә кирәк: И. Нуруллинның «Габдулла Тукай» китабы безнең әдәбият тарихы өчен зур әһәмияткә ия булган һәм укучыларны шатландырган җитди күренеш, дияргә мөмкин. Китапта бөек шагыйрьнең тормышы беренче көненнән башлап соңгы сулышына кадәр эзлекле рәвештә укучы күз алдыннан үтә. Авыр, катлаулы, төрле фаҗигаләр белән тулган тормыш. Бик кечкенәдән ата-ана назыннан мәхрүм калган ятимнең бер чит җирдән икенчесенә озатылуы... «Ятимнең кара бәхете үзеннән калмый йөри икән»,—ди бу хакта автор. Шагыйрь үзе дә авыр тормышы турында күңелне тетрәтерлек сүзләр әйтә:

Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем.

Тукай тормышы искиткеч авыр шартларда уза. И. Нуруллин китабында бу хакта тәфсилле мәгълүматлар китерелә. Авыр тормыш шартлары Тукайның характеры формалашуга зур йогынты ясый. «Үтәр еллар,—дип яза автор,—ул яңа эчтәлекле олы иманына таянып эш итәр, дөньяның тәкәллефләрен танымый, таш яуса да, юлыннан тайчанмый торган принцип кешесе, хөр табигатьле шагыйрь булып житешер...» (35 бит). Шул ук тормыш Тукайда тыйнаклык һәм әйтеп бетергесез тырышлык тәрбияли.

Балачак тәэсирләре Тукайның рухи дөньясын тәрбияләүдә дә хәлиткеч роль уйный. Нечкә күңелле шагыйрь йөрәге туган ягының шигъри хәзинәсен үзләштерә бара. «Тукай шигърияте бүтән бер шагыйрьдә дә табылмаган дәрәҗәдә халыкчан,—дип яза автор.— Татар халкы тормышы анда барлык төсләре белән ялтырый. Мондый халыкчанлыкның орлыгы, һичшиксез, шушы Кырлайда салынган» (31 бит). Шагыйрь туган ягының гүзәл җырларын, серле әкият-легендаларын тыңлап үсә. Халык иҗаты аның рухи дөньясын, эстетик карашларын тәрбияләүдә зур роль уйный. Бала чакта алынган матур тәэсирләр аның бөтен гомере буена дәвам итә, халык җырларына багышланган җыентык төзергә, принципиаль әһәмияткә ия булган теоретик хезмәт— мәгълүм лекциясен язарга ярдәм итә. Моннан кала, халык иҗаты Тукайның «Туган

[1] Ибраһим Нуруллин. Атаклы кешеләр тормышы. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979.

тел», «Зиләйлүк», «Пар ат», «Шүрәле», «Су анасы» кебек бик күп әсәрләренә йогынты ясый. «Тулаем алганда исә, — дип яза автор,— Тукай үз халкын, игелекле бала шәфкатьле анасын яраткан кебек, тирән һәм самими ярату белән яратты, аның телен, авыз иҗатын яратты» (188 бит). Шул рәвешчә, автор бөек шагыйрьнең һәрбер җитди адымын, аның тормышындагы әһәмиятле вакыйгаларны җентекләп тикшерә һәм китапның ахырына таба мондый нәтиҗәгә килә: «Гомере төгәлләнеп килә торган Тукайның яңа революцион күтәрелеш еллары иҗатында гаҗәеп бер сыйфат күзгә ташлана: киләчәккә өмет белән карау, тарихи оптимизм» (271 бит).

Бөек әдипләрнең шәхес буларак характеры, шәхси сыйфатлары һәрвакыт киләчәк буыннарны кызыксындырып килде. Кем дә булса берәүнең шәхси тормышын күз алдына китерү өчен ул кеше белән бергә гомер иткән яисә еш очрашкан кешеләрнең истәлекләре җитди роль уйный. Тукай турындагы истәлекләргә багышланган китаплар, аерым авторларның хатирәләре моңа кадәр дә басылып килде. Тукай тормышын, аның шәхси сыйфатларын, характерын күз алдына китерүдә, берсүзсез, бу чыганаклар әһәмиятле роль уйнады. И. Нуруллин шагыйрь исеме белән бәйле истәлекләрнең барысын да җентекләп өйрәнгән. Өйрәнгән генә дә түгел, принципиаль тәнкыйть күзлегеннән тикшереп чыккан.

Әмма истәлекләргә нигезләнеп кенә объектив китап язып булмый. Чөнки аерым истәлек кеше тормышындагы билгеле бер моментка, билгеле бер вакыйгага гына кагыла. Димәк, истәлекләр кеше тормышын, әгәр шулай дип булса, аерым кисәкләргә бүлеп күрсәтә. Аннан соң һәрбер истәлекнең эчтәлеге субъектив карашлардан, үзара мөнәсәбәтләр йогынтысыннан да азат була алмый. И. Нуруллин моны яхшы аңлый. Нәтиҗәдә китапның тагы бер әһәмиятле уңай сыйфаты ачыклана: китап җитди документаль нигездә язылган. Тукай исеме белән бәйле документларны, йөзләрчә газет-журнал, архив материалларын, дистәләрчә китапларны автор зур тырышлык белән барлап, үзара чагыштырып, тикшереп чыккан.

И. Нуруллин Тукай тормышын һәм иҗатын күп еллар буена өйрәнеп килә. 1976—1978 елларда гына да ул Тукайга багышланган ике китап һәм 9 мәкалә бастырып чыгарды. Күрсәтелгән мәгълүматлар авторга китаптагы һәрбер фикерне документлар белән дәлилләп, матбугатта элегрәк басылып чыккан материалларга төзәтмәләр кертеп барырга яисә аларны киңәйтергә, тулыландырырга мөмкинлек биргән. Төрле характердагы төзәтмәләр китапта файдаланылган истәлекләрнең дә байтагына, шул исәптән Г. Тукайның үз истәлекләренә дә кагыла. Г. Ибраһимов, М. Гафури, С. Рәмиев кебек әдипләрнең истәлек-мәкаләләренә дә әһәмиятле генә төзәтмәләр кертергә, аларны, төрле документларга таянып, объектив бәяләргә кирәк булып чыга...

И. Нуруллин—галим генә түгел, язучы да. Әйтик, аның шул ук Тукайга багышланган художество әсәрләре киң катлау укучыларга мәгълүм булса кирәк. «Габдулла Тукай» китабында автор үзенең әнә шул мөмкинлекләреннән дә файдалана. Шигъри уйдырмага артык киң урын бирмәсә дә, ул аерым очракларда үзенең фантазиясенә дә мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә Тукай тормышы белән бәйле кайбер моментлар җанлы картина булып гәүдәләнә, китапның гомуми яңгырашын җанландырып җибәрә. Уфада Г. Тукайның М. Гафури белән очрашуын сурәтләгәндә автор күрсәтелгән алымны куллана (275 бит). Шуның нәтиҗәсе буларак, бу ике шагыйрьнең үзара якынаеп китүе җанлы бер күренеш булып күз алдына килеп баса.

Бер карасаң, документаль нигездә язылган китапта мондый алымга мөрәҗәгать итү ярамый да кебек. Тулаем алганда, бу шулай, әлбәттә. Моны автор да яхшы аңлый, әлеге алымга ул сирәк кенә туктала, һәм үзенең уй-фикерләрен әдәбият тарихының бүгенге югарылыгыннан торып дәлилли. Шул ук алым авторга кайвакыт җитди нәтиҗәләргә килергә дә мөмкинлек бирә. Ул Тукайның башка кайбер әдипләр белән булган кискен мөнәсәбәтләрен җентекләп тикшерә, объектив дөреслекне мөмкин кадәр тулы һәм тирән итеп ачарга тырыша. Тукайның Г. Ибраһимов, К. Мотыйгый, С. Рәмиев һ. б. кайбер әдипләр белән мөнәсәбәтен ачыклаганда ул аерым истәлекләр, әлеге әдипләрнең мәкаләләре белән генә чикләнми. Чөнки бу материалларның берьяклы булуы мөмкин. Шуңа күрә автор беренчелекне ышанычлы документларга бирә. Аннан соң ул һәрбер әдипнең характерына хас сыйфатларны, аларның әдәбият тарихында тоткан урынын, иҗтимагый-политик һәм эстетик карашларын да истән чыгармый. Мәсьәләне тарихилык принцибы нигезендә һәрьяклап тикшерә. Шуннан соң гына үзенең фикерен әйтә.

Китапның тагы бер җитди үзенчәлеге— автор Г. Тукайның барыннан да элек бөек шагыйрь булуын һәрвакыт истә тота. Дөресен әйткәндә, Г. Тукайның биографиясе аның әсәрләрендә. Әнә шул хакыйкатьне истә тотып, автор Г. Тукай әсәрләренә зур игътибар белән килә, аларның идея-эстетик үзенчәлекләренә генә түгел, язылу тарихына, тормышчан нигезләренә, шагыйрь биографиясе белән бәйләнешенә киң туктала. Ягъни, автор Тукайның тормыш юлын гына түгел, аның иҗатын өйрәнүгә дә әһәмият бирә.

Кибеп беттек,
Саргайдык без,
Корып беттек
Таяклардай;
Исәп нәҗес
Ләззәтләндек
Бөтенләй кыр-
гаяклардай.

Ашсыз-сусыз,
Утын-шамсез
Тар җирләрдә
Яттык сасып,
Гаетләрдә
Төш күргәндә
Коендык без
Бозга басып.

Г. Тукайның «Пар ат» (1907) шигыре мондый юллар белән башлана:

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап,

Әсәр шагыйрьнең Уральскидан Казанга килүе турында сөйли кебек. Әмма чынлык-

та мәсьәлә башкачарак тора икән. Бу әсәр турында И. Нуруллин болай ди: «Күп еллар буе әдәбият сөючеләр генә түгел, бәлки белгечләр дә бу шигырен Тукай Казанга кайткач язган дип уйлап килделәр. Менә без «Фикер» төпләмен актара башлыйбыз. 1907 ел. Январь, февраль, март, апрель, май... Чү! «Пар ат» шигыре! 17 сан, 6 май... Димәк, шигырь Тукайның Казанга чыгып китәреннән 5 ай элек язылган. Шагыйрьнең «Пар ат» дигәне хыял канатлары икән» (118 бит). Әнә шундый фактлар Г. Тукай әсәрләренең тормышчан нигезен генә түгел, әдәби-эстетик үзенчәлекләрен дә тирәнрәк аңларга ярдәм итәләр.

Г. Тукай — күп санлы һәм гаять үткен телле эпиграммалар авторы. 1907 елларда шагыйрь белән яхшы гына мөнәсәбәттә булган С. Рахманколый бер ара артыграк кылана башлый. Шул уңайдан шагыйрьнең түбәндәге эпиграммасы барлыкка килә:

Бул кеше, байбәтчәләрнең калдыгы хәмрен кәтеп,
Алты еллык образованьеңне йөрмә селкетеп.

Шагыйрьнең иң җитди, катлаулы, кискен сатира уты белән сугарылган «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» (1908) поэмасының шигъри һәм реаль тормышчан нигезләренә багышланган юллар аеруча матур тәэсир калдыра (169—178 битләр). Автор поэманың идея эчтәлеге, геройларның прототиплары хакында киң мәгълүматлар бирә, Г. Тукайның шигъри фикере бөреләнүе, әсәрнең сюжеты оешуы, геройларның шәхси сыйфатлары ачыклануы кебек мәсьәләләрне җентекләп тикшерә.

Шулай итеп, китапта Г. Тукай әсәрләренең байтагы кайчан, ничек, нинди шартларда барлыкка килүе турында әһәмиятле күзәтүләр табарга мөмкин. Гомумиләштереп әйтсәк, биредә шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты органик берлектә өйрәнелә.

Тукай тормышын өйрәнүче галим гадәттә шул чорның катлаулы иҗтимагый-политик проблемалары, әдәбият һәм сәнгать тарихы мәсьәләләре белән очраша. И. Нуруллин әнә шундый проблемаларны да читләтеп үтми. Әйтик, рус һәм татар әдәбиятларының үзара мөнәсәбәте, Тукай иҗаты бу мәсьәләне өйрәнү өчен бай материал бирә. Автор әнә шундый мәгълүматларга киң туктала, Тукайның Крылов, Кольцов, Пушкин, Лермонтов, Л. Н. Толстой, Некрасов, Никитин кебек әдипләргә мөнәсәбәте, бу язучы-шагыйрьләр иҗатының Тукай поэзиясенә, аның иҗтимагый-политик һәм әдәби-эстетик карашларына йогынтысы хакында тәфсилләп яза.

Үзенең иҗтимагый-политик программасы, бөек рус халкына мөнәсәбәте турында Тукай 1907 елда ук «Китмибез» шигырендә ачыктан-ачык әйткән иде: «Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт—хөр Русия!» Гомеренең соңгы көннәрендә язылган «Олугъ юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре» (1913) әсәрендә шагыйрь шул ук фикерне тагы да ачыграк һәм тәгәлрәк итеп әйтә. Китап авторы шагыйрьнең бу әһәмиятле әсәрләренә анализ биреп бара.

И. Нуруллинның «Габдулла Тукай» китабы әдәбият тарихында үзенә лаеклы урынны яулар дип ышанырга кирәк. Ул— күп еллар буена һәм зур тырышлык белән алып барылган эзләнүләр нәтиҗәсе. Тик китапның яңа басмасын әзерләргә кирәк булса, аны җентеклебрәк редакцияләсе бар. Кайвакыт автор вак-төяк детальләр белән кирәгеннән артыграк мавыгып китә. Нәтиҗәдә хикәяләүнең дәрәҗәсе түбәнәя. Аерым очракларда автор үз китабының киң катлау укучылар өчен (30 мең тираж белән) чыгарылганын онытып җибәрә кебек. Тукай һәркем күңелендә бөек шагыйрь буларак саклана. Аның тормыштагы һәм иҗаттагы батырлыгы, принципиальлеге, даһилыгы һәркемне сокландыра. Халык күңелендә Тукай беркайчан да һәм беркем алдында да баш имәгән бөек шагыйрь. Ул—татар халкының милли горурлыгы. Аның образы беркемнең дә кулы җитмәстәй биек пьедесталда тора. Һәм даһи шул пьедесталында калсын иде, хәтта документаль китапта да... Югыйсә китапның кайбер битләрен укыганда Тукай өчен күңел рәнҗеп куя. Бездә бит әле Әхмәт Фәйзи, Сибгать Хәкимнәр тарафыннан иҗат ителгән Тукай образы да бар. Биредә сүз художество әсәрләре турында барса да, күрсәтелгән әдипләр Тукай тормышын яки аның образын бозып сурәтлиләр дип әйтү һич тә дөрес булмас иде...

«Габдулла Тукай» китабының авторы еш кына әдәби мещанлык турында киңәеп сөйли. Әйе, әдәби мещанлык—начар күренеш. Ул безнең көннәрдә дә очрый. Әмма Тукай кадәр даһи исеме мондый вак-төяк, кайвакыт берникадәр детектив төс алган детальләргә мохтаҗ микән? Әдәбиятның йөзен әдәби мещанлык билгели алмый. Милли әдәбиятның асылы Тукай, Ибраһимов, Җәлилләр исеме белән бәйләнгән... Әйтергә теләгәнем шул: «Габдулла Тукай» китабына, минемчә, масштаблык җитми.

Китапта кайбер техник җитешсезлекләр дә очрый. 1908 елда «Вакыт»ның редакторы Фатих Кәримов чакыруы буенча Борһан Шәрәф һәм Кәбир Бәкер Оренбургка китеп баралар. Шул уңайдан Г. Тукайның түбәндәге сатирик куплеты барлыкка килә:

Безнең урам аркылы ага суның салкыны;
Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны.

Бу куплет И. Нуруллин китабында да китерелә (130 бит). Шул ук юллар һәм шундый ук вакыйгалар уңае белән бу өзек китапта тагы бер тапкыр кабатлана (184 бит). Басмада башка кайбер кабатланулар да очрый.

Ниһаять, китапның соңгы битенә килеп җиттек. Анда мондый юллар бар: «Татар халык шагыйре Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты турындагы бу әсәр— «Атаклы кешеләр тормышы» дигән сериягә башлап җибәргән беренче китап». Димәк, Татарстан китап нәшрияты яңа, зур әһәмияткә ия булган серия ачып җибәргән. Документаль әдәбиятка ихтыяҗ елдан-ел арта һәм киңәя барган безнең көннәрдә бу серияне башлап җибәрү чор таләпләренә җавап булып яңгырый. Сериянең бөек Тукайга багышланган китап белән ачылуы исә әдәбият сөючеләр өчен символик бер мәгънә ала.

**ФАТИХ УРМАНЧЕЕВ**

# ИХЛАС КҮҢЕЛДӘН

*Хәсән Хәйригә 70 яшь*

Күренекле әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Хәсән Фәхретдин улы Хәйригә (Хәйруллинга) 70 яшь тулды. Журналистика һәм әдәбият сараеның ишеген шакып, бусагасын атлап керүенә ярты гасыр. Истәлекле мондый бер көнне, зур вакыйгаларга бай гомер юлына күз ташлап, башкарылган эшләрне барлап алу да гөнаһ булмас. Хәсән Хәйринең халык алдында, коммунист буларак партия алдында йөз кызартмыйча исәп-хисап тотарлык яшәү үрләре, башкарган эшләре, иҗат җимешләре бар. Мөстәкыйль тормышка, бик яшьли аяк басканнан башлап хәзерге көнгә кадәр халыкка, аның шиңмәс рухи бакчасы — әдәбиятны үстерү һәм чәчәк аттыруга намус белән, ихлас күңелдән хезмәт ителгән.

Ил язмышы — ир язмышы, дигән канатлы гыйбарә Хәсән Хәйринең тормыш баскычларын, иҗат үрләрен бик төгәл чагылдыра кебек.

Ул 1910 елның 5 февралендә Казагыстанда батрак гаиләсендә туа. Бик иртә ятим калып, Җаек шәһәрендә балалар йортында тәрбияләнә. Тормышның алгы сызыгында булырга омтылуның беренче аңлы адымы: Хәсән Хәйрулин 1924 елда Ленин чакыруына кушылып комсомол сафына керә. Бу вакытта аңа 14 яшь була.

1927—1930 елларда ул Омскида рабфакта укый. Аның беренче әдәби тәҗрибәләре шунда башлана. Әдәбиятка һәм журналистикага хиреслеген исәпкә алып, аны партиянең Көнбатыш Себер крайкомы органы булган «Азат Себер» газетасына җаваплы секретарь итеп билгелиләр. Х. Хәйринең шуннан соңгы язмышы журналистика һәм әдәбият белән өзелмәслек булып бергә үрелә.

Кузнецк металлургия комбинаты төзелә башлауга ул комсомол путевкасы белән шунда юнәлә. М. Горький инициативасы белән Кузнецкстройның елъязмасын алып бару, художество әсәрләре, очерклар иҗат итү өчен махсус редакция коллегиясе төзелә. Аның составына Илья Эренбург, Александр Бек кебек язучылар, танылган журналистлар кертелә. Х. Хәйри «Кузнецкстрой тарихы» дигән редакциянең оештыручы секретаре була. Әлеге редколлегия һәм редакция әзерләгән җыентык 1932 елда Новосибирскида басылып чыга. «Новокузнецк кешеләре» дип атала ул.

Хәсән Хәйринең 1934 елда берьюлы ике җыентыгы дөнья күрә. Берсе — «Зур Кузбасс» дигән очерклар һәм шигырьләр җыентыгы — Новосибирскида, «Тавышлы ялкын» исемле хикәяләр һәм очерклар җыелмасы — Казанда. Беренче бишьеллыклар рухы, шул елларның фидакарь кешеләре турында алар. Х. Хәйри бу елларда 20 гә якын хикәя, 30 дан артык очерк язып бастыра. Димәк, ул әдәбиятка тормыштан килә. Моның булачак әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче өчен зур әһәмияткә ия икәнлеге көн кебек ачык.

1934 елда Хәсән Хәйри Казанга килә. 1934—1939 елларда педагогия институтында укый. Студент елларында да әдәби иҗат эшен дәвам иттерә: хикәяләр яза, алар «Азат хатын», «Совет әдәбияты» журналларында, «Кызыл Татарстан» газетасында басыла. Институтны тәмамлагач, «Совет мәктәбе» журналында җаваплы секретарь, Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият редакциясенең сектор мөдире булып эшли.

1939 елда татар телен һәм әдәбиятын фәнни нигезләрдә өйрәнү максаты белән Казанда фәнни-тикшеренү институты төзелә. Х. Хәйрине әлеге институтның әдәбият секторына мөдир итеп билгелиләр. 1943—1947 елларда партиянең өлкә комитетында эшли. 1947—1950 елларда Хәсән Хәйри — «Совет мәктәбе» журналы редакторы.

Дөньяга карашын һаман да киңәйтү, белемен арттыру теләге аны КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясенә китерә. Ул анда, теоретик белемен күтәрү белән берраттән, «Сугыштан соңгы татар әдәбиятында социалистик реализмны үстерү өчен көрәш» дигән актуаль темага кандидатлык диссертациясе яза. Аны уңышлы яклап Казанга кайткач, Х. Хәйрине СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалының тел, әдәбият һәм тарих институтының директоры итеп куялар. Лаеклы ялга чыкканчы, ул әлеге институтның әдәбият секторы мөдире булып хезмәт итә.

Анкета мәгълүматларыннан гына торган кыска белешмә үк Хәсән Хәйринең идеология тормышының гел үзәгендә кайнап яшәвен һәм эшләвен раслап тора. Ул — төрле дәреслекләр, хрестоматияләр, «Татар совет әдәбияты тарихы»ның авторы һәм редакторларыннан берсе буларак, аларны әзерләү һәм дөньяга чыгаруда зур хезмәт куйган



кеше. Әдәбиятыбызның тарихын һәм бүгенге хәлен чагылдырган байтак хезмәтләргә оештыручы, киңәшче, редактор буларак өлеше кергән аның.

Хәсән Хәйринең иҗаты заман агышы, үз чоры әдәбияты, аның ихтыяҗлары белән бәйле. Заманчалык хисе — аның иҗатына аеруча хас сыйфат. Чор әдәбияты аз гына да «суынып», «утырып» өлгермәгән, дулкыннары үз ярларына кайтып төшмәгән, ә Х. Хәйри шул дулкыннар үзәгендә. Моңа ышану өчен аның бер-бер артлы чыгып торган китапларына күз салу да җитәр. Әйтик, 1953 елда дөнья күргән «Әдәбият һәм тормыш» исемле китабында да шул ук хәл. 1970 елда «Эзләнүләр һәм казанышлар» исеме белән басылган китабында да сүз 60 нчы еллар әдәбияты турында.

Әлбәттә, Хәсән Хәйринең әдәби мираска багышланган хезмәтләре дә байтак. Мәсәлән, аның Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, Г. Камал, Ш. Камал, Һ. Такташ, Г. Кутуй, руслардан В. Белинский, А. Пушкин, М. Салтыков-Щедрин, А. Островский, А. Чехов, М. Горький, В. Маяковский турында мәкаләләре бар. Ләкин тәнкыйтьче әдәби мираска да бүгенге көн ихтыяҗларыннан карый, ягъни тарихтан бүгенге әдәбиятыбызның төпкелләрен эзли, элекке әдәби традицияләрнең бүгенге көндә ничек дәвам иттерелүен тикшерә.

Галимнең бөтен иҗаты татар әдәбиятында социалистик реализм методының үсүен төрле җәһәттән тикшерүгә багышланган. Бу иҗат әлеге методның партиялелек, халыкчанлык, гуманлылык, интернационализм, тормыш белән элемтә кебек асыл принципларының сафлыгы өчен көрәш хисе, аларны үстерергә омтылу рухы белән сугарылган. Социалистик реализм теориясенең күп санлы катлаулы проблемалары Х. Хәйри әсәрләрендә төрле яклары, төрле җирлектә, гомуми характердагы мәкаләләрдә дә, әдәбият үсешенең аерым чорлары җирлегендә дә, теге яки бу әдипнең иҗаты мисалында да, аерым әсәр нигезендә дә анализлана. Автор проблемаларны фәнни адымнар белән дә, публицистик алымнар белән дә хәл итәргә омтыла.

Х. Хәйри иҗаты турында сүз барганда, аның колачлылыгына игътибар итми мөмкин түгел. Бу, беренчедән, авторның әдәбият гыйлеменең өч өлкәсендә дә, ягъни әдәбият теориясе, тарихы буенча һәм тәнкыйтьтә актив эшләвендә, икенчедән, тикшеренү объектының төрледән-төрле булуында, ягъни әдәбият үсешенең төрле чорларын (узгәнен һәм хәзергесен), барлык жанр төрләрен (проза, поэзия, драматургия), бик күп авторлар иҗатын колачлауда да күренә.

Шулай да Х. Хәйринең аеруча яраткан өлкәсе бар. Ул үзен аеруча проза, аның да роман жанрында иркен хис итә. Моның шулай ук үз сере бар. Мәгълүм ки, әдәбиятның җитлеккәнлеген, барыннан да элек, халык тормышын киң планда тасвирлаган роман һәм повестьлар билгели. Автор өчен бу әдәби мәсьәлә генә түгел, ул әдәбиятыбызның үсеш дәрәҗәсен күрсәтүче бер фактор.

Бу проблематика аның «Иҗат чишмәләре» һәм узган ел гына дөнья күргән «Язучы һәм халык тормышы» исемле китапларында аеруча зур урын тота. Әлеге хезмәтләрендә романның асылы, үзенчәлекләре, үсеш тенденцияләре узгандагы һәм хәзерге әдәби факторлар җирлегендә ачыла.

Дөнья күргән 7 китап, 100 дән артык мәкалә, төрле басмаларда, шул исәптән «Кыскача әдәби энциклопедия»дә урын алган хезмәтләр Х. Хәйринең иҗат активлыгы турында ачык сөйли. Алар татар әдәбият гыйлемен һәм тәнкыйтен үстерүгә җитди өлеш булдылар.

Партия һәм хөкүмәтебез 1941 елдан КПСС члены, 1933 елдан СССР Язучылар Союзы члены Хәсән Фәхретдин улы Хәйринең хезмәтләрен югары бәяләде. Ул — «Почет билгесе» ордены кавалеры, Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе.

**ФЛОРИД ӘГЪЗӘМОВ.**

РЕДАКЦИЯДӘН

**Әле һаман иҗат дәрте белән ялкынланып яши әдип. Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе хөрмәтле галим һәм тәнкыйтьчене олы юбилее җәһәтеннән ихлас күңелдән котлый, аңа озын гомер, ныклы сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары тели һәм журнал укучылар да шушы тәбриккә кушылырлар, дип ышана.**

# ГАЗИЗ НӘБИУЛЛИНГА 60 ЯШЬ



*Унбишенче февральдә каләмдәшебез, СССР Язучылар союзы әгъзасы, Бөек Ватан сугышы ветераны шагыйрь Газиз Нәбиуллинга 60 яшь тулды. Саба районының Керәнне авылында туып үскән әдип Арча педагогия училищесын тәмамлаганнан соң күп еллар буе журналистика эшендә эшли — Саба район газетасында хезмәткәр, соңрак редактор була. Хәзергe көндә ул—бу газетаның җаваплы секретаре, шулай ук газета каршындагы әдәби түгәрәк җитәкчесе.*

*Газиз Нәбиуллин укучыга күбесенчә балалар өчен шигырь китаплары, пьесалар һәм юмор әсәрләре буенча таныш.*

*Әдипне юбилее белән котлап, бу санда без аның берничә яңа лирик шигырен тәкъдим итәбез.*

## Газиз Нәбиуллин

### Көтәләр кебек

Төнгә каршы төштем поездлан мин,
Кем дә мине көтеп тормаган.
Юлым уза минем балачактан
Якын дустым булган урманнан.

Мүк күмгәндер инде дигән идем,
Мин йөрмәгәч, таныш сукмакны.
Ә ул һаман мине көтеп торган,
Күңел күзе аны тиз тапты.

Кошлар җырын тыңлый-тыңлый барам,
Кайткан төсле нәни чакларым.
Иптәшләрем белән монда бит мин
Җәй буена атлар сакладым.

Их, урманның дымлы төннәре лә,
Туктап шунда ятып аунарга.
Дус малайлар һаман көтә кебек
Ерак кына түгел аланда.

Күңелләрдә урын бетми икән
Үткәннәрдә калган моңнарга.
Иптәшләрем күптән йоклый инде
Ерак аланнарда, кырларда.

## Уҗымнарым нишли?

Туң аз булды быел көздән,
Әнә шуңа
Минем йөрәк туңа.

Уҗымнарым нишли,
Уҗымнарым?
Барлап чыгар идем
Үзем барын!

Уҗымнарым туңмый микән,
Уҗымнарым нишли?
Шуны уйлап
Йөрәк өши.

Буразналар сыза кырга
Корыч юргам.
Ябып йөрим уҗымнарга
Мамык юрган.

## Төзисе бар минем

Сугыш минем тәнне җиңеләйтте,
Җәзалапмы, әллә аяпмы?
Дунай аръягында калдырдым мин
Авыр атлап йөргән аякны.

Аяклылар йоклый курганнарда —
Каршыламас таныш бусага.
Мин бит әле атлап уздым аны
Сыңар аяк белән булса да.

Сыңар аяк белән атлыйм җирдән,
Бурычлар күп минем өстемдә.
Атлыйсы бар минем, төзисе бар
Кайтмый калган дуслар өчен дә.

# ТҮРЕБЕЗДӘ — РУС МӘСӘЛЧЕЛӘРЕ

*Рус әдәбиятында мәсәл моннан ике йөз илле еллар чамасы элек үк мактаулы урын били башлый. «...Русь илендә мәсәл шуңа күрә гадәттән тыш уңыш казанды ки, чөнки ул бездә очраклы рәвештә түгел, ә мәзәк сүзне кызыклы, аны куллануны чиксез яраткан халыкның рухи ихтыяҗы нигезендә туды... Мәсәл, сатира буларак, чын мәгънәдә поэзия ул... Мәсәл, сатира буларак, бу өлкәдә талантлы һәм акыллы эшлеклеләр әле булганда, һәрвакыт шигъриятнең гүзәл бер төре булды һәм һәр вакыт шулай булып калачак» (Белинский)[1].*

*Моны шул жанр осталарының берсе Василий Тредиаковский сүзләре белән дә куәтләү биредә урынлы булыр. «Мәсәлнең, — ди ул, — ... өнсез-тавышсыз телен барча халыклар аңлый». Чөнки һәр әдәбиятның мәсәлләре фольклор һәм халык фантазиясе җирлегендә генә үсеп чыга алган иҗат, атаклы сатирик Гоголь әйтмешли, халыкның үз зирәклегеннән гыйбарәт булган китап ул. Бөек француз мәсәлчесе Лафонтен мәсәлне «дөньякүләм сәхнәләрдә уйнала торган киң колачлы, йөз пәрдәле комедия» дип тикмәгә атамаган, әлбәттә.*

## Василий Тредиаковский

*1703—1769*

*Астраханьда рухани гаиләсендә туа. Мәскәүдә Славян-грек-латин академиясен тәмамлагач, чит илләр буйлап сәяхәт итә, 1732 елда Фәннәр академиясендә тәрҗемәче итеп раслана. Күп төрле шигъри хезмәтләре һәм тәҗрибәләре арасында мәсәлләр киң урын били. Башлыча үзенең «хорей гекзаметры» дигән үлчәме (унөч иҗек, җиде басым) белән 51 мәсәл яза.*

### Бала табып азапланган тау

Сыкрый-сыкрый көчәнә ди бик дәү бер тау:
«Бала табам, — ди икән ул, — менә хәзер!»
Ишелмәсен иде безнең өскә, диеп,
Чара күрә халык: аңа ярдәм әзер.
Юк, кирәкмәс булган икән, халык, гауган, —
Бәп-бәләкәй тычкан туа шул зур таудан.

[1] Әсәрләренең тулы басмасы. Мәскәү АН СССР, 1955, 8 том, 575—576 битләр.

## Антиох Кантемир

*1708—1744*

*Россиягә күчеп килгән молдаван господареның улы була. Әле шул чакта гына ачылган Фәннәр академиясен тәмамлый. Тәхеткә Анна Иоанновна менгәч, ул, Петр Беренче башлангычларын яклаучы князь буларак, почетлы сөргенгә озатыла — башта Лондонда, аннары Франциядә илче була һәм калган бөтен гомерен шунда үткәрә. 1731—1739 елларда язган алты мәсәле Россиядә бу жанрның беренче үрнәкләреннән санала.*

### Ут һәм сын

Була шундый чын бер оста: балавыздан
Сыннар ясый гүя җанлы кеше итеп.
Шундый матур була икән барча төше —
Һәркем карый һәм соклана исе китеп.

Ә бер чакны уттан ерак куярга ул
Оныта сынны — аны хәтер алдый, димәк. —
Булыр икән хәтта шундый ямьсез очрак —
Гүзәл бер эш эреп юкка чыга кинәт.

Эшем уңсын, ул мәңгелек булсын, дисәң,
Комачауга һич тә урын калдырма син.
Зыянлыны, зарарлыны юк итә бел,
Кирәкмәгән чакта утлар яндырма син.

## Александр Сумароков

*1718—1777*

*Рус классицизмының күренекле вәкилләреннән берсе. Петербургтагы Шляхет корпусында белем ала. Башта хәрби хезмәттә, ә 1736 елдан башлап император театры директоры була. Драматург, мәсәлче, сатирик, лирик, тәнкыйтьче, теоретик, публицист буларак таныла. Мәсәл тибындагы дидактик-аллегорик жанрда алты китап (өч йөз җитмештән артык әсәр) яза.*

*
* *

Йомшара һәм юешләнә башлагач кар
Бала-чага аңардан шар ясый башлый, —
Бәп-бәләкәй, түм-түгәрәк туптай иткәч,
Кызык өчен кемнәргәдер атып ташлый.
Ә аннары шарчыкка шар өстәлә дә
Менә дигән зур йомарлам пәйда була.
Нәкъ шундый бит ялганлау һәм гайбәт сүзе:
Күп тәгәрәү аңа бары файда гына.
Йомарлакка әйләндереп шарны шулай,
Бар бит әле сөйләү юкны-барны шулай.

— Ах! Ах! Хатын, мине кемдер сихерләгән, —
Дип кычкыра таң алдыннан торып ире: —
Мин йомырка салдым төнлә.
— Юләр, тиле!
Төш күргәнсең. Мондый хәл һич була алмый...
— Мин йомырка салдым, әйе, хатынкаем!
Тискәрегә сукалама, булма кире.
Ирең түгел, инде синең тавыгың мин.
Бу бәладән, белмим, ничек арынырмын?
Әйе, тавык — чөнки мин йомырка салдым,
Үз хәлемне белеп үзем хәйран калдым.
Һичбер кемгә әйтә күрмә: чөнки берсе
Белсә шуны, күпертәчәк икенчесе.
Зинһар, димен, әйтә күрмә — кызартырлар,
Я, бәйләнеп, чебешен дә чыгартырлар.
Әйтә күрмә — чөнки гайбәт дөнья гизәр,
Тулы итим диеп, аны һәркем бизәр.
— Әйтәсем юк хәтта моны кодагыйга,
Шуның өчен тел биргәнме хода миңа?! —
Шулай диеп хатын кат-кат антлар итә.
Гайбәт исә дөнья буйлап атлап китә.
Башта бик тиз кодагыйга җитә гайбәт.
«Бу бик кызык, бу бит сәер, бу бит әйбәт!» —
Дип тала тел — хаклыкны күз шәйли алмый, —
Андый телне хәтта шайтан бәйли алмый.
Бер йомырка. Өч йомырка. Кичен — биш йөз...
Китә ялган. Үзенекен итә ялган.
Чөнки аны зурайталар, арттыралар,
Һич кирәкмәс йөкне күпләп тарттыралар.
Нишләтәсең? Йөри ялган, атлый биеп.
Дәрәҗәсе инде аның шактый биек.
Ә икенче көнне күпләп җыела халык.
Нигә димсез? Йомырка алырга диеп.

## Василий Майков

*1728—1778*

*Ярославльдә бай алпавыт семьясында туа. Петербургтагы академик гимназиядә бераз укыгач, хәрби хезмәттә унбиш ел уткәрә. 1768 елда яңа «Уложение» төзү комиссиясе секретаре була. Башта комик поэмалар, аннары «Нәсыйхәтле мәсәлләр» дигән ике китап яза.*

## Җайдак һәм ат

Акылга әле утырып җитмәгән
Бер егет атка менеп ала да
Камчылый атны:
Көннең көн буе
Җан-фәрман чап! — ди,
Мин сиңа хуҗа,
Шуңа син ат! — ди.

Бичара малкай
Арый һәм тала —
Инде көч-хәлгә
Кыймылдый ала.

Шулай көн үткәч, кара төн җиткәч
Җайдак өстенә өч бур ташлана —
Коточкыч янау-һөҗүм башлана.
Ә егет — куркак. «Һәлакәт якын...»
Ди дә ул тагын камчылый атын.
Ә ат кузгалмый.
Чөнки хәл беткән,
«Әй ял итәсе...»
Дип уйлый күптән.

Әйтә җайдакка: «Теләсәң нишләт —
Ник соң көндезен саклый белмәдең?
Каты шпорла, туйганчы кыйна...
Мин көчсез хәзер, ярдәм юк сиңа.
Әй, көндез газап күрмәсә идем,
Сине бурларга бирмәс тә идем».

Телим, укучым, шундый фикергә
Китерсен сине кыска бу мәсәл:
Яшьлек юлында кем дөрес яшьнәр,
Картлыгы килгәч шул тыныч яшәр.

## Михаил Херасков

*1733—1807*

*Ун яшендә Петербургтагы кадетлар корпусына укырга бирелә, шуннан соң берничә ел хәрби хезмәттә була да Мәскәү университетына асессор булып керә, ә 1763 елдан ул — Мәскәү университеты директоры. «Нәсыйхәтле мәсәлләр» җыентыгы 1760 елда чыга.*

### Чишмә һәм елга

Таудан төшә икән бер Чишмәчек ярсып:
«Мин түбәнгә очам! Үрләр артта калсын.
Тугай күрер минем тиңсез купшылыкны.
Елга гына белән торган буш тынлыкны
Шаулатырга төшәм!..» Тып-тын аккан елга
Әйтә шул чак аңа: «Бик ашыкма юлда,
Тавышланма болай. Мине ким дә, хур да
Итәлмисең барыбер — чөнки үзең бит син
Болганчыксың, тарсың... Мин тынычмын, мин киң.
Юк, сокланмыйм сиңа, юкка сөрән салма.
Шуңа нык төшен дә, шуны тирән аңла:
Талап кына уза җирне синең агым,
Мин яшәртәм, бизим аның бөтен ягын,
Барып җитәрсең син кайчан, ничек, кайда?
Ә бит кеше белә: кемнән, нинди файда!

(Дәвамы бар.)

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ИҖАТ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ПЛЕНУМЫ

Узган елның ноябрь аенда Казанның Актерлар йортында иҗат оешмаларының берләштерелгән пленумы булды. Ул КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карары, идеология работникларының Бөтенсоюз киңәшмәсе үнае белән республикабыз иҗат оешмалары алдында торган бурычларны тикшерүгә багышланды.

Доклад белән Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов чыкты. Доклад буенча фикер алышуларда әдәбият һәм сәнгать әһелләре — Художниклар союзы идарәсе председателе Ә. И. Тумашев, Композиторлар союзы идарәсе председателе М. З. Яруллин, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе Р. А. Җиһаншина, «Казан утлары» журналының баш редактор урынбасары Ә. Ф. Баянов, Журналистлар союзы идарәсе председателе, «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Ш. Х. Хамматов, Казан кинохроника студиясе директоры И. Н. Алексеев, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы Н. Г. Ихсанова, шагыйрь Р. М. Миңнуллин, композитор Р. Н. Билялов иптәшләр катнашты.

Пленумда КПСС өлкә комитеты секретаре иптәш М. Ф. Вәлиев чыгыш ясады.

Пленум эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының бүлек мөдирләре Ю. М. Воронин, М. М. Мусин иптәшләр катнашты.

## ФОЛЬКЛОРЧЫЛАР КИҢӘШӘ

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының конференц-залында «Идел һәм Урал буе халыклары фольклорында этник уртаклыклар һәм үзара бәйләнешләр» дигән темага багышланган симпозиум уздырылды. Ул СССР Фәннәр академиясенең фольклор буенча фәнни советы, М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты, Совет тюркологлар комитеты һәм Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан оештырылды.

Фольклорчылар симпозиумын кереш сүз белән оештыру комитеты председателе, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, тарих фәннәре докторы, профессор М. К. Мөхәррәмов ачты.

Симпозиум барышында филология фәннәре докторлары В. М. Гацак (Мәскәү), Б. Н. Путилов (Ленинград), Х. Г. Күроглы (Мәскәү) үзләренең докладларында илебез халыклары фольклорының уртаклыкларын һәм үзара тәэсирен өйрәнүнең мөһим мәсьәләләрен яктырттылар. М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтының өлкән фәнни хезмәткәре А. С. Мирбадәлева СССР халыкларының эпосын бастырып чыгару турында сөйләде. Филология фәннәре кандидатлары И. Н. Надиров (Казан), Н. Т. Зарипов (Уфа), Т. Г. Перевозчикова (Ижевск) һәм А. Е. Китиков (Йошкар-Ола) докладлары Идел һәм Урал буе автономияле республикаларындагы төрле милләт фольклорын өйрәнү мәсьәләләренә багышланды. Симпозиумда шулай ук филология фәннәре докторы Л. Г. Барагның (Уфа) «Башкорт новеллистик әкиятләренең милләтара бәйләнешләре», филология фәннәре кандидатлары С. Ә. Галинның (Стәрлетамак) «Татар бәетләрендә һәм башкорт тарихи җырларында эпик традицияләр», А. Ш. Кичиковның (Элиста) «Калмык тарихи-эпик поэзиясендә башкорт мотивлары», С. Х. Акбиевның (Махачкала) «Татар-кумык фольклор бәйләнешләре» дигән кызыклы докладлары тыңланды.

## ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында Язучылар союзы партия оешмасының ачык җыелышы булып узды. Көн тәртибендә КПСС Үзәк Комитетының «Хокук тәртибен саклау эшен яхшырту һәм хокукны бозуларга каршы көрәшне көчәйтү турында»гы карарын тормышка ашыруда язучыларның бурычлары мәсьәләсе каралды. Докладны Татарстан АССР прокурор ярдәмчесе, юстиция өлкән советнигы, язучы Мәгъсүм Насыйбуллин ясады. Фикер алышуларда Г. Ахунов, Р. Ишморатов, Т. Миңнуллин, М. Вәлиев, Р. Мостафин һәм А. Хәсәнова иптәшләр катнаштылар.

## ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ — ЯШЬЛӘР

20—21 ноябрьда Кукмарада яшь язучыларның бишенче республика-зона конференциясе үткәрелде. Кукмара районында яшәүче яшь әдипләрдән тыш, бирегә Мамадыш һәм Әгерҗе районнарыннан да яшь авторлар чакырылган иде.

Конференцияне Татарстан Язучылар союзының партия оешмасы секретаре, драматург Туфан Миңнуллин ачып җибәрде. Конференциядә катнашучыларны район хезмәт ияләре исеменнән КПССның Кук-

мара райкомы секретаре З. Ш. Сәйфетдинов котлады. Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов «КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карары яктылыгында яшь язучыларның бурычлары» дигән темага доклад ясады. Ул тыңлаучыларның игътибарын ил алдындагы җаваплылык, әдәби осталык, марксизм-ленинизм тәгълиматын тирәнтен үзләштерү мәсьәләләренә юнәлтте, яшь әдипләрне иҗатта кыюрак булырга, авыл тормышы һәм бүгенге көн кешеләре турында ешрак язарга чакырды. Аннары яшь һәм башлап язучылар алдында өлкән әдипләрдән Сибгат Хәким, драматург Туфан Миңнуллин һәм прозаик Вакыйф Нуруллин чыгыш ясадылар. Алар үзләренең иҗат тәҗрибәсе белән уртаклаштылар, язучылык эшенең нечкәлекләре турында сөйләп, аның авыр һәм мактаулы хезмәт булуы турында әйттеләр.

Кукмара районының «Восток» колхозы председателе Гафият Гарифуллин һәм Зур Кукмара сигезьеллык мәктәбе укытучысы Зөфәр Гомәров иптәшләрнең чыгышларын да залдагылар зур кызыксыну белән тыңладылар.

Чыгышлардан соң Кукмара, Мамадыш һәм Әгерҗе районнарыннан җыелган укучы балалар иҗаты тикшерелде. Танылган әдипләр мәктәп балаларының иҗатлары турында озаклап, җентекләп сөйләделәр, аларга файдалы киңәшләрен әйттеләр.

1927—1928 елларда күренекле татар совет язучысы Ибраһим Гази Кукмарада яшәгән, волкомол секретаре булып эшләгән. Конференциянең икенче көне әдип яшәгән йортка истәлек тактасы кую белән башланып китте. Анда Г. Ахунов чыгыш ясады.

Әдәби түгәрәкләрнең эше турындагы сөйләшүдә язучылар да, түгәрәк членнары үзләре дә актив катнаштылар. Кукмара район газетасы каршындагы «Аһәңле сүз» (җитәкчесе Ш. Мостафин), Әгерҗе районының Девятерня авылында эшләүче «Беренче адымнар» (җитәкчесе Ә. Фәтхетдинова) һәм Мамадыш район газетасы каршында оештырылган «Агымсу» (җитәкчесе Ч. Хөснетдинова) әдәби түгәрәкләренең эшенә югары бәя бирелде. Яшь авторлардан Ш. Мостафин, Ә. Фәтхетдинова, Р. Шәрипов, А. Герасимов, Р. Закирова, Р. Миңлегалиев, Ч. Мусин һ. б. иҗаты тикшерелде. Фикер алышуларда катнашкан язучылардан Г. Ахунов, С. Хәким, И. Юзеев, Т. Миңнуллин, Л. Ихсанова, В. Нуруллин, Ш. Рәкыйпов ,М. Хәбибуллин, Г. Шәрәфи, Л. Хәмидуллин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Гатауллин, Зөлфәт, Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин, М. Галиев, М. Вәлиев яшьләр иҗатына җентекле анализ ясадылар, уңай һәм кимчелекле якларны билгеләп үттеләр. Яхшы дип табылган әсәрләр республика матбугатына тәкъдим ителде. Яшь драматурглар Ризван Хәмид, Фоат Садриев, яшь прозаик Нәбирә Гыйматдинова конференция исеменнән СССР Язучылар союзына членлыкка тәкъдим ителделәр.

## ЯШЬ АВТОРЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮ КОМИССИЯСЕНДӘ

Язучылар союзының яшь авторлар белән эшләү комиссиясе яңа составта эшли башлады. Анда түбәндәге язучылар керделәр: Шәукәт Галиев (председатель), Роберт Миңнуллин (секретарь), Илдар Юзеев, Әхсән Баянов, Шәйхи Маннур, Геннадий Паушкин, Ринат Мөхәммәдиев, Мансур Вәлиев.

* * *

Яшь авторлар белән эшләү комиссиясенең чираттагы утырышы булды. Аны комиссиянең председателе Шәукәт Галиев алып барды. Утырышта яшь язучыларның Кукмарада үткәрелгән зона конференциясе йомгаклары, шушы зона районнарындагы әдәби берләшмәләргә шеф-консультантлар билгеләү (Кукмарага — Ләбибә Ихсанова, Мамадышка — Рәдиф Гатауллин, Ринат Мөхәммәдиев, Әгерҗегә — Шамил Маннапов, Мансур Вәлиев), республика районнарындагы яшь авторлар арасында әдәби хәрәкәтне тагын да ныграк җанландыруга кагылышлы башка мәсьәләләр тикшерелде.

Яшь язучыларның зона конференциясе йомгаклары турында Язучылар союзы идарәсе председателенең яшь авторлар белән эшләү буенча урынбасары, шагыйрь Илдар Юзеев чыгыш ясады. Фикер алышуда Гариф Ахунов, Туфан Миңнуллин, Әхсән Баянов, Шәйхи Маннур, Габдулла Шәрәфи, Геннадий Паушкин, ВЛКСМ өлкә комитетының яшь язучылар белән эшләү буенча җаваплы хезмәткәре, яшь драматург Ризван Хәмид иптәшләр катнашты.

## ЛИТФОНДКА 120 ЕЛ

СССР Литфондын язучылар совет әдәбиятының ышанычлы тылы дип атыйлар, чөнки ул язучының иҗат эшенә ярдәм итә, медицина, көнкүреш хезмәте күрсәтүдә, иҗади атмосфера тудыруда зур роль уйный. Язучыга иҗат шартлары тудыруда бигрәк тә иҗат йортлары ярдәмгә килә. Литфондның барлыгы 19 иҗат йорты бар. Алар илебезнең төрле почмакларына урнашкан. Татарстан язучылары да бик күп әсәрләрен әнә шул иҗат йортларында язып кайталар. Алар ял итү, иҗат итү белән бергә, төрле кичәләрдә, очрашуларда да катнашалар.

* * *

Шагыйрь Зәки Нури Ялтадагы иҗат йортында ял иткән вакытта «Плакат һәм вакыт» исемле политик плакат кичәсендә катнашты. И. Беляев, И. Василевский, Л. Кондрашенко, Г. Пятков кебек язучылар белән бергә чыгыш ясады, шулай ук Ялтадагы балык комбинатында, «Крымстрой» автобазасында, Белогорский районының Зуя поселогындагы мәктәптә, «Цветочное» колхозының Культура йортында укучылар белән очрашты, аларны татар әдәбияты яңалыклары белән таныштырды, шигырьләрен укыды, фронт истәлекләре сөйләде.

## АЛТАЙДА КОНФЕРЕНЦИЯ

Таулы-Алтай автономияле өлкәсенең башкаласы Горно-Алтайск шәһәрендә «Төньяк, Ерак Көнчыгыш һәм Көньяк Себер язучыларының әсәрләрендә тарих һәм бүгенге көн» дигән темага конференция булып үтте. Шул халыкларның балалар әдәбиятына күзәтүне Татарстаннан язучы Ләбибә Ихсанова ясады.

Конференция соңыннан Таулы-Алтайда совет әдәбияты көннәре башланып, Ләбибә Ихсанова Мәскәү, Ленинград, Таулы-Алтай язучылары белән бергә, өлкәнең Ончудай районы мәктәп балалары, колхоз һәм совхоз эшчеләре белән очрашуларда катнашты.

* * *

Яшь тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев М. В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының күп милләтле совет әдәбиятының теориясе һәм тарихы буенча махсус гыйльми советында «Татар әдәби тәнкыйтенең формалашу проблемалары (1905—1917)» дигән темага кандидатлык диссертациясе (фәнни җитәкчесе — профессор М. Х. Хәсәнов) яклады. Яклауда совет әдәбиятының күренекле галимнәреннән А. Метченко, Г. Поспелов, Х. Госманов, Ч. Гусейнов, А. Соколов, П. Николаев, П. Юшин, Р. Бикмөхәммәтов һ. б. катнашты. Алар яшь галимнең хезмәтенә югары бәя бирделәр.

* * *

Шагыйрь Роберт Миңнуллин Башкортстанның Уфа шәһәрендә, «Кызыл таң» газетасының үз хәбәрчесе, СССР Журналистлар союзы члены Зөфәр Хәмидуллин белән Чишмә, Благовар, Бүздәк һәм Илеш районнарында булып кайтты. Ул анда «Казан утлары» журналы укучылары белән очрашты, журналның ничек таралуы һәм укылуы белән кызыксынды. Р. Миңнуллин шулай ук Бүздәк районының «Коммуна» колхозы төзелүгә 50 ел тулу уңае белән уздырылган юбилей тантанасында да катнашты, тантанада катнашучыларга татар әдәбияты хакында, «Казан утлары» турында сөйләде, үзенең шигырьләрен укыды.

## УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Ноябрь аенда Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы укытучылары һәм студентлары язучы Вакыйф Нуруллинның «Аккан су юлын табар» исемле яңа повесте буенча укучылар конференциясе уздырдылар. Конференциядә студентлар, шулай ук башкорт язучыларыннан Г. Рамазанов, С. Поварисов, Р. Баимов, профессор Г. Әхәтов, филология фәннәре кандидаты Ә. Нигъмәтуллин иптәшләр чыгыш ясады. Сөйләшүдә университетның проректоры, профессор М. Гайнуллин да катнашты.

Соңыннан Вакыйф Нуруллин үзе сөйләде, сорауларга җаваплар бирде.

## ВЛКСМ ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА

ВЛКСМ өлкә комитетында «Икмәк фронты батыры» исемен яулап алу өчен республикабыз кырларында барган социалистик ярышта җиңеп чыккан яшь механизаторларның традицион очрашуы булды. Очрашуда язучылар Мөсәгыйт Хәбибуллин, Фаил Шәфигуллин һәм шагыйрь Фәннур Сафин да катнашты.

## ИҖАДИ СӨЙЛӘШҮ

Язучылар союзы каршындагы проза секциясендә, Мөхәммәт Мәһдиевнең «Кеше китә, җыры кала» повестен тикшерү уңаеннан, әдәби осталык, бүгенге заман проза жанрларының үзенчәлекләре турында зур сөйләшү булды. Проза секциясе җитәкчесе Атилла Расих повестьның үзенчәлекле, халыкчан әсәр булуын, аның укучылар тарафыннан яратып кабул ителүен билгеләп үтте.

М. Мәһдиев повестьның язылу тарихын, тормышның үзеннән алынган кызыклы детальләрнең ничек итеп әсәргә кереп китүен сөйләде, үзенең иҗат процессына караган кайбер фикерләр белән уртаклашты.

Утырышта язучылардан С. Хәким, Р. Мостафин, Ә. Еники, И. Нуруллин, Ф. Ганиева, И. Юзеев, Ф. Миңнуллин, Р. Ишморатова, М. Әмир, И. Ахунҗанов һ. б. иптәшләр чыгыш ясады.

* * *

Балалар әдәбияты секциясендә яшь язучы Дамир Галимовның балалар өчен язган «Кызыл шарф» операциясе» дигән повесте тикшерелде. Повесть турында сөйләшүдә Шамил Рәкыйпов, Ләбибә Ихсанова, Адлер Тимергалин, Таһир Нурмөхәммәтов, Фаил Шәфигуллин һ. б. язучылар катнашты. Авторга әсәрен тагын да яхшырту юнәлешендә киңәшләр бирелде, повестьның кирәкле темага язылуы билгеләп үтелде.

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘРЕ

«Советский писатель» нәшриятының «Шагыйрь китапханәсе» исемле зур сериясендә Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең «Сайланма әсәрләр»е басылып чыкты. Шагыйрьнең бу китабы, элек рус телендә чыкканнары белән чагыштырганда, шактый күләмле һәм тулы сайланмаларның берсе. Анда М. Җәлилнең бала вакытында дөнья күргән беренче шигырьләреннән алып, фашистлар тоткынлыгында язган «Моабит дәфтәре»нә кадәрге иҗат юлы чагылыш тапкан. Эчтәлеге һәм формасы ягыннан гаять төрле шигырьләрне күренекле рус шагыйрьләре тәрҗемә иткән.

Җыентык ике бүлектән: шигырьләр һәм поэмалардан тора. Балалар өчен язган әсәрләр, фронт лирикасы һәм «Моабит дәфтәре» аерым бүлекчәләр итеп бирелгән. «Сайланма әсәрләр» Җәлилнең төрле елларда төшкән фоторәсемнәре белән бизәлгән. Анда шагыйрьнең үзе язган «Минем тормыш юлым» исемле автобиографик мәкаләсе һәм аңлатмалар да бар. Китапка кереш сүзне Рафаэль Мостафин язган.

## ШАГЫЙРЬГӘ БАГЫШЛАП

Оренбург өлкәсенең Илек авылындагы 1 нче урта мәктәптә Советлар Союзы Герое, патриот-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган зур кичә булды. Кичәдә шагыйрьнең иҗаты һәм тормыш юлы турында «Урал» район газетасының җаваплы секретаре, СССР Журналистлар союзы члены Равил Енакеев сөйләде. Ул укучыларны Җәлил турындагы китаплар белән, Җәлил турында язучыларның яңа хезмәтләре белән таныштырды.

Соңыннан укучылар башкаруында Җәлилнең татар, рус һәм казакъ телләрендә шигырьләре яңгырады.

## ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

Казанның Актерлар йортында драматург Шәриф Хөсәеновның 50 еллык юбилеена багышланган иҗат кичәсе булды. Кичәдә иҗат интеллигенциясе, шәһәр хезмәт ияләре, студентлар һәм язучының каләмдәшләре катнашты.

Ш. Хөсәеновның иҗаты турында драматург Туфан Миңнуллин сөйләде. Казан театрлары артистлары «Әни килде» («Әниемнең ак күлмәге») спектакленнән татарча һәм русча өзекләр уйнап күрсәттеләр, «Генераль җыештыру» спектаклен уйнадылар, драматург сүзләренә язылган җырлар яңгырады.

## ҖИҢҮЧЕ КИТАПЛАР

1979 елдагы китап басмаларының иң яхшы художестволы бизәлеше һәм полиграфик эшләнеше буенча уздырылган конкурс тәмамланды. Беренче дәрәҗә диплом һәм акчалата премия «Татар табышмаклары» дигән китапка бирелде. Икенче бүләккә «Татар теле» дәреслеге һәм «Коммунистлар партиясе Манифесты»ның сувенир басмасы лаек булды. Өченче бүләкне «Эңә терапиясе атласы», балалар өчен чыгарылган «Җирдәге кояш» дигән китап һәм «Борынгы шәһәрнең яшьлеге» дигән җыентык яулап алды. Әлеге китаплар барысы да Татарстан китап нәшриятында әзерләнгәннәр, Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинатында басылганнар.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәт язучыларының чираттагы утырышы очерк һәм публицистика турында сөйләшүгә багышланды. Татарстан Язучылар союзының очерк һәм публицистика секциясе председателе, язучы Марсель Зарипов үзенең докладында очерк жанрының үзенчәлекләре турында сөйләде, очеркистлар алдында торган бурычларга тукталды.

Язучы Самат Шакир Бөек Ватан сугышы каһарманнарын ничек эзләп табуы, аларга багышланган документаль әсәрләр өстендә ничек эшләве турында сөйләде. Фикер алышуларда Ш. Бикчурин, Г. Афзал, Ә. Маликов, Җ. Рәхимов һ. б. язучылар катнашты.

* * *

Бүлек җыелышында «Авыл прозасы һәм аның проблемалары» дигән мәсьәлә тикшерелде. Язучы Хәниф Хәйруллин доклад белән чыкты. Фикер алышуда Ә. Маликов, Ю. Әминев, Ш. Бикчурин, Җ. Рәхимов, яшь язучылар Н. Әхмәдиев, А. Хәсәнов, Х. Сафина иптәшләр катнашты.

* * *

Әлмәт нефтьчеләренең Техника йортында Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь Гамил Афзал иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Кичәне шагыйрь иҗаты турындагы кереш сүз белән Әдип Маликов ачып җибәрде. Аннары Әлмәт Татар дәүләт драма театры артистлары, шәһәр үзешчәннәре шагыйрьнең шигырьләрен, аның сүзләренә язылган җырларын башкардылар. Кичәдә Г. Афзал үзе дә чыгыш ясады.

## ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм илле яшь тулу уңае белән, СССР Верховный Советы Президиумы язучы **Шәриф Нургали улы Хөсәеновны** «Почет билгесе» ордены белән бүләкләде.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдәге, республикада китап нәшрияты эшен үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм Татарстан китап нәшриятының 60 еллыгы уңае белән түбәндәге иптәшләргә Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 9 август Указы белән **Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде:

**Нурмөхәммәтов Таһир Мирзагаләмовичка** — Татарстан китап нәшриятының өлкән редакторы;

**Салихова Эльза Гашимовнага** — Татарстан китап нәшриятының өлкән редакторы;

**Хәкимов Салих Камаловичка** — Татарстан китап нәшриятының өлкән редакторы.

* * *

Совет әдәбияты һәм матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы **Әдип Маликовични Маликовка** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 14 сентябрь Указы белән **Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет циркы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен дәүләт циркларының Бөтенсоюз берләшмәсе артистлары **Рамазан Равилевич Абдикеевка** һәм **Замир Миркасыймович Мостафинга** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 14 сентябрь Указы белән **Татарстан АССРның атказанган артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!

Инде журналның алдагы айда чыгачак саны белән таныштырып үтик. Анда да укучы игътибарын үзенә тартырлык әсәрләр шактый. Журнал Татарстанның күренекле шагыйре Сибгат Хәкимнең яңа шигырьләре белән ачылачак. Алар арасында шигырь сөючеләрнең төрледән-төрле таләпләрен канәгатьләндерерлек юллар бар.

Быел март аенда оста прозаик Хәсән Сарьянның тууына илле ел тула. Журнал шушы уңайдан Г. Ахуновның әдип иҗаты турында язылган мәкаләсен һәм Х. Сарьянның «Җәза» исемле зур күләмле соңгы әсәрен тәкъдим итә.

Мәгълүм булганча, март аенда бөтен прогрессив кешелек дөньясы Халыкара хатын-кызлар бәйрәмен билгеләп үтә. 3 нче санда хатын-кыз язучылар иҗатына зур урын биреп, журнал да бу тантанага кушыла. Монда К. Булатова, С. Гәрәева, И. Ганиева, Б. Рәхимова шигырьләре һәм Рәисә Ишморатованың «Сүз» исемле озын хикәясе урнаштырылган. Автор хикәядә яман сүзнең, гайбәтнең кеше күңелен ни дәрәҗәдә кимсетә алуын, коточкыч ямьсез нәтиҗәләргә китереп чыгаруын тасвирлый.

Бу санда В. И. Ленинның тууына 110 ел, Татарстан төзелүгә 60 ел тулуга багышланган язмалар аеруча мул бирелгән. М. Гәрәевнең «Ильичка хатлар» очеркы, А. Җәләлев, М. Мостафин язмалары шул җәһәттән урнаштырылган. Бөек җиңүнең май аенда билгеләнәчәк 35 еллыгына карата язылган Г. Гурьевның «Лачын йөрәкле егет» очеркын да укучы, мөгаен, яратып кабул итәр.

«Яшьләр иҗаты» рубрикасында Ф. Хуҗиәхмәтованың «Шулай була икән» хикәясе, Ф. Низамова шигырьләре урнаштырылган. С. Маннаповның «Әдәби тәнкыйть» бүлегендә бирелгән «Тормыш үзәннәреннән» исемле мәкаләсе язучы Х. Камал иҗатына багышланган.

Болардан тыш журналда «Әдәбият тарихына материаллар», «Дуслар иҗаты», «Культурабыз тарихына материаллар», «Тел белеме», «Китап күзәтү» рубрикалары бар. Укучылар арасында бу язмаларны көтеп алучы, кызыксынып өйрәнүче һәм алардан файдаланучылар шактый.

Журналның март ае саны да, гадәттәгечә, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары белән тәмамлана.


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210